# казан утлары

10
ОКТЯБРЬ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**
ОКТЯБРЬ
1974

## Бу санда

**Р. МИНГАЛИМОВ.** Игенче егеткә. Шигырьләр . . 3
**Т. ГЫЙНИЯТУЛЛИН.** Солдат үлеме. Хикәя . . . 7
**Ә. ДАВЫДОВ.** Галәмнәргә хатлар язу. Шигырьләр. 28
**Х. ХӘЙРУЛЛИН.** Ургыл. Роман . . . . . . . 33
**К. СИБГАТУЛЛИН.** Кибәнче карт. Баллада . . . 63
**Н. МАДЬЯРОВ.** Ник тынычлык бетми урнашып ла. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 66

СӘЙФИ КУДАШКА 80 ЯШЬ

**С. ХӘКИМ.** Олылык . . . . . . . . . . . 70
**С. КУДАШ.** Атлыйм әле. Шигырьләр . . . . . 71

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . 78
**М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ.** Күңелең керсез булса . 80

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Я. АБДУЛЛИН.** Иҗтимагый яңарышны яклап . . 89

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Татарстан язучыларының VIII съезды резолюциясе . . . . . . . . . . . . . . 101
**З. НУРИ.** Заман белән бергә . . . . . . . 103
**Г. АХУНОВ.** Татар совет прозасының офыклары. 119
**И. ЮЗЕЕВ.** Тукай, Җәлилләр биеклегенә . . . 130
**Т. МИҢНУЛЛИН.** Шатлыклар һәм борчулар . . 140
**Л. ИХСАНОВА.** Матурлык һәм батырлык дөньясында . . . . . . . . . . . . . . . 146

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

**Р. МОСТАФИН.** Әдәби тәнкыйтьнең уңышлары һәм бурычлары . . . . . . . . . . . . . 156
**Т. ЖУРАВЛЕВ.** Рус язучыларының иҗаты . . . . 165
**С. МИХАЛКОВ.** Халыкчан әдәбият, тормышчан әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
**С. ХӘКИМ.** Җаваплылык хисе . . . . . . . . . 174
**Н. ДӘҮЛИ.** Рухи күпер . . . . . . . . . . . 176
**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Югары идеяле поэзия өчен . 180
**Ф. МИҢНУЛЛИН.** Тәнкыйтьнең төп бурычлары . 184

Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

*Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.*

Телефоннар: Баш редактор — 3-03-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-01-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/VII-1974 ел. Басарга кул куелды 22/VIII-1974 ел. ПФ 09142. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87.000 экз. Заказ Ю-170. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары», 1974.

## Рөстәм Мингалимов

### Игенче егеткә

Уңган бодай!
Уракка да
Төшәр вакыт
Җитте бугай.
Син бирегә
Бүген, егет,
Ник киләсе
Иттең болай?

Синең басу —
Бодай иле!
Нинди иркен,
Нинди сары!
Үзгәртте шул,
Эре итте
Заман аның
Башакларын.
Авыр итте
Кургаш кебек.
Тотып кара
Син кулыңа!
Ярый әле,
Башакларда
Кургаш түгел,
Бодай гына.

Уңган бодай,
Уракка да
Төшәр вакыт
Җитте бугай.
Ә син бүген
Бу басуга
Ник киләсе
Иттең болай?
Уйланырга,
Уйларыңны
Араларга,
Тасларгамы?
Матур кырда
Син борчулы
Уйлар белән
Йөрмә тагы?!

Кайлардадыр
Бомба яуган,
Кырлар янган
Чак булса да:
Газеталар
Үзәк өзеп
Хәтәр хәбәр
Кычкырса да —
Яшәү дигән
Бөек куәт
Югарыга
Үрли әле:
Узган гомер,
Исән җырлар,
Исән кырлар
Моңа дәлил.
Шунда яшәп,
Шунда эшнең
Иң асылын
Сайлагансың.
Чынында бер
Атом-бомба
Бер бодайга
Торамы соң?!

Кешеләр
Өлгергән чакта,
Юк, төшмәс
Үлем уракка —
Бу кешелек
Матур итеп
Китәр әле
Бик еракка.
Синең кырың
Бодай иле —
Җиргә һаман
Шулай сарыр:
Сары булыр,
Эре булыр,
Авыр булыр
Башаклары.

## Сез кай яктан?

Сез карагыз әле безнең җәйне,
Нинди җайлы, нинди килешеп тора.
Тау өстендә туган яшел дулкын
Бакчаларга хәтле төшеп тора.
Койма асларыннан сукмакларга
Кыяр сабаклары шуып чыга.
Яшел исен җәйнең һәр йорт белә,
һәр тавыгы тоя, һәр чыпчыгы.
Сез кай яктан? Әй, карагыз әле!
Безнең якның сере бар шул аның.
Охшамыйдыр бер дә безнең җәйгә
Һичкайдагы җәе бу дөньяның.
Җәйдән куркып кыш юк була диләр,
Ә безнең кыш җәен юкка чыкмый:
Сез белмәгән бер өй кыегында
Ул ак мәче булып
кызынып йоклый.
Өй артында ак сакаллы бабай
Яшел-бөдрә җәйне карап тора.
Кеше телен аңлый бездә үлән,
Таш өстендә чишмә сайрап тора.

## Фанер япкан өстәл

Ана хатыннан

Саумы, әнкәй, дигәнсең,
Шикәрең-чәең бармы?
Апа белән энекәш,
Дигәнсең, язалармы?
Хатыгызны еш алам,
Шикәрем бар, балым бар,
Тик балымның тәме юк,
Янымда юк балалар.
Сез кайтарган өстәлнең
Өсте гел күзгә кебек —
Куркып калам шуңарда
Йөземне ялгыз күреп.
Җайсыз булды бу өстәл,
Ашъяулык шуа анда,
Кайтып чык әле, балам,
Бер вакытың булганда.
Шул өстәлне чоланга
Чыгарып куйыйк әле.
Кертим әткәң ясаган
Фанер япкан өстәлне.

# Кечкенә генә кыз бала

Бер гаилә хәленнән

Чатнагач
Тормыш —
Ярылыр,
Ярылыр төсле тоелды,
Гел шулай гына тоелды —
ярылыр кебек бер?!

Ак белән бәйләп карадык,
Ал белән бәйләп карадык,
Тасмалар сайлап карадык —
таралыр кебек бер?!

Балдаклап,
Саклап
Карадык,
Кечкенә генә кыз бала
Аны кочаклап карады,
Булмады,
ярылды тормыш,
ярылды барыбер.

...Инде менә шактый вакыт
Ул кечкенә кыз баланы
Күргәнем юк,
Ә күзләрем
Тулы минем
Бала эзе белән!
Башымда да бала эзе,
Йөрәктә дә бала эзе.
Өйдә үзем генә.

Өйдән чыксам,
Урамда да
эзләр генә.
Барысы да
Бала эзе генә.

...Ничек матур батып барган
Кар өстеннән бала эзе —
аның эзе кебек?!

...Җәйгә керсәм, ком өстендә
Тезелеп калган бала эзе —
аның эзе кебек?!

Юл буеның туфрагыннан
Озак барган,
Бала барган,
Биш бармагы кала барган,
Ялан аяк кая барган?
Аның эзе микән?

Аны куып җитәрменме?
Шушы эздән китсәм?
Һәм нишләрмен, ни әйтермен
Әгәр куып җитсәм?!

## Иртә

Төн эчендә бу җирләрдә,
Бу тормышта ни булмас?!
Офыктан баш сузып карый
Дөньяга кызыл кояш.
...Идел буе талларыннан
Суга яфрак коела...
Ярга килеп сары көймә
Яфрак кебек сыена...
Комлы җирләр — кичәгедәй,
Камчы кебек шәп юллар;
Таулар исән, шәһәрләр сау,
Төркем-төркем авыллар.
Гүя төнлә бу дөньяда
Бер читен хәл булмаган.
Ялгыш кына кулдан төшеп
Көзге дә ватылмаган.
Юрга килә, куе-кызыл —
Кояштан туган микән?!
Гашыйкларның төнге сере —
Түбәндә томан микән?!
Бу бакчага иртүк торып
Теге кызый ник чыккан?
Күрше йорты — койма аша,
Койма буе — кычыткан.
Койма аша карагандай
Күрше малай — гашыйк баш,
Офыктан баш сузып карый
Дөньяга кызыл кояш.

Талха Гыйниятуллин

# СОЛДАТ ҮЛЕМЕ

хикәя



Уттай кызган дала өстенә снарядлар шартлап туз-гыткан сары тузан болыты күтәрелә, дөрләп янган танклардан һавага майлы кара сөрем бөркелә. Җил аларны бер якка куып авыштырып тора, көйгән ит исе аңкый—бая җимерелгән танкта янып калган теге ике фрицтан килә, ахры...

Дүрт почмаклы кубны хәтерләткән соргылт-яшел бу танклар, әллә нинди ерткыч албасты ши-келле, борыннарын алга таба сузып, җансыз бер куәт-дәһшәт белән әкрен генә Киньягулов өстенә килә башлагач, танклар белән бергә, киеренкелек-тән тетрәп торган, ут кебек кызган бөтен тирә-юнь күчеп килә сыман тоелды. Немецның корычтан койган бу дәһшәте каршында беренче тапкыр куркып-каушап калуны Киньягулов инде күптән кичергән һәм оныткан булса да, өскә танклар килә башласа, бөтен җанны һәм тән-не тетрәткән әнә шул яман тойгы яңадан кузгала иде. Киньягулов инде сугышта ике тапкыр яраланды, үлемнән курку дигән ямьсез тойгыны бер генә тапкыр кичермәде (бигрәк тә ял итеп яки госпитальдә ятып яңадан сугышка кергәннән соң көчле була ул тойгы), һәм, ниһаять, ул күпне күргән солдат кебек сабыр була белергә өйрәнде; юк, батыр-лык түгел иде бу — батырлык ул гайрәт, тәвәккәллек белән дә бәй-ләнгән — сугышка, үлемгә һәм немецка ничектер тыныч һәм гади итеп карарга өйрәнде ул... Окоп өстенә басып кергән танкны шартлатырга дип, брустверга бәйләме белән гранаталар урнаштыргач, Киньягулов үзенең «дегтярев»ыннан танклар артында кайнашкан пехотага төбәп атты, патронны кызганмыйча, тоташ-тоташ сиптереп торды, пулемет-ның казеннигы кулны пешерерлек булып кызды.

Снаряд тиеп шартлауга танк дер селкенеп куйды, өзелгән чылбы-рын сала-сала, бер урында әйләнә башлады һәм ян бронясын артил-леристларга таба каратып туктап калды. Икенче снаряд тиеп, танк-ның бронясына кырыйлары төерләнеп торган түгәрәк тишек тиште, һәм танктан куе төтен бөркелә башлады. Шул вакыт люк капкачы ачылып, сөремле кара төтен эченнән немец күренде, әкрен генә люктан

чыкты да калтыранган куллары белән әрле-бирле тотынгалап аска шуыша башлады. Бер аягын танкның чылбыры өстендәге канатына басты, икенче аягын җиргә тидерәм дигән чагында гына Киньягулов тәтәп янган бу мишеньне мушканың түгәрәге эченә туры китерде дә тырылдатып атып алды. Бөтенләй ялкынга чорналган хәлендә икенче танкист та күренде. Анысы бил тиңентен чыкты да люк кырыеннан асылынып тынып калды. Әнә шуннан бирле алар, күмерләнеп каралган кисәү башы төсле булып, танктан көйгән ит исе таратып торалар...

Танклар һөҗүменнән соң солдатлар әле исләрен җыеп тәмәке көйрәтеп алырга да, тылдан ике термос белән старшина Сысоев алып килгән суны котелокларга бүлеп эчәргә дә өлгермәгәннәр, пулемет һәм тупларның кызган көпшәләре суынып та җитмәгән иде — кинәт тирә-юньдә снаряд һәм миналар шартларга тотынды. Бу снаряд һәм миналар, сызгырып-чыелдап, әле генә немец пехотасы белән танклар чигенгән үр артыннан ява башлады. Окоплар өстен соры тузан һәм дары сөреме каплап алды. Зәһәр тол исе тынны әчетеп, сулышны буа иде. Киньягулов белән аның икенче номеры Васин окоп төбендә арка капчыклары, буш котелоклар һәм атылган гильзалар арасында балчыкка буялып беткән шинельләре өстендә яталар иде. Васинның сугышка беренче керүе иде. Аның аксыл-сары кашлы, малайларча сипкелле йөзендә аптырашлы бер елмаю галәмәтләре чагыла. Бик эчәсе килсә дә, ул капчыгыннан сохари алып кимерергә керешә. Киньягулов та бик сусаган иде. Ул вакытны бушка әрәм итмәс өчен, аннан да бигрәк, кулын тик тотмас өчен, дискка патроннар тутырырга керешә. Һәр вакыт шулай була: кеше җаны да түзмәслек каты сугыш басылып-тынып калдымы, ул үзенең тормышын исенә төшерә, һәм, үзе дә сизмәстән, күңелендә нидер бер борчу-шом баш калкыта. Шушы борчу уяндымы, балалары, хатыны һәм әнисе исенә төшә, бу — аларның борчуы, Киньягуловның исән булуын теләп ут йотулары кебек тоела. Ул аларның инде өч елдан бирле хәтереннән җуела башлаган йөз-сыннарын күз алдына китерергә тырышты. Сугыш тынганнан соң аларга язасы хатының сүзләрен дә күңеленнән уйлап куйды. Әмма шул вакыт сызгырып-чинап килгән чираттагы мина гөрселдәп шартлады да аның күңелендәге уйларны, газиз йөз-сыннарны өзгәләп туздырып ташлады...

Траншея эченнән, иелә-иелә, взвод командиры ярдәмчесе Чуйков килә иде. Ул сугышның беренче көннәреннән бирле сугышып килүче кадровый сержант, өч тапкыр яраланган, кырыс булса да гадел кеше, солдатларга да «сез» дип кенә эндәшер, бер вакытта да тәмсез телләнеп сүгенмәс; еш кына аның үзеннән: «Син теге генерал Чуйковның туганы түгелме?» — дип тә сорыйлар, бу сүзгә каршы ул коры гына итеп: «Юк, мин үземә башка Чуйков», — дип җавап кайтара. Аның дала кояшында янып, тузанга батып каралган битләреннән балчык катыш тир ага иде. Ул:

— Киньягулов, пулеметка ят! Хәзер фриц килә башлый! — дип кычкырды да ары китеп барды.

Киньягулов урыныннан кузгалды... Дошман ягына таба каратып тар гына пулемет оясы казыды, кырыйларын әйбәтләп кәс белән ныгытты. Кипкән әрем сабаклары арасында яткан «дегтярев»ына таба бер адым атлауга, коточкыч бер көч белән гөрселдәгән шартлау дулкыны аны окоп төбенә ташлады. Киньягулов башын калкытты һәм тузан, дары сөреме аша Васинны күреп алды. Васин, бик җайсыз яткан сыман кырын авып, башы белән окоп стенасына терәлгән, сул кулында — сохари кисәге, ә уң кулы белән, калтырана-калтырана, ботын тоткалый иде. Мина кыйпылчыклары тиеп аның аягын өзгән, чалбары теткәләнеп беткән һәм пыскып яна башлаган иде. Бер тамчы кан әсәре күренмәгән, майлаган сыман ялтырап торган аксыл ботыннан

чип-чиста алсу сөяк башы тырпаеп чыккан. Авызы җан ачысы белән кычкыра алмыйча газапланган кебек ачылып калган, күзләре шардай булып каткан, ә йөзе шул хәтле агарган — сипкелләре кап-кара дияр-лек бөртек-бөртек булып беленеп тора иде.... Киньягулов боларның барысын берничә мизгел эчендә генә күреп калды, шуннан соң Васин аңлаешсыз, ят бер нәрсә сыман ераклаша-ераклаша, соры томан эчен-нә китеп югалды...

Киньягулов аңына килгәндә, тирә-як дөм-караңгы, тып-тын иде. Баш өстендә тоныкына булып соры, тәбәнәк күк йөзе күренә. Ул, окоп стенасына сөялгән хәлдә, әллә кара балчык өемнәре, әллә кеше мәет-ләре арасында, һаман шул урынында, бая мина килеп төшкән чак-тагы җирдә утыра, әмма хәзер аңа мондагы бөтен нәрсә гаҗәп сәер, җан өшеткеч дәрәҗәдә шыксыз-ямьсез, бөтенләй чит-ят булып тоелды. Ияләшенгән, үз булып беткән бу җирне бәлки караңгылык белән тын-лык шундый шыксыз иткәндер... Киньягулов кинәт төшенеп алды: акылга да килмәслек, һич ышанмаслык бер хәл булган: уттай кызган киеренке пространство аның аша узган да тирә-яктагы бөтен даланы иңләп, һөҗүм итүче немец танклары белән бергә әллә кая еракка китеп барган. Монда хәзер алгы сызык та, безнең җир дә, окоплар да калмаган, снарядлар, танк табаннары сөреп киткән үле җир, кеше мәетләре һәм ватык-җимерек металл гына торып калган. Ә ул, Кинь-ягулов, дошман тылында икән.

Киньягулов ут кебек әрнетеп, сулкылдап торган башына кулын куйды, баш сөягендә ачылып торган зур яра барлыгын тойды: шул төштә миен касмакланып каткан кан гына каплап тора иде. Яраны тиз генә бәйләргә кирәк иде, ләкин аның янында бинты юк икән. Киньягу-лов тирә-ягын капшап карады, пилоткасын тапты, тузанын каккалады да әкрен генә, сакланып кына яралы башына киде. Ярасы бик авыр икәнлеген, гомере күп калмаганлыгын ул аңлый-сизә, ләкин әҗәленең якынлашуы, озакламый үләчәге аны куркытмый, киресенчә, ул шушы төн үткәнче үлми калырмын да терелэй немецлар кулына эләгермен дип кенә курка. Әҗәле алдыннан ул боздай салкын күзле баскынчы адәм затларының масаеп авыз еруларын, үзенә таба төбәлгән автомат көпшәләрен күрергә теләми. Тик бер генә үкенеч йөрәген сызлата: ул туган ягыннан әллә кайдагы чит-ят җирдә үлеп кала, аны җирләүче булмас, гәүдәсе чит җирнең эссе кояшы астында ятып череп бетәр, аның ак сөякләре өстендә вак кына дала кырмыскалары йөгерешеп йөрер... Ул туган авылының кысан, кайгылы-тыныч зиратын хәтерләде. Кайчандыр дөньяда иң күңелсез, иң ямьсез булып тоелган бу зиратны хәзер иң рәхәт, иң тыныч бер урындыр кебек хис итте. Ул зират авыл кырыенда гына, калкурак бер җирдә. Шуннан карасаң — елга аръ-ягында җәелеп яткан болыннар, еракта күкселләнеп-зәңгәрләнеп тор-ган Урал таулары, әтисе белән кайчандыр атта узган юллар, яшел тугайлар күренә (анда ул печән чапкан иде, каен күләгәсендә хаты-нын кочаклап яткан иде). Шуннан караганда аның йортының түбәсе дә күренә, ул өйдә Киньягуловның уллары яши, алар аны исләренә төшерәләрдер; ул өйгә берөзлексез кайнап-кайнашып торган кешеләр тормышының авазлары ишетелә: авылда кемдер балта тукылдата, бә-рәңге бакчасында әнә бер хатын җырлый, кайдадыр бер бала елый, әтәчләр кычкыра, тавыклар кытаклаша... Ул зиратта аның әби-баба-лары, әтисе череп туфрак булган. Аларның җиргә ингән каберләре өстендә куе булып сарут үскән, кыр үләннәре чәчәк аткан. Тамырлары җир эченә бик тирән киткәндер, үлгәннәрнең сөякләренә хәтле төшеп җиткәндер. Ул чәчәкләргә бал кортлары, төрле-төрле күбәләкләр куна. Зират уртасында бик биек, карт карагай үсеп утыра,— Салават зама-

нында ук кисеп бетерелгән Урал карурманнарыннан калган бердәнбер агачтыр ул. Аның төбе генә дә өч колач кадәрле, кәкре-бөкре тамырларына могыллар үскән, сагызлар укмашып каткан. Агачның очын кайчандыр яшен суккан булган, күмерләнеп каралган ботаклары борынгы зур бер җанварның сөякләре шикелле тырпаеп тора. Шулай да карагай яши, үлми. Аның җәелеп үскән аскы тармаклары яз саен яшел чук сыман йомшак, исле ылыслар белән каплана. Бу карагай Киньягуловның бабасының бабасы заманында ук инде шундый булгандыр, бабасы белән этисе дә аны нәкъ шушы рәвешендә күргәннәрдер... Алар авылыннан чыккан зимагурларны язмыш кайларга гына илтеп ташласа да, картлык көннәрендә алар, үлгәч туган туфракка җирләсеннәр дип, үз авылларына кайтып егылганнар. Андый кешеләр турында: «Карагай ышыгына кайтты»,— дип әйтә торганнар иде. Тик Киньягуловның гына кабере карагай ышыгында булмас. Зират буеннан узган чагында улы да күңеле тулып: «Әнә эти кабере!» — дип әйтә алмас.

Киньягулов, соңгы сулышы җиткәнен сизеп, якын кешеләрен: авыру әнисен, хатынын һәм малайларын күз алдына китерде. Чем-кара күзле, теречә ике малаен (олысы алты яшендә, кечесе — дүрттә) һәм сөйгән хатынын күңеленә иң якын җирдә — өендә итеп күрде. Шулай да аның күз алдына бөтен өй эче түгел, өйнең бер почмагы гына — йон палас җәелгән сәке, аның янында почмактагы яшел сандык, сандык өстенә өелгән ястык-түшәк, юрган һәм киезләр килде. Кичке ашчәйдән соң, малайларның көн буе уйнап алҗыган, йокымсыраш башлаган чакларын хәтерләде. Менә әниләре аларга сандык буена киез җәя, баш асларына икесенә бер ястык сала һәм өсләренә иске юрганны яба. Шуннан соң малайлар юрган астында шаяра-котыра башлыйлар, кайвакыт сугышып та китәләр, малайларның чәчләре китәрелгән дәү башлары юрган астыннан бер чыга, бер яшеренә. Аннары көне буе уйнап арыганлык үзенекен итә: малайлар үзләре дә сизмәстән йоклап китәләр. Шуннан соң инде эти-әниләре дә йокларга ята, беренче тапкыр, кабатланмас кебек тоелган ләззәтле төнге яратышудан соң алар да татлы каты йокыга талалар... Их, нинди бәхетле чаклар булган! Төштә генә булмадымы икән ул, өндә булдымы икән?!

Аның бичара авыру әнисе ишегалдындагы кечкенә йортта аерым яши: килене белән сыеша алмадылар. Карчыкның, элекке замандагы шикелле, бөтен йортка бер үзе баш буласы, киленен үз кул астында тота торган усал кайнана буласы килде. Бөтен йорт-хуҗалыкны үз җилкәсе белән күтәреп, бирчәеп беткән куллары белән җир тырмап ул җитештергән, ә килененең бу йортка килгәндә, карчык әйтмешли, бете дә юк иде. Карчык улын килененнән көнли, янәсе, ул аның улын сихерләгән, аны бер манка малай урынына гына күрә, ә үзе ипи дә пешерә белми, юган савыт-сабасы чиста түгел, муеныннан шакшыга баткан. Киньягулов аларның кайсын ачуланырга, кайсын якларга да белми: хатынын ярата, әнисен кызгана иде. Ахырда ул ишегалдына каен агачыннан кечкенә генә өй бурап, әнисен шунда урнаштырды. Юк, авылда кайбер гайбәтчеләр таратканча, ул аны куып чыгармады, карчыкның үзенең аерым яшисе килде. Шулай да Киньягулов аның каршында бик зур гаепле, чөнки күп вакыт ул хатыны хаклы булмаганда да аны яклады. Андый вакытларда аңа әнисе үзенең авыр холкы белән аларга бер-берсен яратышып тыныч кына тормыш итәргә комачаулый сыман тоела иде. Хәзер Киньягуловка ул талашуларның сәбәбе бик вак нәрсә булган, гомерләренең иң матур чакларын чүп белән булашып уздырганнар кебек тоелды. Ул бичара тол әнисе хәзер ни хәлдә яши икән? Чәе, керосины, кабарына икмәге бармы икән? Киткән чакта хатынына, әнине рәнҗетәсе булма, дип бик ныгытып әйткән иде,— уртак кайгы-хәсрәт, газап-михнәт татулаштырды микән алар-

ны?.. Их, әгәр могҗиза булып, Киньягулов урыныннан кузгала алса иде дә, шушы караңгы чокырдан чыгып, үзебезнекеләр янына җитсә иде, исән-сау калып, өенә кайта алса иде... Шуннан ул әнисенең аягына егылып, ачы күз яшьләре белән елый-елый, аңардан гафу сорар иде... Шулай ук ул әнисен, хатынын, малайларын бүтән бер дә күрмәс микән, алар белән бергә сәкедә утырып ашыкмыйча, тәмләп кенә сөйләшә-сөйләшә чәй эчә алмас микән?!.

Өметсезлектән, күңеленә тулган ямансу уйлардан Киньягулов елап җибәрде. Бик озак, бәгыре әрни-әрни елады. Күк йөзе һаман да яссытәбәнәк, соры иде. Киньягуловның нигәдер әҗәле дә килеп җитми иде. Ул әле һаман да баш сөягендәге ут кебек әрнетеп сулкылдаган ярасын тоя, гәүдәсе, кул-аяклары барлыгын, тере тәнендә беркадәр көче калганлыгын тоя иде. Аннары ул кинәт хәрәкәтләнә алуын аңлады. Менә ул кулларына таянып күтәрелә төште, ишелеп-шуып торган салкынча җиргә капланып ятты һәм балчыкны куллары белән ишә-ишә өскә таба үрмәли башлады. Ниһаять, чокырдан чыгып җитте, бераз ятып хәл алды һәм әҗәл китергән шушы каргышлы урыннан шуышашуыша китеп барды. Ул исән калырмын, берәр могҗизага очрап котылырмын дип өмет итмәде, аңсыз рәвештә диярлек, күңеле-җаны туган ягына омтылганга, шунда таба берничә адым булса да якынайыйм дип кенә шуышты. Ул актык тамчы көченә хәтле шуышып барды — яралы башын тотып торуы авыр, көчәнүдән тамырларга кан төелә, башы туктаусыз шаулый, ут кебек кызышып әрни — ярасына каткан кан ярылып китәр дә мие агып чыгар сыман тоела иде. Киньягулов җиргә тезләнде, аннары аягына басты. Егылмыйча басып тора алуына гаҗәпләнмәде, сөенмәде дә, бары тик әҗәленең берничә сәгатькә соңгарып килүен генә аңлады. Башын туры тотып, җирне аягы белән капшый-капшый атлап китте. Актарылып беткән караңгы кыр өстеннән, мәетләргә абына-сөртенә, авып яткан туплар, җансыз танклар һәм башка шундый янган-көйгән металл арасыннан атлады. Шуннан соң таныш булмаган ниндидер тигез җир башланды. Бу караңгы буш җир дә дөм-караңгы төн эченә китеп, еракта түбәнәк күк йөзе белән тоташкан иде. Күктә дә, җирдә дә бернинди яктылык әсәре — кеше кабызган ут та, энә очы чаклы гына булып җемелдәгән йолдыз да юк. Киньягулов эчке бер сизем белән генә юнәлешне чамалый — ул көнчыгышка таба, фронттан тылга, дөресрәге, немец тылыннан фронтка таба атлый иде. Тирә-юнь тып-тын, офыкта бернинди дә сугыш уты күренми — немецлар ил эченә таба шактый ерак киткәннәрдер. Ул фронт аша чыгып, үзебезнекеләргә кушыла алырмын дип тә өметләнми, фәкать аягымда басып тора алган чагымда, башымны көнчыгышка, кояш чыгышына таба куеп юлда үлим дип кенә атлый... Тормыштереклек әсәре күренмәгән, тавышсыз-өнсез, ялан дала буйлап берничә чакрым барганнан соң, ул кинәт биек итеп өелгән тимер юл нигезенә килеп төртелде. Сөзәк нигез буенда куе булып сарут үскән, ә шпаллар арасын, чуер таш аша чыгып, әрсез алабута, әрем баскан. Бик күптән поезд тәгәрмәчләре тимәгәнгә, рельсләр күгәреп, тузан белән капланган. Бу рельсләр кайдадыр еракта башка юл рельсләре белән кушылып, туган якка, Урал тауларына таба китәдер, безнең станция аша үтәдер, аннан авылга йөз генә чакрым кала, шулай булгач, димәк, бу юл туп-туры өйгә алып кайта, дип уйлады Киньягулов һәм шпаллар буйлап атлап китте. Озак, бик озак барды, әллә ни гомерләр узган кебек тоелды аңа. Вакыт-вакыт бу караңгы дала туп-туры күккә менеп киткән тоташ стена шикелле аның каршына килеп баса һәм ул, шпалдан шпалга атлап, бик зур баскычтан шул стенаның очыкырые күренмәгән түбәсенә күтәрелә сыман тоела. Төн һаман дөмкараңгы, бернинди тавыш-өн ишетелмәслек тынлык... Аннары ул озын бер составка тезелгән тимер юл вагоннарын күрде; вагоннар, озын

бер кара нәрсә кебек, каядыр аңлаешсыз караңгы бушлыкка таба сузылып киткән иде. Мөгаен, Киньягуловны бөтен Рәсәй аша уздырып фронтка китергән поезд шушыдыр, шул ук акбур белән чуарлап язып бетерелгән пульман вагоннары, Рәсәй хатыннарының ачы күз яше тамган, чуен тәгәрмәчле менә шушы солдат торагыннан төшеп, алар туп-туры сугыш уты эченә кергәннәр иде. Алар вагоны составның башыннан бишенче иде. Азык-төлекне беренче вагоннан бирәләр, медпункт та шунда урнашкан, эшелон башлыгы, старшина һәм медсестра да шул вагонга утырып баралар иде. Менә икенче, өченче, дүртенче вагон һәм менә бишенчесе. Вагонның ишеге яртылаш ачып куелган.

Киньягулов ишектәге бик тимерен кулы белән капшап тапты да бөтен көченә тартылып-этенеп караңгы, буш вагон эченә керде. Бер-ике адым атлауга таныш тимер мичкә килеп төртелде. Бу мичне алар үтә күренердәй итеп кып-кызыл булганчы ягалар иде. Шунда тары ботказы пешерәләр, чәй кайнаталар, утлы очкыннар чыгып торган морҗасыннан тәмәке элдерәләр иде. Ишектән уңга да, сулга да ике катлы нарлар ясалган. Киньягуловның урыны паровоз ягында, икенче катта, кырыйда иде. Ул нарны табып, икенче катка, үз урынына үрмәләп менде, һәм күңеленә үзәк өзгеч дәрәҗәдә бик ямансу булып китте.

Әле кайчан гына алар монда, менә шушы агач нарларда фронтка барганнар иде! (Киньягулов моның шул ук состав, шул ук вагон икәнлегенә шикләнми иде инде.) Төрле өлкәләрдән җыелган тыныч-сабыр холыклы рус кешеләре, кызу-кызу сөйләшүче чая Казан татарлары, хәрби хезмәтне ярата торган, аз сүзле, һавалырак башкортлар, киң битле, кысык күзле Себер ягы кешеләре, эчкерсез, ачык күңелле, талымсыз казакълар, башкалардан араланыбрак торырга яратучы, шикләнүчән, диндар Урта Азия уллары — шулар барысы бергә җыелып бер сугышка барганнар иде, тән җылысы белән бер-берен җылытышып янәшә йоклаганнар, чиратлашып тимер мичтә ботка пешергәннәр, бер котелоктан ашаганнар, җырлаганнар, шаян сүзләр әйтешкәннәр, көлешкәннәр, ачуланышып та алганнар, кайвакыт малайларча сугышып та киткәннәр, хәтта гарьләнеп елаганнар да иде. Алар барысы да сөенешкән, рухлары күтәрелеп киткән иде: запастагы полкта ач яту, борчалы землянкалар, эт чыкмаслык төндә өйрәнү тревогасы буенча сикереп тору, бил тиңентен кар ерып йөрү, фанер мишеньга атулар артта калды, шуннан алар фронтка, чын сугышка киттеләр. Билгеле, сугышта кем дә булса үлми калмый. Аларның байтагы, бәлки ул, бәлки тегесе, бәлки бусы — бәлки бөтенесе бергә — бер атнадан яки бер айдан җиргә ятып үлеп калырлар. Ләкин ул хәл әле бер атнадан яки бер айдан соң гына булачак... Хәзергә алар поездга утырып баралар, фронт паегы ашыйлар, йоклыйлар, туганнарын, сөйгәннәрен искә төшерәләр, аларга хат язалар, хыялланалар, вагон ишегеннән кызыксынып чит-ят җирләрне карап баралар. Сугышка, үлемгә баруларын күңел сизгәнгә, яшәүнең һәр мизгеле, дөньяның һәр төс, тавыш, тәм, исләре тагы да татлырак, тагы да тансыграк тоела иде... Шушы вагонда фронтка барганда яшь кенә бер егет акылыннан язды. Нарда яткан җиреннән тәрәт итә һәм үз тәрәтен үзе ашый башлады. Старшина Сигачев аның акылдан язуына ышанмады, җүләргә сабыша гына ул, диде. Поезд барган шәпкә вагон ишеген ачты да акылдан язган егеткә: «Сикер!» — диде. Егет ишеккә таба атлады, сикерәм дигәндә генә аны тотып калдылар; кайсыдыр станциядә аны поездан төшереп, госпитальгә озаттылар... Старшина Сигачев хәзер кайда икән, башкалар кайда?.. Менә монда, Киньягулов янында, Васин дигән, сипкелле битле яшь кенә егет йоклый иде. Аның әле кызлар кочканы да булмагандыр, кешеләрнең ничек өйләнешүләре турындагы мәзәкләрне тыңларга бик ярата иде... Шуннан соң окоп... төтәп янган чалбар... һәм алсуланып агарып торган бот сөяге...

Киньягулов, карангыда капшана торгач, почмакны тапты, аркасы белән такта стенага сөялде, уң як җилкәсе белән икенче стенага терәлде, башын иплэп кенә кытыршы җылы тактага сөяде дә аякларын сузып, күзен йомды. Шушы вагонда, шушы сәндерәдә ул гомеренең соңгы сәгатен яшәячәк... Ни генә дисәң дә, баш өстендә хәзер түбә бар, өй сыман нәрсә бар, әле кайчан гына ул монда иптәшләренең тавышын ишеткән, шушында йоклаган, төшләр күргән иде. Моннан аны фрицлар да таба алмаслар... Күңелдә кечкенә генә бер өмет чаткысы да бар: бәлкем безнекеләр озакламый немецларны моннан сөреп чыгарырлар да Киньягуловны килеп табарлар, исән булмаса, ичмасам, гәүдәсен туганнар каберенә күмәрләр, ә аның медален, бумажнигы белән йөз сум акчасын, шәмәхә карандаш кисәген һәм ялтыравыклы чәй кәгазенә төрелгән өч почмаклы күн бөтине әнисенә, хатынына, улларына җибәрерләр... Гомеренең соңгы сәгатьләрендә күңеле белән балалары янына әйләнеп кайту өчен, ул курку тойгысына, башы авыртуына һәм бүтән шундый вак-төяк тән борчуларына бирелмәскә тырышты. Аның барлык уй-тойгысын ярату һәм сагыну хисләре генә билэп алды. Ул әнисенең тормыш нужасыннан һәм үпкә-рәнҗүләрдән җыерчыкланып каралган ябык йөзен, хатынының елт кына карап ала торган соргылт күзләрен күрде,— хатынының ул карашында ярату да, яраттырырга теләү дә һәм оялчанлык та бар иде,— малайларының нindидер бер кош исе сыман ис килеп торган башларыннан сыйпап үпте һәм күңеле булып, күңеле тулып елап җибәрде... Аннары поезд тартылып куеп кузгалып киткән сыман тоелды. Менә ул кызулаганнан-кызулый бара, тәгәрмәчләр рельс ялгауларында ешрак тукылдый, вагон үзе калтырана, чайкала һәм дырык-дырык сикертә башлады. Киньягулов башта миңа шулай тоела гына торгандыр дип уйлады, аннары яралы башының калтыранган вагон стенасына бәрелгәләвен тойды. Ярасы шундый авырта-әрни башлады — баш сөяген нindидер очлы бер тимер белән төеп-тишкәләп торалар сыман иде. Бу авырту-әрнү төштә генә түгел, өндә,— димәк, поездның баруы да чын. Поезд кая барса да, Киньягуловның йокымсыраган-оеган, хәлсез гәүдәсен кая илтеп ташласа да, аңа барыбер иде, чөнки ул ярасы авыртуына түзә алмый газаплана, һәм аның күңеленә: мин бик җайсыз ятканмын, яралы башым вагон тактасына бәрелә, уянып, җайлабрак утырырга, башны турырак тотарга кирәк, дигән әйле-шәйле бер уй гына килә иде. Бөтен тән-әгъзаларын хәлсез иткән бу йокыдан ул һаман уяна алмады, киресенчә, тагы да ойый барып, ярасы сызлавын бөтенләй онытты һәм чын мәгънәсендә төш күрде. Имеш, ул караватта, иягенә хәтле одеял ябынып, соры бер чыбылдык эчендә ята. Ком төсендәге сары, йонтәс одеял, әллә кая, дистәләрчә, йөзләрчә чакрымнарга сузылган киң дала шикелле, аның аякларына таба сузылып китә дә шунда еракта-еракта нindидер сары, кайгы-хәсрәтле ялан калкулык итәкләренә әйләнә, имеш. Сары калкулыкларга җитә торган бу одеял да, үзенең җир шикелле бик дәү, бик авыр гәүдәсе дә (бәлки, ул хәзер инде чыннан да аның гәүдәсе түгелдер, аның үзен чүретеп туфракка әйләндергән җирдер, үзенең дәүлеген, авырлыгын, кайгы-хәсрәттә икәнлеген тоя, аңлый торган җир генәдер ул) түзеп булмаслык газаплы, авыр бер нәрсә булып тоелды һәм ул чабалана-чабалана кычкырып җибәрде, ыңгыраша башлады... Шуннан соң янадан вагон стеналары калтыранырга тотынды, башы, сикергәләп тактага бәреләбәрелә, түзеп булмас дәрәҗәдә авыртырга-сызларга керешге. Бу хәл озак, бик озак дәвам итте. Бик күп сәгатьләр, көннәр, атналар узгандырмы — Киньягулов аңсын белмәде. Ул бары тик газап белән тулган вакытның һаман дәвам итүен генә тойды. Аннары тынычланып калуын тоеп, күз кабакларын күтәрде: стена ярыкларыннан, ачык ишектән көндезге кояш яктысы балкып керә иде. Димәк, төн узган, ә ул үлмә-

гән, дошман сулышы белән агуланган шушы бушлыкта, дала җирдә ташландык бер станциядәге вагонда газапланып яту өчен исән калган: бик озак тимер юл буйлап барам дип тоюы бары тик төшләнүе генә булганлыгын, башындагы ярасының ут шикелле әрнетеп сулкылдавын вагон селкенүе итеп тойганлыгын хәзер инде ул аңлады... Кызыксыз һәм кирәксез булып калган бу көн хәзер аңа тагы нинди газаплар китерер? Үзен немецлар килеп тапканчы, «А, русс, выходи!» дип кычкырганчы ул үлеп өлгерерме? Ярабби, дошман кулына гына эләгә күрмәсен! Шунсы бик кызганыч — янында автоматы юк! Фрицларны кырып салыр иде дә соңгы пуляны үзенә атар иде... Кинәт ачык ишектән ике кеше йөзе күренде. Киньягулов, сискәнеп китеп, башын ия төште. Бу ике кеше борчулы төс белән вагон эченә күз йөртеп чыктылар. Киньягулов башта аларның фәкать күзләрен генә күрде, бу күзләрнең карашындагы мәгънәне аңларга тырышты: алар Киньягуловны шәйләмәделәр. Тагы бер секундтан соң ул аларның үзебезнең рус кешеләренә охшашлы таныш йөзләрен, өс-башларын — кояшта уңып беткән солдат пилоткасын, пилоткадагы йолдызны, берсенең иңендәге өч сызыклы погонны һәм икенчесенең башындагы тимер юлчы фуражкасын күреп алды. Солдат белән тимер юлчы — үзебезнең кешеләр икән! Алар үзара нидер сөйләшеп алдылар, тик Киньягулов аларның бер сүзләрен дә ишетмәде; тегеләр әнә шулай үзара сөйләшеп алдылар да бөтенләй юкка чыктылар... Киньягулов беравык аптырап уйланып торды, аннары кинәт аның башында өермәдәй бөтерелеп үз тирәсендәге дөнья турындагы төшенчәләре алмашынды, пространство күченде, һәм әшәке бер төш күргәндәге шикелле әллә нинди акыл ышанмаслык, буталчык хәлләр, вакыйгалар эченнән чын дөнья билгеләре калкып чыкты. Димәк, немецларның берничди һөҗүме булмаган. Киресенчә, безнекеләр һөҗүмгә күчкән булганнар, кичә сугышкан җирләр безнекеләрнең тирән тылы икән... Аның күңелен зур өмет нуры яктыртып җибәрде. Менә ул вагоннан чыгар да теге солдатны күреп: «Туганкай, медсанбат моннан еракмы?» — дип сорар. Аннары инде госпиталь, ап-ак чиста җәймәләр, ак халатлы ягымлы сестралар. Хирург аның миенә кергән кырлы-кырлы чуен кыйпылчыгын алып, баш сөягенә ямау салыр. Бу әле бәлки әҗәл сәгатен арткарак чигереп тору гына булмас, бәлки бөтенләйгә исән калыр... Савыккач, өенә кайтып китәр, хатынын, балаларын куенына алып сөяр; сугыштан соңгы тыныч тормышта әле бик озак яшәр, карт әнисен җирләр, үзе дә картаеп бабай булыр, картларча талчыккан күзләре белән чын ир булып җиткән улларына карап торыр, сөякчел кулларына йомшак кына тәнле нәни оныкларын алып сөяр... Аннары инде, бу дөньяга кирәге калмагач, картаеп әҗәле җиткәч, аның үзен дә зиратка, карт карагай ышыгына илтеп җирләрләр. Бүтән төрле язмыш кирәкми дә аңа... Киньягулов иплән кенә нардан төште. Ачык ишектән сарыга буялган кечкенә станция йортын, ачык платформалардан тезелеп киткән составны, андагы өсте ябулы тупларны, корымлы сасы төтен бөркә-бөркә юлдан-юлга күчеп йөрүче кечкенә генә җитез паровозны, паровоз тәрәзәсеннән башын чыгарган, кап-кара ач яңаклы, соры мыеклы машинистны күрде. Бу кечкенә станциянең фасадына зур кара хәрефләр белән язып куелган исеме дә Киньягуловка таныш кебек тоелды. Моның үзләре поездан төшеп фронтка киткәндәге станция икәнлегенә ул бөртек тә шикләнмәде. Ләкин, вагоннан чыккач, әйләнә-тирәсе көтелмәгән, аңлаешсыз бер урын сыман булып тоелды. Иң әлек кечкенә генә станция дигәне зур бер станция булып чыкты, әмма станциянең исеме, күрше авыл яки үзләренә якындагы шәһәр исеме шикелле, гаҗәп дәрәҗәдә таныш тоелды... Аңа иң гаҗәп тоелганы тагы шул булды: станция йортларыннан ары берничди дала юк — анда шәһәр иде, ә шәһәр йортлары артында тәбәнәк кенә ялангач калкулыклар күренә, тагы да

арырак киткәч, томанлы офык эченнән зур-зур тау итәкләре шәйләнә. Болары да бик таныш кебек иде... Кинәт Киньягуловның аңында, өермәдәй бөтерелеп, янадан вакыт һәм тирәлек алмашынды, әле генә чын булып, өн булып тоелган дөньяның асты-өскә әйләнде, һәм шул болганыш-чуалыш эченнән чынлык билгеләре калкып чыкты. Димәк, аның поездда баруы хак. Поезд аны фронттан читкә алып киткән һәм көнтөн бара торгач, бөтен Рәсәйне узып, Киньягуловны, буш вагонда аңын югалтып яткан яисә бик каты йоклаган хәлендә, Урал таулары тирәсенә китереп җиткергән. Әйе, әйе, бу — теге үз станцияләре, моннан аларның авылына йөз чакрым чамасы гына... Окопта чакта снаряд кыйпылчыгыннан яраланып аңынны җую, дөм-караңгыда шуышашуыша ниндидер станциягә барып җитү, буш вагонга үрмәләп кереп, каты йокыга талу яки аңсыз-һушсыз калу, аннары, уянып китеп, үзенне әллә кайда тыл эчендә күрү — бер уйласаң... Хәер, Киньягулов бу хәлгә шаккатмады — сугыш инде аны бернигә дә шаккатмаска өйрәтте. Ул фәкать шәһәргә барып военкомны табарга да үземнең хәлне сөйләп бирергә кирәк, дип кенә фикер йөртте... Шуннан соң аны госпитальгә салырлар, ап-ак чиста җәймәләр, ак халатлы ягымлы сестралар, операция, ул терелер һәм исән калыр... Әгәр алай булмаса... Аның гомерен беразга гына озайтсалар... Бер атнага, бер айга гына... Киньягуловның госпитальдә ятканы бар инде: башы яраланган кешеләр бик сирәк терелә... Туган йортыннан йөз генә чакрымда булып та әниенне, хатынынны, балаларынны күрмәү... Җәяүле юлдан гына китәргә кирәк, аякларың атлый алмас хәлгә җиткәнче барырга да барырга, туган йортынның бусагасы төбенә шуышып булса да кайтып җитәргә. Аннары хатынын, балаларын кочаклап сөяр, яралы башы белән әнисенең аякларына егылып, битендә аның гафу итеп сыйпаган җылы кулын тояр, аннары инде... ни булса да булсын... Киньягулов тимер юл буйлап китеп барды, ниндидер ямьсез, шыксыз кирпеч биналар, стеналарына ут сүндергеч баллоннар асып куелган агач складлар, таудай калкып торган соры элеватор янышнан узды, ямь-яшел үлән үскән ниндидер бер урамнан китте, аннары шәһәр читенә килеп чыкты. Монда кеше йорт кормаган иркен яшел болын-кырлар башланып китә, мондагы үләннәр, игеннәр өстеннән, урманнар, таулар һәм елгалар аша бормалы-сырмалы ат юлы сузылып, әллә кайда еракта очы белән Киньягуловның туган авылына, аларның тузанлы урамына барып керә...

Бик күптәнге, бик борынгы юл ул. Ташлы Урал җиренә ул юлны ат тояклары, арба тәгәрмәчләре, сөялләнеп каткан ялан аяклар таптап салган. Бу җиргә кешеләрнең тире, күз яше сеңгән, бу җир тапталып он шикелле тузанга әйләнгән. Киньягуловка бу юлның һәр түмгәгечокыры, һәр борылышы таныш. Бу юлдан ул малай чагында әтисе белән калага бара — элеваторга икмәк, базарга ит-май алып баралар, ситсы, кием-салым, чәй, шикәр юнәтергә баралар иде. Шул юл белән сугышка киткәндә аны гармун уйнатып, елашып озатып калдылар... Хәзер инде ул юл тып-тындыр, аны үлән баскандыр, анда кешеләр кайнап тормыйдыр, чөнки сугышка китәсе кешеләр күптән китеп бетте инде, ә аннан әйләнеп кайтучы юк. Калага да йөрмиләрдер, чөнки анда чәй, шикәр дә, ситсы да юк.

Киньягулов солдат атлавына хас булмаганча авыр итекләрен көчкә өстери-өстери бик озак барды. Аның юлга төшкән күләгәсе башта уң якта иде, озын иде, аннары бөкре кеше гәүдәсе шикелле кыскарды, шуннан соң тагы озаеп, сул яктан ияреп бара башлады. Һәр аяк басуы ярасын ут кебек әрнетеп-сызлатып башында яңгырый, аяклары инде тәмам арып-талып берни тоймас хәлгә җиткән, бөтен тәне сасы тиргә

баткан. Юл буендагы йомшак, жылы үләнгә утырасы, рәхәтләнеп сузылып ятасы килсә дә, Киньягулов алданмый. Белә ул: әгәр хәл алыйм дип утырса, яңадан торып китә алмаячак, торып китә алса да, гомереннең берничә минутын тик утырып әрәм итәчәк. Өенә кайтып җитү өчен бәлки әнә шул берничә минут кына җитми калыр. Киньягулов, көч килүдән һәм кан кайнарлыгыннан кызган йөрәге салкынча кыр җилендә бераз суынсын дип, гимнастерка изүен чишеп җибәрде. Ул калку үрләргә менде, иңкү үзәннәргә төште, елга ярлары буйлап, иген басулары кырыйлап атлады. Аңа бытбылдыклар кычкыруы да, тургайлар сайравы да, сулар чылтыраганы да ишетелмәде. Шулай да дымлы кара балчык исен, үләннәр, каен яфраклары исен, ташлы калку битләрендәге тау чәчкәләре исен артыгы белән тойды. Туган авылы җирләренә кайтып җитәргә әле байтак ара калган булса да, бу калкуларны, бу басуларны таныды ул: бу төшләр дә үз җирләре төсле үк иде. Көз алдындагы дөнья аның туган җирләрен сагынган күңеленә беренче тапкыр күргәндәй гаҗәеп ямьле, өр-яңа, саф-пакь булып күренә иде: калкулык битләрендә зөбәрҗәт төсле булып бодай уҗымнары яшәреп утыра, урманнар — куе яшел, ерак офыктагы киртләч таулар — шәмәхә-күксел, һава — жылы-рәхәт, күктә чалт иткән кояш, мамык кебек кабарган бөдрә-бөдрә ак болытлар. Шул ук вакытта Киньягуловның күңеле бу тауларның, урман-кырларның илаһи матурлыгында йөрәкне әчтән генә ямансулата торган кайгы-сагыш барлыгын да тоя. Аның авыл кешесенә хас күзе моңаеп яткан кысыр басуларны да, начар гына булып үсеп утырган арыш башакларын да, чүп баскан сирәк бодай уҗымын да, сөрелми калган чи җирләрне дә (хатыннар, үсмер малайлар сөргән, алар чәчкән шул), болын-тугайлардагы биек үләннәр басып киткән юлларны да күрә.

Аннары Киньягулов басуда кешеләр күрде. Калкулык битендә су шикелле агылып-чайкалып торган яшел уҗым өстендә ак яулыклар, чуар күлмәкләр күренә иде. Хатын-кыз бер рәткә тезелеп — кайсы иелеп, кайсы чүгәләп — чүп утый иде. Киньягулов, якынлаша төшкәч, аларны әйбәтләбрәк күрде: болар — кечкенә генә карчыкларга охшаган, җитди чырайлы, ялан аяклы үсмер кыз балалар, ямаулы иске-москы чалбар кигән берничә малай һәм ике хатын иде. Шуннан ары ерактарак эссе рәшә дулкыны эченнән соры чүп өемнәре төсле булып авыл күренә. Чит авыл булса да, монда тамак ялгарлык ризык, төн кунарлык урын һәм ачык чырайлы кешеләр табылмый калмас иде. Тик шулай да Киньягулов бу авылга тукталмаячак. Коеларыннан су эчәр дә китеп барыр. Бер адым атласаң да туган авылыңа якыная барасың... Бер кыз чүп утаган җиреннән күтәрелеп Киньягуловка карады. Юлдан кайтып барган солдатны күргәч, башкаларга нидер әйтте. Калган кызлар, малайлар һәм ике хатын да барысы берьюлы күтәрелеп Киньягуловка карадылар. Аннары малайлар белән кызлар кинәт йөгерешә башладылар, ялан тәпиләрен елтырата-елтырата, туп-туры бодай басуы өстеннән авылга таба чаптылар. Үзләре нидер әйтә-кычкыра иде, ләкин Киньягулов аларның ни дип кычкыруларын ишетмәде. Хатыннар да, кулларын каш өстенә куеп, Киньягуловка текәлеп карый-карый һәм аңа таба әллә ничек кенә яннары белән якыная-якыная, авыл ягына таба атладылар. Менә малайлар, кызлар, куллары белән Киньягуловка таба ишарәләп, нидер кычкыра-кычкыра, алабута-әрем баскан авыл урамы буйлап йөгерделәр. Моңарчы бер җан әсәре юктыр кебек тоелган авылда кинәт ыгы-зыгы башланды: янтайган-кыйшайган өйләрдән, ауган-түнгән читәннәр, череп яткан тирес таулары артыннан, тузанлы әрекмән яфраклары, әрем-алабута сабаклары арасыннан ачык урамга кешеләр чыкты: корышкан ябык кулларын каш өстенә куеп карана-карана, Киньягуловка таба озын итәкле күлмәк кигән карчыклар, шомырт таякларына таяна-таяна, каешланып беткән түбәтәйле, чал са-

каллы бөкшәйгән картлар килә башладылар. Таяк атларына атланып, кәкре аяклы, ертык ыштанлы малайлар йөгерештеләр. Авыл урамы Киньягуловка ишетелмәгән кеше авазлары, шау-шу белән тулды. Киньягуловны чолгап алган халык төркеме — арада бер генә дә яшьрәк ир заты күренми иде — аның белән бергә авылның икенче башына таба агылды. Елый-елый күз яшьләре корып беткән карчыклар Киньягуловка яратып, өмет белән карыйлар, аннан нидер көтәләр сыман иде. Картлар, дәрәҗәле һәм горур кыяфәттә сакалларын чөебрәк, солдатка астан күз салдылар, аның медален тотып карадылар, аяк астында чуалган малайларга таяклары белән кизәнгән булдылар. Шул вакыт кешеләр кинәт йөзләрен алга, авыл башына таба бордылар. Тәрәзә капкачлары тупсаларыннан купкан кечкенә генә өйдән бер карчык чыгып, халык төркеменә каршы йөгереп килә иде. Карчык, аяк астындагы балчык кантарларына абына-абына, иске күлмәгенең озын итәкләренә аяклары бутала-бутала йөгерә иде. Кешеләр хөрмәтләп-олылап аңа юл бирделәр. Карчык Киньягулов янына килде, куллары белән күкрәгеп тоткан хәлдә, сукырая башлаган яшьле күзләре белән солдатка карады. Киньягуловның йөзенә текәлгән хәлдә, кырын-кырын артка чигенә башлады. Аптыраган, ачу-шелтә белдергән бер төстә кешеләргә карады, кулларын селкеде һәм башы белән Киньягуловка ымлап, нәрсәдер әйтә башлады. «Минем энигә бик охшаган икән!» — дип уйлады Киньягулов, карчыкны чын күңеленнән кызганып куйды. Аннары, бу авыл кешеләре мине фронттан кайтып килүче икенче бер солдат дип, шушы карчыкның улы дип белгәннәр, ә хәзер ялгышуларын күргәч, үзләренең кояш баешы ягында сугышып йөргән уллары, ирләре турында миннән берәр төрле хәбәр белергә телиләр, дип уйлады. Ләкин Киньягулов аларның тавышларын ишетмәде, ишетсә дә, берни әйтә алмас иде ул. Кешеләр аңа иплэп кенә кагылып-кагылып алдылар, туктап бераз ял ит, өебезгә кереп тамак ялгап чык, сугыш хәлләрен сөйлә дип үтенделәр. Киньягуловны авыл читенә хәтле озата бардылар да аптырашкан сыман шунда торып калдылар. Тик малайлар гына, агач атларына атланып, аның артыннан байтак ара ияреп килделәр. Кайгы-хәсрәт, борчулардан картайган солдат аналарын, тол хатыннарны, ач-ялангач балаларны кызганып уйлана торгач, Киньягулов моннан ары авылларга кермәскә, улларын, ирләрен, әтиләрен зарыгып көткән кешеләрне шушылай аптыраштa калдырмас өчен, читләтеп үтәргә карар кылды.

Урман кырыеннан икенче авылның соры түбәләре күренгәч, Киньягулов юлдан чыгып, урман эченнән китте. Атлавы бик авыр иде: биек куе үлән аякларга урала, әледән-әле черек агач төпләренә, түмгәкләргә, күптән авып муртая башлаган агач кәүсәләренә сөртенеп китә. Киньягулов адашудан куркып, урман кырыеннанрак барырга тырышты. Вакыт-вакыт бу каен урманы аңа бик таныш та кебек тоелды. Бирегә кайчан килгән иде соң ул? Бу — хатыны белән икәү каен себеркесе сындырырга барган Кызлар тавындагы урман төсле үк бит. Ул вакыт аларның нинди яшь чаклары, бер-берен сөеп туймый торган чаклары иде бит! Каен яфракларыннан шундый тәмле ис аңкый иде! Ул хатыны белән ирләрчә дорфарак итеп шаяра башлагач, хатыны, күгәрчен күк гөлдерәп кенә көлә-көлә, иренә каршы каен ботагы белән селтәнгән иде... Аннары хатыны ул себеркеләрне, унар-унар итеп көянтә башына бәйләп, өйгә күтәреп кайткан иде. Ә кыш көне инде мунчада чабынганда каен себеркеләренең исе башка иде... Каен яфраклары исе Киньягуловның сугышка хәтле булган иң татлы мәхәббәт минутларын хәтерләтте... Юк, таныш урман түгел бу, ят урман, тик исе генә таныш.

Авылны читләтеп узгач, ул яңадан юлга чыкты, үргә күтәрелгәч, тагын кешеләр күрде. Шул минутта ук күңеленә «кире борылып, тиз

генә урманга йөгерим» дигән уй килде. Әмма шунда шаккаткыч бер хәл күреп, тораташтай басып калды. Якындагы офык турысында басуда, күксел-зәңгәр күк фонында аермачык булып, сабан тарткан егермеләп хатын-кыз күренде. Алар янындагы сукаланган кара җир өстендә кечкенә генә бер карт сажин таягы белән җир үлчәп бара иде. Хатыннар алга таба иелеп-көчәнеп сабан тарталар — бау аларның йомшак тәннәренә батып кергәндер. Хатыннар күлмәк итәкләрен күтәрә төшеп кыстырып куйганнар, ялангач балтырларында, йөк тарткан ат тәнендәге кебек, тамырлары бүртеп-бүртеп тора. Сабан авырлыгыннан алар уңлы-суллы чайкалып китәләр; әледән-әле туктап, бауны рәтлиләр дә тагы өстерәргә керешәләр. Сабанны этисенең сынык козыреклы дәү кепкасын кигән бер үсмер малай тоткан. Ул, бөтен көче белән сабан тоткасына ябышып, буразнадан бара. Малай артыннан, кап-кара җир өстеннән, эре генә селкенгәләп, кара каргалар атлый. Кыньягулов хатыны язган хатны исенә төшерде. Язга таба, азык юклыктан, бик күп ат үлде, дигән иде хатыны. Бөтен азыкны ашатып бетердек, хәтта каралты түбәләрендәге черек саламны да ашаттык; корчаңгылап беткән арык атларны иртән күтәреп торгызалар да бауга асып куялар, дигән. Җир сөрерлек ат калмады хәзер, тракторга маңка малайлар, кызлар утырды, тракторлар ватыла, атна буе тик тора, сыерлар, үгезләр җигеп сукалап караган идек тә, рәт чыкмады, чөнки безнең якларда моңарчы сыер җигеп җир сукаламаганнар, ул эшнең рәтен белмиләр, аннары сыерлар буразнадан йөри белми, үзе бер җәфа икән ул, шулай булгач, без хатыннарга үзебезгә җигелеп җир сөрергә туры килер, ахры, дигән иде... Шул вакытны бер хатын Кыньягуловны күреп алды. Хатыннар туктап, бауларын ташладылар да юлга таба карап тора башладылар. Аннары кинәт барысы берьюлы кулларын болгарга, кычкырырга кереште. Кыньягулов хатыннарның ни дип кычкыруларын ишетмәде, шулай да аларның кояш, җил ашап каралткан, тиргә баткан йөзләрен, көтелмәгән сөенечтән, мәхәббәт һәм өмет чаткысы белән нурланып киткән күз карашларын күрде. Ул хатыннарның үзенә эндәшүләрен аңлады. Алар: «Әй, солдат, безнең янга кил! Кая барасың? Аннан кайтуыңа күптәнме инде? Бәлкем безнекеләрне дә күргәнсеңдер? Безнең янга килеп, бераз сөйләшеп утыр!» — дип кычкыралар иде. Бер хатын Кыньягуловка таба килә дә башлаган иде инде, аны күреп, Кыньягулов борылды да тиз-тиз атларга тырышып үз юлы белән китеп барды... Бу солдат хатыннарын яратып, кызганып, ул эчтән генә әрнеп елады, шулай да яннарына туктап, ирләрегезне күрмәдем шул, дип әйтә алмады: бушка вакыт әрәм итәсе килмәде, чөнки аның үзен дә солдат хатыны көтеп тора бит... Ярты чакрымлап ара киткәч, Кыньягулов борылып карады: хатыннар әле һаман да баскан урыннарында аңа таба карап торалар иде.

Аннары төн җитте. Кырлар, урманнар, калкулыклар, үзән һәм елгалар караңгыда тоташ бер яссы кара җиргә әйләнеп калды, тик бу җирнең иң читендә, еракта гына, урыны-урыны белән сынык тешкә охшап, тигезле-тигезсез Урал таулары күренә иде. Тынып калган соры күк йөзендә болытлар туктап йокыга талганнар. Елга үзәннәреннән, калкулык битләрендәге урманнардан хуш исле, дымлы сулыш бөркелә. Төнге тынлыкта шылт иткән аваз да ишетелми. Кыньягулов һаман бара да бара. Ул берәр җиргә туктап төн куна алмый, йоклап вакытын әрәм итә алмый, чөнки ул, йокласа, иртән торуга туган йортыннан ун чакрымга, хәтта егерме чакрымга ераграк торып калган булачак — аннары инде бу хәлсез аяклары белән ул кадәр араны уза алмаячак. Вакыт-вакыт ул, солдат гадәтенчә, аяк өсли генә йоклап та китә һәм һаман бер үк төш күрә. Ул йөнтәс, сары одеял ябынып яткан, имеш, шул одеял очсыз-кырыйсыз ялан дала булып аның аякларына таба сузылып киткән дә еракта ниндидер күңелсез, ялангач калкулыкларга

әйләнгән, имеш... Шуннан соң Киньягулов сискәнеп уянып китә һәм алга таба юлын дәвам иттерә. Таң атып яктырган чакта инде ул тәмам хәле бетүен тойды. Адымнары аның кыскарды, итекләре таш шикелле авырайды, күз аллары караңгылана башлады, аяк астындагы җир чайкалып китә дә стенадай үрә торып каршысына баса сыман иде. Туктап бераз хәл җыярга кирәк иде. Ләкин ял иткәндә аякларының алга таба атламавы һәм гәүдәсенең бер урында гына торуы белән күнеле килешмәде. Ичмасам, бара-бара ял итеп булса икән... Шуннан соң ул кинәт бер тавык фермасы күрде — читәннән үреп салынган салам түбәле озын гына ферма, шуның янында бер якка янтайган тәбәнәк кенә өй дә бар, өйнең моржасыннан ефәк тасма төсле сузылып ап-ак төтен күтәрелә. Ферма янындагы тавык тизәкләре чуарлап бетергән киртәсез ачык урында ап-ак көтү булып тавыклар кайнаша. Алар ферма тирәсеннән шактый ерак китеп, үлән арасында да агарып күренәләр, урман эчендә дә тырманып йөриләр, ашыга-ашыга нидер чүпләнгән булып юлга йөгерешеп чыгалар. Яшь әтәчләр яңгыравык, әче тавыш белән түшләрен киереп кычкыралар да сугышырга тотыналар, урактай кәкре койрыклы, без шикелле очлы тырнаклы, кызыл мәрҗән төсле купшы кикрикләрен кырын салган карт әтәчләр вәкарь белән генә тавыклары янында бөтерелеп алалар.

Шул тавык көтүенә карап, таныш тизәк исен исни торгач, Киньягуловның менә берничә көн инде авызына бер тәгам ризык капмаганлыгы һәм шул хакта уйламаганлыгы да исенә төште. Ашыйсы килмәсә дә, бераз тамак ялгап алырга кирәк дип уйлады, югыйсә, бөтенләй хәлең бетеп, юлда үлеп калуың мөмкин. Аның тавык тотарлык хәле юк, тотса да, пешерә алмас иде, тәмәке тартмагач, кесәсендә шырпысы да, «катюша»сы да юк. Ләкин фермада күкәй булмый калмас. Күкәйне чи килеш тә ашап була бит. Әгәр дә берничә күкәй алып тамак ялгасаң? Колхоз аннан гына бөлмәс әле. Малай чагында ул кеше йортына кереп күкәй урларга, амбар асларыннан, печәнлектән, читән буйларыннан һәм башка шундый ышерен-аулак урыннардан күкәй эзләп табарга ярата торган иде. Аларны ул ашар өчен урламый, бары тик кызык өчен генә урлый, үз өеннән алуга караганда, кешенекен эзләп табуы кызыграк була иде. Кибеттә, күкәйгә алмаштырып, кармак бирәләр иде... Билгеле, ике-өч кенә күкәйне тавык карауччылардан сорап яки сатып алырга да була, ләкин аның кешеләр белән очрашасы килмәде, аларның нидер көткән, нидер өмет иткән монсу чырайларын күрергә теләмәде... Тавык фермасының ишеге ачык иде. Киньягулов, теге кечкенә йортка таба каракларча карана-карана, тавыкларны куркытып, капкадан керде дә ярым караңгы кетәклек эченә үтте. Тишек-тошык салам түбә астында, җеп шикелле сузылган кояш яктысында чыпчыклар очкалап йөри иде. Читән стена буендагы ояларда Киньягулов ясмыктай түгәрәк күзләрен селкетмичә карап утырган кызыл кикрикле берничә тавык башы күрде. Бер тавыкның астына кулын тыгуга, тавык кырылдап җибәрде дә, Киньягуловка канатлары белән җылы һава җилпеп, оядан очып төште. Киньягуловның кулы кайнар күкәйләргә тиде. Куллары аның дер-дер калтырый, йөрәге малай чагындагы шикелле дөрселдәп тибә иде. Ул ике күкәйне алып кесәсенә тыкты, икене кулына тотты да тышка чыкты һәм, ап-ак тавык күлен аралый-аралый, фермадан китеп барды. Бераз ерагайгач, ничектер үзенә арттан карап калдылар кебек тоелды — борылып карады. Ферманың теге тәбәнәк өе янында ак күлмәкле, такыр башлы бер карт белән бер карчык басып тора иде. Беренче карауга Киньягулов, бу карт мина йодрык селкер, я булмаса, таягын күтәреп артымнан килә башлар, дип уйлаган иде. Тик карт белән карчык урыннарыннан кузгалмадылар. Карт кулларын асылындырып тик кенә басып тора, карчык исә кулларын алъяпкычы астына тыккан иде. Солдат ар-

тыннан алар сәерсенгән, берни аңламаган кыяфәттә бик озак карап тордылар. Алар тирәсендә мәш килеп ак тавыклар йөри, тәбәнәк өйдән тасмадай булып ак төтен күтәрелә, җилдә агачлар чайкала, үләннәр селкенә, күктә ак болытлар агыла, тик карт белән карчык кына бер хәрәкәтсез басып калганнар. Киньягулов шактый ерак киткәч тагы әйләнеп карады: карт белән карчык әле һаман шунда басып торалар иде... Ул урман кырыена кереп,— юлга чыкканнан бирле беренче тапкыр,— каен төбенә утырды, кулындагы ике күкәйне үләнгә куйды, чалбар кесәсеннән тагы ике күкәй чыгарды, берсен агачка бәреп ватты да кабыгын ачып карагач, күкәй эчендә йон чыгып җитмәгән алсу тәнле тере чеби күрде. Күкәйне читкә ташлап, икенчесен ватып карады — анысы да чебиле булып чыкты, өченче һәм дүртенче күкәйләрдә дә чеби бар иде. Киньягулов гарьләнеп, үз-үзен кызганып елап җибәрде, башын каен кәүсәсенә терәде дә күзен йомды... Шуннан соң ул янында әле генә кеше барлыгын тоеп уянып китте. Ләкин беркем дә юк иде, тик аның янында, үләндә, көлгә һәм күмергә буялган көлчә кисәкләре, ике күкәй һәм гәзит кәгазенә салынган бер чеметем тоз ята иде... Тамак ялгап вакыт әрәм итмәс өчен,— агач төбендә ул болай да ярты сәгатьләп утырды инде,— күкәйләрне кесәсенә тыкты, тозны көлчәгә сипте дә ашый-ашый китеп барды. Үр өстенә менгәч, артка, ерактагы тавык фермасына әйләнеп карады: карт белән карчык әле һаман, шул урыннарында баскан килеш, аңа карап торалар иде.

Таулар өстенә кибән-кибән болытлар калкып чыкты һәм, куера-карала килеп, Киньягулов өстенә ябырылдылар. Ул шомланып-борчылып дәһшәтле болытларга каранды, берәр авыл, ферма яки, һич югы, берәр салам чүмәләсе күренмиме дип еракка текәлде. Билгеле, ул яңгырга да карамас иде, бара бирер иде, тик яңгыр аның башына ябышып каткан пилоткасын чылатып җибәрүе һәм ярасы өстендәге касмакны куптарып, миенең бөтен канын юып төшерүе мөмкин... Гадәттәгечә, башкорт авылы аның каршына, җир астыннан калыккандай, көтмәгәндә генә килеп чыкты. Таулардагы башкорт авыллары кебек, бу авыл да аулак бер тау аралыгына утырган, төньякның салкын җилләреннән аны биек тау ышыклап тора, янында, ташлар арасыннан чылтырый-чылтырый, күз яшедәй елтырап торган саф сулы кечкенә генә чишмәсе дә агып ята. Киньягулов юл буйлап бара бирде, тау араларыннан югарыга менде, тирә-ягында бары тик таш, үлән, агачлар һәм баш өстендә кара-кучкыл күк йөзен генә күрде, тагын бер адым атлауга — каршысында бөтен авыл пәйда булды... Каты яңгыр аны авыл башында куып җитте. Киньягулов, башын куллары белән каплап, бакча артларыннан гына йөгерде, берәүләрнең мунчасын күреп, читән аша төште дә бәрәңге буразнасы буеннан барып, мунча чоланына керде. Мунча эче караңгы, җылы иде, кичә генә яккан булганнар, күрәсең. Күңелгә якын, таныш ис — пешекләгән каен себеркесе исе, көл, төтен исе һәм ниндидер мунча череге исе килә иде. Киньягулов итекләрен салып, ләүкәгә менде, баш астына кипкән иске себерке салды да иплән-җайлап кына сузылып ятты, аякларын җылы мич кирпеченә терәде. Караңгыга күзе ияләшкәч, кечкенә тәрәзәдән төшкән сыек яктылыкта мунча эчен карады. Буралары — кызудан һәм төтеннән ысланып каралган, тәрәзә төбендә мунчала, сабын кисәге һәм куыксыз лампа бар. Идәндә — ләгән, почмакта — салкын су мичкәсе, шуның янында идәндә чүмеч ята,— әлбәттә, яньчелеп-тишелеп беткән иске чүмеч инде ул... Киньягулов үз авылларына кайткан да үз мунчасында ята кебек хис итте, мунчадан чыгып, ишегалдына керә торган ян капканы ачса, малайлары, хатыны һәм әнисенең тавышларын ишетер кебек тойды. Аулак мунча эчендәге тынычлыкка, рәхәтлеккә бирелеп, татлы истәлекләренә чумды. Өйләнеп туй иткәннән соң беренче тапкыр хатыны белән мунча керүләре, икәүдән-икәү генә

ялангач калгач, бер-берсеннән оялулары, бер-берсенә карамаска тырышулары исенә төште... Аннары инде икәү мунчага керү тән сорап торган рәхәт бер гадәткә әйләнде. Башта хатыны балаларны юындыра, ә ул аларны юрганга төреп өйгә илтә дә шуннан соң үзе керә. Җылы мунчага кереп, ялангач хатынын күрүгә, бөтен тамырларында дәрт уяна иде. Баш астына себерке салып, ләүкәгә яталар, бер-берсен иркәләп яратышалар. Аннары эссе салып чабыналар, чабынганнан соң, ашыкмыйча гына, тегене-моны сөйләшкәләп, я бөтенләй сөйләшми генә юыналар, аннары тагын тәннәре кып-кызыл булганчы чабыналар, идәнгә ятып хәл алалар... Мунчадан чыккач, ул салкын әйрән яки кымыз эчә иде, сәкегә йомшак мендәр салып, сузылып ята торган иде... Чын булды микән ул хәлләр? Моннан соң да күреп булыр микән шуны?!.

Каты итеп төрткәнгә Киньягулов уянып китте. Башта ул үзенең кайда икәнлеген, ярым караңгыдан үзенә ачулы-шикле күзләрен төбәгән кешеләрне аңгышмый торды. Аннары авыл башына җиткәч, каты янгырга эләгүен, яңгырдан качып кемнәрнеңдер мунчасына керүен исенә төшерде. Исенә төшерү белән дерт итеп сискәнеп китте: мунча ләүкәсендә йоклап ятып, ул күпме вакытын әрәм иткән, ничә чакрым юлын кайтмый калган бит!.. Киньягулов тиз генә ләүкәдән торды, итекләрен киеп алды да, мунчага кереп тулган кешеләрнә этә-төртә, ишеккә омтылды. Ләкин кешеләр аны тотып калдылар. Базардагы каракны тоткан шикелле, каты итеп эләктереп алдылар. Киньягулов аларны танып калырга тырышты: берсе — кара постау китель кигән, уң күзенә ак төшкән, таза куллы яшь кенә ир, икенчесе — башына иске тула эшләпә кигән, битен сакал баскан, олы яшьтәге ир, ике малай һәм бер хатын да бар иде. Бу кешеләр ашыга-ашыга нидер сөйләнәләр иде, тик Киньягулов аларның тавышларын ишетмәде. Барысыннан да бигрәк, Киньягуловка ачулы күзләре белән кадала-кадала, әлеге хатын кычкырына иде. Киньягулов аларга карышмады. Аны мунчадан алып чыгып, ишегалдыннан уздырдылар да урам буйлап каядыр алып киттеләр. Күзенә ак төшкән таза куллы ир белән эшләпәле карт ике яктан аны беләкләреннән кысып тотканнар. Хатын белән малайлар арттан килә иде. Капка төпләреннән картлар, карчыклар, хатыннар һәм бала-чага Киньягуловка әллә ничек ятсынып карап калдылар... Чит авылга барып, гомерендә бер тапкыр да кеше мунчасында качып ятканы һәм үзен ристан урынына урам буйлап алып барганнары булмаса да, Киньягуловка бу хәл дә гаҗәеп таныш кебек, аны ул кайчандыр кичергәне бар кебек тоелды. Кинәт шунда хатынының бер хатында язганы исенә төште: күрше Афзалларның мунчасына хезмәт армиясеннән качкан бер кеше кереп кунган, шул кеше таулар аша үтеп, Урта Азия ягына китмәкче булган, дип язган иде. Күрше Афзалның хатыны Салиха, иртән мунчаларына кергәч, әлеге кешене күреп коты алынган, кычкырып кешеләр чакырган, ди; бу кешене тотып авыл Советына илткәннәр, аннары районга алып киткәннәр...

Киньягуловны ниндидер конторга алып килделәр,— авыл Советына түгел, бу кечкенә генә бер авыл иде, авыл Советы күрше авылда иде. Бәлки бу контор — колхоз идарәседер: Киньягулов ишек башындагы язуга карамады. Ләкин бу контор да аңа бик таныш кебек, таныш кына да түгел, нәкъ үз колхозларының идарәсе шикелле булып тоелды: Себергә сөрелгән кулак яки мулладан калган алты почмаклы, калай түбәле таза гына йорт, бер почмагында калай белән тышлаган түгәрәк мич; тынчып беткән әче тәмәке исе, кәнсәләргә хас кәгазь, келәй, тузан исе; стеналарына портретлар элгәннәр, иске стена сәгате, шкафлар, өстәл өсләрендә кәгазь, счет, мәрмәрдән ясалган кара савыты һәм пресс-папьелар. Эшләпәле карт белән «төймә күзле» яшь ир өстәл артына кереп утырдылар да бүлмә уртасында басып торган

Киньягуловка түрәләрчә бер кыяфәт белән карадылар. Төймә күзнең гайрәтле какча йөзе белән кара постау кителе дә Киньягуловка бик таныш сыман тоелды. Шунысы гаҗәп: ул хәтта сугыш алдыннан бу кешенең уң күзе чык суында юылып елтырап торган карлыган төсле чем-кара булганлыгын, дөньяга комсызланып, кешеләргә — майландырып һәм оятсыз итеп каравын да белә, алай гына да түгел, бу кешенең солдат өчен иң кирәкле уң күзенә тырнак очы белән кырып ак төшергәнен һәм хәзер, бер күзе күрмәү сәбәпле, сугыштан котылып калгач, хатыннар, картлар һәм бала-чагага баш булып ятуын да белә иде. Киньягулов бу кешегә нәфрәтен яшермичә батыр карады. Немец «тигр»ларыннан да курыкмаган, әле яңа гына кан исе, янган кеше ите исе аңкып торган сугыш мәхшәре эченнән чыккан Киньягуловка фронтовиклардан уттай курыккандай куркучы, хатын-кызларга баш булып ятучы бу тыл түрәсе бик көлке һәм беткән бер кеше булып тоелды. Ул, әшәкелеген, астыртынлыгын уң күзендәге ак тап астына яшергән хәлдә, түрәләрчә туры, батырып карый торган сул күзен Киньягуловка төбәде, аңа нәрсәдер әйтте, нәрсәдер кычкырып сорады шикелле, тик Киньягулов берни ишетмәде. Аның ни сораганлыгы болай да аңлашыла: кайдан киләсең, кая барасың, нигә мунчада качып яттың, янәсе? Киньягулов, аңа җавап бирмәкче булып сүзен әйтә башлауга, үзенең сөйләшә алмавын белде, сүз әйтергә кирәкле тел һәм башка әгъзаларының үзенә буйсынмавын тоеп, йөрәгенә курку йөгерде. Ул үз тавышын үзе ишетмәсә дә, теге төймә күз белән картның сәерсенүләрен күреп, үзенең кеше төшенерлек бер сүз дә әйтә алмаганлыгын аңлады. Төймә күз боеручан бер төс белән кулын сузып документлар сорады. Киньягулов гимнастерка кесәсеннән бумажнигын чыгарып тегеңә бирде. Төймә күз бумажниктагы төрле кәгазьләрне, иске хатларны актарып карады, күн эченә төреп теккән өч почмаклы бөтине күргәч, авыз кырые белән генә көлеп куйды, бер дә исе китмәгән кебек акчага күз төшерде, аннары кызылармеец кенәгәсен табып алды. Бик игътибар белән тикшереп чыкты, шулай-шулай дигән сыман баш каккалады һәм канәгатьсез бер төс белән Киньягуловка сыңар күзен төбәде дә, сөякчел яңакларын, ирен һәм телләрен тиз-тиз хәрәкәтләндереп, нидер әйтергә кереште. Киньягуловның аңлавынча, ул командир имзасы куелган, печать сугылган тагы ниндидер кәгазь сорый иде, ахры. Киньягулов бүтән бернинди кәгазем юк дип башын селкеде. Төймә күз аңа тагын нәрсәдер кычкырып әйтте, моңа каршы Киньягулов, ишетмим дигән мәгънәне аңлатып, кулын колагы янына куеп селкеде, башын чайкады... Киньягуловның башта үз-үзен сабыр тыныч һәм горур тотышы әкренләп аптырау, өметсезлек белән алмашынды, моңарчы төймә күзле кешегә ул нәфрәтләнеп, җирәнеп караган булса, хәзер түрә кеше каршында ялагайланган, аңардан шүрләгән сыман иде. Таулар арасындагы бу авылда бер күзенә ак төшкән әлеге кеше Киньягулов өчен министр да, маршал да иде — кодрәтле власть дигән нәрсәнең бердәнбер вәкиле иде. Менә Киньягулов аңа хөрмәтихтирам белән карый башлады, әлеге түрә кеше аны теләсә ни эшләтә алачагын аңлагач, Киньягулов үзен көчсез, чарасыз бер кеше итеп, хәтта ниндидер гаебе дә бар кебек тойды. Һәм гарьлегеннән тавышсыз гына үксеп-әрнеп елап җибәрде. Төймә күз, Киньягуловка кызганып-җирәнеп карана-карана, эшләпәле карт белән нәрсәдер киңәшеп алды, аннары бумажнигын кире кайтарды да, бар кит! — дигән шикелле, ишеккә таба кулын изәде. Киньягулов, бәладән котылуына ышанып та бетмәстән, ишеккә таба борылды, беренче адымын атлауга ук күңелендә «котылдым!» дигән шатлыклы уй чагылып китте, һәм шул ук вакытта йөрәген хурлык тойгысы көйдереп алды,— шушы адәм алдында горурлыгын саклап кала алмады, үзен-үзе кимсетте бит! — тагын бер адым атлады һәм идәнгә дык итеп нидер килеп төшкәнне

тойды, ялт кына әйләнеп карады: идәндә, аның аягы янында алсу кәгазьле пресс-папье ята, ә төймә күз Киньягуловка мыскыллы гына елмаеп карап тора, теге карт та чыраен сыткан; тышкы яктан тәрәзәгә малайлар килеп өелешкән — алар да кызыксынып карап торалар иде. Киньягулов берничә секунд аптырап пресс-папьега карап торды, аннары карашын өстәл янында утыручыларга күчерде. Һәм шунда гына аның аңына барып житте: төймә күз аны алай ансат кына чыгарып җибәрергә уйламый икән! Киньягулов ишеккә таба киткәч, ул юри идәнгә пресс-папье ыргыткан — янәсе, ишетерме-юкмы, ишетсә, әйләнеп караса — димәк, симулянт бу кеше. Киньягулов пресс-папьеның идәнгә бәрелүен аягы белән, табаны белән тойды бит...

Шул чагында Киньягуловның күңеленә кылт итеп: пилоткамны салып, бу адәмнәргә ярамны күрсәтим дигән уй килде. Пилоткасын тотып тартып карады — салынмады, катырак тартуга — ярасы авыртып китте: пилоткасы ярага бик нык ябышып каткан, аны ярасын каплаган кан касмагы белән бергә генә куптарып алырга мөмкин иде. Киньягулов, ни булса — шул! дип, пилоткасын башыннан йолкып алды һәм үзәккә үткән әрнүдән күз аллары томаланып китте. Күз алдын каплаган аллы-гөлле томан таралуга, төймә күз белән картның көлдәй агарынган йөзләрендә һәм шардай ачылган күзләрендә... үзенең чәрдәкләнгән башын, ярасыннан чыгып сулкылдап торган коточкыч канлы миен күрде... Ул арада каяндыр бер хатын, йөгереп килеп, Киньягуловны урындыкка утыртты, башына бинт урады һәм шуның өстеннән пилоткасын кигезеп куйды. Аннары аны иплэп кенә урамга алып чыктылар. Баскыч төбендә таза-көр алмачуар айгыр җиккән арба тора иде. Киньягуловны арбага утырттылар, берни җәймәгән каты арбага бик җайсыз утырды ул. Төймә күзле кеше каяндыр бер иске сырма белән чалгы алып килде, сырманы Киньягулов астына тыкты да чалгыны арба артына куйды, аны киндер җәймә очы белән каплады, үзе дә шул җәймәгә утырды, һәм алар кузгалып киттеләр. Авылны чыккан чакта Киньягулов капка төбендәге карчыклар һәм бала-чаганың үзенә кызганып карап калуларын күргәч, йөрәге әрнешеп-әрнешеп сулкылдады. Авылны чыгып, тыныч һәм битараф табигать эченә кергәч кенә хәле җиңеләя башлаган кебек булды.

Ул үзен ат белән алып китүләренә каршы килә алмады. Балаларымны да, әнине дә, хатынымны да күрмичә, госпиталь топчанында үләрмен инде дип эченнән генә кайгырып уйланды. Күңел түрендә каядыр еракка китеп онытыла башлаган газиз кешеләренең йөз-сыннарын күз алдына китерергә тырышып, хәтер истәлекләренә чумып бара бирде...

Төймә күз чыбыркысын уйнаткалап айгырга селтәштереп ала. Аның чыраенда баягы түрәләрчә кырыслыкның әсәре дә юк. Гадәттәге хәйләкәррәк кыяфәтле, хатын-кыз белән аракы ярата торган гади бер авыл егете булып калган иде ул. Киньягуловка ул риясыз, хәтта дустанә елмаеп карап ала: менә бит без нинди, янәсе, күрдеңме: кирәк булса, фронтовик солдатка ярдәм итәргә һәр вакыт әзер, кечкенә бер аңлашылмаучылык кына килеп чыкты, янәсе, син инде, солдат, ачуланма, имеш. Киньягуловка тагын бу төймә күзне кайдадыр күргәне бар шикелле, хәтта аны белә, аны яратмаган-өнәмәгән иде кебек тоелды, ләкин кайда күргәнлеген, исеме ничек икәнлеген хәтерли алмады.

Юл, зур бер чокырны уратып, уңга, район үзәгенә таба борылды. Олы юл буйлап район үзәгенә чаклы — ун чакрым, шуннан соң Киньягуловлар авылына хәтле егерме биш чакрым ара кала. Шушы тирәдә олы юлдан бик күптәнге кечерәк бер юл аерылып, тау сырты аша турыга китә. Ул юл белән китсәң, Киньягуловлар авылына унбиш

чакрымнан артык түгел. Юк шул инде, Киньягулов ул юлдан бүтән кайта алмас...

Борылышта төймә күз атын юлдан читкә чыгарып туктатты, аркалыкны чиште, айгыр сутлы яшь үлән ашарга кереште; төймә күз үзе арбадан чалгысын алды да юлдан эчкәрәк, урман кырыена — үлән биегрәк һәм куерак булып үскән төшкә китеп, үлән чабарга кереште. Кәкре ботларын ерып баскан килеш, чалгысын киң-киң селтәп, әйбәт чаба иде ул. Аның үлән чабуы — бик яхшы, утырып барырга йомшаграк булыр, ятып ял итәргә дә әйбәт булыр, дип уйлады Киньягулов. Төймә күз үлән чапкан арада, Киньягулов арбадан төшеп, тышка чыгып алырга булды. Арбадан төшкәч, тирә-юньгә караштырып басып торды. Таныды ул бу тирәләрне: әнә чак кына тегендәрәк алар авылына кайта торган юл. Үләннәр үсеп беткән иске бер юл ул. Киньягуловның йөрәге ашкынып-каушап тибәргә тотынды. Төймә күзгә карады: төймә күз, ана таба аркасы белән баскан килеш, һаман үлән чаба иде әле. Тагын берничә тапкыр селтәнгәннән соң ул чабуыннан туктап, үләнне арбага ташый башлаячак. Шул вакыт Киньягулов гомерендә булмаганча алдашырга, хәйлә корырга уйлады. Ул, чалбар каешын ычкындыра-ычкындыра, ашыгып кына юл аркылы урман ягына чыкты. Нindидер коточкыч бер упкын яныннан китеп барган кеше кебек тойды ул үзен: менә тагын бер адым атласа, тагын бер адым, иплэп-иплэп! Чак кына ялгыштымы — кире, упкынга, мәңге кайтып булмаслык җиргә китәчәк. Шул рәвешчә ул юлны аркылы чыгып, урманга керде, әйләнеп карады: төймә күз үлән чабуыннан туктаган, иелеп, кочагына үлән җыя иде. Йөгерергә, качарга кирәк!.. Һәм Киньягулов ялт кына атылып агач арасына йөгерде. Бар булган көчен туплап йөгерде. Аның тыны бетте, шабыр тиргә батты, башы әйләнгәнгә аягында көчкә басып калды. Артында, якында гына төпсез упкын барлыгын, үзен куа килгән атның тоягы дөпелдәгәнен, җилкәсенә кайнар сулышы бөркелгәнлеген тоеп йөгерде. Юлдан эчкәрәк, эчкәрәк китәргә, төймә күздән ераграк качарга кирәк!.. Киньягулов нарат урманы аша йөгереп узып, иркен бер ачыклыкка — урман кисентесенә килеп чыкты, аннары каен урманы эченнән йөгерә торгач, теге иске юлны тапты, ләкин юлга чыкмады, аннан ерак китмәскә тырышып, урман эчләп кенә йөгерде. Ахырда, тәмам хәлдән таеп, агачка килеп капланды, артына әйләнеп карады: аны куа килүче юк икән... Әйләнәтирәсендә тоташ таулар калкып тора, тау битләрендә каты җилдә яшел дулкын сыман булып урманнар чайкала, урман өстендә салмак кына канат кагып ялгыз козгын оча, иске юлның як-ягында юеш үлән һәм чәчкәләр өстендә, аллы-гөлле нурлар уйнатып, янгыр тамчылары җемелдәшә, ләкин юлның үзендә, төймә күз калган төшкә — олы юлга хәтле бер җан әсәре дә күренми иде. Киньягулов бераз хәл җыеп басып торды да әкрен генә китеп барды. Шушылай ансат кына котыла алуына бик сөенде ул, йөрәгенә янадан өмет җылысы кайтты.

Тау итәгендә бер чишмә очратты. Су эчим дип, кечкенә генә чокыр эчендәге чишмә өстенә иелде һәм шунда үзенең шәүләсен күрде. Тик үз-үзен бөтенләй танымады ул: аның битләре җир төсле кап-кара булган, кутырлап-касмакланып каткан, ямьсез булып сакал-мыек баскан. Ачлык, хәлсезлек, ярасы сызлавы аның битендәге бөтен итен суырган, һәм юка гына тире астыннан баш сөяге бик котсыз, килбәтсез булып беленеп тора. Тик Киньягуловның эчкә баткан хәлсез күзләрендә генә, кайгы-хәсрәт һәм газап-михнәт пәрдәсе белән өртелеп, сүнәрсүнмәс бер чаткы елтырый иде.

Чишмә янында туктап хәл алганнан соң, Киньягулов тагы китте. Хәзер инде ул тауга менә башлады, шуңа күрә аның адымы кыскара төште, гәүдәсе дә туган авылы ягына таба әкренрәк бара иде хәзер. Киньягулов куркып-пошынып урманлы тау түбәсенә күз салгалады:

анда караңгы кыялар арасында кара болытлар тулгана, шыксыз тау җилләре сызгыра иде. Төн җиткәнче тау түбәсен үтә алса, аннары тауга түбән атлавы да җиңелрәк һәм күнеллерәк булыр иде...

Шуннан соң ул бүтән берни уйламады, кайгырмады да, үкенмәде дә. Ул фәкать йөрәге тибүен, башындагы ярасы сулкылдавын, гәүдәсе авырлыгын, аяклары арыганлыгын һәм эчәсе килеп бик сусавын гына тойды. Бөтен көчен, бөтен игътибарын ул гәүдәсен туры тотып, алга таба аягын атлауга гына юнәлтте. Вакыт-вакыт ул аяк өсли оеп йоклап киткән яки һушын җуйган шикелле дә була иде...

Аннары ул болытлар эченнән атлады. Астан алар тоташ булып, тыгыз булып күренгәннәр иде. Ә якыннан күргәч, эчләренә кергәч, бу болытлар гади бер томан гына икән, шундый куе томан — ун адымнан берниндн агач күренми, энә очыдай вак кына су тамчылары Киньягуловның киеменә утырды. Аңа юлының буеннан-буена диярлек томан эченнән барырга кирәк, чөнки юл тауга каршы борыла-сырыла сөзәк итәкләр буйлап менә, кыя ташларны, упкын җирләрне, әрәмәлекләрне әйләнеп уза, аннары, тураеп хәл алган шикелле, тау сыртының түбәсеннән үк үтә дә ашыкмый гына үзәнлеккә төшеп китә иде. Хәзер инде Киньягулов таулар аша туры гына китүенә үкенә дә башлады.

Тау түбәсенә менеп җиткәндә генә төн килде — соры томан пәрдәсен үзәнең дөм-караңгы япмасы белән каплап алды, әйләнә-тирәдәге бушлык корым төсле кап-кара, яссы-тәбәнәк һәм хәтта тыгыз бер нәрсәгә әйләнде. Киньягулов, агачка бәрелмәгәем, берәр ботакка төртелмәгәем дип, кулын алга сузып, юлны аяклары белән капшый-капшый, сакланып кына атлады... Шуннан соң аның аяклары такыр юлны тоймый башлады, тоташтан йомшак үләнле җир китте. Үлән ерып шактый озак барды ул, менә-менә хәзер юлны табам дип өметләнде, ләкин юл күренмәде. Шунда гына ул үзенең юлдан язганлыгын аңлады. Башта ул, юлдан сулга чыкканмын дип, уңга таба китте. Анда да бөтен җирдә бил тиңентен юеш үлән икән. Шуннан соң ялгышканмын, юлдан уңга чыгылган булган, тагы да ераграк киткәнмен дип уйлады һәм кирегә китте, ләкин үзенең кире якка, кирәкле якка баруына ышанып җитмәде. Биек үлән арасыннан йөз адым чамасы үткәч тә, берниндн юл тапмады, аякларына очы-кырые күренмәгән биек, юеш үлән генә уралды. Киньягуловның йөрәгенә курку төште. Караңгы бер тыгызлыкта ул арлы-бирле сугылды, агачларга, очлы ботакларга барып төртелде, куллары белән үлән арасын капшап карады, аннары искәрмәстән абынып китте дә күкрәге белән йомшак, калку бер нәрсә өстенә егылды: кырмыска оясына егылган икән, Урал урманнарындагы әчкелтем ис, җылы бөркеп торган гади бер кырмыска оясы. Шушы йомшак, тере түмгәккә яткач, Киньягулов тынычланып китте: сугышның нинди генә тамашаларын күрмәдем, нинди мәхшәрләрендә булмадым — анда да куркып калмадым, ә монда, туган авылымнан ун гына чакрымдагы таныш урманда, малай-шалай шикелле, караңгыдан, юлсыз адашуымнан шүрләп калдым, дип фикер йөртте. Тау бите буйлап аска таба төш тә төш, берәр юлга яки ачык кырга чыкмый калмассың. Шулай дип җирдән торды да аска таба төшеп китте, бик сакланып, кармалана-кармалана гына атлады: кыя кырыена килеп чыгып, упкынга төшеп китүеннән курыкты. Ауган-сынган агачлар, куе чытырманлыклар аша үтте, зур-зур ташларга, агачларга килеп төртелде, юеш үлән арасыннан мүкәйләп тә, яны белән ятып та шуышты, тау түбән арты белән шуып төште, упкын кырыенда үләннәргә, куакларга тотынып калды, яңадан югарыга үрмәләп, текә ярлы урыннарны әйләнеп узды. Вакыт-вакыт хәле бетеп җиргә ятты да хәрәкәтсез торып вакытын әрәм итмәс өчен әкрен-әкрен аска таба тәгәрәде... Ниһаять, бик озак вакыттан соң ул дөм-караңгы бушлыкның аз гына соргылтлана һәм киңәя башлавын, өстәге кара-кучкыл агач

ябалдашларының аермачык күренүен шәйләде: әллә инде яктыра башлады, әллә Киньягулов болытлар эченнән чыкты. Шуннан соң ул кинәт ачыклыкка килеп юлыкты: монысы урман кисентесе икән. Киньягулов күз алдында үзенең туган ягын — Урал аръягындагы җирләрне: тәбәнәк кенә яшел тауларны, күнелгә ямь биреп торган ап-ак каенлыкларны, еракларга китә-китә Азия далаларына әйләнә торган киңиркен иген кырларын күрде; хәзергә әле каршыда таныш басулар, таныш таулар күренмәсә дә, ул туган җиренең дымлы сулышын бите белән тойды, күкрәген тутырып аның татлы исләрен иснәде. Еракгагы кара-кучкыл офыкка текәлеп карый торгач, кинәт җирдә энә очы кадәр генә якты нур күрде. Бу нур караңгыда елт итеп кабынды да сүнде. Бәлки бу — авылдан, берәр кеше тәрәзәсеннән күренгән ут булгандыр. Киньягулов утны шәйләгән вакытта әлеге кеше лампасын өреп сүндергәндер, я булмаса, ерактагы юлдан машина узгандыр да урман яки тау артыннан фара яктысы чагылып киткәндер, бәлки төнлә эшләүче трактор калкулык артына борылып киткәндер... Ләкин әлеге якты нурның күренүе чын иде... Ут булган җирдә кешеләр бар, тормыш-тереклек бар. Хәзер инде Киньягулов адашмаячак, туп-туры утка таба китәчәк. Һәм ул, тормыш-тереклек чаткысы күренгән юнәлештән язмаска тырышып, урман кисентесе буйлап аска төшеп китте. Кисентене узгач, тагын урман эченнән атлады. Кайдадыр шушы тирәдә генә юл булырга тиеш. Киньягулов аның якын булуын сизә, тик агачлар һәм үлән арасыннан аны таба гына алмый. Хәзер инде ул әйләнә-тирәсендәге агачларны аермачык күрә, каенны усактан аерып була. Наратлык эчендә караңгы иде, каенлык эче яктырак икән: каен агачларыннан көмеш нур сирпелеп торган шикелле. Бая дөм-караңгыда күренмәгән үлән дә куе яшел булып шәйләнә башлады. Җәйге кыска төн бетеп бара. Озакламый сары таң яктысы бу ямьсез төн караңгысын куып алып китәр дә ерактагы томан эченнән таныш калкулар, басулардагы таныш юллар килеп чыгар. Тау түбәсенә менгәндә тәмам арган, хәлдән тайган Киньягулов әнә шул өмет белән генә аягында басып тора, ул инде үзенең исән калу-калмавы турында уйлый алмастан, ярым түнгән хәлдә, алпан-тилпән атлый иде.

Биек, юан агачлы урман әкренләп вак каеннарга күчте. Аяк асты юешләнде, Киньягуловның ялан аяклары җылы саз суында чупырдый башлады. Аннары аяклар мамык шикелле йомшак, сыгылмалы-тирбәнчек мүкне тойды. Аяк басуга, мүк йомшак кына булып батып китә, аның астыннан саркылып су чыга иде. Каеннар шактый сирәгәйде, алар хәзер түмгәкләр өстендә генә үсеп утыра, түмгәкләр арасында кара-кучкыл су. Шуннан соң каеннар бөтенләй бетте — түмгәкләр генә калды. Бу түмгәкләр биек-биек, өсләренә чәч шикелле булып күрән үскән. Түмгәкләр арасында — аяк баскан саен шупырдап бата торган сыек торф баткаклыгы. Киньягулов үзенең кеше аяк басмаган кыргый бер сазламыкка кереп барганлыгын күнеленең бер почмагы белән сизенсә дә, кире артка борыла алмады, ул турыда уйламады да. Атлаган саен өйгә якынаям дип, ул гел алга баруын гына белде. Озакламый сазлык бетеп, каты җир башланачагына ул ышана иде. Менә аның аягы болын юлына чыгып басар да шул юл белән ул туп-туры туган авылына кайтып керер... Су инде аның биленә житте, Киньягулов түмгәкләргә килеп төртелде, пычак кебек үткен кырлы күрәннәргә тотынды. Бу үлем сазлыгын тизрәк ерып чыгыйм дип, гел алга, һаман алга омтылды... Шуннан соң су күкрәк тинентен булды, һәм Киньягулов: «Бу бит Торна баткаклыгы!» — дип сөенеп уйлап куйды. Ана урман кисентесеннән уңга китәргә, Шарлавыклы елга аша чыгарга кирәк булган икән. Шуннан авылга бер генә чакрым кала: таныш болын юлы белән китеп ферма янынннан узасы... Киньягулов аякларын арлы-бирле китереп басар-таяныр җир эзләде, ләкин аяк-

лары төпсез, салкын баткаклыктан башка нәрсә тоймады... Су аның муенына җитте... Киньягулов кара сазламык авызында җан ачысы белән тыпырчынып кулларын селтәнде, аяклары белән тибенде, торф боламыгын, мүк һәм түмгәк кисәкләрен кулы белән ишеп-эткәләп җибәрде. Шушы талпыну-тыпырчынуга ул иң соңгы тамчы көчен бирде. Тончыкмас өчен башын артка каерды һәм тәнендәге тереклеккә колак салып тынып калды. Күкрәк читлегендә дөп-дөп итеп, буылып-кысылып йөрәге тибә, бөтен тәнен күңел болгаткыч бер хәлсезлек баскан иде... Ул үзенең инде моннан котыла алмаячагын, үләчәген сизә иде, гомеренең соңгы мизгелендә күз алдына балаларын, хатынын, әнисен китерергә, күңеле белән аларның газиз йөз-сыннарын күрергә теләде, әмма аларны күңел түрендә бик еракта, әллә нинди таныш булмаган бер яктылык эчендә, ниндидер киртә аръягында, чит-ят сыман итеп, томан эченнән генә күрде... Шуннан соң кинәт аның колагы тавыш ишетә башлаган кебек булды, туган авылында таң әтәчләре кычкыра сыман тоелды... Һәм аның сүнеп барган аңыннан, соңгы тапкыр, нур шикелле булып: «Барыбер кайтып җиттем, барыбер туган җиргә кайтып җиттем, өем янына...» дигән уй сызылып үтте...

65 нче гвардия полкының дүртенче ротасы, беренче взвод рядовое, Башкортстанда туып үскән Киньягулов Гайса, башы каты яраланып, операциядән соң аңына килә алмыйча, әнә шулай кыр госпиталендә вафат булды...

ЯХЬЯ ХАЛИТОВ
тәрҗемәсе

# Әнвәр Давыдов

Шагыйрь архивыннан

●

Галәмнәргә хатлар язу — гадәт,
Гасырларга —
сайлап ерагын.
Ә мин исә менә
иң-иң якындагы
Көн алдында каушап торамын.

Очрашу бар алда,
замандашыма
Яңа шигыремне укыйсы...
Нинди кайтавазлар ишетермен?
Ничек тыңлар мине ул кеше?
1967

●

Бу дөньяның чиксезлеген беләсезме?
Күпме анда хәрәкәт бар, күрәсезме?
Шатлык, кайгы, үлү, туу, газаплану
Һәм кояшлы көндә күңел канатлану,
Сөю, көнләү, ышану һәм өмет өзелү,
Зәңгәр күктә болыт куерып яшен сызылу...
Шагыйрь сыйдыра йөрәгенә мең дөньяны.
Шуңа, дуслар, гаепләмәгез сез аны,
Алмаштырса шатлык җырын кайгы моңы,
Уйламагыз шагыйрьнең дип тайпылуы.
Ничек юлдан тайпылсын ди ул дөньяда,
Дөнья үзе булгач аның йөрәгендә?!
1957

## Нева ярында

Болытлы көн. Көзге Нева салмак кына
ага. Гүя маңгаеннан сайлап куа
җыерчыгын иң дәһшәтле кичерешләрнең.
(Кайгырта ул: исемә төшсә, мин нишләрмен?)
Булдыралмый. Судагы вак-вак дулкыннар
өелә миңа сырлы-сырлы көртләр булып.
Ыжгыра җил, әче буран битне кисә.
Бомба, ядрә улаулары җанны өзә.

Шул давылда Нева өстендә кара нокта...
Тагын... тагын... Торбаларда су да юк ла! —
Ач корсакны юатырга су да бара,
Башкаларга ияреп, чана сөйри бала.
Ярны менә. Тик... тагын көрт... торып булмый...
Ярдәмгә бер карт... егыла... икесе битендә кар уйный
Мин ерактан күрәм моны, аргы яктан —
Волховтан мин ярсып-ярсып ядрә атам...
һәм ашыгам монда таба... «Соңладым!» дим...
Бәлки бүген нәкъ шул җирдә торамдыр мин.
Невадагы вак дулкыннарның ярсуы
Шул баланың бәлки соңгы ыңгырашуы...
...А, ул көннәр хәзер ерак тарих инде.
Шәһәр балкый. Киң урамнар көтә мине.

1965—67

●

Иркәм,
Синең сурәтеңне
Ничек дөресрәк коярга?
Художниклар рәсем ясау өчен
Ара кирәк диләр тоярга.
Ә мин сине
Тик бер тапкыр гына
Күрдем бугай ерак арадан:
Без ул көнне, ашыгыч чакыру алып
Ватан-анадан,
Ерак юлга, авыр сугышларга
Бөтен авыл белән җыелдык.
Безнең күңелләрне көрсендерде
Илдә калганнарга кыенлык.
Күпме бетермәгән эш калды бит
Безнең сөекләләр өлешенә...
Озын обоз белән күтәрелгәч
Шау каенлы тауның өстенә,
Борылып карап тордык басуларга,
Каршы тауның аксыл ташына,
Аллы-гөлле чәчкә кыры кебек
Дулкынланган авыл башына.
Анда — картлар, безнең кадерләләр,
Сөекләләр, газиз аналар
Июнь кояшыннан кайнаррак
Ачу хисе белән яналар.
һәм һәр кеше кайнар теләк тоя
Кушылырга безнең төркемгә,
Изге үчнең сусавына бирелеп,
Онытып тора тирен сөртергә...
Күкрәгеңдә ялкыныңны саклап,
Син дә калдың шунда, аппагым.
Сугыш елларында күңелемдә мин
Шул күренешне һаман сакладым.
Бүген янәшә без. Син нинди матур —
Җирдән күтәрелгән томанда
Бодай кыягында чык бөртеген
Карап, уйга талып торганда...

1947

•

Яхшы кеше, яхшы дус син үзең,
Ләкин, менә, әйтим дөресен,
Гаҗәпләнәм, нигә син үзеңне
Шагыйрь диеп атап йөрисең?

Дөрес, күңелеңдә бар кайбер уйлар,
Ни әйтсәң дә инде күңел бит,
Күлнең дә бар суы, дулкыннары,
Барыбер ул диңгез түгел бит!

1953

## 3. Мансурга

Кичер, бармадым күмәргә.
Тыным бетә соңгы көннәрдә.

Бер «высота» өчен сугыша идек...
Күптән тынган сугыш утлары
Шунда безне һаман кыса барды,
Үрләдек без әмма югары.
Ядрә бүген синең өскә төште.
Шартлау дулкыны миңа кагылды.
Менәрмен мин, дустым, «высота»га
Йөрәгемдә саклап исән чагыңны.

12 ноябрь, 1965

## Дусларның портретлары

С. Хәким

Төрле була күзләр —
карап туялмыйсың:
Зәңгәр күл төслесе,
тирә-ягы керфек урманы.
Ә моңарда —
Бер энә очына җыелган
Бөтен җирнең кояш нурлары.
Ул текәлә синең күзләреңә,
Үз соравы аның, үз уе...
Дус өчен дә, дошман өчен дә
Карамыйча аңа
мөмкин түгел узуы.
Гадиләрдән,
Ләкин үз хәйләсе белән
Ул
бу Казан арты кешесе.
Иң зур уе — үткен киссен өчен
Иртәгәгә пычкы тешисе.
Трибунадан аңа кидерәләр төрле таҗлар...
Күтәрми лә борынын шул чагын.
Күбрәк сүгенүен ишетәм мин:
— Эшләү кирәк!
Калганында нәрсә пычагым!

Төрле күзләр була:
Зәңгәр күл төслесе,
тирәсендә керфек урманы...
Ә моңарда —
Бер энә очына җыелган
Бөтен җирнең кояш нурлары.

1964

●

Исте җил,
Агач яфраклары
пышылдашып
көмеш тавыш белән

Көлештеләр.
Ә без —
бер үбештек синең белән,
бер
урман буйлап йөгерештек,
шаркылдаштык...

Җил китте,
урман тынды...
яшьлек үтте...
Әрни йөрәк!..

1963

●

Мин яратам сине, чөнки синдә
Садә бер матурлык күренә.
Аккош кебек талгын очып төште
Күңелемнең моңсу күленә.

1947

●

Яшел күлмәк —
Гүя яшел болын,
Шунда —
Кара елан кебек
Ике толым
Боргалана,
Үрмәли,
Сикерә
һәм ияртә сине
Сихерләп.

1957

●

Кара син, ә, һаман кабаланып
Үтеп бара бит, әй, тормыш та,
Ә мин һаман: үз өстенә алган
Йөктән арыналмаган кырмыска.

1964

●

Тагын башым томан белән тулды,
Урап алды тәнне авырлык.
Әйтер сүзләрем дә онытылды...
Бер булырмы чирдән арынып?!
Әнкәй миңа шундый йөрәк биргән,
Бу дөньяның күпме ялкыны
Аңа тулган, аңа үтеп кергән
Киң ачылган хисләр аркылы.
Тик бер юл бар аны бушатырга —
Ак кәгазьдә шигырь юллары.
Ләкин авыру тагын хәлне алды,
Тагын әйтеп бетереп булмады.
«Жар бар, диләр, градусник, диләр,
39 ны ук күрсәтә»,
Әйтеп өлгермәгән уйларым бит
Шулай янып ята күкрәктә!

1964

●

Синнән башка мин үземне
Шундый ялгыз тоямын,
Гүя галәм бушлыгына
Ташланган бер дөньямын.

1965

●

Сокланамын сездә мин шушыңа,
Ике агым бер ташкынга кушыла:

Сугыш күптән түгел беткән еллар...
Тын авылда сезне тыңладым.
Тол апалар үксеп тыңладылар
Мадам Баттерфляй моңнарын.

Аннан затлы концерт залларында
Аз булмады минем күргәнем
Сез җырлаган халык җырларына
Эстетларның да баш игәнен.

Халык моңы плюс бөек сәнгать.
Шушы изге канун — сезнең сәләт.
Сокланамын сездә мин шушыңа,
Ике агым бер ташкынга кушыла.

Ераклардан килгән моң агымын
Тоташтырасыз яңа чорга сез.
Меңнәр сезне тыңлый дулкынланып,
Я, Зөләйха, тагын җырлагыз...

1965

Хәким Хәйруллин

# УРГЫЛ

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Кайсыдыр кычкырып җибәрде:

— Эй, малайлар! Күрегез әле, күр! Җәй көне кар ява икән монда.

Малайлар, баржа идәненә җәелгән арыш саламын туздырып сикерешә-сикерешә, өске катка менеп тулдылар.

— Кар ява, кар!..

— Эх, чаңгы белән әнә теге таудан выжлатып кына бер төшәргә!

— Ну, бар икән күрәселәребез! Монда елның унике ае кыш, калганы гына җәй икән.

Якуп белән Хәмзә, яшь-җилкенчәкләрнең берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә гәпләшүләренә кысылырга кыймыйча, иренеп кенә төшкән җепшек кар бөртекләрен уч төпләренә аулап, шаккатып карап торалар. Чыннан да, нигә болай көз үтмәс борын кыш килә икән? Авылларда бу чакта бәрәңге дә казымыйлар бит. Әле генә бөркү иде, ә хәзер суык колакларны чеметтерә башлады. Сәер дә соң!

— Эх, шушы минутта авылда булсаңие! Малайлар сабакка йөриләрдер... Быел үзебезнең авылда сигезенче класс ачыла бит...

— Хәмзә, карале теге як ярга! Дөнья хәтле зур болын, житмәсә, сәкедәй тип-тигез. Әнә, ике кечтеки кыз казлар куалый. Болын тулы терлек-тару.

— Атлары да атлары! Гали батыр дөлдөлемени! — Хәмзәнең кинәт тавышы калтырый башлый. — Әни яңа арыш оныннан ипи салгандыр... Сөтләп чәй эчә торганнардыр...

— Еламасана! Өйдән чыкканыңа унөч тәүлек тә тулмаган әле. ФЗО ны тәмамлагач, мәҗбүри дүрт елыңны тутырырсың да, ошатмасаң — дүрт ягың кыйбла. — Якуп, баржа әйләнәсендәге терәккә күкрәге белән сөялеп, күзләрен аска текәде.

Һавага тамчылар чәчрәтә-чәчрәтә күбекләнеп ага елга. Исеме дә кызык, җисеменә бик туры килә: «Ургыл». Ургылып-ургылып ак,

янәсе... Алар ягындагы тын Ашыт елгасы түгел инде бу. Чын-чыннан ургып, ярсып, бөтерелеп ага. Ә нигә шулай татарча исем куштылар икән? Әллә якутлар кушканмы? Барасы шәһәр дә шулай дип атала, ди. Бәхет оялары әнә теге таулар астында түгел микән? Гарәфи абыйсы әйтә иде: шахтер авырлыкка баш имәс, җир астында аңа җил-буран тимәс, дия иде.

— Якуп, әй, Якуп! Безгә дигән шахта да шушы таулар астында микән? Өстенә ишелсә, тәбегә төшкән тычкан шикелле изелерсең, име.— Хәмзә дә сокланып тирә-якны күзләп барган икән. ФЗОга алмасалар, мондый шаккаттыргыч җирләрне кайчан күрә алыр идең.

— Җир астында йомран ничек, шахтер да шахтасында шулай йөри, ди, белдеңме? Юллар алда да, артта да, уңда да, сулда да тулып ята, ди, нәкъ экияттәгечә. Һәммәсе мич эчедәй тар, учактай кысан. Кайсысының исеме дә мич икән. «Турысына китсәң, бәхетеңне табарсың» дигәне бар Гарәфи абыйның. Кызыкмы? — Якуп бу сүзләрне дусты йотардай итеп, матур итеп сөйли.

Хәмзәнең эченә жылы кергәндәй итә, «шахта басып үтерми икән болай булгач» дип куя. Якуп кыза-кыза бәхәсләшкән малайлар ягына карап ала да дустына таба борыла: үзе тәбәнәк, үзе ябык, беләкләр көрәк сабыдай нәзек, муены тырпаеп тора, коңгырт күзләре эчкә батып кергән. Икесенең дә аякларында кирза ботинка, өсләрендә сырган бишмәт. Кайсыдыр тагын кычкырды:

— Кояш чыга, кояш!..

Бар нәрсә искитмәле икән монда: көтмәгәндә күбәләк-күбәләк кар ява башлый, аннары кояш чыга да, кылычтай нурларын сирпеп, малайларның туган якларыннан сәлам әйтә шикелле.

Менә шушындый кызык җирләр аша еракка, Ерак Көнчыгышка баралар алар. Мәгарәләргә кереп эшләргә туры киләчәк.

Аларны озата барган таза-озын гәүдәле рус кешесенең кичә: «Шахтада күмерне корычтай таза беләкле, батыр йөрәкле егетләр генә авызлыклый ала», дигән сүзләрен Хәмзә эчтән генә кат- кат кабатлый. Үзенең беләк сумнарын капшалап карый: «Песнәк чукырлык та ит кунмаган», ди дә борчыла. Ә менә Якуп — батыр, ичмасам. Сабан туе көрәшләрендә екмаган малае, аркылы йөзеп чыкмаган елгасы, сикереп төшмәгән ат чоңгылы калмый иде.

Әнә, авылдашы каршында теге кичәге кыз да басып тора, нигәдер авызын ерган була тагы. Татар кызлары шикелле колакларына бәләкәй генә алка таккан. Өздереп алган суыкка карамыйча, зәңгәр күлмәге өстеннән кигән кызыл кофтасының төймәләрен ычкындырып җибәргән. Кашлары да Якупныкы төсле кап-кара, нәзек, матур гына сызылып киткән. Бит очлары алмадай алсу — салкынга микән, әллә гел шулаймы?

Кичә һәммәсе өерелешеп төртешә-төртешә баржа эченә кереп тулды. Ә бу кыз көчәнә-көчәнә яр буеннан төргәк-төргәк китап, плакат, әрҗә ташый иде. Шул чакта Хәмзә йөгереп килде дә булыша башлады. Аңа Якуп та иярде. Алар кергәндә баржаның җайлырак урыннарын алып бетергәннәр иде инде. Кыз катерга кереп китте, ә Хәмзә белән Якупка бер читтә, түбәсез якта урнашырга туры килде.

Менә хәзер шушы кыз тел очын күрсәтеп малайлар арасына кереп югалгач, Хәмзә:

— Әй, кыланчык! Шар күз, житен чәч! — дип калды.

— Аның каравы, этисе — менә дигән шахтер. Кичә җыелышта ут чәчте, ишетеп утырдың ич.

— Исең киткән икән иске чикмәнгә! Күп сөйләгән — җир чүпләүчән. Карап торырсың менә — йомшак җәеп катыга яткызыр әле. Шахтасына кызыктыра ул безне, качып бетсәк, үзенә әләгәчәк.

Шулай сөйләшсәләр дә, икесенең дә колакларында кичә җыелышта ишеткән сүзләр чыңлый: «Шахтерның юлы туры, бәхеттер юлы тулы...»

Әйе, бәхет кемне генә кызыктырмый икән дә, кем генә аны эзләми икән! Чыга алырлармы шул бәхетле юлга, тота алырлар микән шул бәхетнең койрыгын?!

Уйларына чумып бара торгач, Хәмзә тагын телгә килде:

— Исеңдәме, икебезнең дә колакка киртеп җибәрделәр. Атка утыргач, әни сиңа әйтте: «Улымны караштыргалап йөр, яме, Якупҗан энем, син инде җиткән егет», дигәние. Ташлашмыйк, яме. Бары бергә, югы уртак булсын. Читкә-чотка кереп, адашып йөри башласак, туры юлга безне кем салыр?

Якуп исе китми генә әйтеп куйды:

— Әниеңнең сүзләре исемдә. Ә миңа теге абзый кичә «шушындый батыр егетләребез барында мәңгелек тун җирдә шәһәр калкып чыкмасмы соң» диде. Кызык, име? Безне генә көтеп ятканнар икән монда.

Бер көтү малай Хәмзә белән Якуп каршына килеп туктады. Кайсысының өстендә сырган бишмәт, берәүсендә кайры тун, башларында каты козыреклы картуз яисә колакчын бүрек, күбесенең аягында галош, кайберләре кирза итек кигән. Үзләре кызып-кызып гәпләшәләр, дәррәү кубып көлешеп алалар. Арада бер сипкеллесе Якуптан да озынрак күренә, бик кыю да, ахры. Шунысы әйтте:

— Әй, егетләр! Сез ат ите ашыйсыз, әйеме?

Якуп кыю гына:

— Ашыйбыз, әлбәттә. Сиңа шуны белү бик кирәкмени?! — диде.

Сипкелле малай иптәшләренә таба борылды.

— Ишетәсезме, йолкышлар? Ышанмаган буласыз.

Малайлар хихылдарга керештеләр. Хәмзәгә бик гаҗәп: ат ите ашауның ярамаган ни ягы бар икән? Ә бу, житен сипкән бит, миңа карамый да, кәтүк дип кимсетүедер. Әнә тагын тотынды.

— Сез дуңгыз ите ашамыйсыз, әйеме? Мин «татарлар дуңгыз ите ашамыйлар» дигәч, болар: «алдыйсың» диләр. Алдамыйм бит, әйеме?

— Иптәшләрең хаклы, — диде Якуп, — син алдакчы гына түгел, бәйләнчек тә икәнсең әле.

Сипкелле үзен тыныч тота, аның ачуланышырга исәбендә дә юк.

— Син нәрсә? Минме алдакчы? Мин Пензада татарлар белән бергә балалар йортында үскән кеше. Пензалар ашамагач, сез дә ашамыйдыр дип уйладым.

Арада берсе, бишмәт чабуыннан дуңгыз колагы ясап, чинагандай итеп үчекләп маташа, икенче берсе ат булып кешнәргә итенә иде.

Сипкеллесе малайларны тыймакчы:

— Гау-гау-гау итүегезне ташлагыз, зинһар!..

Һәммәсе шундук элеп алды: «Гау-гау-гау...» Хәзер аны үчеклиләр.

Сипкелле, малайларга кул селтәп, Якуп каршысына килеп басты.

— Теш ыржайтырга дигәндә боларга бир инде,— диде ул, эре генә. Аннары Якупның башыннан аягына кадәр күз йөртеп алды да кулын сузды:

— Таныш булыйк. Мин — Судаков Илья.

Якуп аның кулын чытырдатып кысып куйды.

— Синең куллар алай камырдан әвәләгәнгә охшамый.— Илья бармакларын тиз-тиз йомарлап бер язып алды.— Әйдә, булмаса, көч сынашабыз.

Өстеннән кайры тунын, колакчын бүреген салып ыргытты. Якуп та өс киемен Хәмзәгә тоттырды. Көрәш башланды. Көрәшчеләрне сырып алдылар. Кем атып бәрер дә, кем лапылдап төшәр? Судаков көрәштәшен җиңел генә сырты белән җиргә салмакчы итә, юк, булдыра алмый. Әйләнәләр, тулганалар: берсе дә бил бирми. Ахырда Судаков баш аркылы очканын сизми дә калды. Малайлар бер мәлгә шып тындылар, аннары дәррәү кубып җиңүчене мактарга, җиңелүчедән көләргә тотындылар.

Илья берни булмагандай тиз генә киенде дә әйтеп куйды:

— Таза егет икәнсең! Әмма, кара аны, җир астында забойда да сынашып карарбыз, кем кемне — күрербез.

— Чебешне көз көне санылар,— диде Якуп, эре генә.

Татарлар янына теге кыз килеп туктады.

— Хәзер сезнең белән танышырга да була. Мин — Оксана. Ә сез? Якуп үзенең дә, Хәмзәнең дә исемен әйтте.

— Берегезгә Яша, икенчегезгә Хәмзушка дип дәшәрмен.

— Сез кайда торасыз? Ургылдамы? Укыйсызмы, эшлисезме? — дип сорады Хәмзә, кыюсыз гына.

— Сигезенчене бетергәч, укырга туры килмәде. Ургыл шахтасында китапханәдә эшлим. Аннары күз күрер. Әти үзенә ияртеп клуб өчен кайбер нәрсәләр хәстәрләргә алып чыкты. Кичәге ярдәмегез өчен тагын бер кат рәхмәт, егетләр!

— Әтиең маладис кеше. Кичә шәп тә сөйләде, ичмасам. «Шахтерны җир өстендә бал-майга салсаң да, ул һаман шахтага тартыр»,— диде. Үзе дә шундыйдыр әле. Начальник булып безгә эләксен иде.

Ул арада баржа эченнән «кызым, вакыттыр» дигән тавыш ишетелде, кыз көлә-көлә Хәмзәнең бүреген иягенә тикле шудырып төшерде дә күбәләктәй пырхылдап, баскычларга тып-тып басып, аскы катка төшеп китте. Хәмзә мыгырданып калды: «Әй, кыланчык! Күзе бахбайда, ыспайлана тайга». Янәсе, Якупка күзе төшкән, ә Хәмзә белән юри генә шаяра.

Илья аскы катка төшеп барышлый, туктап, йомшак кына әйтте:

— Яша, Хәмзушка, уртага, безнең арага ятыгыз. Сезнең турыда салкын бит анда.

*
* *

Аскы катта, кысыла-кысыла малайлар арасына кереп ятуга, Хәмзәнең борынын бик таныш бер ис кытыклап алды. Салам исе, арыш саламы исе икән ич! Баржа төбенә салам җәйгәннәр, шуннан аңкый...

Күңелгә бик тә якын шушы ис малайны туган якларына алып кайтып та китте. Әнә дулкынланып торган арыш, бодай басулары... Яшел болыннар, сыер, сарык көтүләре... Әнә ул ат саклап йөри, тайлар әйрәтә. Авызы бөрешкәнче шомырт ашый, әнисенә, әтисенә, сеңелләренә дә җыеп, атка атланып өйгә кайта. Өйдә ярмалы бәрәңге ашый, яңа сауган җылы сөт эчә...

Аны татлы уйларыннан әллә нинди җыр тавышы, малайлар шаушуы бүлдерде.

Кичә пристаньда баржага бер кеше кереп утырган иде. Төн буе балалайкасын чиртә-чиртә җырлап барды. Әнә хәзер дә аны һәммәсе сырып алган. Куркынычлы җырлары белән малайларны шүрләтеп бетергән, йокыларын качырган.

— Ни күрсә дә ат башы белән ир башы күрә, име, малай?

Дусты дәшмәгәч, вагонетка астына кереп тапталган теге коногон атына охшатып, үзенең дә авылда калган кашка таен исенә төшерде. Абзар-кура, мал-туар арасында чуалып үскәнгәдер инде, бил-баш бирмәс тайларга җиде яшьтән үк атлана башлаган иде ул. Бригадир атлы эшкә кушса, дөньясын онытыр, китаплар кулыннан төшәр иде. Әгәр канатлары булса, очып кына кайтып керер иде дә хәзер, кашка таеның муенына асылыныр иде. Кайтыр, ник кайтмасын, киткән кошлар да әйләнеп кайта ич. Әнә теге сукбай тагын җырлый.

— Якуп дим, Якуп, ач әле күзеңне! Теге сукбай татарча җырлый.

— Әй, таман! Бетмәс андый зимагурлар. Оксананың әтисе белән

забойда күмер чабып ятканда уяттың,— дип, Якуп икенче ягына әйләнеп ятты. Шулай да тыңлады җырны.

Зимагур булып йөргәндә
Каты җирдә ятмадым.
Баш асларына салырга
Ярты кирпеч тапмадым.

Җыр тынгач, уйланып, әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнгәләде Якуп. Шушы җырчының кем икәнен тизрәк беләсе килә иде. Чыннан да, сәер адәм, җырларында иман әсәре булмаса да, күз карашлары моңлы. Бүреген кыңгыр салган да әле һаман балалайкасын сайрата, үзе тагын да моңлырак күренә. Сөйкемле дә шикелле... Кем булыр икән?

Якупның йөрәге сулык-сулык тибеп куйды. Авылда чакта үзе турында «каторжан Әхмәтҗан малае» дип такылдаганнарын ишеткәч, азмы ачы күз яшьләрен агызды Якуп. Ләкин әтисеннән килгән хатлар бер дә алай куркыныч булмый иде. «Себер киңлекләрендә, кыенлыкларга аз гына да баш имичә, тимер юл салабыз. Безнең алда табигатьнең барлык кырыслыклары баш иде», дип яза иде ул. Ләкин кай тирәләрдә салалар икән ул тимер юлны? Себер бик зур бит. Хатларындагы кире адресларында бары саннар гына күрсәтелгән була. Соңгы елларда андый хатлар да өзелде.

Эзләп таба алыр микән Якуп әтисен шул серле хатлар буенча?

*

* *

Караңгы төште. Ашыт буйларындагы кебек, акрын гына, моңсу гына иңеп маташмады караңгылык, ничектер күз бәйләнде дә калды.

Начальникның әмере буенча, һәммәсе урыннарына кереп чумды. Баржа эче тын. Вак яңгыр тамчылары брезент түбәне әкрен генә шакылдата. Сирәк-мирәк нәзек тавышы белән баржаны өстерәүче катер кычкыртып ала, таулар аңа кырык кат яңгырап сәлам кайтара.

Шул тавыш Хәмзәне тагын, тагын авылга алып кайтып китте.

Әтисе белән әнисе, ике кечкенә сеңелесе аны авыл башына хәтле озата бардылар. Олы урамны узганда, түбән очта солдатка китәсе яшьләр дә җырлап үтте. Хәмзәнең үзенә атап җырланган шикелле тоелды бу, аздан гына үксеп җибәрми калды.

Кояшлар чыга әйләнеп,
Алмагачка бәйләнеп.
Еламагыз, яшь түкмәгез,
Бер кайтырбыз әйләнеп.

Хәзер иптәшләре мәктәпкә йөриләрдер инде. Исәбе сигезенче класска керергә иде, насыйп булмады. Авыл Советына чакыртып, ФЗО мәктәбенә җибәрәбез, диделәр. Кызыктырдылар: «Анда, Ерак Көнчыгышта, кибетләрдә ситсы-мазар, кием-салым тулып ята. Посылка салырсың, шахтада акчаны да көрәп кенә алалар. Бик сагынсаң, ял алып кайтып йөрерсең, бару-кайту бушлай», диделәр. Күрше егетләренә тикле җанын кытыклап үртәп бетерде. Имеш, череп баеп кайтыр да, бүләк-санаклар өләшеп, затлы киемнәр киеп, күкрәк киереп йөрер. Аңа карап, җыен чибәр кызның баш-күзе әйләнеп бетәр. Дусты Якупның да язылуын ишеткәч, китәр көннәрен санап кына тора башлады. Китүен китте, әмма, бүгеннән үк сагына башлагач, саргаеп үләргә генә кала түгелме соң? Әнә, Якуп гырлый-гырлый йоклый. Авылда ул олылар белән беррәттән эшләп, тәмам пешеп житкән, чыныккан. Азрак дөнья күрсен, кеше арасында йөреп кайтсын дигәндер инде, әнисе дә тоткарламады аны. Яман телдән котылыр, өс-башы бөтәер, тамагы ипигә туяр, ичмасам, дип өметләнгәндер ана.

Хәмзә: «Өстеңнән төшеп беткән ич, малай».— дип, дустының өстенә әйбәтләп салам өйде.

Ләкин Якуп йокламый иде. Аның уйлары әллә кайларда уратып-уратып йөреп, инде кичәге көнгә килеп җиткән иде.

Поездан төшкәч тә аларны, төрле җирдән җыелган утызлап малайны, йөк машинасына утыртып, таш клубка алып килделәр. Әллә тагын, тора-бара, меңләгән малай җыелгандыр монда. Яшь кенә бер апа сәхнәгә менеп, гыйбрәтле сүзләр сөйли башлады: «Бүгеннән башлап сез эшчеләр сыйныфына аяк басасыз. Гәүдәгез кечтеки, әмма ул үсәр, акылыгыз да аннан калышмасын. Шахтерлар — җир астында гомер кичереп тешләрен койган бабайлар да, сезнең кебек яшьләр дә, чын мәгънәсендә батыр егетләр алар. Сез дә хәзер үзегезне малайлыктан егетлеккә күчтек дип исәпләгез». Шулай диюгә малайларның түбәсе күккә тигәндәй булды, дәррәү кубып кул чаптылар, куанычларыннан көлеп җибәрделәр.

Эшче турында сөйләүче апа райкомолдан булган икән. Аның артыннан ук хәзер шушы баржада малайларны алып баручы руска сүз бирделәр. Һәммәсенең шар күзе анда гына иде. Шәп тә сөйләде соң! Иң әүвәл бармагын залга төбәде дә сорады: «Син шахтер булырга телисеңме?» Шулай дип әле берсенә, әле икенчесенә «син, син?» дип чыкты. Кайсы «телим» дигән була, кайсы сүзсез генә авызын ера. Ә менә Якуптан сорамады да, төртеп тә күрсәтмәде.

— Минем фамилиям Уханов,— дип тотынды аннары.— Гәүдәмә кызыгасызмы? Шахта үстерде мине шулай, җир асты чүпрәдәй күпертте. Участок начальнигы булып эшлим. Сезне, ФЗО мәктәбен тәмамлагач, минем участокка эшкә җибәрәчәкләр. Кайсыгыз забойщик, кайсыгыз нигытучы, кайберегез коногон булачак.

Гаҗәпләнеп ята Якуп: «Юри әйткәндер, тәп-тәбәнәк кысрык штреклар кешене ничек үстерә алсын!» Гарәфи абыйсының «Шахтада уклау йотып йөрсәң, маңгаеңа бик тиз фонарь аласың» дигәне бар.

*
* *

Саламда ауный-ауный биш тәүлек чамасы баргач, баржа бозга килеп терәлде. Малайлар ду кубып этешә-төртешә көзге боз өстенә сибелделәр. Кайсы арты, берәүләре итекләре белән шуарга кереште. Уханов, катерны тизрәк кире җибәрү ниятеннән, баржада килгән йөкне тизрәк бушатырга кушты. Теләр-теләмәс кенә боз өстен ташлап, эшкә тотындылар. Иң элек, озын-озын бүрәнәләр куеп, йөк автомобилен, аннары шахта җиһазларын төшерделәр. Бүтән тимер-томырны, әрҗәләрне, капчыкларны чыгарып өйделәр. Барысы да кырмыскадай кайнаша. Тик теге балалайкачы гына яр буена чыккан да моңаеп утыра.

Уханов салмак кына атлап аның каршысына килеп басты:

— Малай-шалай тир түккәндә, кадалып утырырга оялмыйсыңмы? Атна буе шыңшыдың, ә хәзер ыңгырашасың! Кара аны, Харитонов, моннан соң «Коногон»ыңны ишетәсе булмыйм!

Харитонов, оешкан буыннарын шарт-шорт китереп, урыныннан кузгалды. Якуп аны байтактан бирле күзәтеп йөри: бу кеше Ухановтан слырак күренә, күзләре дә эчкә кереп баткан, карык-корык ютәлли, җитмәсә, бите, маңгае тулы җыерчык. Карашлары ук күпне күргән бәндәнекенә охшый, аркасында кечтеки генә бөкресе дә бар. Сихәте дә чамалы, ахры — моңлы йөзе көз көннәрендәге имән яфрагыдай сапсары. Әнә, юан бармагы белән өскә таба күтәрелеп торган мыек очларын бөтергәләп алды, җайлап кына әйтеп куйды:

— Кемнең кемне рәнҗетергә хакы бар, начальник?

— Башта хезмәт, аннары хөрмәт!

— Һәр кошның үз моңы. Минем сүзнең эштән аерылмаганы сиңа күптән мәгълүм. Бала-чага алдында рисвай итеп, йөрәк җәрәхәтенә нигә тоз сибәргә! Эх! Юаш булсаң басарлар, усал булсаң асарлар.— Соңгы сүзләрен Харитонов үз-үзенә әйтә-әйтә, капчык өемнәре янына китте.

Кара син аны, кайчандыр дөрләп янган, хәзер генә сүнә төшкән учак икән ич бу! Бишәр потлы шикәр капчыкларын ярыйсы гына очырып йөртә.

Баржа бушатылгач, катер аны арканга элэктерде дә өстерәп кире кайтып китте. Малайлар бик озак, күздән югалганчы, аңа кул болгап калдылар. Үзләренең өсләреннән пар күтәрелә, кызарынганнар, янганнар. Уханов аларга машина әрҗәсенә менеп утырырга кушты, үзе иң беренче булып сикереп менде. Оксана белән Харитонов кабинага урнаштылар. Кузгалып киттеләр.

Салкын җил колакларны чеметтерә, куенга үрелә, аякларга «тараканнар» үрмәли. Салынасы тимер юлга дип өелгән дамба буйлап, такыраеп каткан балчык өстеннән чаптыра гына машина. Әнә, бушатылган йөкне алып китәргә трактор килә, артына олы-олы ике чана таккан. Әрәмәлек арасыннан бер көтү кыр кәҗәләре чыгып карап тора иде — малайлар сызгыруга, секунд эчендә юкка да чыктылар. Алда нибары тик шушы юл гына, артта әле һаман елга ялтырап күренеп тора. Тирә-якта кеше юанлыгындагы усаклар үсә, читтәрәк мәңгелек сазлык җәйрәп ята. Ничаклы җир узып, ник кенә бер авыл очрасын.

Көн кичке якка авышканда, машина туктап калды: дамбаның дәвамы юк икән, машина барырлык түгел, Уханов әйтүе буенча, аны моннан трактор чанасына салып алып китәчәкләр. Малайлар шыбырдашып машинадан коелуга, аяклар шундук тубыктан сазга кереп батты. Ләчкелдек, ботинкаларда су чыптырдый, Харитонов авыз эченнән генә әйтеп куйды:

— Сабыйларны эшкә өйрәтергә алып бара начальник.

Һәм капчыгын, балалайкасын аркасына асып, карлы пычракны ера-ера, сазлыклы әрәмәлек эченә кереп күздән дә югалды.

Уханов та, кызын иярттеп, карт артыннан атлады, малайларга да үзеннән калмаска кушты. «Барасы җир биш кенә карыш, теге урманлы тау артында гына»,— диде. Бөтенесе ботинкалары эченә тулган карлы суны чыптырдатып, капчык, чемоданнарын асып китеп бардылар.

...Кая ул карышлап кына, әллә тагы унлап чакрым үткәннәрдер инде, шәһәр дә юк, шахталар да күренми.

— Иптәш Уханов, кайда калагыз? — дип сорап куйды Якуп.

Уханов усал итеп аңа карап алды.

— Шыңшымаска! Шахтер тау-таш җимереп җир астында юл сала, ә сез әзер сукмактан атларга да ыңгырашасыз. Марш! Җырларга! Кайсыгыз башлый? Шыңшучы синме?

«Күзең бик очлы, телең бик әче, ник сүз каттым икән?» — дип үкенеп алды Якуп. Тик менә ничек кенә башлап җырларга?! Авылда концерт куйганда, хорда басып җырлаганы бар барын, әмма анда татарча...

Ул да түгел:

— Я, кемгә боералар! — дип кычкырды начальник.— Әйдәгез, «Если завтра война»ны җырлыйбыз.

Мәңгелек тын җирнең тынлыгын бозып, җыр яңгырады. Тау башына үк менеп китә дә җыр, урман аша узып, яңадан кире әйләнеп, ишаеп кайта.

Если завтра война,
Если завтра в поход,
Будь сегодня к походу готов.

Шулай атлый торгач, алларында ап-ак шәһәр барлыкка килде. Тау итәкләрен брезент йортлар сырып алган. Алар арасында кара таплар да бар. Һәммәсенең күзе шул кара тапларга төбәлгән. Сәер дә икән бу якта кала дигәннәре! Йортлары игез балалар кебек бөтенесе бер төсле, бер тигез. Ә тап булып күренгәннәре — иң кызыгы икән: күмер өемнәре.

«Шушы микәнни без яшисе Ургыл каласы? Без эшлисе шахта?» — ди Якуп эченнән һәм тизрәк, барысыннан да алданрак барып күрергә ашкына, күмер өемнәре янына йөгереп китә.

— Әнә шахта! Әнә мәгарәсе! — дип кычкыра-кычкыра тау итәгенең астыннан, җир белән бер тигезлектә үк тау астына кереп киткән куышка күрсәтә. Малайлар шунда җыела. Ифрат та зур икән бу тау асты тишеге: рәхәтләнеп авылның бер өе сыярлык. Хәмзә шүрли үк башлый: «Шушы була икән инде коногонны харап иткән җир! Безнең дә тир түгәсе төшебез, көн саен кереп-чыгып йөрер куышыбыз».

— Маңгаена «Беренче шахта» дип язылган язуны күрәсезме? — Уханов кулын мәгарә ягына суза-суза сөйләп китте: — Бу куыш «штольня» дип атала, анда ике участок бар, берсе «Сивак», икенчесе «Чаланык» исемле. Чыгарылачак күмерне тимер юл вагоннарына төяп озату өчен эстакада төзибез. Икенче елга тимер юл да килеп җитәр дип өмет итәбез...

Кыюрак малайлар күз күрерлек чамада шахта эченә үк үтеп кергән. Монда биткә җиләс дымлы һава бәрелә, аяк асты пычрак, ботинкаларны салдырып калмакчы итә, җибәрми тора. Куышның ике як стенасын да кеше юанлыгы баганалар белән терәтеп куйганнар, түшәмдә дә шундый ук баганалар. Борынга, иске бәрәңге базындагы шикелле, черек гөмбә исе бәрә. Бер кавым карап торгач, күзләр дә ияләнә. Әнә, бик еракта утлар җемелди, тимерме, күмерме дөбердәп ала. Терәүләргә элеп куелган тимер торбалар туктаусыз зыңгылдап тора.

Штольня авызыннан ерак түгел арба шыгырдаган тавыш ишетелде, малайлар тизрәк тышка атылды, ә күзләре һаман эчтә. Иң әүвәл куыштан атның башы, аннары үзе дә күренде: көчәнә-көчәнә вагонеткалар тартып чыга. Бу вагонеткаларга өч-дүрт ат арбасы сыя торгандыр, билләһи. Саныйлар: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү. Якуп ат башы хәтле күмер кисәге алып калды, коногон вагонеткалар бушатыла торган җиргә чаптырып китте. Хәмзә ат артыннан йөгерде.

— Менә маладис, ичмасам, бахбай! Берүзе йөкле килеш биш арба тартып йөри.— Шпалларга абына-сөртенә аттан калмаска тырыша. Бу ат куучының кулында ни чыбыркы, ни чыбык, ни дилбегә. Тычкан уты шикелле генә җемелдәп торган шахта лампасын түшенә аскан. Өсте суга манып алгандай юеш, бер сызгырып җибәрүгә аты читкә атылып чыга. Коногон вагонеткаларын ычкындыра да бушларын тага. Бик җитез кылана. Хәмзә сокланып туялмый: дөлделе дә дөлделе! Егете дә егете! Теләсә кайсы атны, теләсә кемне куймыйлардыр мондый кыю эшкә...

Кире әйләнеп килгәндә, Якуп белән Илья күмер кисәген таш өстенә салып, ватмакчы булып азапланалар иде. Кая ул, битләренә борчак-борчак кыйпылчыклар гына чәчри. «Сәер икән бу күмер дигәннәре, меңләгән йолдызчыклары күзне чагылдырып җемелди»,— дигән була кайсыдыр.

Илья күмерне тешләп карый, чәйнәп карый, тәмсез икән дип төкеренә, борын төбенә үк китереп исни, аннары иңбашларын җыерып куя: шайтан исе дә юк. Якуп берсенә дә ышанмый, Илья эшләгәннәрне кабатлый. Авылда чакта Гарәфи абыйсы әйтә иде бит: «Күмердән йөзләгән шахтерның тир исе аңкый», дип. Ә моннан бер ис тә килми. Шахтаның килеш-килбәтен ишетеп тә, китаплардан укып та белә белүен, әмма үз күзләрең белән тикшерү гаҗәеп кызык икән! Эх, очып

кына кайтып авылдашларны янына җыярга да кызыктыра-кызыктыра сөйләп бирергә бөтен күргәннәрне!

Хәмзә пышылдый:

— Әнә, әнә, шахтерлар чыга.

Чыннан да, шахтадан бер төркем шахтер чыгып килә иде. Өсләрендә пычракка батып беткән брезент кием, аякларында шахта галошы, башларында бүреккә дә, картузга да охшамаган түбәтәй сыман колакчын бер нәрсә. Кайсы кәйлә, кайсы көрәк, кайсы балта-пычкы, кайсы нәрсә күтәргән, кулларында янып торган лампа. Гарәфи абыйларының да шушындый лампасы бар иде. И кызыгалар да иде малайлар шуны яндырып кичләрен урамда йөрергә. Тик ул аны малайларга бик сирәк тоттырды, узган гомеремнең истәлеге итеп саклыйм ди торган иде. Бу лампам җирнең астын гына түгел, тормышымны да ялт иттереп яктыртып торды заманында, ди иде. Инде Якупның да үз лампасы яктыртачак.

Менә малайлар, Ухановка ияреп, палатка шәһәрчеге аша узып баралар. Монысы да кызык аларга. Бу брезент йортның ишек урынына тишек кенә: эленеп торган ак пәрдәне төртәсе дә керәсе. Тәрәзәләре дә пыяласыз, дәфтәр бите хәтле генә үтә күренмәле ак ситсы белән капланган.

Ә инде биек тау башына менгәч, палаткаларның заты да юк. Монда икешәр катлы агач өйләр салынган. Кырдай иркен урамнарда карагай, кара каен, кәрлә имән үсеп утыра. Яңа гына салынып ята торган Ургыл шәһәренең бу урамнары «Яшьләр шәһәрчеге» дип атала икән.

Уханов малайларны «Ургыл шәһәренең ФЗО мәктәбе» дип язылган йортка алып керде. Өске катка менделәр. Анда аларны чандыр гына гәүдәле, ябык чырайлы олы яшьләрдәге бер агай бишәр-бишәр итеп бүлмә саен урнаштырып йөрде. Аннары җыеп мунчага алып китте. Шаяра-шаяра рәхәтләнеп юынгач, чистарынгач, бит алмалары кызарды, арулар әллә кая югалды. Һәрберсенә ап-ак күлмәк-ыштан, соры төстәге йон кәзәки, кул яссылыгы сары бил каешы, кара төстәге бишмәт бирделәр. Урак-чүкеч сурәте төшкән сап-сары төймәләре елык-елык итә. Аякларга менә дигән ботинка да киеп җибәргәч, түбәләре күккә тиде малайларның. Сафка тезелеп ашханәгә киттеләр. Икешәр тәлинкә итле карабодай боткасын тетеп салгач, агай яңадан сафка тезелергә кушты, үзе уртага басып болай диде:

— Минем кем икәнлекне беләсегез киләдер, җанкисәкләрем, мин сезнең мастерыгыз булам, һөнәргә өйрәтүчегез. Фамилиям — Степанов. Узган набор егетләре «иптәш мастер» дип кенә дәшәләр иде. Ә хәзер, җанкисәкләрем, рәхәтләнеп йоклагыз.

Шушы дүрт-биш сүз арасында да берничә тапкыр «җанкисәкләрем»не кабатлагач, малайларга җитә калды: пырхылдый-пырхылдый анынча итеп сөйләнә башладылар.

Менә шушы була икән инде куанып та, шикләнеп тә көткән ФЗО мәктәбе. Хәзергә рәхәт. Бүлмәләрдә пружиналы тимер караватларга ак җәймәләр җәелгән, баш-башлары яшел сызыклы одеял, кабарып торган мендәр. Урын җәя, өнгә килә алмый Хәмзә: «Мондый урын-җирне әни янына больниска баргач кына күргәнием, ә хәзер үзем көн саен сузылып ятачакмын»,— ди.

Тышта салкын җилле көз. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Монда, одеял астында, майдай җылы, тамак тук. Өсләр дә бөтен хәзер. Түшәмдә ял-якты булып электр лампочкасы яна. Барысы да бар, тагын ни кирәк? Шулай да, «рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил», дип юкка гына җырламыйлар икән. Хәмзә пышылдап дустын уятып маташа:

— Якуп дим, Якуп, йоклыйсыңмы әле син?

Әмма дусты ишетми, башы мендәргә тиюгә үк йокыга талган ул.

Аларның тәрәзәләреннән ап-ак башлы галәмәт биек таулар күренеп тора. Якында гына кебек алар, урам артына чыксаң, тегә итәгеннән күтәрелә дә башларга булыр кебек. Ләкин алай түгел икән. Мондагылар әйтә: ул тауларга кадәр барып җитәм дисәң, өч көн, ике төн тәпиләргә кирәк, диләр. Анда да әле, бара белеп барсаң гына... Юкса, очсыз-кырыйсыз төпсез сазлыкларга мәңгегә кереп чумуың, усак урманнарында башың чыкмастай адашып калуың да бик ихтимал икән. Мондагы асты тулы ташкүмерле Ургыл таулары шул ак башлы тауларның фәкать итәкләре генә, ди.

Якуп белән Хәмзә, буш вакытлары булды исә, бу сәер һәм гаҗәеп якларны хозур кылып йөрергә бик яраталар.

Ургыл тавын төшүгә, сазлык башлана. Шул сазлыкны ерып үтә алсаң, ургыла-ургыла аккан ташкын сулы елга буена килеп чыгасың. Атаклы Ургыл елгасы бу. Елга буенда колач җитмәслек усак бүрәнәләреннән салынган озын-озын бараклар тезелешкән. Ваграк йортлар да бар — аларын шахтерлар үзләре салып чыккан. Тагын яңадан-яңа өйләр салып яталар. Шушында ук бүрәнәләрен дә кисәләр, биек станнарга басып, тактасын да яралар. Тук та тук балта тавышы, чыж да чыж пычкы чыңы өзлексез яңгырап тора монда.

Шушы авазлар күңелгә якынмы, әллә өйләрен үз авылларындагыга охшаталармы, малайларның аяклары гел бу төшләргә тарта. Аннары, елга буйларында нәкъ авылдагыча шомырт, тал агачлары да очрый — болары да күңелгә бик хуш. Тик шунысы: өйләр авылдагыга охшаган, ләкин ник кенә бер этәч кычкырсын да, ник кенә бер мал-туар тавышы яңгырасын... Бигрәк сәер икән ул этәчсез, мал-туарсыз йорт-җир.

Шулай да бервакыт малайларның күңеле булды.

Ургыл буенда әлеге шул җанга якын шомырт агачлары эзләп йөриләр иде алар. Икесенең дә күзләре тирә-юньне айкый, ә күңелләре әллә кайларда... авылга ук кайтып киткән. Сөйләшмичә генә атлыйлар.

Шул чак Хәмзәнең кинәт кенә ташып торган шатлыклы тавышы ишетелде.

— Якуп! Тыңла әле, каргалар! Каргалар каркылдый. Тыңла әле... Әнә, үзләре дә...

Чыннан да, биек усак башына ала каргалар оя корганнар, шул тирәдә оча-куна каркылдашалар иде. Малайларның дөньялары онытылды. Таныш кошкайлардан күзләрен ала алмыйча, бик озак басып тордылар. Авылларында өздереп-өздереп сандугач сайрауларын да болай ук бирелеп тыңлаганнары юк иде аларның. Туган-үскән якларның кадере, чит-ят җирләргә киткәч, ай-һай, чиксез була икән!

Ургыл буйлатып, кайтыр юлга таба атладылар. Хәмзәнең йөзеннән моңсу гына елмаю китми, ә Якупның чырае бик җитди иде.

Бераздан Якуп тукталып калды. Ярсып, чәчрәп, ашкынып аккан Ургылга карап, тик басып тора.

— Әтинең сүзләре искә төште,— диде ул бераздан, һаман да шулай Ургылга текәлгән килеш.— «Җир йөзендә үрмәләп яшәгән кәлтәнең бөтен гомере бөркетнең биектә талпынып яшәгән бер сәгать гомеренә дә тормый»,— ди иде әти.

Аннары Хәмзәгә таба борылып өстәде:

— Минә шушы елга кебек ургып, ашкынып, янып яшәргә кирәк, име?

— Әлбәттә,— диде Хәмзә, күзләрен зур ачып. Якупның әтисе турында искә алуын беренче ишетүе иде аның. Дустының йөрәк ярасын кузгата күрмим дип, үзе дә бу турыда һич вакыт авыз ачмый иде.

* * *

Иртәгесен, җир астында хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәнү бүлмәсеннән чыккач, Якуп әйтеп куйды:

— Атналар буе тик ятабыз. Бездән шахталарын кызганалар, күрсәтергә дә алып төшмиләр, ичмасам.

Укучыларга шул җитә калды. Степанов күренүгә, унысы ун яктан сорау яудыра башлады:

— Кайчанга тикле класста аунарбыз, иптәш мастер?

— Лекция тыңлатасыз. Без сезгә сабыйлармыни!

— Даешь шахта!

— Без Ерак Көнчыгышка күмер чыгарырга килдек.

Степанов, сизелер-сизелмәс елмаеп, кулын күтәрде.

— Сабыр, җанкисәкләрем, һәртөрле җимеш үз вакытында пешә. Ниһаять, ул көн җитте.

— Әнә, коридорда кием. Сайлагыз! Шахтага киттек,— диде мастер бер иртәдә.

Малайлар тизрәк киенеп алдылар да сафка бастылар. Беренче шахтаның штольнясе янындагы такта алачыктан һәрберсенә лампа, соскы, көрәк, өч-дүртенә берәр кәйлә өләшенде.

— Якуп, малай, синең дә йөрәгең җилкенәме? — дип пышылдады Хәмзә.— Минеке очып чыгардай итә. Бүтәннәрнеке дә шулай микән, сора әле.

Дустының бик исе китми иде, «әйдә, артта калма» дип кенә куйды.

Эчкә кереп киттеләр. Биредә бер нәрсә күренми. «Күз тышта калган». Баш штрек эче биек, түшәмгә баш бәрелми. Степанов ашыкмый гына алдан атлый бирә, укучыларына әйләнеп тә карамый.

Ара-тирә: «Петя, галошыңа су тулдымы?», «Лампаң белән селтәнмә, аякка бәрәсең!» дигән тавышлар ишетелеп куя. Тездән лай ярып бара торгач, Хәмзә шпаллар арасындагы суга кереп баткан да сукрана: «Җәһәннәм чокырына төштем, егетләр!»

Якуп гаҗәпләнә: нигә бу мастер укучыларын бер дә күзәтми? Әнә, малайлар терәүләргә бәреләләр, чыланып беттеләр, кайберләренең лампа пыялалары чәлпәрәмә килгән. Юри күрмәмешкә салышадыр ул, әйткәннең кадерен белсеннәр, дидер. Хәйләкәр төлке.

— Иптәш мастер, нишләп штольнягә электр лампалары куелмаган? — дип сорады Якуп, мастерны куып җитеп.

Степанов, туктап, башкаларның да килеп җиткәнен көтеп торды да аңлатырга тотынды:

— Электр станциясе төзелеп беткәч, уты да булыр, электровозы да чаптырып йөри башлар, врубмашиналарны да гөрләтерсез. Ә хәзергә электр су түктергеч насосларга гына җитә.

Тагын алга юл алдылар. Кайдадыр гөрселдәп шартлаган тавышка һәммәсе шып туктап калды. Борынга сасы төтен исе бәрелде.

Мастер өйрәнчекләренә карап елмая:

— Эй, арыслан дип торам тагы мин сезне,— ди.

Өйрәнчекләре батырая төште. Мондый шартлатулар көн саен булып торачак лабаса. Баш очыбызда каты таш катламы, юан-юан карагай бүрәнәләре, ишелмәс әле...

Еракта утлар җемелди, дөбер-шатыр итеп тимергә әллә нәрсә бәрелеп китә. Җемелдәгән утлар отыры якыная. Килеп тә җиттеләр. Забойны күмер тузаны каплаган. Ике забойщик ат башы хәтле күмер кисәкләрен буш вагонеткага салганда шулай каты дөбердәтәләр икән. Өсләреннән пар күтәрелә, шабыр тиргә батканнар. Олы кисәкләр беткәч, көрәкләре белән вагонетканы төяп бетерделәр дә, малай-шалайга игътибар итмичә, аякларын шпалларга терәп, көчәнә-көчәнә, урыныннан

кузгаттылар, җилкәләре белән этеп бара-бара, караңгыга кереп чумдылар. Бераздан бушын этеп китереп, яңадан тәяргә тотындылар. Малайлар күз алдында тәяп тә бетерделәр.

— Исәнме, яшь гвардия! — диде арадан берсе, ап-ак тешләрен елтыратып. Лампасын баш очына күтәреп, берәм-берәм карап чыкты.

— Федор Иванович, безгә менә дигән алмаш әзерлисең. Болардан рәт чыгачак.

— Бөркет балалары болар, Малик туган. Канат кына кагасылары бар.

Степанов өйрәнчекләренең кайсы көрәк, кайсы кәйлә, кайсы балта тотып кайнашканын күзәтә. Пычкыга тикле тылсымлы тоела малайларга: тешләрен тоткалап карыйлар, кисеп маташалар. Арадан берсе:

— Юньлерәк кораллары бардыр шахтерның дигәнием, кәйлә дә пычкы, көрәк тә соскы икән,— дип куйды.

Забойщикларның Малик дигәне ялт итеп аңа таба борылды:

— Ялгышасың, энекәш. Бөтен эш коралының да үз көе, үз җыры бар.— Пычкысын алып бармаклары белән суккалап, көйгә охшаган тавыш чыгарды.— Корал — ул синең укучың да, укытучың да. Бигрәк тә балта белән пычкы бик нәзберек нәрсәләр. Алар белән эш итә белсәң, алтын куллы егет диярләр үзеңне. Коралын тоткан — таш кискән, әмәлен тапкан — су кичкән. Коралсызның кулы ике, коралльныкы унике.— Шулай диде дә эһ дигәнче юан гына бүрәнә башын кисеп ташлады.

Хәзер икенче забойщик иплән кенә сүз башлады:

— Эшләгәнче көлмә, эшләп аргач көл, диләр бездә. Әүвәл-әүвәлдән кәйлә җир казыганда хакимлек итеп килгән. Хәзер дә шулай. Әмма ләкин көеннән тормасаң, күз ачарга өлгергәнче аудара да сала үзеңне. Суга белеп суксаң гына буйсына. Ягъни мәсәлән, менә болай. Карап торыгыз! — Ул селтәнгән саен йодрык-йодрык кисәкләр бәргәләп төшерә, аннары туктый да сүзен дәвам иттерә.— Бик таләпчән, ачу тотучан бу. Вакытында очлат аны, сапларын җайла. Шул чакта гына сиңа ул таҗ кигезер, данга күмәр. Кадерен белмәгән бәндәгә бәла тудырыр.— Менә ул яңадан күмер тәяргә кереште. Хәмзә аны танып алды: баржада бергә килгән теге зимагур икән ич. Әттә генә шәп уйната кулында көрәгеи! Эх, үземә дә шулай...

Кузгалып киттеләр. Текә баскыч буйлап мич арты шикелле кысан штреккә үрмәләп менгәч, Степанов аңлатырга кереште:

— Бу авыш штрекне без «мич» дип атыйбыз. Шахтаны файдалануга тапшыргач, монда ниләр булачагын кем әйтер?

— Тимер колашалар. Лавада чыгарылачак күмер шушы колашалар буйлап ага-ага баш штреккә коелып торачак. Ә анда вагонеткаларга тәялә.— Монысын Якуп әйтте.

Мастер аның сүзен раслый, молодец икәнсең, беләсең, ди дә өскә таба үрмәли. Биленә чыдар әмәле юк Якупның. Кысыла-кысыла башны билдән дә түбәнрәк иеп атлаган саен аяклар тая, артка шуыша бара. Аяк очларында гына яткан колашалар буйлап өске яктан бәреләсугыла күмер кисәкләре оча, абайламасаң, бәреп егарга да күп сорамас. Җитмәсә, түшәмнән муенга су тама. Яна-пешә конвейер штрегенә менеп җиттеләр. Монда тигез, биек, иркен, коры. Забой түре тулы шартлатылган күмер: хет буа бу. Баш очында бүселеп-бүселеп таш кисәкләре асылынып тора.

— Кайсыгызның маңгаена мөгез чыкты — бер адым алга! — дип, мастер имгәнүчеләрне тикшерде. Андыйлар күренмәгәч, ягымлы тавышы белән сөйләргә кереште:— Бөркет шулай канат кага, җанкисәкләрем. Очып китсә, аннан да батыр, көчле кош булмый. Ә хәзер шушы күмерне колашаларга тәягез! Ялт иттерүгә, кайтып та китәрбез.

Малайлар шаулаша-шаулаша өемне сырып алдылар да күмер

төяргә керештеләр. Менә кайчан кирәк икән мастерның атналар буе тукыган дәресләре! Лампаңны җиргә куйсаң — төртеп аударасың, кулда тотыйм дисәң — куллар буш түгел. Юк-бар гына нәрсә үзе, әмәлсез суя да сала. Этәләр, төртәләр көрәкләрен, ә ул эре-эре кисәкләргә килеп төртелә дә күмерне көри алмый аптырата. «Мастер әйткәние,— ди Якуп үз-үзенә,— башта баскан урынында өемнең төбенә кадәр бер урында гына казып төшәргә дә,— дигән иде,— аннары таш җирлек буйлап көрәк майлаган табадагы кашык шикелле шуып кына йөрер». Менә, мастер өйрәткәнчә ун өлеш асатрак: көрәк шуа гына, ал да сал күмерне, ал да сал. Хозурланып төйи Якуп, кулы кулга йокмый, мангаеннан шыбырдап тир ага. Куанычы эченә сыймый: «Азаплана торгач, күмер төяүнең дә әмәлен таптым»,— ди.

Күмер төялеп бетте, забой чистарып калды, тагын да иркенәйде. Мастер, забойны, терәүләрне тикшереп чыккач, малайларга килгән юлдан кайтып китәргә кушты. Җир асты буйлап адашмаслармы, җитди кыланырлармы, янәсе. Ә өйрәнчекләре колашаларга менеп утырдылар да «мич» буйлап тәгәри-тәгәри, караңгылыкка кереп чумдылар. Рәхәт тә соң! Биек тау башыннан чанага утырып төшкән кебек. Тик, бер рәхәтнең бер михнәте дә була икән. Артык кызу төшүдән, баш штреккә җитәрәк туктый алмыйча, штольняда колашалар астына куелган вагонетка эченә мәтәлеп килеп төштеләр. Кайсының сырты сызлый, кемдер башына зарлана, кайберләренең битләре сыдырылган, күз төпләре кара янып чыккан. Якупның чалбар арты умырылган, тәне күренеп тора иде. Берәүләре әле һаман лампаларын таба алмый интегә, көрәкләрнең кайда икәнлеген белгән кеше дә юк. Орышмый, әрләми мастер, авыз чите белән генә елмаеп, малайларның корал һәм лампа эзләгәннәрен күзәтеп тик тора: болай да ярыйсы сабак алдылар ич. Судаков пышык-пышык килеп кулларын изи:

— Карагыз әле Яшага, карагыз! Оксана күрсәие...

Бөтенесе Якупка карап ахылдадылар: умырык чалбар, умырык чалбар...

Тегесе чынлап та борчуга калды: шәһәр буйлап бу килеш ничек кайтыр? Нишләп ул кыз атна буе бер дә күренми әле? Үч иткәндәй, хәзер туры килсә? Чалбарның ертык җирен тимер чыбык белән элэктергәләде дә иптәшләре артыннан чапты.

— Кайчан гына сезне бераз юынгалап-суккалап шахтер сурәтенә кертеп булыр икән? — дип уйлап атлады Степанов алар артыннан.

...Бу төнне май кебек эреп йоклыйсы урында, берсе дә тиз генә ятмады, шахта турында сөйләшеп сүзләре бетмәде. Яткач кына беләкләре, билләре, кулбашлары сулкылдап сызлавын сизделәр. Якупка тикле зарлана.

— Болай булса, ничек эшләрмен еллар буе. Ярты көн казынып, кулбашсыз калдым. Авылда ат белән сука сукалап та болай булганы юк иде. Шахтер чыгачак түгел бездән... түгел...

Хәмзә уфылдап ята, кичке ашка да бармый калды, дустына әйтә:

— Якуп, малай, мин үләм бугай. Иртәгә торалмам, ахры. Җирләгәч, авылга хат яз, ямe! Хәмзәгез батырларча вафат булды, диген...

Якуп шаркылдап көлде, малайларга әйтимме, ди. «Авыру» әйтеп кеше көлдермәскә кушты.

*
* *

Менә ун көн чамасыдай алар шахтага йөриләр. Тора-бара, яңадан атналар үткәч, сызланулар кимегән шикелле булды. Хәзер иртән кузгалып китүе генә кыен, аннары тәннәр языла. Инде күмер төяргә генә

түгел, түшәм астына терәү куярга да остарып баралар. Монысы да бик авыр эш. Үзең юанлыгындагы икешәр-өчәр метрлы карагай бүрәнәләрен кысрык штрекләр буйлап өстерәп кара әле! Төгәл үлчәп кисәсе, аннары пот ярымлы тимер тукмак белән тукмый-тукмый нык иттереп үз урынына бастырасы бар.

Шулай бер көнне Илья, Якуп белән икәүләп забойны ныгытып ятканда, тукмагын җиргә атып бәрде.

— Яша, өченче бүрәнәне әрәм итәбез бит, дөрес үлчәп кисәргә кирәк,— ди.— Ярты сәгать тукмаклап та кертеп булмый бу терәүне.

— Китер! — дип, Якуп тукмакны алып үзе дөнгечли башлады, манма тиргә батты. Тәки үз урынына утыртты терәүне.

Эш беткәч, авызларын ерып, икәүләшеп карап тордылар, үз эшләренә үзләре сокланып туя алмадылар. Аннары, каткан гәүдәләрне бераз турайтып алыйк дип, күмер өстенә сузылып яттылар.

Якуп үз уйларына чумды. Кичә Хәмзә аңа бер газета күрсәтте. ФЗОның кызыл почмагыннан элəктергəн икән.

— Кара әле, безнең Хафиз түгелме соң бу? — дип, бер рәсемгә төртеп күрсәтте, үзе, кош тоткандай, иреннәрен җыя алмый иде.

Газетадан очлы иякле, киң маңгайлы, сөйкемле генә бер егет елмаеп карап тора, астына язылган: алтын приискасының алдынгы эшчесе, читтән торып тау эшләре техникумында укый, комсомолның район комитеты члены Хафиз Сафин, дигәннәр.

— Шул бит, каһәр! — дип кычкырып җибәргәнен Якуп үзе дә сизми калды.— Исеме, фамилиясе дә туры килә, төсе дә аңа тартым.

— Тартым да... Ул бит Судаков кебек сипкелле иде, җирән иде. Ә моның сипкеле юк, чәче-кашы да кара, әллә коңгырт...

— Ул түгел бугай шул,— диде Якуп.— Дөньяда азмыни охшаш бәндәләр, Сафиннар да Хафизлар...

— Һәм ерык авызлар,— дип өстәде Хәмзә.

Менә хәзер Якупның күз алдына шул рәсем килеп басты да уйлары әллә ни ерак та булмаган бала чак истәлекләрен актара башлады.

Бик сәер дуслар иде алар Хафиз белән. Икесе ике күрше авылдан килеп, бер үк мәктәптә укыдылар. Икесе дә классның алдынгы укучылары иде. Ләкин шунысы кызык: Якупның берәр «отлично» билгесе Хафизныкыннан артык булса, моның сөмсерләре коела, әллә ничә көн дусты белән сөйләшмичә йөрер иде. Менә «отличнолар» саны тигезләнә, болар тагын аерылмас дусларга әвереләләр.

Бишенче классны тәмамлагач, икесен дә пионер лагерена җибәрделәр. Шунда Якупны звено вожатые итеп куйдылар. Тагын араларыннан кара мәче үтте боларның. Көнләшүен һич яшерә алмыйча, җае чыккан саен төрттерергә генә тора иде Хафиз. «Син вожатый кеше, әйдә, безгә үрнәк күрсәт», ди дә, Якуп башлаган бер генә эшкә дә, уенга да катнашмый. Ә Якуп, аңа үчегеп, йөгерү, сикерү ярышларында беренчелекне бирми. Тегермән буасы артындагы биек күпердән юри Хафиз алдында сикереп төшә, елганы икешәр-өчәр тапкыр йөзеп чыгар иде. Ә Хафиз, никадәр генә тырышса да, аңа житә алмый, гәүдәгә калкурак булса да, Якуптагы кебек каксаң кадак сикереп чыгарлык тыгыз мускуллар юк иде шул аңарда... Аның каравы, сүзгә бик оста Хафиз. Отряд сборларында, пионер костерларында шигырь сөйли башласа, бөтенесен авызына карата, котыра-котыра кул чабып, кабат-кабат сөйләтәләр иде үзен.

Яңа уку елы башлангач, дуслар арасында мондый астыртын тартыш йомшарды, хәтта бетте диярлек. Хафизны класс старостасы итеп сайладылар. Мактаулы староста булды ул. Малайларны шома тел белән юмалап та тыңлата белә, кайбер баш бирмәсләрне «акылга утыртуның» да әмәлен тапты. Еш кына Якупны аулаккарак дәшеп ала да:

— Әйдә, теге Тәкә маңгайның арт сабагын укытыйк әле. Тарихтан бөтенләй тыңларга да бирми бит,— ди.

Тәки укыталар арт сабагын Тәкә маңгайның. Озын тәнәфестә сарай артына алып чыгалар да икәүләп кабыргаларын саныйлар тегенең!.. Дәрес башлангач, Хафиз, күзләре белән теге малайга ымлап, Якупка бик дустанә елмая. Чыннан да, майлаган күк булган бит Тәкә маңгай. Күзләрен челт-челт йомгалап, кымшанмый да утыра.

Шулай да арада тагын бер бәхәс чыкты.

Башка авыллардан килеп укучыларга торак урыны итеп буш класс бирелде. Егермеләп малай, дәресләрен караштыргалагач, төн уртасына тикле шаярып чыгалар, асылмалы унлы лампаны сүндергәч тә, әкиятләр сөйлиләр, бәетләр көйлиләр иде.

Бер кичне тагы да уздырып җибәрделәр. Берсе әкияттәге аждаһа, икенчесе җен-пәри булып әверелде. Улашалар, тәртешәләр. Китте әүмәкләшү, дөмбәсләшү, мендәр атышу... Кайсы пышык-пышык елый, кайсы шырык-шырык көлә. Ничек кирәк алай тынычланып, таң алдыннан гына йокыга изрәделәр.

Күпме генә йоклаганнардыр, коридорда команда яңгырады:

— Тревога! Коридорга тезелергә!

Малайлар күзләрен уа-уа баш калкыттылар, ә коридорда физкультура укытучысының командасы тагын, тагын кабатланды. Бүлмәдә ыгы-зыгы купты, киемнәрне таба алмый йөдәделәр, бер-берсенең чабаталарын, киез итекләрен бутап бетерделәр. Мыгырданалар, балавыз сыккан тавышлар да ишетелеп куя. Ничек кирәк алай кушылган җиргә чыгып тезелделәр.

Физрук укучыларны караңгы урам буйлап алып китте. Төн салкынча, җилсез. Дөм караңгы. Тик янгын сарае тәрәзәсендә генә ут җемелди. Малайлар чаба, капка асларыннан өрә-өрә этләр чыгып, аларга ияра.

Менә басу капкасы да артта калды. Күе гына куаклыкка барып керделәр. Монда шомлы, бүреләр яки җен-пәриләр килеп чыгар кебек. Бот тиңентен кар ярып, тау астына ук төштеләр. Шунда физрук туктарга кушты. Артта калучыларны көтеп алдылар. Кайсы мышный, кайсы кырык-карык йөткерә, кайберләре мышык-мышык борын тарта. Төнозын шаярып ятуның җәзасы шушы икәнен һәммәсе сизенә.

Физрук ачулы тавыш белән әйтте:

— Таң атканчы, без моннан биш чакрымдагы Шушмабаш авылына барып кайтырга тиешбез. Кем дә кем шушы сугышчан бурычын үтәргә әзер, ике адым алга!

Саф дулкынланып ала, әмма берәү дә алга атламый. Бераздан соң Хафиз ялгызы гына физрук каршына чыгып басты.

Алга чыгарга тагын, тагын команда яңгырады. Кымшанучы юк. Физрук малайларны әрләргә тотынды. «Куян йөрәкләр сез, патриотлар чыкмаячак сездән»,— ди. «Ә төн буе хулиганланып чыгарга булдырасыз», ди. Соңгы сүзләргә тәмам җеннәре котырды малайларның. Инде теләүчеләрне алга чыгарга кыстап-кыстап тормыйча, барысына берьюлы «Алга, шагом марш!» командасы бирелсә дә, саф урыныннан кузгалмады.

Менә шушы вакыйгадан соң тагын аралары салкынайды Якуп белән Хафизның. «Бу төнге поход Хафиз эләкләве буенча икән, барысы да йоклап беткәч, мыштым гына чыгып китүен күрүчеләр булган», дигән сүзләр йөрде. Якупның монысына бик ышанасы да килми, әмма Хафизның берүзе алга чыгып басуын һич тә оштамады ул.

Икенче елны Якупка мәктәпкә йөрергә туры килмәде. Семьяның бердәнбер таянычы булып ул калды. Озакламый Хафизның да әтиәнисе белән Үзбәкстан ягына күчеп киткәннәрен ишетте.

Әйе, Үзбәкстан ягына китkәннәр иде алар. Бу якларга ничек килеп чыкты икән? Юктыр, ул белгән Хафиз түгелдер бу. Шулай да очрашсаң күңелле булыр иде. Ни генә әйтмә, вакыт-вакыт ачуланышып-көнләшеп йөрсәләр дә, әйбәт дуслар иде алар. Эй, сагындыра шул чаклар...

*

* *

Малайлар күмер төяп ятканда, алар янына забойдашы Малик белән Харитонов килеп китте. Бик хикмәтле сүзләр әйттеләр алар. «Җир асты,— диде Харитонов,— кәйлә белән китереп төрткән һәр кешегә дә үз байлыгын бирми. Күмернең, аның, һәр килеш-килбәтен, ятыш-торышын аңлый белергә кирәк. Шахтага гашыйк булырга кирәк. Шулай итмисең икән, күмерне дә азаплама, үзеңне дә интектермә».

Малик та хәтердә калырлык сүзләр әйтте: «Эх, тоя белсәгез икән сез, агай-энеләр, күмер исен,— диде.— Аңламыйсыз шул аның күңел түрендә кояш балкытуын. Югыйсә, саф бодай бөртегедәй күмерне таш-комга бутап, пычратып бетермәс идегез. Карагызсана, бөтенләй тәмен җибәргәнсез ич! Бакчы, кайсы хатынның үз миченә ягасы килсен моны! Янган утынны да сүндереп бетерер». Шулай диде дә күмер арасыннан берәмләп бармак башыдай таш кисәкләрен чүпләргә кереште.

Якуп бик уңайсызланды. Түшәмне үз вакытында ныгытырга иренеп, ком-таш койдырган, ә чүпләп ыргытырга башына да килмәгән. Киткәндә Малик аңа ачык итеп әйтеп китте: «Әйе, агай-эне, сез әле забой һавасын аз иснәгән, маңгай тирен кара алтын өстенә аз агызган. Ничава, килер бер көн, Малик абзагызның сүзләрен искә төшерерсез».

Кичен, Хәмзә белән йокларга гына ятканнар иде, бүлмәләренә тагын Харитонов килеп керде. Бүтән малайлар әле кайтмаган. Менә ул керде дә караватт читенә утырды. Өчәүләшеп күзгә-күз терәшеп озак кына утырдылар. Ахырда кунак сүз башлады:

— Я, белгәнегезне укырга тотыныгыз! Лә хәүлә вәлә куатә... Тотып ашыйм хәзер икегезне дә! Иң әүвәл кечтекидән башлыйк.— Шулай диде дә куен кесәсеннән шешә алып, өстәлгә куйды. Якуп белән Хәмзә аның һәр карашын, хәрәкәтен күзләп яталар. Әнә, чылгыйлары өскә таба күтәрелгән кара мыегы астыннан елмайгандай итә. Калын иреннәре селкенеп куя, куллары кисәк-кисәк калтыранып куя. Тышта өздереп ала торган суык булуга карамастан, башындагы эшләпәсен кыңгыр салган — андый киез эшләпәне авылда татар картлары бик яратып кия. Эшләпәсен салса — дулкынланып торган чем-кара чәч. Аягында йонлы ягын өскә каратып тюлень тиресеннән теккән, тездән дә югары унты. Өстендә бүре тун. Бөтен киеме затлы, җылы, үзенә бик килешә. Уң кулының бирчәйгән бармаклары белән мыегын бөтергәли. Гәүдәсе бөкрәйгән булса да, беренче көннәрдәге кебек түгел, таза сыман.

Якуп кыяр-кыймас кына:

— Харитонов абый, нишләп сезне үз исемегез белән йөртмиләр? — дип сорады.

Тегесе бик теләп җавап кайтарды:

— Бүтәннәр шулай дисен, ә сез Хәертдин абзый дип әйтегез. Мин татар, әлегә ана телемне онытмадым. Ә хәзер — салганны тотыгыз! Бу карт пәри сөмсезлек кыла икән диегез! Стакандагы мәй сезгә үтенечем түгел, әмерем. Җә, кайсыгыз?

— Без эчмибез бит, Хәертдин абзый.

— Эх, хөрәсәннәр! Шахтер булыйм дисәң, өстәл янында да егет булырга кирәк. Ашаганда колагың селкенеп, эшләгәндә йөрәгең жил-

кенеп торсын.— Үзе шулай ди, үзе салган аракының чиреген дә чыраен сыта-сыта гына йотты.

«Ятып тору килешмәс» дип, Хәмзә караваг читенә аягын асылындырып утырды.

— Күрәм, сез җәһәннәм артына әҗәл эзләп түгел, чәчәк атарга килгәнсез. Җәһаләт галәмәте ул бездә мәйгә үрелү.— Карт офтанып куеп сүзен дәвам иттерде:— Язмыштан узмыш юк, якташлар. Үпкәм зур сезгә, бик зур. Килгәнегезгә ничә ай, үз кешеләребез бар микән монда дип, гамегездә дә юк. Ә мин, авылдан Донбасска килеп төшкәч үк, дуслар эзли башладым һәм йөзләгән дус таптым. Урысы да, хохолы да калмады.

Якуп белән Хәмзә уңайсызланып, астан гына бер-берсенә карашып алдылар.

Ә Хәертдин абзыйлары һаман сөйләнә:

— Умыртка баганаңны бөкрәйтеп бил бөксәң дә, күл-күл тир түксәң дә, кара сакалың үзеңнән калмый ул... Фани дөнья ачысын да, төчесен дә татыта. Әмма намусны яшьли саф тотарга тырыш икән. Күмер дивары белән ант итәм, бу галәмдә алла да юк, иман да. Бар ие безләрнең дә әдәмгә тәнгәл, җиһанга йөз белән караган чаклары! Җә, кай мәкамьгә сыздыртабыз? «Тәфтиләү»неме, «Галиябану»нымы? Әллә «Коногон»нымы? Телегезне йоткансыз, ахры! Барыбер мин сезне үз итәм, ыланнар, күңел түремә менмәкче буласыз.

Ул моңлы гына җыр башлады:

Шахтер кия шапкысын, тота кулына лампысын.
Сәгать алтыдан алтыга күрми дөнья яктысын.

Эх!..

Кулмәклеккә алдым ак китән,
Шахталарга, әнкәй, мин китәм.
Җиһан гизеп туйган газиз башкай
Туган илгә бер кайтыр микән?

Аның җырларын малайлар бу юлы, баржадагы кебек, котлары очып түгел, йотлыгып тыңлап утырдылар.

Якупның һаман үз кайгысы кайгы — сорап куйды:

— Хәертдин абзый, күмер чабу сезгә дә җиңел генә бирелмиме әллә?

— Забойщик күмер чабып юана, йолкыш. Бер көн кәйләсен кулына алмаса — сыны ката. Бар икән кулында инәдәй очлы кәйләсе, пәкедәй үткен көрәге, тәнендә җаны да бар дигән сүз. Килегез катыма, иртәдән үк иттифаклы булыгыз: күктәге йолдызларга тикле үзара тәртиптә урнашкан. Күмерне җир астына салучы да бик тә аңлы булган — аркылы-торкылы тутырмаган. Зәһәр нәрсә, хәйләкәр ул — ала белсәң бирә... Кая соң, гармуныгыз юкмы? Патефон тәлинкәләрегез, яңа җырларыгыз?..

Малайлар дәшми. Бик уңайсыз килеп чыкты, ул сораганнарның берсе дә юк.

— Патефон тәлинкәләре алып килмәгәнбез шул. Соратып яздым әле, җибәрерләрме, юкмы,— диде Хәмзә.

— Туган якларыгызны өзелеп сагынсагыз-саргайсагыз, халкыбызның моңнарын сөйсәгез, өемә рәхим итегез, ыланнар. Сезнең өчен һәр вакыт ишегем ачык. Ухановлардан ерак тормыйм, сорарсыз, әйтерләр.

Хәертдин, калтыраган бармаклары белән тун төймәләрен каптыра-каптыра, урыныннан торды.

Ул ишек тоткасына үрелүгә, тук-тук ишек шакыдылар.

Якуп ачып җибәрсә, май кояшы кебек балкып Оксана тора!

— Хәерле кич, егетләр! Атна буена бүлмәгездә очрата алганым юк. Эти шахтага төшерми. Бик кирәк идегез, минем бәхеткә өйдә туры килдегез.— Шулай дип, кыз керүгә үк сүз башлады.

Хәертдин еламсыраган кыланып:

— Исәнме һәм сау бул, хыянәтчеләр токымы,— дип чыгып шылмакчы иде, кыз ишек бусагасына басып, көлә-көлә җавап кайтарды:

— Беркемгә дә хыянәт иткәнем юк, Харитон Харитонович. Ә егетләрне и көттем клубта, и көттем, эзләре дә юк.

«Саннарны кечкә кыймылдатып йөрибез, синдә биләм кайгысы»,— диде Якуп эченнән. Ә үзе:

— Көн саен шахтада кино карыйбыз, шуңа күрә шәһәрнекенә йөрмибез. Ә без сине көттек, килмәдең ич,— диде.

Оксана, бүлдерә күрмәсеннәр дигәндәй, тиз-тиз сөйләп китте:

— Беләсезме, Яша, комсомол комитеты миңа концерт куярга кешеләр табарга кушты. Анда руслар да, украиннар да, якутлар да, татарлар да, бүтәннәр дә катнашырга тиеш. Хор да, ялгыз җыр да, бию дә, гармун уйнау да кирәк. Сез татарча җырларсыз, ярыймы? Теләсәгез биерсез.— Хәертдингә олы зәңгәр күзләрен тутырып карады.— Бу юлы, Харитон Харитонович, карыша күрмәгез, яме? Баржада барганда һич тә артисттан ким җырламадыгыз.— Кара пальтосының җиң очыннан дәфтәр белән карандаш чыгарып, язарга җыенды.

— «Зимагурны»мы, «Каторжан»нымы җырларга кушасыз? Әллә берәр романс сиптеримме? — диде Хәертдин.

— Юк, юк, бүтәнне, тик боларны түгел. Шахта турында да, «Катюша» да ярый. Үзегез белерсез.

— Татар көйләрен җырлармын. «Тәфтиләү»не, «Зәңгәр шәл»не. Үзебезнең Габдулла Тукайны, Мәүлә Колыйны сөйләргә телим... Әгәр дә әүвәлге дәрәҗәм, элгәрге дәртле чакларым булса, фетнәле йөрәккәйләрнең гыйсъяны басыла төшсә. Менә хәзер сезгә аз гына Мәүлә Колый:

> Бу көндә дә, таңда да сагыш,
> Бизәге юк, дегел нәкеш...

Такташыбыз безнең:

> Мин карадым, ә ул йөзкәйләрен
> Ябынчасы белән каплады...

Габдулла Тукаебыз:

> И туган тел, синең белән
> Иң әүвәл кылган догам —
> Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
> Әткәм-әнкәмне, ходам!

Оксана белән малайлар бирелеп тыңлап тордылар: чыннан да, Хәертдин артист шикелле бик матур итеп сөйли. Заманында нинди кеше булды икән бу абзый?

— Репетициягә килербез, концертта җырларбыз, сеңелкәш. Аннан эш тормас. Минем үтенечне дә җиренә җиткерсәң иде: әтиеңә әйт, моннан ары җыен хәчтерүш алдында йөзне кызартмасын минем! Әүвәл аңына алсын: менә бу лавадан зәһәр ялкын дөрләп чыгуы ихтимал. Ә сез, йолкышлар, кирәк сабыгызга язып куегыз: ашлык башын боз бозар, егет башын кыз бозар. Мәгънәсенә тора-бара төшенерсез.

Якуп бик гаҗәпләнеп тыңлый: бозның ашлыкны бозып киткәнен яхшы белә ул, ә нишләп шушындый матур кыз егет башын боза икән? Сихерле микәнни? Кызык та соң бу кеше!

Хәертдин серле сүзләрен һаман дәвам иттерә.

«Бик тә чуар йөрәкле икән бу,— ди Хәмзә үз-үзенә.— Тагын нинди хикмәтле сүзләр сөйләр икән?»

Ләкин Хәертдин бүтән сөйләмәде, саубуллашып чыгып китте.

— Гафу итегез, егетләр, башка бүлмәләрне дә әйләнәсем бар,— дигән булып, Оксана да урыныннан торды, ничек очынып керсә, шулай очынып чыгып та китте.

Бер кавымнан Хәмзә сүз башлады:

— Якуп дип, Якуп! Авылга хат яздым, тынлыйсынмы? Укыйммы? Якуп:

— Иртәгә, иртәгә,— диде дә юрганын башына ук тартты.

...Оксана Хәертдин сүзләре турында уйланып кайта: «Моннан ары йөзне кызартмасын минем!» дияргә ничек теле бара аның? Харитон абзыйның үпкәләргә хакы юк. Әти аны икенче тапкыр инде, шахтадан китеп юкка чыгып торгач, эзләп алып кайтты да эшкә урнаштырды. Үз участогындагы менә дигән забойга куйды. «Тагын качсаң, жаныңны суырырмын, дустым дип тормам»,— диде. Әле дә хәтерендә Оксананың, әтисе пристаньда уйламаган жирдән аны очратты. Күрүгә үк аңа әйберләр алу турында кәгазьләр тоттырды. Тегесенең күзләре шар булды: «Миңа, хезмәт дезертирына, ун мең сумлык әйбер ышанып тапшырасын?» — дип, баскан жирендә катып калды. Әтисе тагын: «Кабул итеп ал да тизрәк баржага китереп төят, кичкә юлга чыгабыз»,— диде. Авыр сүзле, каты куллы аның әтисе, тоткан жирдән кара көйдерә торганнардан. Ярата ул әтисен, бераз курка да төшә. Шахтерлар да шүрли бераз. «Чакыртып мунча кертер»,— диләр. Шуңадырмы, әллә намусы кушкандырмы, Харитон складтан әйберләрне ала да төятеп тә куя, үзенә уйнап торырга балалайканы гына алып кала.

«Раббым, гомеремдә беренче тапкыр кирәктән, кәйләдән башка дөнья хәтле байлык тоттыралар»,— ди ул, айкала-чайкала үзе китергән шахта җиһазлары арасына кереп утыра.

Оксана, өенә кереп тормыйча, әтисе янына нарядныйга керергә булды, Хәертдиннең теләгән жиренә житкерергә. Тик тыңлармы әтисе, юкмы? «Әйдә, килешерләр әле карт бүреләр»,— диде дә, ярты юлдан кире борылып, өенә таба китте.

*

* *

Теләр-теләмәс кенә кыш үтеп бара. Кояш арканы хәтсез жылыта хәзер. Әмма саран март бөтенләй үк жылы кочагын киереп ачып бетерми әле. Ишегалларында, урамнарда өелеп кар ята, тәрәзә кыекларына тезелешеп чыпчыклар да чыр-чу килми. Нииндидер моңсу яз, сагышлы яз.

Хәмзә бигрәк тә ямансулый: авылда чана ташлаганнардыр, сукага әзерләнәләрдер... Малай-шалай тай өйрәтәдер... Тиздән сабан туйлары житәр... Ат чабышына барырга — мин, көрәшергә Якуп булмас...

Бүген ул өйдән хат алды. Үзе дә дәфтәр битен тутырып куанычын да, сагышын да язып бетерде. Кичен эштән Якуп кайтуга аңа кычкырып укый башлады. Тегесе, бүтән чактагы кебек, чын ихластан тыңлый.

«...Әти, әни, без иртәгә бөтен группабыз белән, кулларыбызга кәйлә тотып, күмер чабарга шахтага төшәбез. Кем күбрәк һәм остарак тураклый белә — аңа «бик яхшы» куячаклар. Якуп электерми калмас, остаруы тәмам житкән. Аны Хәертдин абзый өйрәтә, бик тә гайрәтле кеше. Төяүләрен күрсәң! Кулы-кулга йокмый. Мин дә алардан калышмаска

ант итеп куйдым. Башлап кубарган күмер кисәген истәлек итеп сандык төбенә салып куярмын, кайткач сезгә күрсәтермен. ФЗО мәктәбен тәмамлагач, забойщик булырсыз, диләр. Минем кәйләгә һәвәслегем чамалы, коногон итеп куйсалар ие, шахтадан ат белән күмер ташырга. Бушаган арада җир асты атлары янына баргалыйм, солы каптырам, су эчерәм. Җәй җиткәч, яшел чирәм ашатам әле. Минем өчен кайгырмагыз, хәзергә сау-сәламәт, тамак тук, өс бөтен. Сагынып саргаймасак ярар иде дип, кайтыр көннәребезне саныйбыз. Яңа ел көнне концерт куйдык, Якуп җырлады да, биеде дә. Мин биедем генә. Патефон тәлинкәләрегез озаклады, көтәм һаман. Татарча китаплар да. Бигрәк тә «Совет әдәбияты» журналын укыйсым килә. Шуның тәмам, хушыгыз, туганнар!

Уфа таракларым сынды чәчләремне тарарга.
Таулар биек, баскычлар юк сагынганда карарга.»

Хатны укып чыккач, сәер генә бер кавым дустына карап торды, аннары өйдән алган хаты турында сүз кузгатты:

— Якуп дим, беләсеңме ни язганнар? Синең әниең минем әни янына хатыңны тотып килгән. Сорый икән: «Майшәкәр, телеграм баганасы чәчәк атамыни?» дип. «Саташа башладың мәллә, Мәликә?» дигән җавап ишеткәч, әниең: «Якупҗаным, телеграм баганасы чәчәк аткач кайтабыз, дип әйтеп язган»,— дигән дә кычкырып елап җибәргән. Әни: «Яшь бит әле алар, сабый гына, юри генә язгандыр, ай кебек балкып кайтып керерләр әле бәбчекләрем»,— дигәч, Мәликә апа: «Ай, раббым, баганаларның чәчәк атканын кем күргән? Әтисе дә китеп юк булды шул юкка, инде монысы да»,— дигән. Шулай өй буенча йөргән әниең. Ышанмасаң, укып кара. Нишләп хатыңны җибәрер алдыннан миңа укытмыйсың? Мин һаман укытам ич сиңа. Бер дә кешене кызгана белмисең икән...

— Йокла, яме! Йокыны ачма! — диде Якуп.

Ул тәмам эштән чыгып арган кыяфәттә кайтып кергән иде. Йөзе мич төсле агарган, күзләре кызарган. Хәзер ул баш тиңентен одеялын ябынды да кыймылдыйсы да килми. Хәмзә аның өстеннән одеялын тартып төшерде:

— Якуп дим! Арганыңны онытып тор! Клубка киттек! Оксана килергә кушты. Әйдә, тор инде!

— Иртәгә барам. Йокла!

Шулай көн саен Хәмзә аның белән интегә: иртәгә дә иртәгә...

Атна буе ялгызы гына йөри клубка. Аруын дустыннан ким армый, әмма, аның хәтле күмер чапмагангамы, бик тиз хәл җыя. «Акрын баскан — ат булган, ашыкмый йөргән — ир булган,— ди ул Якуп турында.— Колын анасына адалангандай, Якуп та шахтасына ябышып ята. Булыр булмас көч белән нигә азапланырга ул хәтле!»

Бүген дә ялгызы гына китте Хәмзә клубка.

Оксана аны якты йөз белән каршы алды. Көннән-көн матуррак һәм сөйкемлерәк тоела шушы кыз егеткә, күбрәк аны күрергә йөри дә. Ни кушса шуны үти: плакатлар элә, эскәмияләр тезә. Оксана бу юлы аңа яңа гына чыгарылган стена газетасын залга элеп куярга кушты.

Бөтен газета ФЗО укучыларының тормышына багышланган. Иң уртада бик олы соскы көрәк тоттырып, ерык авызлы Якупны ясаганнар. Шундый ук көрәкләр белән биш-алты малай аның алдына күмер ыргытып тора. Якуп берүзе шуны тәяргә өлгерә.

Газета каршына Судаков килеп басты, авызы колагына җиткән.

— Молодец, Әхмәтҗанов! Синең белән без махы бирмибез,— дип телен шартлата.

— Әйе шул, яуда батыр бер иде, яу үткәч бар да батыр,— дип куя ялпык борынлы бер малай.

— Яша тирләп-пешеп күмер төягәндә, өем өстенә кем сузылып менеп яткан иде?

— Күмер төяү сиңа пипруз кабып, борын күтәреп йөрү түгел шул!

— Яша егет тә соң! Күпме мактасаң да артык булмас...

Гәпләшәләр, көлешәләр малайлар. Хәмзә уйларына кереп баткан. Якупның җан теләгәне трактор да машина иде авылда, ә хәзер мактаулы шахтерга әйләнеп бара. Адалана, шахтада азау ярыр, ахры. Башыкүзе белән эшкә баткан, бичара. Кул-аягы сызлаусыз булсын.

Мәшәкатьләр, борчу-шатлыклар белән ямьле җәй дә житте. Тау итәкләрендәге ком-таш араларына көчле тамырларын батырып үскән карагайлар кыш буе кәүсәләрендә асылындырып яткызган сап-сары ылысларын яшелгә алыштырдылар. Мәңгелек сазлык өстенә дә чәнчә бармак озынлыгы гына мүктән яшел җәймә җәелгән. Ургыл буйларында, очлары күккә ашкан усакларда ала каргалар, саесканнар, ә палаткалар тирәсендә чыпчыклар күренгәли. Тик туган якларында сагынасагына көтеп ала торган кара каргалар да, йөз төрле көйгә сайраучы сыерчыклар да бу якларга килми икән шул. Очмыйлар алар әлегә бу якларга. Көндезләрен чыдамаслык бөркү булса, кичтән үк җылы киенергә кирәк. Җәй дигәне дә бер-ике ай гына, ул чакларда да Ургылдан боз аккалый, ерактагы тау башларыннан ишелеп кенә тора. Ничек кенә кырыс булмасын, җәйне барысы да зарыгып көтте. Ник дисәң, кайтып китәр көннәре якыная ич. Күбесенең чемодан төбендә бүләк-санак, чәй-шикәре ята. Шушы көзгә укый башлауларына ел тула, аннары бер айлык ял бирәчәкләр өйгә кайтып килергә.

Их, тизрәк житсен иде шул көннәр!

Туган-үскән җирләрдә туйганчы аунап, һавасын сулап, катык-сөт эчеп, әти-әниләр, туган-тумачалар белән туйганчы чөкердәшеп-гөрләшеп, сабан туйларында гармунга җырлап килгәч, яңа дәрт белән, чын шахтер булып эшкә башларлар иде.

Ләкин ул шатлыкларны күрергә язмаган икән аларга. Чемоданэрҗәләрне төяп юлга чыгарга дип торганда, 1941 елның дәһшәтле июнь таңы килде.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Канлы сугышның ялкыны Ерак Көнчыгышта да көйдерә башлады. Донбасс, Ростов шахталары дошман кул астында калгач, партиянең Үзәк Комитеты һәм Дәүләт Оборона Комитеты тиз арада Себердә һәм Көнчыгышта күмер чыгаруны унлата арттыру бурычын куйдылар. Шул хакта газеталарда языла, җыелышларда сөйләнә. Клубта һәм китапханәдә, урамнарда һәм ашханәләрдә, эш урыннарында, хәтта мунчада да бурычны намус белән үтәргә өндәгән лозунглар, плакатлар эленгән. Партиянең район комитеты «Октябрьның егерме дүрт еллыгына Беренче шахтаны файдалануга тапшырыйк!» дигән мөрәҗәгать белән чыкты. Исеме генә түгел, бу әле Ургылда чын мәгънәсендә беренче шахта.

Бу көннәрдә җир асты да, шәһәр үзе дә казандай кайнап тора. Җир өстендәгеләргә генә түгел, забойда, ныгытуда эшләүчеләргә дә фронтка китәргә повесткалар килә. Шундый кәгазьне бүген Малик та алды. Менә ул эш урыны белән исәп-хисапны өзеп, төрле хисаплардантеркәүләрдән төшеп, шәһәр буйлап чаба-чаба, тәмам арып кайтып керде. Әле хатыны Фатыйма эштән кайтып өлгермәгән, малайлар билләмдә, энисе дә килене янына киткән иде.

Пычкысын һәм көрәген, кәйләсен һәм балтасын вазелин белән майлап чүпрәккә төрде дә чолан стенасына элеп куйды. Ата-бабасыннан мирас булып калган шахта лампасын самавар шикелле ялтыратканчы ком белән агартты, керосин салды, ут кабызды да өстәлгә утыртты. Бик озак карап торды ул лампага. Аннары ишегалдына чыгып китте. Өй түбәсенә, йорт стеналарына күз салды. Әле бу өйдә тыныч кына йөз ел яшәргә дә була. Малик шушында усак кисеп, өмә ясап салып чыккан иде бу йортны. Быел җәен шушы төпләрне казып ташлап, бәрәңге һәм яшелчә утыртырга хыялланып йөрде. Шәһәрдә беренче булып кәбестә, кишер, суган үстереп карамакчы иде. Ул бөтен гомере буенча бәхетне үз кулы, үз көче белән тапты. Җилкәсеннән тирәүләкләр, кулыннан балта-пычкы төшмәде, әмма эшеннән һәм тормышыннан тәм, ямь табып яшәде. Фашистлар ил өстенә афәт төшермәгән булсалар, бөтен гомерен шахтада эшләп уздыру иде исәбе. Әйләнеп кайтыр әле ул. Аны монда әнисе, хатыны, балалары, иптәшләре, йорт-җире һәм өй эчендә балкып янган шахта лампасы көтә, балта-пычкысы көтә.

Менә ул капка төбендәге эскәмиягә килеп утырды. Әти-әниләрен, үзенең бөтен тормышын күңеленнән уздыра башлады. Әби-бабалары Казан каласы тирәсендәге бер авылда яшәгәннәр. Гомер-гомергә җирсезлектән, ярлылыктан иза чиккәннәр. Ат-арбага акча юнәтергә дигән булып, әтисе Донбасска чыгып киткән. Кая барсаң да, кара сакалың артыңнан калмый икән шул: бөкре белән шахта лампасыннан бүтән нәрсә алып кайта алмаган.

Беренче бишьеллык чорларында Малик та әтисенең шахта лампасын алып, Донбасска китте. Электән балта тота белү шахтада да бик ярап куйды, аны агач эшенә — җир астында тирәүләр куючы, шахтерча әйткәндә, ныгытучы итеп билгеләделәр. Бик тиз арада дус-ишләр табып өлгерде, йөзләренә кызыллык төшермичә, тату яшәде. Аның алтын куллы, аз сүзле булуын бик яраттылар. Әмма Фатыймасы гына иләнеп җитә алмады, авылын өзелеп сагынды. «Китик моннан!» — дип интектерде. Үгетләүләр, иркәләүләр дә җиңә алмады аны: ирен калдырды да туган ягына кайтып китте. Яратышып яшиләр иде, бик яратышып, рәхәт торалар иде. Икесенә бер бүлмә, йорт җиһазлары, кием-салым юнәткәннәр иде. «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил»,— дип, борын-борынгыдан юкка гына җырламаганнардыр зимагурлар. Ләкин «кан тартмаса да, җан тарта» дигәне дә бар бит әле. Соңгысы җиңде, һәм Фатыймасы ире янына кире әйләнеп килде. Шулай ике малайлары туды. «Ерак Көнчыгышта күмер ятмасы эзлиләр икән, анда аның иге-чиге юк икән, җитмәсә, ул өстә генә дип әйтерлек ята икән»,— дип ишетте Малик. Түзми янар йөрәк: язылып, шунда китеп тә бардылар. Алар килеп төшкәндә, монда хәтта палаткалар да юк иде әле, беренче атналарын шалаш корып яшәделәр. Шәһәрдә беренче казыкны үз кулы белән Малик какты. Беренче шахтаны казый башлаганда беренче көрәк балчыкны да ул алып ыргытты һәм, вакыты җиткәч, тирәүне дә беренче булып куйды...

Әнә, аның әнисе белән Фатыйма да кайтып килә. Нәфисә әбинең бер-ике генә теше калган, бите тулы җыерчык, озын гәүдәсе, сыгып алган сөлектәй, юка. Өстенә сырма бишмәтен элгән, башында бүрек. Ул да заманында картына ияреп зимагурлыкта йөргән, күпне күргән. Ә килене карчыкның нәкъ киресе, су мичкәседәй юан гәүдәле, беләкләре бүртеп-бүртеп тора, төскә-биткә дә ярыйсы. Гадәттә такылдарга ярата да, бүген йомыкыйланган, күз төпләре шешенгән. Сүз ялганып китә алмый: әйтәсе күптән әйтелгән, түгеләсе яшь тә түгелгән. Нәфисә карчык Гитлерны каргый, сүзләре авызыннан сызгырып чыга:

— Мөрәвәтсез мөртәт, муйны астына килгере бәдбәхет!.. Килер бер көн, килер, чәнчелеп китәр! Утыз көн уразаның бер гаете булмый кал-

мый ул! Әй син, улым, коштай әйләнеп кайтырсың. Синең әле шахтада тау-тау чабасы күмерең кала, без калабыз. Өзелеп көтәрбез, теләк теләрбез.

— Рәхмәт, әнкәй! Теләгең изге сәгатьләрдә булсын!

Төннең бик кыска чагы хәзер, бөтенләй юк дип әйтерлек. Маликның китәр сәгатьләре, саубуллашыр минутлары да житеп килә. Өчәүләшеп өйгә керәләр, кирәкле әйберләрнең барысы да салынганмы дип, юл капчыгын тикшереп чыгалар. Аннары өчесе өч жирдә утырып дога кылалар. Бераздан Малик телгә килә:

— Үтенечем шул: лампамны көн саен шушында өстәлгә куеп яндырыгыз. Истәлек кенә булып түгел, якты өмет булып янып торсын каршыгызда.

— Ярый, ярый, Малик. Шул лампадай балкып кайтып керергә язсын! — ди Фатыйма, балавыз сыга-сыга.

— Тынычлан, анасы. Синең өскә генә төшкән авырлык түгел. Тагын бер үтенечем: үзеңне сакла!

Малик йоклаган малайларын уятып бик озак итеп күкрәгенә кысакыса үбә. Урамга чыгалар. Саубуллашу өчен күршедәге иң якын дусты Хәертдин өенә таба атлыйлар. Ләкин ул үзе, таягына таянган килеш, ашыга-ашыга болар янына килә. Бик каты ябыккан, саргайган, атлаулары да алпан-тилпән. Кул биреп күрешәләр. Ярты гомерләрен диярлек бергә яшәделәр, ничәмә еллар бер забой тузанын эчтеләр, ә Маликны рәтләп күргәне булмаган икән Хәертдиннең. Карап туймаслык кеше икән ич бу Малик!.. Мондый киң җилкәләрне, таза буй-сынны бер аңа гына биргән икән тәгаләсе. Азынып-тузынып йөрмәде, авызы ни әйткәнен колагы бик яхшы ишетте. Җирән чәчен, сакал-мыегын кыркып ташлагач, яшәреп киткән кебек. Шулай да кысык зәңгәр күзләре уйчан бүген, нур чәчеп тормыйлар. Йонлач саргылт кашлар да сынык. Шушындый искитәрлек кешеләр кулында булганга күрә гөрләп яшәгән икән шахта...

Сүзне Хәертдин башлый:

— Әгәр дә мәгәр үземне алсалар, каһәр суккан Гитлерның сыртын каезларга бүген китәрием.

— Син инде, кордаш, монда махы бирмә! Ярый, туганнар, юл кешесенең юлда булуы яхшы.

Урам буйлап атлыйлар. Аларга Алеша белән аның хатыны Талига да килеп кушыла. Яңадан бер төркем фронтка китүче шахтер куып житә. Хәрби комиссариат янында төркем-төркем кеше басып тора. Гел елаш кына түгел монда, гармун-җыр тавышлары да ишетелә.

Талига иренең муенына асылына, күп елаганнан күзләре шешенеп беткән, сүзләрен әйтә алмыйча тотлыгып азаплана, күз яше бугазына төер булып утырган. Алеша аны ничек тә юатмакчы, тынычландырмакчы итә, булдыра алмый.

— Йөрәккә кояш ташучы кыз, бәгърем, көт мине, ямe? Матурым, йолдызым минем, сүнмәс утым, сөмбел чәчәгем! Мин синең янга жиңү яулап кайтырмын... Тукта, яшь түкмә инде шул кадәр? — Маңгаеннан, битләреннән, күзләреннән бертуктаусыз үбә дә үбә, аннары хатынының башын күкрәгенә куеп сүзсез кала.

Менә бер төркем малайлар белән Илья да килеп житте. Аңа яңарак кына унсигез тулган иде, ул да армиягә китә, иптәшләре аны озатырга килгән. Ул бүген дә үзен иптәшләреннән өстенрәк тотарга тырыша, әмма авызы ерылган булса да, ара-тирә күзләре юешләнеп ала. Җитди генә әйтә:

— Эх, егетләр, шунысы үкенеч, Яша белән көч сынашып карарга иде исәп. Булмады. Аерылабыз.

Якуп күренмәгәч, кайсыдыр җавап кайтара:

— Кайткач, кайткач, Илюша. Без синең махы бирмәсеңә ышанабыз ич.

— Син анда Гитлерның сыртын сындыр, арт сабагын укыт тизрәк! Без монда синең өчен дә берәр эшелон күмер чыгарырбыз. Билләһи дип әйтәм...— ди Хәмзә. Ул һаман Илья тирәсендә кайнаша: күңеленә хуш килгән иде бу малай.

— Барып җиткәч, ничек сугышканыңны әйтеп яз, яме?

Ул арада Якуп та йөгереп килеп житте.

— Эх, Илюша, бәхетле дә син! Фронтның үзенә үк китәсең, безнең кебек ерактан гына кызыгып калмыйсың. Кулында винтовка булачак. Бәлки туптан да атарга туры килер. Ә безгә монда кәйлә дә көрәк.

— Бер дә офтанма, Яша, киләсе елга үзең дә караласы.

— Без сине көтәрбез, Илюша.

Илья иптәшләре белән кул биреп күрешеп чыга да хәрби комиссариатка кереп китә.

Озатучыларның изге теләкләре белән машинага төялеп шахтерлар китеп тә баралар. Ә монда сыкрану һәм елау гына түгел, хатыннар йөрәгендә сагыш кала...

Хәмзәнең күз алдына әтисе килеп баса. Алар да шушылай бик авырдан аерылышканнардыр... Хәзер авылда әни атлар карый, әтием урынына калган... Урман чыгарырга да йөргән... Монда да шахтада кеше кимеп кенә тора, безнең ишеләрнең кыйммәте арта... Әнә, Талига апаны да култыклап кайталар, үксп дә үксп, бичара...

*

* *

Күзләренә төшкән кояш яктысыннан Хәмзә елмаеп уянды. Башын мендәр өстеннән калкытты да тирә-якка каранып алды. Бүлмәдәге алты караватның өчесе буш иде. «Бу малайлар төнге сменадан кайтмаган икән әле, вакыт иртәдер»,— дип уйлап куйды ул. Кичә Хәмзә көндез эшләде, ә бүген аңа төнгә чыгасы. Димәк, көнозын диярлек вакыты буш. Мастердан рөхсәт сора да кирәкле йомышыңны юлла. Ә барасы юллар бармак белән генә санап бетерерлек түгел. Тик менә торасы гына килми. Кичә бик каты эшләде, и тырышты, и тырышты забойдагы бөтен күмерне төяп озатырга, тәки булдыра алмады. Нинди гарьлек! Әнә Якуп барысының маңгаена чиртә, ичмасам.

Сугышка хәтле шахтерлар бәхетле дә булганнар соң! Алтышар сәгать эшләп, кесә тутырып акча алганнар, кибетләр тулы кием-салым, ашамлык булган. Ялын да алганнар, туган якларына да кайткалап йөргәннәр. Шәп яшәгәннәр. Сугыш бөтенесен җимерде дә салды. Ипи дә, ашау-эчү дә нормага калды, эш сәгатьләре дә ун ителде. Менә инде ике ай диярлек көн саен фәлән-фәләннең яраланган яки үлгән хәбәре килеп тора. Олы шахтерларны һаман озаталар, эшләргә кеше кими дә кими, шахта малайлар кулына кала бара...

Ямансу уйларга чумып яту егетлек түгел, кояш нурлары да тәрәзәдән тикмәгә генә кереп тулмаган. Егет күңеле һәр вакыт бер булырга тиеш, юкса, адашып китүең дә ихтимал.

Эх, рәхәт тә икән тышта! Кояш баш түбәсендә генә кыздыра. Эссе, бераз бөркүрәк тә кебек, шулай да җанга рәхәт.

Ашханәгә кереп көндезге норма белән тамак ялгап алгач, Хәмзә тар сукмак буйлап турылатып кына клубка таба юл алды. Клубта бик күп китаплы китапханә бар. Анда китап биреп тора торган Оксана бар. Култык астындагы китапларын хәзер ул Оксана янына кереп алыштырачак. Оксана китап тәмен күп татыган кыз, мактыймактый моңарчы ишетмәгән-күрмәгәннәрен тоттырып җибәрә. Күп тә

белә шул кыз! Тоттырган бер китапның эчтәлеген аңлата. Эх, тизрәк русчага өйрәнеп житәргә иде дә татарча укыган һәр китабыңны аңа да сөйләп бирергә иде! Булмый шул. Ярый әле, забойлар турында авыз ачмый, начар эшлисең дип әрләми...

Оксананы уйлап, клуб ишеге төбенә килеп житкәнен сизми дә калган. Керергәме, кермәскәме? Нишләп бу малай гел монда килеп йөри дип уйламасмы?

Көтмәгәндә ишек ачылды да, клубтан житез генә Оксана үзе килеп чыкты, гажәпләнеп Хәмзә каршында туктап калды.

— Алыштырасы иде,—дигән булды Хәмзә, бераз ык-мык итеп торганнан соң.

— Укып та бетердеңмени шул арада? — Оксана хәйләкәр дә, серле дә, ягымлы да елмая иде.

— Мин китапны йотам гына...

— Беләсеңме, Хәмзушка, минем белән барырга телисеңме? — дип сорады Оксана житдиләнеп.

Бармыймы соң Хәмзә. «Кая?» дип тә сорамады, «барам» диде атлыгып.

Култык асларына китап төяп, барактан баракка, палаткадан палаткага, өйдән өйгә кереп китап таратып, китап жыеп йөрделәр алар.

Эх, күңелле дә үтә бүген Хәмзәнең ял көне! Шушылай янәшә кичкә хәтле йөрер иде аның белән, таратырга дип алып чыккан китаплары бетте дә китте бит. Бигрәк кыю, бигрәк туры сүзле, үпкәләр дип тә уйлый белми торган шаян кыз бу Оксана, юл буе үртәп, оялтып бетерде Хәмзәне.

— Хәйләкәр дә син, Хәмзушка, миңа ияреп чибәр кызлар күзләп йөрисеңдер әле,— дигән була, текәлеп карый. Аннары, бөтенләй клуб янына әйләнеп кайткач, бармак янаган булып әйтте:— Кара аны, икенче сине ияртеп йөрисем юк. Ә мин синең көн аралаш китап алыштырырга гына килмәгәнеңне беләм. Нигә дисең?

Нәрсә дисен Хәмзә, кызарып тик тора: болай булырын белсә, бүген клубка ике аягының берсен дә атламаган булыр иде.

— Кинога... Концертка...

— Ябышмый, Хәмзушка. Алдаша белмисең.

— Алайса, үзең әйт. Нигә?

— Мине күрергә. Шулаймы?

Бу сүзләр үтерде дә салды малайны. Ничек иттереп: «Әйе, сине сагынып киләм»,— дисен.

— Теләмәсәң... Ошатмасаң...

— Әллә килмәс идеңме? — Бу юлы Оксананың йөзе житди иде, бусы инде коры шаярту гына түгел бугай. Һәрхәлдә, Хәмзәгә шулай тоелды.

— Син ачуланмасаң, мин гел-гел китап алыштырып йөрер идем, Оксана. Ачуланма, яме?! — диде.

— Ә бүген алыштырып китмисеңмени?

— Укып бетергәч.

— Бик озак укыма, яме, Хәмзушка.— Эх, матур да, ягымлы да иде бу минутларда Оксананың күзләре, һәр карашы, һәр сүзе.

— Иртәгә бетерермен.— Бер дә китәсе килми генә китеп барды шул бүген Хәмзә клубтан. Урам чатына борыла башлаганда, артына әйләнеп карады... Һәм үзәкләре өзелеп китте: Оксана кул болгап куйды. Нигә генә борылырга булган!.. Бу бит үз аякларың белән упкынга барып ташлану! Ян менә хәзер кеше утында... Хәер, нигә кешенеке булсын, йөрәге шулай куша бит. Бәлки... Бәлки бөтен кешедә дә мәхәббәт шулай башланадыр... Әллә Якуптан сорашып белергәме? Ул олырак егет, белми калмас. Бу утта януы газаплы да, рәхәт тә икән.

Хәмзә татлы уйларга батып, атлар абзарына да килеп житкән. Утарда йөргән Акбуз аны әкрен генә кешнәп каршы алды. Аның яллрыннан бераз сыйпаштыргалагач, Хәмзә Ургыл буена чапты.

Кур әле, тубыктан чирәм икән монда! Сары чәчәк тә ак чәчәк басып бетергән бу төшләрне. Җәй көннәрендә ярыйсы гына ямьле икән бу якларда! Авыл болыны диярсең. Тик аллы-гөлле, кызыллы-зәңгәрле чәчәкләр генә житми. Әмма узган көзне һәм быел язны бу жирләр тагын да ямьлерәк иде, тирә-як шаулап-гөрләп тора иде. Әле анда, әле монда шаркылдап көлгән хатын-кыз тавышын, салмак кына гәпләшкән ирләр тавышын ишетергә була иде. Кая гына карама, агач аударып йорт салалар иде.

Сагынып сөйләргә калган икән ул көннәрне!

*
* *

Шул ук көнне, кичкә таба, Якуп та Ургыл буена барып чыкты. Ярсу куңелен шушы ярсу елга буенда гына басар кебек тоелды аңа.

Ә кунел кузгатырлык сәбәпләр житәрлек иде бу көннәрдә. Механически мастерскойда слесаре дә, токаре дә яшь кенә кызлар хәзер. Шахта янына терәүлекләрне дә ат белән урманнан олы-олы апалар ташый. Инде алтмышның теге ягына баскан Прошка агай шартлатучы булып элекке эшенә кайткан. Көндезен ФЗО малайлары күмер төяп торган штрекка Уханов килеп чыкты. Ябыккан, зур зәңгәр күзләре элеккечә елмаеп тормый. Олы гәүдәсе кечерәебрәк калган кебек. Сөйләп алды: тиздән Ургылга тимер юл килеп житә, аннары безнең эшләр шактый жиңеләя, ди.

Аяклары Ургыл буена таба атлады. Монда, чыннан да, тынычлангандай булды. Тик карт усаклар гына, туктаусыз шаулап, куңелгә шом салалар иде.

Юкка гына шауламаганнар икән усаклар.

Кинәт якында гына үксеп-үксеп елаган тавыш ишетелде. Хатын-кыз елый... Мондый елауларны соңгы вакытта шактый ишетте инде Якуп. Ләкин монысы... Әйтерсең кемдер бөтен түгел, ә Якупның үз куңеле шулай сыкрап үкси башлады кебек.

Якуп шул якка таба китте. Аяк астындагы чыбык-чабыкларны сындырмаска, кыштырдатмаска тырышып кына атлады, әйтерсең ярамаган жиргә таба бара төсле иде. Бераздан елаучыны күреп алды. Әнә ул яшь шомырт агачын кочаклаган да башын агачка бәрә-бәрә елый. Бер якка салынып төшкән озын толымнары чайкала-чайкала гәүдәсенә орынып-орынып китә.

Инде караңгы төшеп килә иде. Шулай да Якуп елаучыны күрүгә ук таныды. Талига ич... Мондый озын толымнар, мондый зифа гәүдә биредә бары анда гына. Ашханә буфетында талонга ипиен, тегесенмонысын үлчәп биреп торучы көләч йөзле Талига... Нәрсә булган аңа?

Якуп аңа якын ук килде, ни әйтергә белмичә, туктап калды. Талига, янында кемдер барын сизеп бугай, елаудан туктады, ләкин башын күтәрмәде.

— Талига, нәрсә булды? — дип, ярым пышылдап сорады Якуп.

Талига елаудан туктаса да, һаман сулкылдавын тыя алмый иде әле. Шуңадыр, күтәрелеп бер генә карап куйды да янадан шомыртка иелде.

— Башта ышанмаган идем...— диде бераздан,— Малик абый язган булган Фатыйма апага... Алеша һәлак булды дип... Инде менә военкоматтан хәбәр алдым...

Якупның бөтен эче кайнарланып киткәндәй булды.

— Их, бу фашистларны!..— диде, тешләрен кысып.

Талига, шомырт агачыннан кулларын алуга, чайкалып китте дә егылмас өчендер Якупның җиненнән тотты. Якуп икенче кулын Таliганың кулбашына куйды.

Акрын гына шәһәргә таба атладылар. Саз җирләргә салынган тар басмалардан бер-беренә сыенышып ук үттеләр алар. Хатынның кайнар тәнен тоюы Якупка бик рәхәт тә, шул ук вакытта бик уңайсыз да иде. «Кешенең, ихтимал, мәңге сүрелмәс хәсрәтле чагыдыр, ә син...» дип, үз-үзен тиргәп барды ул.

Ул бүлмәгә кайтып кергәндә, инде барлык малайлар да йоклап беткән. Тик Хәмзә генә китап укып утыра иде. Әллә укыган китабы бик кызыклы — йөзе кояштай балкый иде Хәмзәнең. Ишектә Якупны күргә, авызы тагы да ерыла төште.

Һәм дустының йончыган кыяфәтен күреп, кинәт тукталып калды.

Якуп өстәлдәге графинны күтәреп, голт-голт су эчте, акрын гына үз караватына барып утырды.

— Син Алешаны беләидеңме? — диде.— Ашханәдәге Талиганың ире.

— Нигә белмәскә Алешаны. Мактаулы шахтер иде бит ул. Газеталарда да гел язалар иде аның турында.

— Менә шул кеше инде дөньяда юк. Фашистлар башына җиткәннәр аның.

— Ихх!..— дип кенә әйтә алды Хәмзә.— Ә без монда укыган булып йөрибез. Шушындый чакта...—диде ул бераздан, кемдер артына төрткәндәй, утырган җирендә сикереп-сикереп куйды.

— Җитәр! Иртәгә үк мастерга әйтергә кирәк, эшкә күчерсеннәр безне. Өйрәнеп җиткермәгәнен эш үзе өйрәтер! — Якуп идән буйлап йөренергә кереште.

Башта алар, иптәшләрен уятмас өчен, ярым пышылдап кына сөйләшеп утырганнар иде. Соңга табарак аларның тавышы күрше бүлмәләргә дә ишетелерлек яңгырый башлады.

Ни арададыр бүлмә эче йокылары качкан малайлар белән тулды. Кызу бәхәс китте. Үзбаш эшкә күчәргәме, әллә уку срогы тулганчы, мастерлар, тәрбиячеләр канаты астында, әзергә хәзер булып кына яши бирергәме?

* * *

Иртәгесен участок начальнигы Уханов бүлмәсенә йөзе кояштай балкыган Степанов килеп керде.

— Эшләр харап, начальник,— диде ул, җитди булырга тырышып та, һич ничек булдыра алмыйча.

— Нәрсә булды?

— Минем бөркетләр восстание күтәрделәр анда...

Ухановның бик кәефсез чагы иде. Эш бармый, кешеләр җитми, техника җитми, ә югарыдан «Давай план!» дип телефон шалтырый, телеграммалар килә, вәкилләр килеп төшә, шахта идарәсе начальнигы Михайлов үзе көн-төн шахтада ята...

— Аңлатыбрак сөйлә!

Степановның шунда гына авызы җыелды. Ашыкмыйча гына сөйләп бирде. Башка көннәрне туптан атып та уятып булмастай малайлар бүген иртән мастерны барысы да торган-киенгән хәлдә каршылаганнар. Шау-гөр килеп аңлата башлаганнар: укып йөрер чак түгел, җитте, без эшләргә телибез, дигәннәр.

— Һаман да шул кыбырсык җан Әхмәтҗанов башлап йөри,— дип сүзен бетерде Степанов.

Ухановның бергә кушылган күе кара кашлары язылып китте.

— Чыннан да бөркет егетләр тәрбияләгәнсең, Федор Иванович. Молодец!

Степанов авыр гына көрсенеп куйды.

— Чын бөркет икәннәрен бүген генә белдем мин аларның. Ай, үзәкләргә үткән чаклары булды. Якаларыннан бөтереп алырдай була торган идем. Баксаң, үзәкләре нык икән...

Шул ук көнне Уханов ФЗО укучыларының теләген тиешле оешмаларга җиткерде. Озакламый ФЗО егетләрен «Сивак» участогына үзбаш эшкә күчерделәр. Үз язмышларына үзләре хуҗа хәзер алар. Гомуми торакның җылы бүлмәләреннән палаткаларга күчтеләр.

Күп тә үтмәде, өйрәнчекләре артыннан Степановның үзен дә «Сивак»ка десятник итеп җибәрделәр.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Палаткада беренче булып Якуп уянды. Әле караңгы иде. Торыргамы, юкмы? Бәлки әле йоклыйсы вакыты шактыйдыр? Юк, торырга кирәктер. Әнә, тәрәзә аша әчкә аз гына яктылык үрелә башлаган.

Якуп палатка эчен яңгыратып аваз салды:

— А ну, күпме ятарга була! Торыгыз! Кузгал, эшчеләр сыйныфы!

Малайлар әле анда, әле монда селкенгәлиләр, әмма торырга гамьнәрендә дә юк. Җылы юрган астыннан һич кенә дә торып чыгасылары килми.

Якуп күршесендә яткан Петяның юрганын тартып төшерде, аннары берәм-берәм бүтәннәрне дә төрткәләде. Кайберләре аны санга сугыпмы, үзләре теләпме, торып киенә башлады.

Якуп карават астыннан көрәге белән кәйләсен тартып чыгарды, кичтән үк тимерчелектә очлатып куйса да, печән чапканда чалгы йөзенең үткенлеген тикшереп караган кебек, кәйләсенең очын бармак битләре белән кармалап карады, бераз йөзе дә ачылып киткәндәй булды. Ишектән чыгып сызарга гына торганда, Петя кисәтте:

— Яша, ашханәдә мина да чират алып тор, яме?

Бу яньчек борынлы, табак битле малай буйга-сынга да, көчкә-куәткә дә Якуптан калышмый. Үзе саргылт йөзле булса да, чәче һәм кашлары җете кара. Аның кабаланып эшләвеннән көлсәләр дә, тырышлыгын күреп яраталар малайлар. Соңгы көннәрдә ул Якупның көндәше дә.

— Петя, бүген нинди көн икәнне онытма! — диде Якуп ишектән чыкканда.

Көн чалт аяз булырга охшый. Айдан артык инде Якупның көннәрнең нинди булганлыгын күрә алганы юк. Хәтта кояшны да күрә алмый. Иртән кояшның таулар өстеннән сузылып киткән озын-озын кызыл нурларын гына күреп кала да шахтадан караңгы булгач кына чыга. Көн саен шушы вакытта торып иптәшләре белән ашханәгә ашыга ул. Башка көннәрне бергәләп сөйләшеп баралар иде. Ә бүген — юк. Аңа беренче булып ашханәгә керергә кирәк. Юкса, ашханә ачылганчы ук ишек төбенә чират тезелгән була.

Эх, нигә ашкына икән бу күңел дигәне? Сөенечкә генә булса ярар иде. Шунадыр, юкса, иртән иртүк торып тамак туйдыру өчен генә тилпенмидер ич ул күңел!

Алар палаткасыннан ашханәгә тикле ике-өч чакрымнар бардыр. Бу арага сукмакны да инде йөз еллар элек үк авып беткән черек

карагайлар, усаклар, биек-биек абагалар, еланнар тулы үлән аша малайлар үзләре салдылар. ФЗО дан «Сивак»ка күчкәннән бирле шахта белән ике араны шушыннан таптыйлар.

Иөгереп бара диярлек Якуп. Ашханә ишеге төбендә әле кеше күренми. Шулай ул бик иртә килде микәнни? Әллә соңгарак та калганмы?

Юри генә, ачар-ачмасларына ышанып та түгел, ишеккә төртте, ә ул ачык икән, берничә кеше өстәл артында ашап утыра иде. Якуп, кәйләсе белән көрәген бер почмакка сөяп, буфет янына килде, ипи һәм ашамлык карточкаларын буфетчы хатынга сузды. Һәм... күзләре Талига күзләре белән очрашты. Талига авыз чите белән генә елмаеп куйды. Талиганың мондый матур елмаюын күптән күргәне юк иде Якупның, дөресрәге, сугышка хәтле генә күргәне бар иде. Күптәнге танышына елмайган кебек якын итеп, үз итеп елмаю иде бу. Һәрхәлдә, Якупка шулай тоелды.

— Исәнме, Талига? — диде ул.

Талига җавап кайтарды. Аннары: «Ябыгып киткәнсең, Якуп»,— диде.

Якуп аның бу сүзләренә көлемсерәп кенә җавап кайтарды да буш өстәл янына килеп утырды. Официантка кыз аның алдына бәрәңге боламыгын тәлинкә тутырып китереп бирде, гадәттә, ярты да булмый торган иде. Ипи дә мулрак шикелле. Талига кулы иде бу...

Ашханәдә ул эшне тиз тотты. Мунчада да эш киемнәрен киенгәндә кулы-кулга йокмады.

Эх, бу эш дигәннәре! Көченне кызганмыйча, маңгай тиреңне чишмәдәй агызып күмер төяүдән дә куанычлырак нәрсә юктыр дөньяда. Юкса, ул бит кунакка яки кыз алырга бармый. Барасы җире нибары забой гына.

Забой дигәннән, аларның да төрлесе була. Тубыктан су тонып торганы да, өстән коеп яуганы да, буй җитмәслек биеге дә, бертуктаусыз шатыр-шотыр терәүләрне калтыратып күңелгә шом салып торганы да... Ә бүгенгесе коры, иркен, биеклеге дә таманча...

Бүген Якуп үзенең теге табак битле Петя дусты белән кочышырга тиеш. Алар бер штректә икесе ике забойда эшлиләр. Бу штрек ике яклап кара-каршы тишелеп ята. Арада әле бераз гына стена бар. Якуп бер яктан, Петя икенче яктан шул стенаны җимерәләр, аннары забойлар тоташа да төгәл бер штрек хасил була.

Инде айдан артык көтте бу көнне Якуп. Бу штрекнең — су җыйдыргычның — әһәмияте турында участок хуҗаларының авызыннан күп ишетте, газеталарда да язылды. Менә шушы ике забой кушылып, күмердән арынуга ук Беренче шахтаның бөтен штрекләрендәге су, канаулар буйлап, шушында җыелачак. Көчле насослар суны торбалар буйлап тышка кудырып торачаклар.

Беренче көннәрдә шушындый әһәмиятле забойны үзенә ышанып тапшыруларына бераз шүрләп тә алган иде. Тора-бара эшләре җайга салынгач, үзен бераз олыгаеп киткәндәйрәк сизеп йөри башлады, бераз горурлык та уянды. Шул көннәрдән бирле Уханов та аны олы шахтерлар рәтенә кертеп сөйли...

Якуп нарядныйга кереп күренеп кенә чыкты да забоена йөгерде. Күмер шартлатылган, әллә тагы унлап тонна бардыр. Ә теге якка бармак сыярлык та тишек юк. Димәк, штрек тоташмаган, кәйләләп утәргә кирәк, ара якын, шартлатырга ярамый, геологлар шулай әйтә.

Штрек уртасыннан күршедәге «мич»кә тикле сыңарлап кына такта сузылган. Якуп шартлатылган күмерне тачкага төйи дә шушы такта буйлап «мич»кә илтеп бушата. Янып-пешеп чыкты, забойда күмер һаман кими барды. Ул килгән-киткәннәргә дә игътибар итмәде, хәтта

Уханов иртеп килгән газета корреспондентларын да тыңламады, һаман эшен белде.

Күмер төялеп озатылды.

Менә Якуп, бар көченә кәйлә белән кизәнә-кизәнә, утлар чәчрәтеп, күмер стенасын кимерә башлады: тавыш тонык, димәк, ара бик тә якын. Тагын да хозурланыбрак селтәнә, йөрәге, чабыш атныкы кебек, атлыгып тибә. Әһә! Теге яктан Петя җавап кайтара: тук, тук, тук... Шулай тукылдады-тукылдады да туктады... Ул әле һаман күмерен төяп озатмаган булса кирәк, кәйлә белән күмер чапканы ишетелми аның, болай гына, ара чамасын санап кына сигнал бирә. Тавыш бик якын, шушында гына кебек сизелә. Болай булгач, менә-менә кочышачаклар.

Якуп урта бер тирәдәрәк бармак кына сыярлык ярык тапты, шул ярыкны кәйләләп киңәйтергә, тирәнәйтергә керешә. Инде тәмам кулбашларына кабып бетте, муен сөякләре, билләре сулкылдап сызлый башлады, ә ул һаман селтәнде дә селтәнде... «Юк, сыгылып төшмәскә, сынатмаска! — дип куйды үз-үзенә.— ФЗО ны тәмамлаганны көтмичә шапырындылар да бер-ике айдан мәтәлеп тә төштеләр хөрәсәннәр, диярлек булмасын».

Иптәшләре турында кайгыртып уйлангангамы, көч тә өстәлгән кебек сизде үзендә, ныграк бәргәләргә тотынды.

Һәм...

Менә кая ашкынган икән йөрәк!

Кемдер:

— Ура! — дип кычкырып җибәрде.

Теге яктан Петяның уты ялтырап күренде.

Якуп тагын берничә тапкыр селтәнүгә, тар гына күмер стенасы ике якка да ишелеп төште, тоташ штрек хасил булды.

Якупның җиңүе иде бу, зур җиңү. Һәм ул, малайларча, кәйләсен атып бәрде дә үзе ишеп төшергән стена тишегеннән икенче якка атылды, шаркылдый-шаркылдый Петяны кочаклап алды. Икәүләшеп сикерештеләр, куаныштылар малайлар.

*Дәвамы бар*

## Кадыйр Сибгатуллин

### Кибәнче карт

Баллада

Гайрәтләнеп һәм яшәреп кырга килде,
Бер кечерәк эскерт кенә салыйм, диде.
Аптырашып карап торгач, агай-эне
кибәнчегә кыска саплы сәнәк бирде.

Килде йөкләр. Көлтә түгел, салам гына.
Күтәрәләр. Кибәнче карт сала гына.
Гүргә кабык иңгән кебек, әкрен генә
кибәнчегә сәнәк-сәнәк салам менә.

Ыспай булып үсә эскерт, тигез, шома.
Карт кибәнче егет сыман басып тора.
Җыелышкан бу кырдагы барча халык,
тынган басу, карый басу хәйран калып.

Тулды эскерт. Карт кибәнче дәште өстән:
«Соңгы көлтә! Бер көлтә дә сыймый бүтән!»
...Сәнәк төште әкрен генә шуып күптән,
астагылар эзләделәр картны күктән.

Азга гына, ял итәргә генә ятты:
«Бу һавалар, бу күк йөзе бигрәк якты...»
Уйга салды картны гомер агышлары,
моңсуланып көзге кояш баешлары:

*
* *

«Унсигез яшь... егерме яшь... кырык... илле...
Без бик озак яшәгәнбез икән инде.
Бабагызга алтмыш тулды... җитмеш... сиксән...
Дөнья матур, матур итеп гомер итсәң.

Соңгы көннәр инде орчык төбен сүтә,
үткән гомер хәтеремнән кат-кат үтә.
Ул язларым яңаралар уҗым сыман;
унсигездә егет булып басып торам.

Яшь гомердәй җирдән яшел чишмә ургый,
кырда безнең хисләр кебек серкә уйный.
Юллар сыман ерак китә пакусларым,
бергә туктап чалгы яный бар дусларым.

Атлар сыный, ятлар сыный — түземнәрме? —
Чорнап-чорнап тоткан чаклар тезгеннәрне.
Атка менсәк — үзебездәй ярь-яшь тайлар,
яныбызда — ярь-яшь кызлар — сөйгән ярлар.

Җәйләр әнә килә-китә уйнап-көлеп...
Яшьлек серкә уйнап торган басу кебек.

*
* *

Менә көзләр килде тагын сабырланып,
нурлар тулды башакларга сарыланып.
Без береккән бу кырларга тамырланып,
күңел тулды ир чагымны танып алып.

...Учларымда моңлы кыллар — сары камыл,
чыңлап тора: урак белән генә кагыл.
Каерып-каерып арыш урам чын ир булып:
көлтәләрем тәгәрәшкән басу тулып.

Кайнар һава, кайнар сулыш, кайнар учак...
Ирләр алган басуларны урап-урап.
Башак уйный, учма уйный, көлтә уйный,
билләр ара, куллар ара — җаннар тынмый.

Уйный урак камылларны өзеп-өзеп,
сала куллар учмаларны тезеп-тезеп.
Моңлы көйләр, моңлы җырлар сузып-сузып,
бара ирләр берсен-берсе узып-узып.

Чыңлап торган камылларым, уракларым —
минем чыңлап узып киткән ир чакларым.

*
* *

Кибән салган агай-энем, нәсел-нәсәп.
Бәхет тапкан көлтәләрдән таулар ясап.
Сиксән яшьтә эти соңгы тавын өйде,
очлады да: «Менә күккә аштым»,— диде.

Шуннан бирле миңа җитте инде чират,
атаң кебек күкләргә аш, диде ир-ат.
Кешеләргә бәхет юрап салдым кибән,
беркайчан да гомер зая үтте димәм.

Башы башта, иңе иңдә, биле билдә,
сыенышып, кочаклашып ята көлтә.
Өмет өям, бәхет өям,— көлтә өям,
почмагы нык, нигезе нык — куям кибән.

Күтәреләм хозурлыктан хозурлыкка,
көлтәләргә басып менәм бу зурлыкка.
Әйтерсең лә бу кырларга бер мин башлык,
кибәнемнең эче тулы дәүләт, ашлык.

Офыкларым киңәяләр, күкләр якын,
иркенәя, ачылып китә тирә-ягым.
Минем өчен таңнары да иртә ата,
минем өчен кояшы да соңрак бата.

Соңгы көлтә, бер көлтә дә сыймый бүтән.
...Ничә мендем — һич төшәсе килми күктән.
Кибәннәргә басканым юк инде күптән,
кибән куяр заманалар үтеп киткән...

Күңел уйный, әллә нәрсә көтә-көтә...
Бу гомерләр әнә шулай көлтә-көлтә...

*
* *

Эскертендә карап ята күккә туры.
Җыерчыклар — баеп барган кояш нуры.
Күккә карап чалкан ята, йөзе көләч.
Сөенечләре кимемәгән хәтта үлгәч...

Аптырашып, өннән чыгып торды ир-ат:
күккә ашты кибәнче карт — илаһи карт.

1973

## Нәҗип Мадьяров

●

Ник тынычлык бетми урнашып ла
Бу дөньяга, якты дөньяга?
Йөз миллионнар шулай уйлап үлгән,
Йөз миллионнар шулай уйлана.

Бу шомлыкны вакыт иде дә бит
Бетерергә күптән сүндереп;
Тик кайдадыр — сугыш... ил, җир яна,
Безнең җанны монда көйдереп.

●

Яшьләр җырлый! Ишетәм ашкынулы
Тау елгасы шавын аларда.
Канатлы һәм дәртле көйләреннән
Ромашкалар бии аланда.

Яңгырый җыр. Ул өлкәннәр җыры!
Тын инештәй салмак агымлы.
Гүя шуңа иген дулкыннары
Иңләп йөгерә туган ягымны.

●

Тапшырырга кирәк булса әгәр
Дус-ишләргә яхшы хәбәрне,
Тырышасың аның шатлыгын син
Арттырырга мөмкин кадәрле.

Кайчагында авыр хәбәр иңә
Җиткергәндә инде анысын,
Ирексездән җаның тетрәп тора
Киметергә теләп кайгысын.

●

Бабай

Көмешләнгән сакал, мыек тәмам,
Җыерчыклы йөзе.
Күреп торам: сүрән шатлык белән
Көлемсери үзе.

Карый безгә баеп барган җәйге
Гүзәл кояш сыман.
Сизәм — шушы карашына аның
Гасыр моңы сыйган.

●

Чишмәләрнең суын ятып эчәм,
Әгәр кайтсам туган авылга.
Һәм аларның рәхәт салкынлыгы
Кайнарлыкны бирә каныма.

Инешләрне ярга басып карыйм,
Әгәр кайтсам туган ягыма.
Һәм аларның ярсып агышлары
Сабырлыкны бирә җаныма.

●

Картайды көз. Шәрә үзәннәргә
Чын-чынлап ук кырпак төшәлде.
Дулкыннарны беректергән күлнең
Күзгә кебек булды өсләре.

Ак халатлы авыл үзгәрешкә
Бетмәгән күк әле күнегеп.
Кайдагыдыр бураннарны эзли
Антенналар бәскә төренеп.

●

Түбәләргә штыкларын элеп,
Сөңгеләрен тезеп,
Кыш атака әзерлидер, ахры,
Яз һөҗүмен сизеп.

Әмма мартның җылы нурдан койган
Кылычы нык, көчле.
Кырып төшерә штык, сөңгеләрне
Әкияттәге төсле.

●

Салават күпере сузылды,
Эз салып йөрәкнең түренә.
Бер башы тугайлы инештә,
Бер башы карурман күлендә.

Мәхәббәт күпере сузылган
Безнең дә күңелдән-күңелгә.
Бер башы аерылу төнендә,
Бер башы кавышу көнендә.

●

Гомер буе матурлыктан
Матурлыкка омтылып
Яшәве кешенең җирдә
Үзе дә бит матурлык.

●

Кыю сүзе бер яңгырар
Һәм чишелер мәсьәлә.
Фикере шытмас җебегәннең
Мең мәртәбә әйтсә дә.

●

Мескенләнсәң, күңелең һәрчак
Зарлы булыр.
Биш минутлык шатлыкка да
Ярлы булыр.

●

Берәүгә әйткән ялган сүз
Дөресләнми үкенүдән;
Хаклык барыбер бөтенәйми
Меңнән гафу үтенүдән.

●

Белем кирәк, акча кирәк —
Яшь вакыт бит.
Акча да, белем дә бар, юк
Яшь вакыт тик.

●

Өлкән кешенең кап-кара
Чәченнән көнләш, имеш.
И, күңел, синең акылга
Чал бит кермәскә тиеш.

●

...Аерылганнар. Бу хәбәрне
Җан өшетеп тыңладым.
Ярый әле, ярый әле,
Туйларында булмадым.

●

Гашыйк хәле

— Таныштык та, аңлаштык та, дисең, —
Тик гыйшкы шикләндерә.
— Көтеп алган яңгырларның да бит
Яшене сискәндерә.

●

«Боз йөрәк»кә шул кирәк

Бер боз йөрәк бер бик шәп шигырьне
Утка атты.
Азмы-күпме шулчак бу дөньяда
Җылы артты.

●

Акыл тулылансын өчен,
Чын күңелдән бирелеп
Кирәктер ул бер булса да,
Гашыйк булу тилереп.

●

Дошманның көчен-куәтен
Киметү өчен яуда,
Ачудан ярсып, солдатка
Тешен кысса да файда.

●

Дөреслеккә һәрчак — яшел урам!
Туры килеп әмма сатлыкка
Үзенең якты максатыннан хәтта
Чигенеп тора кайчак хаклык та.

# ОЛЫЛЫК



*Талны яратам. Тал образы минем җырларыма, шигырьләремә кергән. Үз ягыма, Казан артына кайтсам, су буйларына төшәм. Иске су тегермәне урынында колач җитмәс таллар. Тамырлары күрше авыл болыннарына да таралган. Таллар бар җирдә ярлар җимерелмиләр. Төпләрендә утыру рәхәт. Зурлыкларын тоям, шуңа рәхәт. Шундый ук талларны мин Уфа тирәсендә, Агыйдел, Ашказар буйларында күреп сокландым. Араларына кереп китеп онытылып бер йөрисе килде.*

*Бу таллар Сәйфи Кудаш турында язарга керешкәч, күңелдә яңадан уяндылар, шагыйрь дә алар кук тыйнак, нык, таза; яңгырын, җилен, давылын күргән, бирешмәгән. Олы шагыйрь, олы шәхес, юлы озын, иҗаты зур. Үзе бер дәвер, үзе бер чор, катлаулы, давыллы бер чор. Тукайлар тукталган төштә эстафетаны киләчәккә алып киткән шагыйрь. Шуннан бирле бертуктаусыз хезмәт, Тукайлар, Гафуриларга лаек фидакарь хезмәт. Сәйфи Кудашка карата «хезмәт» сүзен кызганмыйча юри күп мәртәбә кабатлыйм. Мин аның ат урынына эшли торган кеше икәнлегенә беркадәр чордашы буларак, күзәтеп торучы буларак ышандым. Габдулла Тукайның:*

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез, —

*дигән сүзләре шушындый кешеләрне дә күз алдында тотып әйтелгәндер.*

*Зур шагыйрь дигән фикерне ачыклыйсым килә. Мин шагыйрьне, просто, шигырь язганы өчен генә шагыйрь дип атамадым. Просто, шигырь язучы күп, бик күп. Зур шагыйрь образы миндә баягы таллар кебек туфрагы, җире белән бергә гәүдәләнде. Зур шагыйрьнең әсәрләре аша һәр вакыт мин ул яшәгән нигезне тойдым, халкының тарихын, культурасын тойдым, мине ул үз җиренә тартты, халкына якынайтты.*

*Тамырлары бүтән болыннарга да җәелгән мәһабәт таллар... Сәйфи Кудашны мин башта бары шагыйрь итеп кенә белдем. Соңгы елларда, бигрәк тә Бөек Ватан сугышыннан соң, ул яңадан бер тапкыр ачылды. Русларда бик матур озарение дигән бер сүз бар. Сәйфи Кудаш иҗатында да яңадан балку, нурлану туды дияр идем мин. Иҗатының рамкаларын киң итеп җәеп җибәрде, шигырьгә генә сыймыйча, прозага ташып чыкты, ул шагыйрь, ул әдип, ул галим.*

*Башкорт, татар, казакъ халыкларының культура тарихына караган дөнья кадәр материалны еллар буена туплап, гыйльми хезмәтләр язды, әсәрләр иҗат итте. Ул күп кырлы. Менә Нәкый Исәнбәт, Сәйфи Кудаш кебек халкының тарихына чумган, шуннан калыккан, җилкәсенә заманның иң авыр йөген салган әдипләр сокландырды, аларга хөрмәтем торган саен, яшәгән саен арта гына барды.*

СИБГАТ ХӘКИМ.

# Сәйфи Кудаш

## Атлыйм әле...

Кышлар буе яуган карлардан да
Иелмиләр иңле тирәкләр.
Күтәрәләр, таудай кайгыларга
Түзгән кебек безнең йөрәкләр.

Әз өймәде язмыш иңнәремә
Кайгыларның калын карларын.
Тик шунда да, тал чыбыктай сыгылып,
Авырлыктан егыла бармадым.

Табаннарга сөял чыкса да,
Күкрәгемне камыт кысса да,
Алга атлыйм әле һаман да,
Илем белән якты заманга...

●

Тау астыннан бертуктамый
Җырлап аккан мин бер чишмә.
Аккан суы — гади бер су.
Ширбәт һәм бал түгел һич тә.

Мин әзермен хезмәтеңә,
Калганчы иң соңгы тамчым,
Файдалан син кирәгеңә,
Ярасам мин,
Туган халкым!

## Китәләр

Әйтерсең лә буталышып,
Бер-берсенә башын салып,
Тузан бөркеп куйлар чаба:
Агыйделнең өстен каплап,
Берсен-берсе этеп-таптап,
Өерелешеп бозлар ага...

Җилләр белән айкалышып,
Һуштан язып, чайкалышып,
Ярдан ашып карлар китә.
Әйтерсең лә яздан качып,
Ишекләрен тулы ачып,
Йөрәкләрдән зарлар китә...

## Ул булмас...

*Мәгъфүрәм истәлегенә*

Сыена идем һәрчак аңа кайтып
Җанга җылы кирәк көннәрдә...
Карт йөрәгем җуйды шул терәген,
Сөйкәлермен инде кемнәргә —
Җаным газап чиккән төннәрдә?

Упкыннардан тартып ала иде
Аның сизгер, изге карашы.
Күзләренең нуры белән юып
Яман карашларның карасын,
Бәйли иде җанның ярасын...

Кемгә генә сыенып сөйкәлсәм дә,
Барыбер инде алар ул булмас.
Йөрәкләре шундый киң булмас,
Сөюләре аңа тиң булмас,
Җан газапларына им булмас;
Ул булмас!..

●

Кайбер вакыт юлга чыга идем
Өйдә аны ялгыз калдырып.
Сагынсын дип, йөрәген яндырып,
Көтсенче дип, күзләр талдырып.

Көткәндерме, юкмы, белмим аны,
Сагынгандырмы ул кабынып.
Тик мин үзем вакытыннан элек
Кайта идем аны сагынып...

●

Күргәч минем арбамдагы,
Аркамдагы таудай йөкне,
Уйламагыз: «Комсыз икән,
Һәммәсен дә алып китте!»

Юлларымның чаңнарында [1]
Битләремнең тире калды.
Төннәремнең таңнарында
Күзләремнең нуры янды.

Уелып туган туфрагымда
Аягымның эзе кала.
Өелеп китап киштәсендә
Кызыл телнең сүзе кала.

---

[1] Чаңнарында — тузанында.

Аркамдагы таудай йөкләр —
Буш савытлар, буш яшникләр:
Бушаганнар... бурычлардан,
Эшкә биргән сулышлардан.

Алмыймын бер шырпысын да,
Һәммәсен калдырып китәм.
Йөрәкнең соңгы ялкынын
Дөрләтеп яндырып китәм!..

## Җырларым

Җырларым — язмышым минем, гомерем,
Тормыш учагын җылыткан күмерем.
Үтсеннәр дип гасырларның арасын,
Дәрттән куйдым мин аларның канатын.
Түзсеннәр дип кышларның салкынына,
Манып алдым йөрәгем ялкынына.
Тапсыннар дип теләкле йөрәкләрне,
Үзләренә бирдем саф теләкләрне.
Качырсыннар дип күзләрнең йокысын,
Керфек какмый төндә язып утырдым.
Кузгатсыннар диеп хис диңгезләрен,
Хисләремә урадым мин үзләрен...
Булсыннар дип кешеләргә сөйкемле,
Җырларыма бирдем мәхәббәтемне...
Җырларым — язмышым минем, гомерем,
Тормыш учагын җылыткан күмерем.
Тик җырларым белән генә терекмен,
Алар үлсә — мин тумаган кебекмен.

1955

## Уңыш җыйганда

Үтте инде яшь гомернең бер дә
Кабатланмый торган көннәре...
Түкте чәчәкләрен көзге җиргә
Гомер бакчасының гөлләре.
Гомер буе чәчкән басуларның
Көлтәләрен ашыгып җыямын,
Калмасын дип көзге яңгырларда,
Зуратларга өеп куямын...
Көлтәләрем булды эреле-ваклы,
Бердәй биек түгел зуратлар...
Калдырганмын җирдә башакларны,
Шәп урмаган кайчак ураклар...
Тик ни файда бүген үкенүдән?
Әрнү белән нәрсә кыласың?
Яз көннәрен үзең нәрсә чәчсәң,
Көзләрен бит шуны урасың!..

1957

## Сукмак

Күз өстенә куеп кулларымны,
Юл чатында басып торам,
Уйлый-уйлый үткән юлларымны,
Таңга калып, шашып торам.
Тар гына бер сукмак иде элек
Чабаталы аякларга.
Шуннан чыктык без дөньяга килеп,
Таянып тал таякларга.
Шул сукмакта
Бер саплам җеп сымак
Сузылып калган гомерем бар.
Яккан идем учак
Шунда бер чак,
Көйрәп яткан күмерем бар.
Кәкере-бөкере бу сукмакны ярып,
Бабайлар түкмәсә тирен,
Бу зур юлга чыкмас идем барып,
Максатка җитә алмас идем.

1960

## Дим ярында

Көзнең караңгы төнендә,
Салкын җил шашкан чагында,
Ут яктык без Дим ярында,
Карт бер тирәкнең төбендә.
Яккан учак тиз кабынды,
Дөрләп һәм ярсынып янды.
Әйтерсең ялкын пычагы
Төн карасын уеп алды.
Җылынгач шулай ут ягып,
Өстән юл тузанын кагып,—
Капчыкларны иңгә салып,
Киттек без тагы кузгалып.
Актык шырпысын сүндергән,
Ут табудан өмет өзгән
Берәр юлчы юлыксын дип,
Туңган кулын җылытсын дип,
Калган утыннарны ягып,
Без аны калдырып киттек.
Ялкынын өреп йөрәкнең
Дөрләтеп яндырып киттек.

1961

## Каеннарым минем, каеннарым

Каеннарым минем, каеннарым,
Кордашларым, сердәш дусларым,
Каршыладык, бергә озаттык без
Тормышымның яз һәм кышларын.

Яшьлек белән дәрләп бергә сүрелә,
Сүнә диләр сөю ялкыны.
Барлык теләкләргә баш идерә,
Җиңә диләр картлык салкыны...
Арткан саен яшьләремнең саны,
Каеннарны ныграк яратам.
Күргән төсле булам яшьлегемне,
Яшел каеннарга карасам.
Каеннарым минем, каеннарым,
Сагынам сезне, сердәш дусларым.
Бергәләшеп каршылыйсым килә
Бик күп язын тагы кышларның!

1961

## Бармыни соң?

Җырлап чапкан чишмә сулары
Акмагач та әллә кирегә,
Уйламагыз бер көн аларны
Кайтмас диеп туган җиренә.
Бармыни соң сагынмаган затлар
Туган ояларын дөньяда?
Булсалар да алар каты таштан,
Бер сагына кайчан булса да.
Бик еш кайта туган туфрагына
Чишмә сулары да сагынып.
Җәен алар яңгыр булып ява,
Кышын төшә энҗе кар булып.

1962

## Бар һәм әзер

Шоңкар килсә — тавыбыз бар,
Кунар кыя сайлар өчен.
Былбыл килсә — талыбыз бар,
Кунып кына сайрар өчен.

Аккош килсә — күлебез бар,
Горурланып йөзәр өчен.
Толпар килсә — кырыбыз бар,
Тузан бөркеп җиләр өчен.

Мәйданнар киң батырларга,
Сынашырга, көрәшергә.
Шагыйрьләр һәм чәчәннәр күп
Сүз йөгертеп сөйләшергә.

Дуслар килсә — ишек ачык,
Өстәлләрдә ашыбыз бар.
Дошман килсә посып-качып,
Томырырга ташыбыз бар.

Кунак килсә хөрмәт көтеп,
Йөзләр ачык, түрләр әзер.
Читләр килсә кылыч тотып,
Казып куйган гүрләр әзер!

## Һәммәсе дә икегезгә

Әллә нинди бер көн бүген!
Әллә нинди бер төн бүген!
Аңкып тора яшел җирем,
Балкып тора зәңгәр күгем!
Ямьләндереп бакчам эчен,
Чәчәк атты гөлҗимешем.
Әллә атты синең өчен?
Әллә атты минем өчен?
Тау буенда, һичбер тынмый,
Чылтыр-чылтыр чишмә җырлый.
Әллә инде сиңа чыңлый?
Әллә инде миңа чыңлый?
Кәккүк чакыра өяңкедә,
Гомер теләп әллә кемгә?
Әллә инде тели сиңа?
Әллә инде тели миңа?
Көмеш сулы күл читендә
Камышлар баш иеп бөгелә.
Әллә инде сиңа бөгелә?
Әллә инде миңа иелә?
Таң җилләре исеп китте,
Яшерен серне чишеп китте.
Шыпырт кына әйтте безгә:
«Һәммәсе дә икегезгә,
Һәммәсе дә икегезгә!»

1960

## Исемем турында

Әти кушкан исемем минем — Сәйфи,
Үзебезчә әйтсәк — «кылыч» була.
Өлешемә чыккан көмеш булгач,
Йөртә бирәм шөкер кылып кына.
Кирәк чакта аны кулда тотам,
Кулга алмаганда кында тотам.
Кулга алмаган, кынга салмаганда,
Ут ургылган кайнар тында тотам.
Кайда гына булсам, нишләсәм дә,
Һәр вакытта була ул янымда:
Я кулымда,
Җырда,
Кында,
Тында,
Я йөрәкнең кайнар канында.

Мин яшәрмен исемемә тиң булып,
Юкка селтәп кулны талдырмам.
Калса калыр ул кителеп, сынып,
Тик тотыккан кылыч калдырмам!

## Буш чагы юк...

Яхшы беләм мин үземнең чамамны,
Арттырмагыз, киметмәгез бәямне.

Белгән өчен кулларемнең куләмен,
Колачымны кымтып кына йөзәмен.

Тирәнлеге үземә таныш булганга,
Үз чамамны белеп чумам чумганда.

Үз урнымны белми, түргә узмыйммын,
Язмаган нигъмәтләргә кул сузмыйммын.

Чиктән узып башны күккә чөймимен,
Мескенләнеп түбәнгә дә имимен.

Үз бакчамның җирен, серен нык беләм,
Ул үстергән гөлне генә үстерәм.

Тыным җиткән җырны гына җырлыймын,
Кулым белгән сырны гына сырлыймын.

Буш чагы юк кулларның да, башның да,
Һәр чак иңем илем йөге астында!

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

*Илебез матбугаты Кама автомобиль заводын төзү турында*

## ОКТЯБРЬ, 1973 ЕЛ

«Новый мир» журналы КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеевның зур мәкаләсен бастырып чыгарды. Автор үзенең бу мәкаләсендә тугызынчы бишьеллыкның удар төзелеше булган Кама автомобиль комплексын салу эшләре барышын киң итеп анализлый.

«Кама буенда бөтен союз күләмендә әһәмияте булган индустриаль комплекс кору безнең республика тормышында зур роль уйный,— дип яза ул.— Промышленностьның төп фондлары артачак, җитештерү күләме үсәчәк. Комплекс сафка басканнан соң, Татарстан фәнни-техник прогресс юлыннан алга атлаячак...»

**«Новый мир», Мәскәү.**

Одесса шәһәрендәге Ленин исемендәге завод «2 М 55» модельле унике станокны Чаллыга вакытыннан элек озатты. Бу станоклар автомобиль детальләрен ике микронга кадәр төгәллек белән эшкәртәчәк.

КамАЗ заказларын үтәүче өч станок төзү предприятиесе коллективлары үзләрен удар төзелешкә катнашучылар итеп саныйлар.

Киров исемендәге фрезер станоклары заводы КамАЗ өчен инде еллык планны үтәде. Одесса пресс заводы да КамАЗ заказларын үтәүнең еллык планын графиктан өч айга элек үтәде.

**ТАСС, Одесса.**

Сидоровка җоселогыннан төзелеш мәйданына беренче трамвай йөри башлады. Шуннан элек кенә Чаллыда трамвайны иң яхшы йөртүчеләргә конкурс булып узган иде. Беренче трамвайны йөртү хокукын А. Сафонова яулап алды. Ул КамАЗга Горький шәһәреннән килгән. Әлегә трамвай юлы биш-алты километр гына. Озакламый төзүчеләр тагын унбиш километр юлны әзерләп бетерәләр.

**«Советская Россия», Мәскәү.**

Озакламый Чаллыда, «Гренада» кинотеатры янында гына беренче спорт залы ачыла. Аның оригиналь, җиңел һәм уңай корпусы Германия Демократик Республикасында ясалган.

Хәзердән үк инде тренировкалар бара. Җәмәгатьчелек тәртибендәге тренер, СССР спорт мастерлыгына кандидат, «Стальмонтаж» тресты слесарь-монтажнигы Николай Шейкин җитәкчелегендә ирекле көрәш осталары чыгыш ясарга әзерләнәләр.

Спортзал янында ГТО нормаларын тапшыру мәйданы да ачылачак.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Сосновоборскида илебездә иң зур автомобиль һәм трактор прицеплары заводларының корпуслары көннән-көн югарырак күтәрелә. Шушы көннәрдә генә төзүчеләр төзелешнең беренче объектын — стандарт булмаган җиһазлар цехын эксплуатациягә тапшырдылар.

Бу яңа предприятие КамАЗның үзенә күрә филиалы булачак. Анда барлык эшләр тәмамланганнан соң, Чаллыга автопоездларны комплектлау өчен ел саен 100 мең прицеп җибәреләчәк.

**«Сельская жизнь», Мәскәү.**

Бигеш аэропортында һава бәйләнеше расписаниесендә 1 октябрьдан яңа авиатрасса барлыкка килде. «АН-24» самолеты Бигеш — Пенза — Ростов маршруты буенча очып китте. Рейслар атнага биш тапкыр булачак. Хәзер Бигеш аэропорты илебезнең 15 шәһәре белән бәйләнгән.

Октябрь ахырында Чаллыда Аэрофлотның яңа агентствосы ачылачак. Ә киләсе елда автомобиль төзүчеләр заводында үзәк аэровокзал бинасын салу планлаштырыла. Аннан пассажирлар автобуслар белән туп-туры самолетларга озатылачак.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Сафка басканнан соң КамАЗ конвейерының озынлыгы нәкъ Дюссельдорфтан Мангейм шәһәренә кадәр булган 300 километр араны тәшкил итәчәк. Шундый проектның ничек реальләштерелүен, без, сигез илдән килгән чит ил хәбәрчеләре, анда үз күзебез белән күрдек. «КамАЗны бөтен ил төзи!» — Чаллыга баргач, мондый лозунгларны без һәр җирдә күрдек. Илнең 5 мең фабрикасы һәм заводы КамАЗ өчен эшли, Кама буендагы бу шәһәргә чит ил предприятиеләреннән дә продукция килеп тора.

Бары тик Германия Федератив Республикасыннан гына да,— дип яза Дюссельдорф шәһәрендәге «Унзере Цайт» газетасы хәбәрчесе,— станоклар әзерләүгә кырыктан артык промышленность фирмалары катнаша. Федератив республиканың металлургия промышленностенда эшләүчеләргә бу озак вакытка эш гарантияли.

**«За рубежом», Мәскәү.**

Днепропетровск механика заводы металлистлары КамАЗ төзүчеләренә 30 тонна йөк күтәрешле кран конструкцияләрен җибәрүгә карар кылдылар. Аны предприятиенең М. Лысенко житәкчелегендәге иң яхшы слесарь-җыючылар бригадасы әзерләде. Бригада эш графигы нормативын 8 көнгә кыскартуга ирешә.

Бу кранны әзерләп бетергәч, Запорожье металлистлары Кама автогиганты төзүчеләре заказларын үтәүнең еллык планын башкарып чыктылар...

**ТАСС, Запорожье.**

Чаллы культура йорты каршындагы халык театры Хәй Вахитның «Рәхим итегез» исемле комедиясен сәхнәдә куюга әзерли башлады.

Рольләрне башкаралар: СМУ-3 экскаваторчысы Ясыйр Шакиров, «Соцкультбытстрой»ның СМУ-13 маляры Гөлзара Гыйльманова, «Спецпромстрой» машинисты Әнәс Ихсанов, КамАЗ СМУсе маляр-штукатуры Земфира Гәрәева, ЗЯБ фактурщицасы Рәшидә Кубиевалар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Камадагы автомобиль төзүчеләр шәһәре үскәннән-үсә, матурая. Шәһәр өстендә октябрь алды вахтасы хезмәт батырлары хөрмәтенә күтәрелгән байрак җилферди. Бүген ул А. Зотов һәм аның иптәшләре хөрмәтенә күтәрелгән, ә иртәгә...

Ярышта намуслы хезмәте белән кем генә җиңеп чыкмасын, гомуми эшкә файда, Кама автогиганты тизрәк сафка басар...

**«Советская Россия», Мәскәү.**

Ярославль шәһәрендә тугызынчы бишьеллыкның мөһим объектын — дизель аппаратлары заводын төзү эшләре инде ел ярымнан артык бара. Бу завод КамАЗ эшләп чыгарачак йөк машиналарын ягулык насослары белән тәэмин итәчәк.

**«Северный рабочий», Ярославль.**

Совет кешеләренең хезмәт энтузиазмы, КПССның XXIV съезды куйган бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән иҗади омтылышы КамАЗ төзелешендә ачык чагыла.

Тормыш Чаллыда заманыбызның типик үзенчәлекләрен бер үзәккә туплады. Мөгаен, киләсе буыннар җитмешенче елларның беренче яртысында илебез кешеләре тормышына КамАЗ тарихы буенча бәя бирер.

Менә шуңа күрә дә Кама автогиганты төзү күренешләрен сәнгатьчә сурәтләүгә бәйле һәр нәрсә безнең өчен гаять мөһим. Менә шуңа күрә экраннан без төзелеш барышы хроникасын гына түгел, шушы төзелеш күренешләре аша фильмнарда безнең көннәр характерына, аның философиясенә, һәм, ниһаять, хәзерге заманга хас әхлак югарылыгына кинематографистларның ничек үтеп керүен дә күрергә телибез.

**«Искусство кино», Мәскәү.**

## Мирхәт Хөснимәрдәнов

# КҮҢЕЛЕҢ КЕРСЕЗ БУЛСА...



Хезмәтен яхшы башкара...

— Аның исеме Мактау тактасында...

— Күпләргә ул үрнәк булып тора...

Нәкыя турында бары тик шундый сүзләр генә ишетергә мөмкин.

Һәм көтмәгәндә, уйламаганда...

Бер ай эчендә «Татсельстрой» трестының 729 нчы механикалаштырылган колоннасы конторасына ике тапкыр жалоба тикшерергә килделәр. Һәр икесе дә Нәкыя турында. Аны — трестның бу колоннасындагы иң яхшы эшчесен, коммунистик хезмәт ударнигын — телефон аша ашыгыч рәвештә конторага чакыртып алдылар. Әллә нинди сораулар бирделәр, ахырдан кемнеңдер аның турында югары органнарга жалоба язганлыгы турында әйттеләр, язылганнарны укып күрсәттеләр. Нәкыя бу эшләрдә үзенең һәм аның бригадасы членнарының берниндн катнашы булмавын, гаепләүнең дөрес түгеллеген аңлатырга тырышты, чөнки язган кеше бөтенләй алар бригадасында түгел, башка участокта эшли һәм шулай булгач, аның бригадасындагы хәлләрне читтән торып язучы кеше һәммәсен дөрес итеп күрә алмаска мөмкин...

Нәкыяне трестның гади эшчеләре дә, җитәкчеләре дә яхшы белә. Шуңа күрә аларның жалобага артык исләре дә китмәде. Ә Нәкыя үзе бик авыр кичерде бу хәлне. Ярый әле, бездә кешене хаксызга рәнҗетмиләр, энәсеннән җебенә кадәр төпченәләр һәм аңларга тырышалар.

Ләкин... өченче тапкыр чакырдылар.

Шакмаклы дәфтәрнең куш битенә ике яклап язылган жалобаны кулына тоттыргач, Нәкыя башта ни әйтергә дә белми торды һәм кыюсыз гына: «Ә укырга ярыймы соң?» — дип сорады.

«Әлбәттә, ярый» дигән җавапны алгач, ул, шунда өстәл янында гына басып, язманы башыннан ахырына кадәр укып чыкты. Дәфтәр битен ике кулы белән кысып тоткан. Куллары сизелер-сизелмәс кенә калтырыйлар. Бүлмәдәге кешеләр — партком секретаре, фабком председателе, контора начальнигы, бу күренештән уңайсызланып булса кирәк, күзләрен Нәкыядән читкә борганнар: без гаепле түгел, чакырып китермәдек, өлкә матбугатыннан килеп кызыксыналар икән, сөйләшмичә булмый...

Бераздан бүлмәдә икәү генә калдык.

Нәкыянең күзләре һаман әле язмада. Укый булса кирәк... Икенче тапкыр инде... Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә, диләр. Үзе

турында шундый сүзләр язылган кәгазьне тыныч күңел белән укып чыгу түгел, кулда тотып торырга да теләмәс иде бүтән берәү булса.

Жалобаның эчтәлеге миңа яхшы таныш.

Кайда соң дөреслек?

Минем шушы язмамны тикшерүегезне һәм чара күрүегезне үтенәм. Хәзерге вакытта мин «Татсельстрой»ның 729 нчы колоннасында эшлим. Эшлим һәм күрәм: юк бездә дөреслек. Нәкыя Гафиуллина бригадасында, мәсәлән, кайберәүләр рәхәт кенә акча алып яталар. Авылга кайтып, бригадирга каз-үрдәк алып киләләр дә, бригадир аларга эштә булмаган көннәренә дә «булды» дип сәгатьләр куя бара. Көн бара, акча килә. Аның бу эшен бригададагы башка эшчеләр кемгә булса да әйтергә куркалар, эштән кудыра ул, диләр.

Нәкыя — партия члены. Кайда соң аның дөреслеге? Нигә ул шулай эшли? Ә миңа авыруым турында белешмәм була торып та яраклы эш бирмиләр. Тормышым бик җиңелдән түгел. Балалар йортында үстем. Минем бирерлек кучтәнәчләрем юк шул. Айлык эш хакым да әллә ни зурдан түгел. Минем семьям бар. Туйдырырга кирәк. Достоевский урамында 45 квартиралы йорт төзедек. Аны төзүдә катнашкан эшчеләргә премия бирделәр, ә миңа юк. Анда минем дә өлешем керде. Дөреслек шушы буламы инде? Квартир турында да шундый ук хәл. Кем Нәкыягә кучтәнәч төртә, ул аны чиратта алгарак күчерә...

Укыгыз һәм чара күрегез...»

Тышта январь суыгы. Ул тәрәзәгә сырлап-сырлап төрле яфрак рәсемнәре төшергән. Пыяланың чатнаган урынында гына нишләптер рәсемнәр юк. Шул ачык калган урыннан Нәкыя бераз урамдагы хәрәкәткә карап торды. Һәммәсе файдалы эш белән мәшгуль, ә кемдер әнә бит нинди күңел кайтаргыч сүзләр язган...

Эссе булып китте Нәкыягә. Пальтосының төймәләрен ычкындырып җибәрде, башыннан мамык шәлен алып урындык артына элде һәм «басып кына җавап биримме, әллә утырырга да ярыймы?» дигән караш белән өстәл янына килеп басты.

— Утырыгыз, утыр...

— Кәгазь ни язсаң да түзә инде ул,— дип сүз башлады Нәкыя, бераз тын утыргач.

— Язган кешесен беләсезме?

— Бер яшь кенә хатын. Төзүче. Инде әллә кайларга язып бетергән. Тикшерүләр белән күпме кешенең вакытын алдылар. Менә тагын сез...

— Бәлки ул чыннан да хаклык эзлидер?

— Хаклыкны алай үзең почмакка посып калып эзләмиләр,— Нәкыянең күңелендә туган ачуы шунда ук йөзенә бәреп чыкты (эчкерсез кешеләрдә генә шулай була. Алар икейөзләнә белмиләр),— дөреслекне, хаклыкны аны, хәбәрче иптәш, кара-каршы утырып, күзгә-күз карашып, йөзгә бәреп әйтеп кенә табышалар.

— Әгәр аның андый мөмкинлеге булмаса... Төрле кеше бар бит.

— Мин бит аның бианасы түгел. Ул да миңа килен булып төшмәгән. Нәрсәгә тел яшерергә... Без бит бер трестта эшлибез, бер үк төрле эш башкарабыз. Бердәй хокукка ия.

Нәкыя белән бәхәскә керү мөмкин түгел иде. Чыннан да нигә соң жалоба язучы боларны коллектив алдына куймаган? Колонна җитәкчесе бар, партком, постройком бар... Курыкканмы? Ә нәрсәдән?

— Сез безне очраштырыгыз,— дип үтенде Нәкыя.

— Шунсыз мөмкин түгел.

...Без көнен, сәгатен билгеләдек.

Ләкин бу очрашуга «буш кул» белән генә бару ике эшче-төзүче арасында кирәкмәгән бәхәс кенә кузгатыр иде. Шуңа күрә ныклап хәзерләнергә, һәр икесе турында төгәл һәм кире кагып булмаслык мәгълүматлар алырга, моның өчен һәр икесенең эш урыннарында булырга,

тиешле кешеләр белән сөйләшергә, кыскасы, жалоба тикшерергә килгән хәбәрче өстенә төшкән бик үк күңелле булмаган, күп вакыт ала торган вазифаларны үтәргә туры киләчәк иде. Һәм шулай булып чыкты да...

Һәр икесенең эше турында кайбер четрекле сорауларны ачыклау өчен колонна начальнигының приказ кенәгәләрен актарырга, бухгалтериягә бригадир керткән хезмәт хакы нарядларын, премия бүлгән кәгазьләрне җентекләп тикшерергә туры килде.

Эштән бушаган араларында контора бүлмәсенә Нәкыя дә кереп чыкkалады. Кергән саен ул сак кына «жалоба язучыны күрмәдегезме әле?» — дип сорый иде. Ләкин минем әле хат авторын күрә алганым булмады. Үзе конторага килмәгәч, йорт адресларын алып, торган җирләренә бардым. 729 нчы колоннада һәм алар торган йорттагы күршекүләннәре авызыннан ни генә ишетергә туры килмәде аның турында. Бераздан инде «үзе теләп бу конторадан китте» дигән хәбәр җиткерделәр. Шуңа күрә инде аның исем-фамилиясен әйтеп тә язарга кирәкмәстер, дип уйладым. Ләкин күңелемдә туган фикерне әйтмичә һич тә булдыра алмыйм: әйбәт күңелле эшче-төзүче булмаган ул. Эштә прогулчы, торган җирендә — җәнҗалчы. Тәртипсезлекләре өчен иптәшләр суды каршына да бастырганнар. Үзен генә түгел, ирен дә. Эчкән, сугышкан өчен...

Чираттагы бер сөйләшү вакытында Нәкыя тормышның, үз тирә-ягындагы кешеләрнең һаман кара якларын гына күреп йөрүче шундыйлар турында гыйбрәтле бер чагыштыру китергән иде: мәсәлән, күмәкләшеп урманга гөмбәгә барасың... Арып-талып йөрисең, кичкә таба бик күпләрнең кәрҗиннәре ак гөмбәләр, каен, нарат гөмбәләре белән тула. Аннан кайтырга чыгасың. Төркемдәге кайсыдыр берәүнең кәрҗине төбендә берничә генә гөмбә тәгәрәшә. Кәрҗин хуҗасы «урманмыни бу, «мухомор» белән «поганка»дан башка гөмбә юк монда», дип зарланырга тотына, кемгәдер гаеп ташлый, аның өчен урман, аның матурлыгы, аның юмартлыгы бернәрсә тормый... Ул бөтенесенә кара тамга ябыштыра. Тормышта да шулай... Кайберәүләрнең күзенә тормышыбыздагы гел начар «гөмбәләр» генә күренә, андыйлар яхшылыкны абайларга күнекмәгәннәр, аларны: «Син нигә алай сөйләшәсең?» — дип әрепли дә алмыйсың... Акыллы сүзәр иде бу. Эшче күңеленнән, гади төзүче күңеленнән чыккан эчкерсез чагыштыру иде. Намуслы кешеләргә күңелендә мәкер саклаган, аларны хурлаган кеше белән сөйләшүе бик кыен, гайрәтне чигерә, дип әйтүе белән Нәкыя, әлбәттә, хаклы. Әйе, сүз әйтергә уңайсызланып, хуҗа өстәлгә куйган тәмсез ризыкны көчләп ашаган кебек буласың.

...Ләкин насыйп булган ризык теш ватып керә, диләр. Нәкыя дә минем бу очеркка әнә шулай көтмәгәндә, уйламаганда килеп керде. Очеркны язганчы, машинкада бастырганчы, аның турында өлкә газеталарында эреле-ваклы мәкаләләр чыга торды, аның эше турында, бригада ирешкән уңышлар турында яздылар, план үтәлеше турында саннар китерделәр... Ләкин Нәкыя үзе, аның күңеле, кеше буларак аның тормыштагы урыны турында ул мәкаләләрдә бер сүз дә әйтелмәгән иде.

Чыннан да кем соң ул Нәкыя?

...Ул төзүче... Ватучы, җимерүче түгел, ә төзүче...

Күптән түгел Нәкыяне КПСС өлкә комитетының Зур залына хөкүмәтебезнең югары бүләген — Ленин ордены тапшырырга чакырдылар. Мин бу турыда радио аша ишеттем һәм шул көнне үк Нәкыяга тәбрикләү хаты яздым. Менә ничек килеп чыккан иде ул тәбрикләү хаты:

«...Хатымның беренче юлларыннан ук сезне, Нәкыя, үткән бишьеллыкта башкарган игелекле хезмәтләрегез, «Татсельстрой» тресты алдына куелган бурычларны уңышлы үтәп чыгу буенча социалистик ярышта керткән өлешегез өчен хөкүмәтебезнең иң югары бүләгенә — Ленин

ордены алуга лаек булуыгыз белән чын күңелдән котларга рөхсәт итегез».

Әйе, чын күңелдән куандым аның өчен. Авылда туып, шунда үскән гади бер кызның үзенә канат биргән, үстергән, мәгърифәт эстәргә юл ачкан кадерле авылы чәчәк атсын өчен үзенең чәчәк кебек кыз вакытын кызганмыйча төзелешкә китүе, кирпеч, таш, алебастр һәм битум белән эш итәргә өйрәнүе, шушы эштә дан казануы беренче карашка бик гади булып тоела. Әйе, кемдер авылда сыер сава, печән җыя, орлык чистарта, капчык ямый, ындыр табагы кыра. Кемдер, әлбәттә, механизатор, кемдер укытучы яки фельдшер... Ә ул төзүче булган. Мондый исемдәге эш остасы авылда әле бик сирәк. Әле аны санга да санап бетермиләр. Ләкин комплекслар, агрошәһәрләр төзи башлаган бу чорда авыл төзүчесенең абруе һаман арта бара. Нәкыя үзенең хезмәт елларын аңлы рәвештә шул эшкә багышлаган. Шунда үз юлын тапкан. Аның бу юлда югары күрсәткечләргә ирешүе, шуның өчен хөкүмәтебезнең иң югары бүләгенә — Ленин орденына лаек булуы безнең социалистик җәмгыятьтә хезмәт кешесенә карата булган иң олы мактаулы мөнәсәбәтнең ачык чагылышы.

Әгәр үзен тагын күреп: Ни өчен бирделәр? дип сорасам да, барыбер, элекке очрашулардагы кебек, «Белмим инде, башкалар шикелле үк эшлим, хезмәтемне яратам һәм шуның белән горурланам»,— дип җавап бирер иде. Бу гади тыйнаклык күрсәтү генә дә түгел, аннан өстен бер сыйфат. Совет иленең илле алты ел яшәве дәверендә бишьеллыклар чорындагы гигантлар белән бергә миллионнарча кешеләр дә әнә шулай үз хезмәтләре белән горурлану дәрәҗәсенә күтәрелделәр.

Нәкыянең хезмәт уңышлары турында «Татсельстрой» трестының 729 нчы механикалаштырылган күчмә колоннасында горурланып сөйлиләр. Зур-зур җыелышларда аның урыны түрдән. Менә биш ел инде депутат буларак аңа кешеләр үз зарлары, киңәшләре белән мөрәҗәгать итәләр. Кеше зарын тыңлап утыру гына түгел, аңа булыша да белергә кирәк, шуның өчен үзеңдә көч табарга, олы җанлы булырга, мәшәкать артыннан йөрергә иренмәскә кирәк. Әнә шундый тынгысыз булганы өчен дә аны бригададагы иптәшләре дә, треста да, партия оешмасында да яраталар һәм чын күңелдән ихтирам итәләр.

Хезмәт юлындагы һәм тормышындагы аерым вакыйгаларны, күңеленә куаныч китергән матур фактларны Нәкыя аерым дәфтәргә теркәп барырга ярата. Шуңа күрә яшьлек хисләренә генә бирелеп, юк-бар язмалар белән бу дәфтәрне тутырмас өчен, ул язарга тиешле вакыйганы үзенчә бәяли, күңел иләге аша уздыра һәм шуннан соң гына язып куя. Тормышта мәгънәсезгә үткән минутлар да була, беркемгә, бернәрсәгә кирәк булмаган эшләр дә эшләп ташлыйсың. Аларның нигә барысын да искә алып торырга. Әйдә, югалсыннар, онытылсыннар кирәкмәгәннәре. Хәтердә үзең өчен генә дип түгел, ә башкалар өчен дип башкарылган күркәм эшләр генә сакланып яшәсен. Алар синең яшәвеңнең чын мәгънәсен ачыклыйлар.

Нәкыянең тормыш дәфтәрендә хезмәт биографиясен чагылдырган юллары бик яшьли башлана. Авыл кызлары хезмәт өчен бигрәк тә иртә өлгерәләр. 1954 елны авылдан үз теләге белән язылып төзелешкә килгәч, әле буе кечкенә дипме инде, әллә болай сабый гына күренгәнгә кызганыпмы, баштарак Нәкыягә шактый вакыт җитди эш бирми йөдәтәләр, ярдәмче эшләрдә генә йөртәләр. Кулы эшкә килеп торуын әнә шул вак-төяк эшләрдә дә күрсәтеп бирә алгач, аны катлаулырак, нәтиҗәсе белән мөһимрәк булган бүтән эшләргә дә куша башлыйлар. Акылың гына җитсен дә, кулың гына чыдасын, төзелештә һәммә һөнәргә өйрәнергә була. Нәкыя моңа башта ук төшенә. Төшенеп кенә калмый, шуңа омтыла да ул. Озак та үтми, ул мозаика эшләрен дә, асфальт җәю, плитә ябыштыру, хәтта пыяла кую кебек шактый четрекле булган эш-

ләрне дә бөтен нечкәлекләре белән үзләштерә. Үзенең тырышлыгы белән бала вакыттан бирле хезмәткә күнегеп, аның тәмен белеп, «булдыклы кыз» дип алган исеменә төзелештә дә тап төшерәсе килмичә, ару-талуны белми эшли дә эшли Нәкыя. Кая кушсалар, шунда бара. «Татсельстрой»ның төзелеш объектлары Татарстанның бөтен почмакларында диярлек. Яңа Актанышны төзүдә дә катнашалар алар. Бервакытта да ерак дип зарланмый Нәкыя. Лаеш тирәсе авылларында, Мамадыш якларында, Арча авылларында кай чакларда өчәр ай рәттән кайтмыйча, җылы өй күрмичә һаман яңа төзелешләр корып йөриләр. Кайда гына булсалар да, аның бригадасы башкарган эшне югары бәя белән кабул итеп алалар. Шәпше авылындагы шәһәр тибындагы йортлар, культура учаклары да Нәкыя һәм аның бригадасы кешеләре катнашында салынды. Авыл төзелешләре өчен аерата кирәк булган керамзит цехын салганда, вакытыннан алда өлгертик дип, куна-төнә эшләделәр.

Механикалаштырылган колонна да булгач, үзе күчеп тә йөргәч, башкаларга ничектер, әмма Нәкыяга ошый иде үзенең хезмәте. Дөрес, мондый күчмә тормыш төзелештәге кайберәүләрне бик тиз сыный, бик тиз бөгә. Алар күбрәк шәһәр тирәсендәге объектларда гына калырга тырышалар, мәшәкатьсезрәк эшне сайлыйлар. Икенче берәүләрнең трестка эшкә урнашып, бераз эленке-салынкы йөргәч, конторага барып «үз теләге белән» исәп-хисап ясаганын сизми дә каласың. Әле башка җиргә барып эшкә кереп урнашкач, «анда фәлән иде, анда төгән иде» дип, төзелешне хурлап та сөйли торгандыр әле. Имеш, эш урыннары ерак, имеш, акча аз төшә, имеш, эш шартлары яхшыдан түгел...

Ә Нәкыянең һич тә китәсе килми. Ошады. Кешеләрен дә яратты. Җитәкчеләр дә һаман яхшы мөнәсәбәттә булдылар. Тырышып эшләгәч, акчасы да ярыйсы гына төшә башлады. Объектны тапшырганда вакытында башкарылган эш өчен еш кына бүләк акчасы да эләгә. Билгеле инде, яхшылыкның чиге юк. Кемгәдер һаман нидер ошамый, нәрсәдер җитешеп бетми. Әмма җиде сәгатьлек эш кайда да бер ул. Шуңа да түзәрлек булмагач, нигә дип төзелешкә килергә! Башка җайлырак урын эзләп карыйбызмы әллә, дигән коткыларның берсенә дә иярмәде Нәкыя. Җиңелрәк, төшемлерәк урын эзләп бер бригададан икенчесенә чикерткәдәй сикереп йөрүчеләрне чын күңеле белән яратмый ул. Үзе генә түгел, ике сеңелесен, энесен дә шушы трестка эшкә урнаштырды. Аларның хезмәтләреннән зарланучы кеше юк. Энесе түбә ябу эшендә оста булып җитеште, сеңелләре дә сынатмадылар, эшләделәр, укыдылар, һөнәр иясе булдылар. Нәкыя үзе белән аларны җәмәгать эшләренә дә тартты. Һәммәсе җырчы-биючеләр. Үзе сыздырып гармунда уйный. Бәйрәм вакытларында гөр килеп концерт оештыралар.

«Яши генә белергә кирәк бу дөньяда,— дип, кайвакыт бригада членнары белән әңгәмә дә корып ала Нәкыя,— тәмен белеп кенә, рәхәтен тоеп яшәү безнең үзебезнең кулда. Безнең җәмгыятьтә бөтенесе кешенең үзенә, аның хезмәткә һәм тормышка булган карашына, хезмәткә керткән өлешенә бәйле».

«Шат күңелле Нәкыя» диләр аның турында һәр чак. Ләкин шат күңелле, мөлаем йөзле бу кыз эш вакытында бер дә авыз җырып, яисә һәммә нәрсә белән килешеп тормый. Киресенчә, бик таләпчән ул. Вак кына кимчелекләрне дә ул «әйдә, ярар» дип үткәреп җибәрүчеләрдән түгел. Һәм моны Нәкыя Гафиуллина кул астында эшләүче төзүче кызлар яхшы беләләр.

...Казанның Зәйни Солтанов урамындагы яңа йорт төзелешендә Нәкыяләр бригадасы трубалар буяу белән мәшгуль иде. Бригадир башка участокларны тикшереп бирегә килеп җитүгә, эшнең сыйфатына игътибар итте һәм аптырап калды. Күгәргән урыннар кырмыйча буялган иде.

— Ник болай эшләдегез? — дип, Нәкыя бригада членнарына сораулы караш ташлады,— кайсыгызның эше бу?

Каракның бүреге яна дигәндәй, «Сиңа гына ярамый инде»,— дип ычкындырды кайсыдыр.

— Ә кемгә ярый?

— Әнә прорабка... Ул бер сүз дә әйтмәде. Кабул итте.

— Ә мин кабул итә алмыйм. Бригада башкарган эшнең сыйфаты өчен прораб түгел, без үзебез җавап бирәбез. Аңлыйсызмы сез шуны, юкмы?

Нәкыя тирә-якта аптырашта калып басып торган төзүче иптәш кызларына, аларның һәрберсенә аерым-аерым сынаулы караш ташлады. Нәкыя шунда ук кемнең «гөнаһсыз» икәнен, кемнең йөзе ризасызлык белдереп җыерылганын, кемнеке уңайсызланганын шәйләп алды.

— Ә Мөнирә... син икәнсең әле бу. Яңадан кырып буярга туры килер. Бушлай, түләүсез...

— Булмый, яңадан кырып булмый аны,— дип каршы төште Мөнирә.

— Була. Теләк кенә кирәк.

...һәм Нәкыя, нидер эзләгәндәй, тирә-ягына каранды, күзенә ташланган беренче кызга мөрәҗәгать итте:

— Тимер чыбыктан эшләнгән щетка алып кил әле. Берне генә түгел, берничәне...

Ничек кырырга кирәклеген Нәкыя үзе менә дигән итеп күрсәтеп бирде. Бераздан, Нәкыя башка эшләрне кабул иткән арада, трубаның чиста итеп кырылган өслегенә яңадан буяу төшерә башладылар. Әйбәт килеп чыкты. Үзләренә дә ошап китте.

— Менә шулай эшләргә кирәк. Иренмичә...

Нәкыя йорт эченә кереп киткәч, брак эшләгән әлеге Мөнирәне үзара әрләп ташладылар: үзең тиешенчә эшләмәгәнсең, үзең бригадирның кисәтүенә каршы сүз әйтәсең. Нәкыя ничек кирәген синнән-миннән күбрәк белә бит инде ул. Төзелештә беренче елын гына түгел, ә егерме ел эшли.

Әйе, Нәкыянең авыл төзелеше трестына килгәненә ике дистә ел. Шушы елларда ул эштән бүленмичә генә бер ел буена бригадирлар курсында укыды, өч ел рәттән йөреп төзүче новаторлар мәктәбен тәмамлады. Аны уңышлы тәгаллләп чыкканнан соң, Нәкыя биргән уңышлы камилләштерү тәкъдимнәре трестка шактый файда китерделәр. Хәзер инде Нәкыя төзелә торган йортның сызымын кулына тотса, беренче еллардагы кебек киреле-башлы карамый, шунда ук өйрәнергә тотына, башкаларга аңлата башлый, чатак урыннарына тап булса, сызымга төзәтмә кертүдән дә тартынып тормый. Сызымчыларның, теоретикларның фикерләрен шулай тормыш, практика төзәткәли бит.

Шушы еллар эчендә Нәкыянең хезмәтләре яхшы бәя алды. Аңа «Почет билгесе» ордены бирделәр. Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән алып барылган социалистик ярышта ирешкән уңышлары һәм аңа хәзерлек көннәрендә җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен Нәкыя юбилей медаленә лаек булды. Трестның Коммунистик хезмәт ударниклары арасында Нәкыя һәм аның бригадасы членнарының күбесе ел саен бу мактаулы исемгә лаек була бара. Алар инде хезмәт ветераннары булып саналалар.

Нәкыя Гафиуллина бригадасы ирешкән уңышларның төп сере, төп чыганагы — бригаданың һәр члены үзләре башкара торган һәр төр эш өчен, аның сыйфаты өчен шәхси җаваплылык тоюда. Бригада составындагы утызга якын кешенең һәммәсе дә бер урында түгел, ә аерым-аерым группаларда эшлиләр. Эшнең ничек башкарылуын даими күзәтеп торырга мөмкин түгел. Ләкин бер генә көн дә Нәкыя аларның ничек эшләүләре белән кызыксынмый калмый. Бригада членнары беләләр: никадәр ерак объектта эшләмәсеннәр, Нәкыя аларның ничек хезмәт иткәннәрен күреп йөри, йөрәге белән сизеп тора, башкарган эшнең кечкенә

генә өлеше дә югалмый, бригадирның дәфтәренә теркәлеп бара. Нәкыйнең үзенә калса, ул, бригадир буларак, артык тәрбия чаралары да күрмәгән шикелле инде, бергә җыеп озын-озын әңгәмәләр дә ясап тормый. Төп тәрбия чараларының иң үтемлесе итеп ул шәхси үрнәк ысулын сайлаган һәм ялгышмаган. Бер тапкыр үзең яхшы итеп күрсәтеп бирү, «тегеләй бул, болай бул», дип корыны бушка әйдәү-үгетләүгә караганда җитәкче өчен иң кирәклесе һәм үтемлесеeдер бәлки.

Нәкыйнең хезмәт дәфтәрендәге тагын берничә битне ачыйк, тагын берничә гыйбрәтле вакыйга белән танышыйк.

Арчадагы төзелешләрнең берсендә түбә ябу эшләренең сүлпән баруын ишеткән дә ПМК җитәкчесе Таһиров, машинасына утыртып, Нәкыйне Арчага үзе алып китә. Нәкыя сүзгә яшьтән үк саран. Күңеленнән генә үз-үзе белән сөйләшеп бара. Ә Таһиров исә Нәкыя сүз башлаганны көтеп, аның турында уйлана. «Нәкыя тотынса, булдырыр. Өлгербез... Ул вакытында төгәлләмичә калмас. Коммунист... партбюро члены...» Колонна җитәкчеләре арасында еш әйтәләр мондый мактау сүзләрен. Эшчеләр дә яманламыйлар Нәкыйне. Аның бригадасына барам гына дип атлыгып торалар. «Сынап карыйк. Батыр яуда беленә...» Юл буе әнә шундый уйлар белән бара җитәкче.

Нәкыя исә авыллар аша үткәндә, җимерек каралтыларны күреп, үзен әллә ничек гаепле итеп сизә. Күпме төзисе бар бит әле авылда. Авылда төзелеш акрын бара. Җитмәсә, сыйфаты да мактанырлык түгел. Төзүчеләрнең үз эшләренә булган җаваплылыкларын бик нык күтәрергә кирәк, аларга куәтле техника биреп кул хезмәтеннән бушатырга кирәк, төзелеш материалларының яхшы сыйфатлысын кайтарырга, тоткарлыксыз эшләргә кирәк. Әнә никадәр проблема, хәл ителмәгән мәсьәләләр... Бригадирларга эшнең барышына күзәтчелек итү кыен. Объектлар әллә ничә урынга таралганнар. Аралары бик ерак. Нәкыйнең әнә шулар турында җитәкче кеше белән фикер уртаклашасы килә! Тиздән булачак партия җыелышында сөйләрмен әле дип, күңеленә беркетә куя.

— Рапортны «эшне төгәлләдек» дип бирсәң генә кабул итәм,— дип кисәтә Таһиров, Нәкыйне калдырып киткәндә.

Нәкыя бер айлап Арчада эшли. Йокысын, вакытын кызганмый ул. Тиргәргә, кайберәүләр белән хәтта ызгышырга да туры килә. Алар бригадасына колхозчылардан уннан артык кешене булышырга җибәргән булалар. Ләкин аларның үз тәртипләре бар икән: теләгән вакытта киләләр, теләгән вакытта кайтып китәләр. Ничек дип аңларга соң моны? Нигә шундый сүлпән караш, ваемсызлык? Үз колхозлары өчен ләбаса. Санга сукмыйлармы, әллә хезмәт дисциплинасы шулай йомшакмы? Беркөнне алар бригаданы аеруча авыр хәлдә калдыралар. Көтмәгәндә машина белән кайнар асфальт килә. Аны тиз генә бушатырга да җәеп тә куярга кирәк. Югыйсә, ул сыйфатын югалта, ката башлый. Булышырга килүчеләрне Нәкыя үгетләп тә карый, ачуланып та... Юк, күндерә алмый. «Безнең төшке аш вакыты»,— диләр дә кайталар да китәләр. Нишләтәсең аларны! Ләкин Нәкыя югалып кала торганнардан түгел. Кранчы кыздан төшке ашка үзенә дә берәр нәрсә алып килүен үтенә дә эш урынында кала. Агач кисәкләре, калдык-постык такталар, корыган чүпчар җыеп алып килә, бушатылган асфальт тирәсенә ут яга һәм башкалар төшке аштан килгәнче, асфальтны кайнар килеш тота, суынырга ирек бирми.

Бусын гына урнаштырып бетерергә дә өлгермиләр, кичләтеп кенә тагын Казаннан ике машина асфальт килеп җитә.

— Иртән тиз генә асфальт китереп җиткермәсләр, соңгарак калып килсәгез дә була,— дип мөрәҗәгать итә Нәкыя ярдәмгә килгән колхозчыларга,— бүген ничек тә бусын башкарып бетереп китик. Бераз соңгарак калып булса да...

Тик аларның үз хәсрәтләре икән. Бер ачы теллесе яра да сала: «Нәрсәгә безгә ул кадәр көчәнергә! Акчасын барыбер сез алаcыз, шәһәрнекеләр... Безгә тиеннәр генә...»

— Әллә сез эшләмичә генә акча алырга уйлаган идегезме? — ди аңа Нәкыя.— Иртән соң чыктыгыз, иртә кайтып киттегез. Эленке-салынкы йөрдегез... Болай бушка вакыт үткәрүчеләргә, әлбәттә, безнең бригадада күп түләнми. Тиеннәр генә... Файдалы хезмәткә керткән һәр өлешегез өчен минутын-сәгатен калдырмыйча алырсыз. Әйе, әйе, бер тиенегез дә югалмас. Мин моны бригадир буларак әйтәм. Теләмәгән кеше китсен. Тотмыйбыз. Калган кеше миннән рәнҗү күрмәс.

Бригада членнары белән аралашып эшләгән көннәрдә Нәкыянең холкын-фигылен, эшкә һәм кешеләргә булган мөнәсәбәтен якыннан белә башлаган «ярдәмчеләрдән» сигез кеше булышырга кала. Бригаданыкылар дүртәү... Өлгерәләр. Асфальтка суынырга ирек куймыйлар. Икенче көнне бригадир шушы сигез кешедән артык башка берәүне дә эшкә кабул итми. Ә бер айдан соң кулларына туксаншар сум акча алган «ярдәмче эшчеләр», үз күзләренә үзләре ышанмыйча, акчаларны кат-кат санап, Нәкыягә чын күңелдән рәхмәт сүзләре яудыралар.

— Миңа түгел, әнә бригада членнарына рәхмәт әйтегез,— ди Нәкыя,— төп эш алар кулында. Хезмәтегезгә күрә хөрмәте...

*

* *

...Караңгы бүлмәдә яңа төшерелгән фотопленкаларны химикатка салып эшкәртеп утырганда сине бертөрле аеруча кызыксыну хисе биләп ала. Менә фото кәгазен — позитивны зурайткыч астына тыгасың да негативтан сурәт төшерәсең һәм кәгазьне химикатка салып көтә башлыйсың. Анда башта ниндидер таплар хасил була. Алар тора-бара үзгәрәләр, төгәл сызыкларга әйләнә башлыйлар. Ниһаять, фото кәгазендә кешенең йөзе, күзләре күренә. Бераздан син инде аның кем икәнен таный башлыйсың, төсмерлисең һәм бу кеше тормышта ничек булса, шулай синең күз алдыңа килеп баса.

Нәкыя дә минем күз алдында әнә шулай акрынлап ачыла барды. Һәм мин аны бүген илебез төзүчеләренең ун миллионлы армиясе сафында аермачык таныйм. Бәйрәм демонстрацияләрендә Нәкыя беренчеләрдән булып күзгә ташлана, чөнки ул алгылар рәтендә, уң флангта байрак тотып атлый. Нәкъ төзелештәге кебек.

Шушы уң флангта атлаучы һәм колонналарны әйдәп баручы мактаулы төзүче өстеннән язылган урынсыз жалобага карата туган фикерләремне кыскача гына итеп туплап, мин редакциягә хат җибәрәм һәм, жалобаның үзен кире кагып, редакциягә кайтарам.

«...Редакциягә килгән жалобаларны тикшергәндә бер генә фактның да расланмаганына очраганым юк иде әле,— дип яздым мин, ә бу жалобада исә бер сүз дә расланмады. Ул намуслы, керсез күңелле кешегә, алдынгы төзүчегә яла ягу, аның абруен төшерү максаты белән генә язылган. Жалоба иясенә ни дип җавап язаргадыр, белмим. Әмма бригадир Нәкыя Гафиуллина турында аерым очерк язарга вәгъдә бирәм».

...Менә вәгъдәмне үтәдем шикелле. Бу көннәрдә Нәкыяне тагын очраттым. Ул ялда булган. Турист булып Венгриягә барган, Будапештны һәм башка шәһәрләрне күргән, чит ил кешеләренең ничек яшәүләре, нинди төзелешләр баруы белән кызыксынган.

— Шулай да аз гына читтә булу да туган илне никадәр сагындырды,— диде ул, безнең сөйләшүләргә йомгак ясагандай.— Читне макта, үз өеңдә тор. Кадерен белеп тор. Шуңа ни җитә!..

Әйе, кадерен белеп яши, кадерен белеп эшли Нәкыя. Соңгы вакытларда мин аны ничектер күздән ычкындырган идем. Күптән түгел аның хезмәт җиңүләре турында тагын куанычлы хәбәрләр ишетергә туры килде. Тукталып калмаган, һаман алга омтыла, көрәшнең яңа сызыкларына чыга, яңа үрләр яулый. Бишьеллыкның хәлиткеч өченче елында югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен Нәкыя бригадасына мактаулы исем — «Коммунистик хезмәт бригадасы» дигән исем бирелде. Почет грамотасы, бүләкләр алучылар, Мактау тактасына кертелүчеләр исемлегендә аның бригадасыннан да лаеклылар күп булды. Нәкыянекеләр быел да — бишьеллыкның дүртенче, иң мөһим елында да сынатмыйлар. Коллективның быел алган социалистик йөкләмәсендә «бишьеллыкны срогыннан алда үтәргә» дигән иң әһәмиятле пункт бар. Шуңа ирешү өчен алар көнлек норманы 120 процентка үтәп барырга, хезмәт дисциплинасын нык сакларга, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәргә, брак эшләүгә юл куймаска, хезмәтнең алдынгы алымнарын киң кулланырга омтылалар. Биектау һәм Мамадыш районы колхозларында һәм совхозларында «Татсельстрой» трестының 729 нчы ПМКсындагы бу мактаулы бригаданы гел уңай яктан гына телгә алалар. Менә хәзер дә Нәкыя Гафиуллина җитәкчелегендәге түбә ябучылар бригадасын Мамадышта салынып ята торган сыр заводын төзүче башка ПМК эшчеләренә булышырга җибәрделәр. Күршеләрнең хәле мөшкел икән, нигә бармаска да, нигә кулдан килгән кадәр булышмаска! Алар өчен кайда эшләсәләр дә барыбер түгелмени. Шәпше авылындагы шәһәрчә төзелгән йортларның түбәләрен алар яптылар, производство биналары салдылар. Башкарган эшеңә үзең генә түгел, башкалар сокланып караганда күңелгә тагын да рәхәтрәк булып китә бит.

Тормышындагы, хезмәтендәге уңышларны язып бара торган дәфтәр хәзер дәфтәр генә түгел, ә калын китап булып һаман тулылана бара Нәкыянең. Кызыклы һәм мактаулы китап булып...

**Яхъя Абдуллин,**

философия фәннәре кандидаты

# ИҖТИМАГЫЙ ЯҢАРЫШНЫ ЯКЛАП

Иҗтимагый яңарыш татар мәгърифәтчеләре философиясендә иң мөһим социологик мәсьәләләрнең берсе булган. Татар халкының артталыгы һәм фәкыйрьлеге, аның урта гасырчылык һәм патриархальлек сазлыгындагы күңелсез тормышы игътибар үзәгенә нәкъ менә шушы мәсьәләне куярга мәҗбүр иткән. Татар мәгърифәтчеләре Европа халыклары тормышында зур үзгәрешләр барган һәм Россия үзе дә шул үзгәрешләр өермәсенә килеп кергән бер чорда яшиләр. Алар башка илләрдә фән һәм культураның, җитештерү һәм сәүдә мөнәсәбәтләренең бик нык алга китүен күреп торалар. Шул ук вакытта аларның үз халкы фәкыйрьлектә һәм мохтаҗлыкта яши, чиксез газаплар кичерә, гомерлек хәерчелеккә дучар ителгән була. Бу хәл аларны борчымый калмый, әлбәттә. «Заманыбыз һәр шәйнең тәрәккый итдеке бер замандыр,— дип яза Ш. Көлтәси.— Ләкин безләр бу тәрәккыйдән һич файда итмичә гафләттә дәвам итмәктәбез» (Ш. Көлтәси. Мөфассал һәйяте җәдидә. Казан. 1900 ел. 105 бит).

Идарәче даирәләрнең башбаштаклыгы һәм залимлеге, мөлкәтле катлауларның эгоизмы һәм комсызлыгы, әхлакый тупаслык, милли һәм дини изү, шәхес иреген кысу, кешеләрне богауда тоткан караңгылык, халык массаларының ишаннарга һәм һәр төрле алдакчы бәндәләргә баш иеп яшәүләре — урта гасырчылыкның татарлар арасында сакланган иң авыр мирасы менә шулар була. Ш. Көлтәси аларны «бәгырьләребезне телгәләгән вә күкрәкләребезне изгән» нәрсәләр дип атый, «аларны искә төшерү дә куркыныч», ди. (Ш. Көлтәси. Һәйяте җәдидә. Казан. 1896 ел. 3 бит). Мәгърифәтчеләр: үткәннең бу авыр мирасы кешенең акылын богаулый, фәнни белемнәр һәм мәгърифәт нурлары таралуга киртә булып тора, иҗтимагый яңарышны тоткарлый, дип саныйлар.

Урта гасырчылык һәм патриархальлек күренешләренә нәфрәт белдерү, артталыкны һәм торгынлыкны гаепләү белән бергә, мәгърифәтчеләр үткәннең шул авыр мирасын яклаучы һәм саклаучыларны — реакцион руханиларны, халык массаларын алдау юлы белән байлык җыйган иске сәүдәгәрләрне дә кискен тәнкыйть итәләр. Тегеләренең дә, боларының да иминлеге артталыкны һәм караңгылыкны саклау, гомере узган иҗтимагый-икътисади тәртипләрне мәңгеләштерү белән бәйләнгән була. Шуңа күрә дә искелек тарафдарлары үз кулларындагы бөтен чаралар белән яңалыкның теләсә нинди күренешләренә каршы көрәш алып баралар, тормыштагы иске гадәтләрне һәм патриархаль тәртипләрне ничек тә булса саклап калырга тырышалар.

Мәгърифәтчеләр искелек тарафдарларының надан һәм чикләнгән кешеләр булуын күрсәтәләр, алар арасында хөкем сөргән комсызлыкны һәм карунлыкны ачып салалар, аларның рәхимсезлеген һәм эгоизмын фаш итәләр. Искелек тарафдарларының мораль йөзен фаш итеп, күренекле татар мәгърифәтчесе К. Насыйри болай ди:

**Бонча җаһил, бонча гафил,**
**Күрдекем юк филкора,**
**Бонча фәттан, бонча дәюс**
**Мәлгунь бәйнәлвәра**[1].

Иске тәртипләрне яклаучыларны фаш итү мәгърифәтчелек әдәбиятындагы барлык әсәрләрдә төп мәсьәлә булып тора. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» исемле әсәрендәге Бикбулат мулла һәм Гали бай, З. Бигиевнең «Гөнаһ кәбаир» романындагы Накәс мулла, Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасындагы Биктимер һәм яучы карчык, Ф. Халидинең «Саран, надан Теллә бай хикәяте»ндәге Теллә хуҗа, билгесез авторның «Комедия Чистайда» әсәрендәге Хәйри бикә — нәкъ менә шул катлауның вәкилләре. Әлеге образлар аша мәгърифәтче язучылар урта гасырчылыкны һәм патриархальлекне яклаучыларның чын йөзләрен ачып бирәләр, алар арасында хөкем сөргән мораль бозыклыкны һәм шәһрәт сөючәнлекне тәнкыйть итәләр, аларның никадәр чикләнгән һәм надан кешеләр булуын күрсәтәләр. М. Акъегетнең үз сүзләренә караганда, Бикбулат мулланың бөтен эшчәнлеге хөр фикерле кешеләрне эзәрлекләүгә, аларга каршы төрле мәкерләр оештыруга кайтып кала. «Бикбулат менда иҗарәе вәзыйфәсилә мәшгуль улып, менлаларга сәдака вирмәк лазем идекене мәхәлләсенә таусыя вә тәнвиһ итеп, аучы куян вә үрдәкне өмет итеп сакладыкы кеби, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде»,— ди язучы (М. Акъегет. Хисаметдин менла. Казан. 1886 ел. 19 бит). Бикбулат мулла кебекләргә җәмәгать мәнфәгатен кайгырту ят, аларның бөтен белгәне үз иминлекләрен кайгырту. Шундый кешеләрнең чын йөзен күрсәтеп, Ш. Көлтәси болай яза:

**Мәдрәсәдән чыгарлар, илгә имам булырлар,**
**Ләкин ил өчен алар кайгырмаслар, дусларым.**

**Бар эше имәк булыр, яхшы киенмәк булыр,**
**Йортын төзәтмәк булыр — максады шул, дусларым.**

**Азга һич разый булмас, барга канәгать кылмас,**
**Илдән тәмәгы бетмәс, күзе туймас, дусларым.**

**Арбасы яхшы булсын, кигәне купшы булсын,**
**Атның юргасын җиксен, чабып йөрсен, дусларым**[2]

Аллага ышанулары һәм руханилыклары белән мактансалар да, үз кирәкләрен кайгыртканда алар һәр төрле этлеккә сәләтле кешеләр. Накәс мулла, әйтик, «хили заманнан бирү «Къ» карьясендә имам улып хәйләи шәргый вә на хәлаль кәсепләр кыйлып, ришвәт вә риба тарикыйлә мал казанып шимдеки хальдә башка имамнара нисбәтән малдар бер углан»дыр (З. Бигиев. Гөнаһ кәбаир. Казан. 1890 ел. 2 бит).

Урта гасырчылыкны һәм патриархальлекне саклаучы икенче төркемгә — иске сәүдәгәрләргә дә шул ук кимчелекләр хас. Рухани кардәшләре кебек үк, болары да артык надан һәм чикләнгән кешеләр, болары да һәртөрле яңалыкка каршы, иске тәртипләрне саклау һәм мәңгеләштерү бәрабәренә, теләсә нинди әшәкелеккә әзер торалар.

Мәгърифәтчеләр халык массаларының мәнфәгатьләрен яклаучылар булалар. Шуңа күрә аларның урта гасырчылык күренешләрен һәм шул ук күренешләрне саклаучыларны тәнкыйть итеп чыгулары котылгысыз төстә социаль тигезсезлекне һәм гаделсезлекне тәнкыйтьләүгә кадәр барып җитә. «Барлык мөселманнарның мәнфәгатьләре уртак» дип лаф оручы феодаль идеологлардан аермалы буларак, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең алдынгы вәкилләре җәмгыятьтәге социаль каршылыкларга күз йомып тормыйлар. Алар җәмгыятьнең капма-каршы сыйныфларга бүленгән булуын таныйлар, байлар һәм ярлылар арасындагы тирән аерманы күрәләр. Шуның белән бергә, алар меңнәр, миллионнар белән эш иткән байлар белән иң кирәкле нәрсәләрдән дә мәх-

---

[1] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Икенче басма. Казан. 1956 ел. 401 бит.
[2] Ш. Көлтәси. Хәлемездән шикаять. Казан, 1903 ел, 9 бит.

рум ителгән ярлылар арасында тигезлек юк һәм булуы да мөмкин түгел, дип саныйлар. Шул мәсьәләгә тукталып, шигырьләренең берсендә М. Акмулла болай ди:

> **Гаҗәп һәр кем гани улса, аңа хәсне дидар әйләр**
> **Фәкыйрь мискингә права юк, мәзалләт берлә зар әйләр...**
> **Ләтафәттә хәсән улса, ки Локман хикмәте улса,**
> **Дәрига! бәхте юк ирне фәкыйрьлек шәремсар әйләр...**[1]

Ачы тормыш хакыйкате, шәхси тәҗрибәләре мәгърифәтчеләрне байлар белән ярлылар арасында бернинди уртаклык була алмый дигән фикергә китерә, алар «барлык мөселманнарның мәнфәгате уртак» дигән сүзләрнең буш сафсата гына икәнлегенә ышаналар. Оренбург шәһәрендә йөреп кайтканнан соң, зур ачыну һәм хурлану хисләре белән, К. Насыйри түбәндәгечә яза: «Шулай итеп Оренбург шәһәрендә тугыз кичә-көндез җыясы ризыгым бар, имеш. Барып ашап кайттым. Ләкин нә мин берәү белән таныштым, нә минем белән берәү таныштьι. Чөнки миндә юктыр кырык-илле мең тәңкә акча, такки байлары белән танышыр идем. Яки юк иде минем башымда зур чалма, такки голямасы белән танышыр идем» (К. Насыйри. 1894 ел өчен календарь. 37 бит).

Татар мәгърифәтчеләре җәмгыятьтә яшәп килгән социаль тигезсезлекне күрү, аңа ризасызлык белдерү һәм кешеләрнең тигезлеге идеясен күтәреп чыгу белән чикләнмиләр. Алар хезмәт иясе массаларының авыр һәм шатлыксыз тормышы турында да ачынып язалар.

Мондый мотивлар К. Насыйри, З. Бигиев, М. Акмулла кебек мәгърифәтчеләр иҗатында аеруча көчле чагыла. Ярлы халыкның авыр язмышы һәм фәкыйрьлеге хакында алар тирән ачыну белән язалар. К. Насыйри новеллаларында фәкыйрьләр тормышы барлык авырлыклары белән сурәтләнә. Аларның иң гади нәрсәләре: йортлары, урын-җирләре, киемнәре, икмәкләре, хәтта эчәр өчен сулары да юк. Җитмәсә, алар күтәрә алмаслык салымнар түләргә тиеш, шуның белән аларны каберге кергәнче җәфалыйлар. «Бер фәкыйрь,— дип яза К. Насыйри новеллаларының берсендә,— үлем сырхавы хәлендә. Якыннарыннан янына җыелган адәмнәр: «И фәлән, хәлең начар, иманыңны әйт»,— дигәч, ул бичара: «Һай, шул үлем хәлендә дә имана белән аптыраталар ла,— димеш» (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан. 1956 ел. 389 бит). К. Насыйриның симпатиясе тулысы белән гади кешеләр ягында. «Әбугалисина» исемле әсәренең төп герое һәрчак ярлыларны яклый, патшаларга, байларга, түрәләргә каршы чыга. Шуның белән бергә, мәгърифәтчеләр мөлкәтле кешеләрне фаш итәләр, алар арасында хөкем сөргән комсызлыкны, акча колы булуны тәнкыйтьлиләр. Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасындагы геройларның берсе, тирән ачыну белән, иптәшенә: «Безнең халыкка бай булсын, бай булса бар да ярый»,— ди. Татар әдәбияты. XIX йөз. 545 бит). Драманың үзендә үк әлеге сүзләргә конкрет иллюстрация китерелә: Мәһитапның әтиәнисе бердәнбер кызларын, акчасына кызыгып, ямьсез һәм эчкече, акыл ягыннан да әллә ни аерылып тормаган бай малае Җантимергә кияүгә бирергә әзер торалар. Татар мәгърифәтчелегенең икенче бер вәкиле, драматург Ф. Халиди әсәрләрендә дә шул ук идея уздырыла. Персонажларының берсеннән автор шундый сүзләр әйттерә: «...Бу мәмләкәттә нә философ кадерене белерләр, нә һөнәр кадерене, бары акча булсын, фәкать бары акча булырга кирәк...» (Ф. Халиди. Морат Сәлимов. Казан. 1905 ел. 8—9 битләр).

Татар мәгърифәтчеләре карашынча, барлык явызлыкның төп чыганагы — байлык. Акчаның зарары, аның күп төрле бәла-казаларның сәбәпчесе булуы хакында XVIII йөз шагыйре Утыз Имәни үк язган иде. XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән мәгърифәтчеләр иҗатында бу мотив тагын да көчәя төшә. «Малны сөймәк — явызлыкның кадагыдыр. Аның өчен явызлык һәммәсе малга могалләкътер», диелә К. Насыйри җыентыгындагы новеллаларның берсендә (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. 1956 ел. 381 бит). Тормышларындагы иң зур идеалны акча җыюда күргән кешеләр һәр төрле җинаятькә әзер булалар. Ф. Халидинең «Залим ачлык...» пьесасындагы Бәкер белән Зәет кебек, акча өчен алар сатылуга һәм хыянәткә кадәр барып җитәләр. Пьеса геройларыннан Сәет Яхья ачыну белән болай ди: «Муса, Муса! Бак Бәкернең йөрешенә.

[1] М. Гайнуллин. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан, 1968 ел, 236 бит.

Ачкычларны алгач ничек шатланды. Бичара, милләтне дошманга сатканга ничек куаныр. Миллионнарга хуҗа булып та канәгать түгел. Янә милләтне сатты. Ваһ, сәүдәгәрләрдә нинди кабахәтлек» (Ф. Халиди. Залим ачлык... Казан. 1906 ел. 6 бит).

Татар мәгърифәтчеләре урта гасырчылык күренешләрен һәм социаль гаделсезлекне гомумтигезлек һәм гуманизм позицияләреннән торып тәнкыйтьлиләр. Мәсьәләгә бу яктан якын килгәндә, аларның әлеге тәнкыйте мәгълүм бер чор өчен генә әһәмиятле адым була, алар иҗтимагый мөнәсәбәтләрне кайсы да булса бер сыйныф ноктасыннан торып бәяләмиләр. Менә шуңа күрә дә, никадәр генә кыю һәм рәхимсез булып күренмәсен, аларның ул көрәше эзлекле булмый, ярым-йорты тәнкыйтьтән ерак китми. Мәгърифәтчеләр милли тормыштагы артталык һәм торгынлык хакында сөйлиләр, нәфрәт белән шул артталыкны каһәрлиләр. Алар кешеләр тормышындагы гаделсезлеккә ачыналар, социаль тигезсезлекне, берәүләрнең балда-майда йөзеп тә, икенче кешеләрнең хәерчелектә яшәргә дучар ителүен фаш итәләр. Шул ук вакытта алар артталык һәм торгынлыкның да, социаль тигезсезлек һәм гаделсезлекнең дә төп сәбәпләрен ачыклауга кадәр барып җитмиләр. Социаль күренешләрне бәяләүдәге идеалистик методология, җәмгыять үсешенең объектив законнарын белмәү аларга артталыкның һәм торгынлыкның, шулай ук социаль тигезсезлекнең чын сәбәпләрен күрергә комачаулый.

Әмма мәгърифәтчеләрнең урта гасырчылык күренешләрен тәнкыйтьләве никадәр генә эзлексез һәм ярым-йорты характерда булмасын, аларның үз әсәрләрендә җәмгыятьтәге ярлы катлауларга теләктәшлек белдерүләрен уңай яктан бәяләп үтми булмый. Акча колы булуга каршы чыгып һәм мөлкәтле кешеләрне комсызлыкта, ачлар хәле белән санашмауда гаепләп, алар шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәренең, бигрәк тә хезмәт иясе крестьяннарының, мәнфәгатьләрен чагылдыручылар буларак чыгыш ясыйлар. Һәм бу яктан караганда, аларның урта гасырчылык һәм патриархальлек күренешләренә каршы көрәше гомумдемократик эчтәлеккә ия була. Абыйсына язган хатларының берсендә, Казан татарларының аяныч хәлен сурәтләп, тирән ачыну белән К. Насыйри болай ди: «Ләкин халык бик ябык. Зарланмаган кеше юк, нәрсә кыйбат, ике бәя»... (Татар әдәбияты. XIX йөз. 143 бит.) Авылда булып кайтканнан соң язган икенче бер хатында мондый юллар бар: «Өйгә кайтып килдем, белдем, күрдем, ишеттем. Нәрсә белдең, нәрсә күрдең, нәрсә ишеттең? — дип сорарсың. Белдем — зур мохтаҗлык. Ул чиктән ашкан. Күрдем — атлар юк...» (Материалы научной сессии, посвященной 120-летию со дня рождения К. Насыйри. Рус телендә. Казан. 1948 ел. 122 бит.) Бу сүзләр К. Насыйриның халык кайгысы белән яшәгән кеше булуын күрсәтәләр. З. Бигиев, М. Акмулла, Г. Ильяси, Ф. Халиди һәм башка мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә дә шул ук идеяләр уздырыла.

*
* *

Татар халкын урта гасырчылык һәм патриархальлекнең авыр мирасыннан коткару, шул заман мәдәнияте ирешкән казанышлардан файдалана белүче халык итеп күрү теләге мәгърифәтчеләр каршына, иң мөһим мәсьәләләрнең берсе төсендә, артталыктан арыну һәм яңарышка киң мөмкинлекләр ачу мәсьәләсен китереп куя. Шул ук вакытта татар мәгърифәтчеләренең иҗтимагый яңарыш мәсьәләләре буенча булган карашлары, философия һәм социология мәсьәләләре буенча булган карашлары кебек үк, җәмгыять тормышын алла тәкъдиренә бәйләп караган һәм җәмгыятьтәге һәр төрле үзгәрешләрне инкарь иткән дини тәгълиматка каршы көрәштә формалаша. Татарстандагы дини даирәләрдә киң таралган гомуми тенденцияне чагылдырып, Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов: «Священникларның христиан дине үзгәрергә дә мөмкин, ягъни даими дин түгел, ислам дине исә үзгәрешсез кала»,— дип яза («Мир ислама» журналы. 1913 ел. XII чыгарылыш. 867 бит).

Ислам динендә дини һәм дөньяви кануннар аерылгысыз төстә бергә үрелгән була, һәм ул кануннар буенча тормыштагы теләсә нинди үзгәреш инкарь ителә. Безнең тирә-юньдәге, шул исәптән җәмгыять тормышындагы вакыйгалар, дип өйрәтә дини тәгълимат, билгеле бер тәртип белән, беркинди яңалыксыз, алла ничек кушса, шулай чиратлаша. Инде сирәк кенә ниндидер яңалык туа икән, бу могҗизалы хәл дип саналырга тиеш. Өстәвенә андый могҗизалы хәлләр үтә сирәк була, анда да алла кодрәте

белән генә. Иҗтимагый күренешләргә менә шундый мөнәсәбәт җәмгыять тормышының закончалыклы характерын, анда барган үзгәрешләрнең прогрессив, алга таба юнәлгән төстә булуын инкарь итүгә китерә һәм аерым шәхесләрнең һәм халык массаларының тарихтагы актив ролен сызып ташлый иде. Бу тәгълимат артталыкны һәм торгынлыкны яклый, патриархаль тәртипләрне һәм урта гасырчылык мөнәсәбәтләрен изгеләштерә һәм шул сәбәпле иске тормыш тәртипләрен яклаучылар кулында яңалыкка каршы идеологик корал ролен үти.

Татар халкын урта гасырчылык богауларыннан азат итүне яклаган мәгърифәтчеләр дини тәгълиматның бу күрсәтмәләрен кыю төстә тәнкыйть итәләр. Аларның актив уйлану һәм эшчәнлек күрсәтү заманы үтте дигән дини карашны кискен тәнкыйтьләп чыгулары үзе үк артталыкка, торгынлыкка һәм урта гасырлардан мирас булып калган мөнәсәбәтләргә каршы юнәлдерелгән була. Татар мәгърифәтчеләре фикеренчә, җәмгыятьнең түбәннән югарыга, гадидән катлаулыга таба үсеше иҗтимагый тормышның төп кануны булып тора. «Адәб вә гадәт үзгәрүчән ула килдеке кеби,— дип яза Ш. Көлтәси,— голум вә фөнүн вә һөнәр вә санаигъларның һәрбере яңару вә арту итеЛә-итеЛә бөтенләй башка бер халәткә килмеш вә даимән бер халәт мөтәрәккыйне белмәктә булынмыштыр» (Ш. Көлтәси. Һәйяте җәдидә. Казан. 1896 ел. 4 бит).

Бүгенге югарылыкка күтәрелгәнче, кешелек җәмгыяте озын үсеш юлы үткән. Мәгърифәтчеләр моны яхшы аңлыйлар. «Истиляхатe җәгърафия» исемле хезмәтендә К. Насыйри тарихи яңарышны хәтта аерым чорларга бүләргә омтылыш ясап карый. Кыргыйлык, күчмә тормыш һәм утрак тормышны ул кешелек җәмгыятенең эзлекле төстә алмашына килгән төп этаплары дип саный. Марксистик-ленинчыл методология күзлегеннән караганда, мондый бүленеш, билгеле, төгәл була алмый. Бирелә чорларга бүлүнең төп сыйфаты итеп җитештерүнең мәгълүм тарихи ысуллары түгел, ә бәлки эшчәнлекнең характеры яки кешеләр тормышының оешу формалары алынган. Шуның белән бергә, бу инде җәмгыять тарихын фәнни нигездә аңлатуга таба мөһим бер адым да. Барыннан да бигрәк, мәгърифәтчеләр җәмгыятьнең түбән формалардан югары формаларга таба үсешен таныйлар һәм бу үсешне алла кодрәтенә түгел, ә кешеләрнең үз эшчәнлекләренә бәйләп аңлаталар. Иң мөһиме шул, иҗтимагый тәртипләрнең үзгәреп торуын тану татарлар арасындагы иске иҗтимагый тәртипләрне саклап калырга тырышуның мәгънәсез булуын аңлауга китерә.

Иҗтимагый яңарышның закончалыклы характерына басым ясау белән бергә, мәгърифәтчеләр ул яңарышның чыганакларын һәм хәрәкәткә китерүче көчләрен аңларга да омтылыш ясыйлар. Билгеле, бу мәсьәләгә дә алар, барыннан да элек, мәгърифәтчелек позицияләреннән чыгып якын киләләр. Һәм җәмгыятьнең яшәеше һәм үсеше нәрсәгә бәйләнгән, дигән сорауга фәннәрнең үсешенә бәйләнгән дип җавап бирәләр. «Мәгърифәт — һәр төрле байлыкның нигезе»,— дип язды Н. Г. Чернышевский. Күренекле рус революцион демократының бу карашын татар мәгърифәтчеләре дә тулысы белән уртаклашалар. «...Дөнья өмерләренең бөтенесенә нигез вә төп сәбәп булган укымак вә язмак хакында,— ди Ш. Көлтәси,— һәр кем фикере ирешдеке вә теле дүндеке кадәр тәргыйб вә тәшвикъ лязуме кабил инкяр түгелдер. «Адәмнең хәйванияте йимәк илә вә инсанияте укымак илә каилдер» казыйсе һәр кемгә мәгълүмдер» (Ш. Көлтәси. Һәйяте җәдидә. 2 бит). Фән һәм гыйлемгә таянып кына кешеләр кешегә яшәешләрен һәм яңарыш юлыннан алга баруларын тәэмин итә алалар. Гыйлем һәм мәгърифәтне тарату, мәгърифәтчеләр фикеренчә, иҗтимагый яңарышка төп юнәлеш биргән көч тә һәм аның төп билгесе дә. Нәкъ менә «шул голум вә фөнүн вә һөнәр вә санаигъның тәрәккыяте сәмәрәсе уларак,— дип яза Ш. Көлтәси,— Көнбатыш Европа дәүләтләре хәд вә хисапка сыймас мал вә сәрвәт, вә хыял вә фикерләргә килмәс нәфүз вә куәт кәсеп» итмешләр (Ш. Көлтәси. Һәйяте җәдидә. 5 бит).

Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең башка илләрдәге вәкилләре кебек үк, татар мәгърифәтчеләре дә гыйлемнең көчен төрлечә күпертеп күрсәтәләр. Әбугалисина гыйлемлек һәм гаделлекнең җанлы гәүдәләнеше булып тора һәм К. Насыйриның яраткан бу герое, акыллы һәм киң белемле булуы аркасында, залим һәм караңгылык белән бәрелештә теләсә нинди каршылыкларны җиңеп чыга. Аңа каршы көрәштә тиран патшалар да, аларның мәкерле вәзирләре дә, галим исемен күтәреп йөргән наданнар да һәм караңгылык патшалыгының башка вәкилләре дә көчсез булып калалар.

Фән һәм мәгариф эшенең чәчәк аткан чорларында җәмгыятьнең прогрессив үсеше һәм илнең алга китүе өчен киң мөмкинлекләр ачылса, фән һәм мәгариф эшенең түбәнгә төшүе, гыйлем тарату юлында торган төрле киртәләр, киресенчә, иҗтимагый үсешне тоткарлауга, җәмгыятьнең таркалуына һәм җимерелүенә китерә. «Бу афәтләрнең берсе,— ди Ш. Мәрҗани,— хикмәт гыйлемнәрен, аның төрле тармакларын инкарь итү, аны белүче, шуңа таянучы һәм саклаучыларны хурлау һәм кимсетү, ... бик кечкенә мәсьәләләрдә дә үзбаш фикер йөрткән, үзенчә караган өчен кяфер дип читкә кагу» (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 22 фонд. 1 саклау берәмлеге. 20 тасвирлама. 107 бит). Шундый тенденцияләрне хуплау, ди галим, кайчандыр көчле булган габбасилар хәлифәтенең җимерелүенә китергән. Анда «мәгариф, һөнәр һәм промышленность бер-бер артлы югала барды; укыту эшләре түбәнгә китте, килешеп эшләүләр кул тимәгәндәй онытылды; гыйлем һәм һөнәрләрне өйрәнү, үстерү, дөньяга кояш кебек яктылык һәм нур сипкәннән соң, бетүнең чигенә килде. Аның эзләрен өйрәнү һәм күркәм рәвештә өйрәнү юллары, наданлык сәбәпле, яшерен калды»,— ди Ш. Мәрҗани (Шунда ук, 106 бит). Нәтиҗәдә габбасилар дәүләте акрынлап үзенең элекке куәтен югалта һәм тора-бара бөтенләй таркала.

Мәгърифәтчеләр җәмгыятьнең нормаль яшәве һәм үсешендә фәннең һәм мәгариф эшенең роленә басым ясыйлар, аларның бу карашында рациональ орлык бар. Шулай да фән һәм мәгариф эшен иҗтимагый яңарышның төп нигезе дип карау методологик яктан дөрес түгел иде. Биредә мәгърифәтчеләрнең иҗтимагый тормыш күренешләренә идеалистларча якын килүләре күренә. Марксизмга хәтле булган тарих фәннәренә бәя биреп, В. И. Ленин болай ди: «Алар, беренчедән, иң яхшы дигәндә, кешеләрнең тарихи эшчәнлегендәге идея мотивларын гына өйрәнделәр, әлеге мотивларның ничек барлыкка килүләрен тикшермәделәр, иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасы үсешендәге объектив закончалыкларны күрә алмадылар, әлеге мөнәсәбәтләрнең тамырларын материаль җитештерүнең үсеш дәрәҗәсе белән бәйли алмадылар; икенчедән, элекке тәгълиматлар нәкъ менә халык массаларының хәрәкәтен иңли алмадылар» (В. И. Ленин. Әсәрләренең тулы җыелмасы. 26 том. 57 бит). Мондый чикләнгәнлек татар мәгърифәтчеләренә дә хас була. Җәмгыять үсешенең объектив законнарын аңламаганга күрә, алар җәмгыять тормышында барган үзгәрешләрне, билгеле булганча, акыл өлкәсеннән эзлиләр һәм, җәмгыять үсешенең хәлиткеч факторы төсендә, фән, мәдәният, мәгариф эшенең чәчәк атуын күтәреп чыгалар. Алар фикеренчә, җәмгыять үсешендәге төп хәлиткеч көч иҗтимагый практика да, кешеләрнең хезмәт эшчәнлеге дә түгел, ә кеше акылы.

Шулай да иң мөһиме шунда, иҗтимагый күренешләрне аңлатканда татар мәгърифәтчеләре шул заманда хакимлек иткән дини кануннар йогынтысыннан котыла алганнар. Дини даирәләрдә хакимлек иткән идеяләрдән баш тартып, алар иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә якын килүдә тарихчанлык позицияләренә басалар, тормышта барган үзгәрешләрнең прогрессив характерда булуына басым ясыйлар. Алар тарихны алла кодрәте белән түгел, ә кеше эшчәнлегенең нәтиҗәсе белән бәйләп аңлаталар. Заманы өчен бу да зур кыюлык була. Алар фикеренчә, кешелек җәмгыяте тарихында гайре табигый бер нәрсә дә юк, җәмгыятьтәге бөтен эшләр кешеләр тарафыннан эшләнә. Рас шулай икән, иҗтимагый күренешләрне аңлату өчен табигатьтән өстен көчләргә мөрәҗәгать итүнең хаҗәте юк, ә бәлки реаль кешеләрнең реаль эшләрен өйрәнергә кирәк.

Татар мәгърифәтчеләре иҗтимагый тормышта барган процессларны материалистик аңлатуга кадәр күтәрелә алмыйлар. Ләкин, аек төстә фикер йөртүче кешеләр буларак, алар фәннең, мәдәниятнең һәм мәгариф эшенең җәмгыять тормышындагы ролен билгеләп үтү белән генә чикләнеп калмыйлар. Алар әлеге иҗтимагый күренешләрнең үсеш сәбәпләрен дә аңлатырга тиеш булалар. Шуның белән бергә, алар фән һәм мәгариф эшенең үсешен тәэмин иткән объектив шартларны ачарга омтылыш ясыйлар. Дөрес, бу очракта да алар, тормышның һәм иҗтимагый үсешнең хәлиткеч нигезе буларак, материаль җитештерүнең ролен һәм әһәмиятен аңлауга кадәр күтәрелеп җитмиләр. Фән һәм мәгариф эшенең, шул сәбәптән җәмгыятьнең дә, үсешен тәэмин иткән факторларның берсе төсендә алар географик тирәлекне күрсәтәләр. Ш. Мәрҗани фикеренчә, мәсәлән, теге яки бу халыкның таулы яки урманлы җирләрдә

башкалардан аерым яшәве ул халыкның рухи үсешенә, фәнни белемнәрнең һәм мәгариф эшенең җәелүенә зыян китерә. Күрсәсез, мәгърифәтче, җәмгыятьнең нормаль яшәешенең бер факторы төсендә, географик тирәлеккә игътибар юнәлтә. Моны социологик фикер тарихында беренче мәртәбә җәмгыять тормышына климат, туфрак һәм башка шартларның тәэсире турындагы фикерне күтәреп чыккан урта гасыр гарәп галиме Ибн-Хандунның тәэсире белән аңлатырга кирәктер, мәгаен.

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, табигый-географик шартлар җәмгыятьнең нормаль яшәве һәм үсүе өчен кирәкле бер шарт булып тора. Әмма ни генә булмасын, җәмгыятьнең үсеше дә, анда барган үзгәрешләр дә аларга гына бәйләнмәгән. Җәмгыять үсеше географик тирәлек шартлары белән түгел, ә материаль җитештерү ысулларындагы үзгәрешләр белән билгеләнә. Әмма шулай да XIX йөздәге татар тормышы өчен игътибарны табигый-географик шартларга юнәлтү зур әһәмияткә ия була, чөнки мондый караш идеализмны фаш итүгә һәм тарихка материалистик караш булдыруга ярдәм итә.

Мәгърифәтчеләрнең фән һәм мәдәниятнең үсеше өчен халыклар арасындагы аралашуның һәм иҗтимагый хезмәт бүленешенең әһәмиятен күтәреп чыгулары иҗтимагый тормыш закончалыкларын аңлатуда мөһим бер адым булып тора. Ш. Мәрҗани фикеренчә, мәсәлән, башка һөнәрләрдән азат галимнәр төркеме аерылып чыккан һәм җәмгыять аларның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге өчен кирәкле шартларны тудыра алган илләрдә генә фән һәм культураның ныклап үсеше өчен уңай мөмкинлекләр туа. Фәнни белемнәрнең һәм мәдәниятнең үсеше өчен халыклар арасындагы аралашуның әһәмиятенә басым ясап, К. Насыйри кеше тумыштан белемле дә, мәгърифәтле дә булмый, ди. Алар кешенең тормыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә туплана, кешеләр никадәр күбрәк аралашса, аларның белемнәре дә шул кадәр күбрәк була. Ш. Көлтәси аралашуны шулай ук яңарышның бер факторы дип саный. Фән һәм мәгариф эшенең яңа замандагы яңарышын ул турыдан-туры информация алышу чараларының үсеше, матбугат эшенең киң таралуы белән бәйләп аңлата.

Шул рәвешчә, тарихны материалистик аңлату югарылыгына күтәрелеп җитә алмасалар да, мәгърифәтчеләр тормыштагы һәм җәмгыять үсешендәге аерым материаль факторларының ролен һәм әһәмиятен инкарь итмиләр. Тормышта һәм җәмгыятьнең нормаль яшәешендә географик тирәлекнең, кешеләрнең хезмәт тәҗрибәсенең, иҗтимагый хезмәт бүленешенең һәм халыклар арасындагы аралашуның әһәмиятенә басым ясап, алар дини-идеалистик карашларның нигезләрен җимерәләр, җәмгыять тормышы турында фәнни белемнәр таралуга җирлек әзерлиләр.

*
* *

Иҗтимагый яңарышның чыганакларына һәм юнәлеш бирүче төп көчләренә анализ ясау белән мәгърифәтчеләр татар халкын артка калдырган һәм хәерчелектә яшәткән сәбәпләрне ачыкларга омтылалар. Татарлар арасында фәнни белемнәрнең йомшак таралуы, халыкның белем дәрәҗәсе түбән булу һәм татарларның культура казанышларыннан читләшкән булуы — алар фикеренчә, әлеге сәбәпләрнең иң мөһимнәре менә шулар. «Җир йөзендә кирәк кайда күрсәң дә,— дип яза К. Насыйри,— замана әһеле гыйлем вә һөнәргә вә санагатькә шул кадәр зиһен куймышлардыр, шуйлә ки, кадимнән укыла килгән голум вә фөнүн генә җитми. Ни кадәр мал сарыф итеп яңа фәннәр иҗат кылырга иҗтиһад итәләр. Әмма ни үкенечтер ки, бөтен галәм гыйлем вә фөнүнгә кәмаль рәгъбәт белән рәгъбәт иткән заманда да милләтебез халкы арасында гыйлемнең әсәре дә юктыр» (К. Насыйри. Санаигъ голфания. Казан. 1900 ел. 2—3 битләр). Фән һәм культура казанышларын белмәү, дип саный ул, безнең халыкны артка сөйри һәм мохтаҗлыкта яшәргә дучар итә.

Ш. Көлтәси дә шул ук фикергә басым ясый. Фән һәм культура, һөнәр һәм промышленность үсешендә алга киткән халыклар искиткеч зур байлыклар, көч һәм куәт тупладылар, шул ук вакытта без, ди ул, фән һәм культура, шулай ук промышленность өлкәсендә артта булуыбыз аркасында, аларга тулысынча бәйле булып калдык. Аеруча үкенечлесе шул, ди галим, без артталыгыбыз белән килешеп яшибез, шуннан арынырга теләмибез, бу артталык һәм хәерчелек безнең халыкның табигатеннән үк килеп чыккан бер нәрсә дигән караш киң таралган (Ш Көлтәси. Хикмәте җәдидә. 18 бит).

Татар халкын артка һәм торгынлыкка сөйрәгән икенче бер җитди сәбәп итеп мәгърифәтчеләр мөселман динендәге актив эшчәнлек күрсәтү һәм мөстәкыйль төстә хакыйкать эзләү заманнары үтте дигән карашларның таралуын, кешеләр аңында тәкълидчелек һәм тәфкирчелек принципларының, шулай ук әлеге принциплар белән бәйле төстә борынгы авторитетларга сукырларча иярүнең, хәр фикерле кешеләрне ээәрлекләүнең нык тамыр җәюен саныйлар. Мәгърифәтчеләр карашынча, мондый хәл татар халкын мәгърифәт нурларыннан каплап тора, аларны фән һәм культура казанышларыннан читләштерә, соңгысы исә, үз чиратында, ярыш процессыннан читкә этәреп, халыкны артталыкка һәм мохтаҗлыкка дучар итә.

Мәгърифәтчеләр татар халкын артка һәм мохтаҗлыкка сөйрәгән җитди сәбәпләрнең тагын берсе халык белән надан муллалар һәм ишаннар идарә итүдә, дип саныйлар. «Бу афәтләрнең янә берсе,— ди Ш. Мәрҗани,— наданнарның галим, бозыкларның яхшы булып танылулары... Белеме, изгелеге... билгеле юлы булмаган бер надан кеше шәехлек дәгъвасы кыла башлый, кешеләрне ялган тынычлануга, дөнья тормышы киң, дәрәҗәсе югары кешеләргә тиешсез хөрмәт күрсәтү һәм шулар артыннан котырган эт кебек чабып йөрү рухында тәрбияләргә иҗазәт ала: гади халык шуларга иярә, алар тирәсенә эшлексезләр туплана. Мондый кешенең дәрәҗәсе күтәрелә, кадере зурая, ...кешеләр аңа киләләр, баш ияләр, уйлары, фикерләре аңа юнәлә... Әмма чын галим... андый надан шәехләргә баш ими һәм шуның аркасында кешеләрдән ераклаша» (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 22 фонд. 1 тасвирлама. 20 саклау берәмлеге. 107—108 битләр). Шушы аянычлы хәл, ди мәгърифәтче, гыйлемнәрнең таралу даирәсен чикли, массаларны караңгылыкка һәм наданлыкка сөйри, халыкның дәртен сүндерә һәм аны гарипләндерә.

Мәгърифәтче язучыларның әсәрләрендә татар халкын артка илткән һәм фән-культура казанышларыннан читләштергән сәбәпләрнең социаль-экономик нигезләрен ачыкларга тырышу да күзгә ташлана. Ш. Мәрҗани шундый факторлар төсендә татарлар арасыннан чыккан галим кешеләрнең материаль яктан начар тәэмин ителгән булуларын, аларның җәмгыятьтә түбән урында торуларын, надан сәүдәгәрләргә һәм башка байларга бәйле булуларын, көчләрен фән эшенә багышларга мөмкинлекләре булмауны күрсәтә. «Әмма безнең гасырыбызда бахосус таифәмездә,— ди ул,— гыйлемгә вә әһеленә рәваҗ юк. Тәхсилгә мәхрәк вә багыйс юк. Тәэмин мәгаш кылырлык вазифалар юк. Шуның өчен дә арамызда гыйлем артмыйдыр» («Мәрҗани» мәҗмугасе. Казан. 1915 ел. 452 бит). Күргәнегезчә, Ш. Мәрҗани бу очракта кешеләр эшчәнлегендә материаль мәнфәгатьләрнең әһәмиятен аңлауга кадәр килеп җитә. «Мокаддимате Вафиятел эль-әсляф вә тахият эль-әхляф» исемле хезмәтендә, әлеге фикерен тагын да үстерә төшеп, Ш. Мәрҗани галимнәрнең кызганыч хәле, сәүдәгәрләргә карагында начаррак тормышта яшәүләре, татарлар арасында фәнни белемнәр һәм мәгариф эше таралуга җитди киртә булып торуы хакында яза. Безнең болгар туфрагында гыйлемгә бернинди игътибар юк, ди ул. Берәү, зур тырышлык куеп һәм искиткеч кыенлыклар күреп, фән биеклекләренә күтәрелә, әмма ахырдан үзенең тормышын тәэмин итә алмый. Мондый шартларда, ди галим, бик аз кешеләр генә көчләрен һәм вакытларын фән юлына багышлыйлар. Күпчелек исә сәүдә эшенә йөз тота.

Татар халкын артка һәм мохтаҗлыкка сөйрәгән иң җитди сәбәпләрнең берсен фәнни белемнәрнең аз таралуында күргәнгә һәм мәгариф эшен, фәнне җәмгыять үсешендәге төп фактор дип санаганга күрә, мәгърифәтчеләр кешеләрне урта гасырчылык богауларыннан, караңгылыктан һәм мохтаҗлыктан коткару өчен, аларга белем бирергә, алар арасында фән казанышларын таратырга кирәк дип уйлыйлар. Моның өчен, диләр алар, башка халыкларның фән һәм культура өлкәсендәге казанышларына битараф мөнәсәбәтне бетерергә, көч һәм байлыкны кызганмыйча, ул казанышларны халыкка җиткерергә кирәк.

Җәмгыять тормышында җитештерүчән хезмәтнең хәлиткеч әһәмияткә ия булуын аңлаганга күрә, мәгърифәтчеләр, фәнни белемнәр белән бергә, практик белемнәр таратуны да хуплыйлар, шул чордагы производство нигезләрен һәрьяклап өйрәнүгә, профессиональ күнекмәләр һәм һөнәр үзләштерүгә аеруча басым ясыйлар. Производство белән бәйле һөнәрләрне белү кешенең иң зур байлыгы дип уйлыйлар алар. «Һөнәр өйрәнегез, дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас,— ди К. Насыйри,— алтын-көмеш сәфәр кешесенә хәтәрдер вә йорт-җир кешесенә дәхи хәтәре бар:

я угры алып китәр, яки утка янып китәр, әмма һөнәр бер агым судыр вә ышанычлы дәүләттер. һөнәр иясе кеше әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк» (К. Насыйри. Тәрбия китабы. Казан. 1898 ел. 2 бит).

Фәнни һәм практик белемнәр таратуның зарурлыгын алга сөргәндә мәгърифәтчеләр бу эш кешеләрнең дөньяга карашын киңәйтергә, житештерүнең заманга хас төрләрен таратырга, кешеләргә наданлыктан, хорафатларга ышанудан, бозык әхлаклардан котылырга ярдәм итәр, аларны максат куеп эшләргә өйрәтер һәм җәмгыять әгъзаларында югары әхлак нормалары тәрбияләргә булышыр дип ышаналар. Ә һөнәр үзләштерү, максат куеп эшләү, үз чиратында, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзгәрүенә китерәчәк һәм яңарышка, мәдәнияткә киң юллар ачачак.

Артталыктан, торгынлыктан котылу өчен мәгариф эшен алга сөрү — мәгърифәтчелек хәрәкәтенең уртак сыйфаты. Ләкин көнбатыштагы күп кенә илләрдә ул иҗтимагый каршылыкларны тыныч юл белән хәл итү һәм мәгърифәтле патшалар, закон чыгаручылар ярдәмендә кешеләрне мохтаҗлыктан һәм изелүдән азат итү идеяләрен алга сөрүгә кайтып кала. Дөрес, мондый тенденция аерым татар мәгърифәтчеләренең карашларында да сизелми түгел. Шундый карашның тәэсирен күпмедер дәрәҗәдә, мәсәлән, М. Акъегет, Г. Ильяси һәм Ф. Халиди әсәрләрендә күрергә мөмкин. Әмма, тулаем алганда, татар мәгърифәтчеләре халык массаларының аңын үстерүгә йөз тоталар һәм аларны артка калудан, мохтаҗлыктан коткаруның юлын шунда күрәләр.

Беренче планга халык массаларын агартуны кую татар мәгърифәтчелегенең бер үзенчәлеге булып тора. Татар мәгърифәтчеләре халыкны изелүдән һәм мохтаҗлыктан коткаруны патшадан да, помещиклардан да, дин вәкилләреннән дә көтә алмыйлар иде. Гасырлар буена туплана килгән тәҗрибә аларны хәерчелекнең төп сәбәбе халык җилкәсендә утырган нәкъ әнә шул искелек тарафдарларында икәнен аңларга өйрәтә. Татар мәгърифәтчелегенең бу үзенчәлеге бездә әлеге хәрәкәт формалашканда яшәгән тарихи шартларга да бәйләнгән. Мәгърифәтчелек вәкилләре җир шарындагы халык массаларының аңы уяна башлаган һәм кешелек җәмгыятен хәерчелектән һәм изелүдән азат итү өчен көрәш алымнары формалаша башлаган бер чорда яшиләр. Чорның шул үзенчәлеге татар мәгърифәтчеләренә дә йогынты ясый һәм алар бәхетле киләчәк өчен көрәштә массаларның аңлы эшчәнлеге никадәр мөһим булуын төшенми калмыйлар. Алар карашынча, аңлы, мәгърифәтле халык бары үзе генә үз-үзен изелүдән һәм хәерчелектән коткарырга, артталыкны һәм торгынлыкны җиңәргә сәләтле. Татар мәгърифәтчелегендә халык мәгарифе мәсьәләләрен, мәктәпләрне һәм укыту эшләрен үзгәртеп коруны бөтен кискенлеге белән кую әнә шуның белән аңлатыла. Газета һәм журналлар чыгаруда, дөньяви фәннәрне укытуны гамәлгә ашыруда, белем бирү методларын үзгәртеп коруда мәгърифәтчеләр халыкны агартуның һәм киң массаларны фәнни һәм практик белемнәр белән коралландыруның бердәнбер дөрес юлын күрәләр. Шуннан чыгып, татар халкының алдынгы карашлы фикер ияләре бер гасыр буена газета-журналлар чыгару өчен тырышалар, мәктәпләрне үзгәртеп коруны, аларда дөньяви белемнәр бирүне яклап киләләр.

Татар мәгърифәтчеләренең социологик карашларына тарихи оптимизм хас. Алар татар халкының гасырлар буена килгән артталыктан, караңгылык һәм хәерчелектән чыгачагына, иҗтимагый яңарыш юлында торган киртәләрне җиңәчәгенә ышанып яшиләр. Шул тенденцияләрне чагылдырып һәм бер үк вакытта татарлар арасында таралган төшенкелек настроениеләрен бетерергә теләп, Ш. Мәрҗани болай яза: «Безнең халкыбыз Болгар вә Казан мәмләкәтләреннән фәйзъ илаһи киселдекен зан кылалар. Шуның өчен араларыннан хакыйкый гыйлемгә малик булган кемсәнәнең зоһурыны вә соңгыларының борынгылар дәрәҗәсенә мөмкин булмаячагыны игътикад кылалар... Болгар вә Казан мәмләкәтләреннән дә фәйзъ бабы киселгәне юк» («Мәрҗани» мәҗмугасе. 613 бит). Бүгенге татарлар, борынгы бабалары кебек үк, белем үрләрен яуларга һәм мәдәният казанышларыннан файдаланырга сәләтле халык. Мәгърифәтче татарлар арасыннан да фән һәм производствоны яңа үрләргә күтәрерлек күренекле фикер ияләре чыгачагына ышана. Өстәвенә, кайбер замандашларыннан аермалы буларак, ул татарларның прогресска каядыр читтә түгел, ә үз ватаннары булган Россиядә ирешәчәкләренә ышана. Шул рәвешчә, татар халкының яңарышка бару юлын Ш. Мәрҗани Россиядәге гомуми яңарыш белән бәйли. Татар мәгърифәтчеләренең башка вәкилләренә дә шундый ук оптимизм хас. Үз романындагы каһарманнарның

берсеннән М. Акъегет болай дип әйттерә: «Татар да яртиян гакыл дәгел, зиһене бик мөкәммәлдер. Зияланмага истигдатлы бер кавемдер» (М. Акъегет. Хисаметдин менла. 46 бит). Рас шулай икән, алар мәдәният казанышларыннан файдаланырга һәм яңарыш юлына аяк басарга сәләтле кешеләр.

*
*   *

Татар мәгърифәтчеләре нинди яңарышны яклыйлар? Алар нинди иҗтимагый тәртипләр хакында хыялланалар? Урта гасырчылык мөнәсәбәтләре сакланган һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрнең үсеше йомшак шартларда яшәгәнгә күрә, алар Көнбатыш тормышы биргән әзер формалардан ерак китә алмыйлар. Көнбатыш үрнәге аларга патриархаль торгынлыктан һәм артталыктан котылу, шәхесне урта гасырчылык богауларыннан азат итү, фән, мәгариф эшен һәм производствоны үстерү юлын күрсәтә. Бу өлкәләрдә Көнбатышта ирешелгән казанышларны мәгърифәтчеләр үзенә күрә бер үрнәк итеп саныйлар һәм тормышның Европача формаларын пропагандалыйлар. Ә ул үрнәк үзенең эчтәлеге белән, мәгълүм булганча, буржуаз характерда була. Урта гасырчылык богаулары белән бәйләнгән булганга һәм аларны яңарыш юлындагы иң зур явызлык дип уйлаганга күрә, алар буржуаз җәмгыятькә хас каршылыкларны күрмиләр һәм күрә дә алмыйлар, көнбатышта тантана иткән тәртипләр урнаштыру яңарышка юл ачар, кешеләргә азатлык һәм тигезлек китерер дип ышаналар. Шуңа күрә дә алар Көнбатыш тәҗрибәсен өйрәнергә һәм шуны практикада кулланырга чакыралар.

Дөрес, татар мәгърифәтчеләре Көнбатышның буржуаз мәдәнияте алдында сукырларча баш иеп тормаганнар. Аек акыллы фикер ияләре һәм хезмәт иясе массаларның мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүчеләр буларак, алар буржуаз мәдәниятнең нинди нәтиҗәләргә китерәчәген дә сизгәннәр һәм аларны нык кына тәнкыйть иткәннәр. К. Насыйри өчен, мәсәлән, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе нәтиҗәсендә социаль тигезсезлек тирәнәюе һәм әхлакларның бозылачагы ачык була. «Бу заманда,— ди ул,— кая карасаң фәкыйрь күп вә фәкыйрьләре кайгыда, хәсрәттә вә каракльпкта, вә байларын күрсәң кефран нигъмәттә..., саранлык вә хәсислек белән күп мал җыймакта» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөласа. Казан. 1884 ел. 177 бит).

Капиталистик цивилизациянең әчкечелек, фахишәлек һәм әхлакка сыймаслык башка яклары мәгърифәтчеләрнең ачуын һәм нәфрәтен кузгата. Язучы З. Бигиев аларны зур гөнаһлар дип атый. Әлеге гөнаһларның нәкъ менә капиталистик цивилизация җимеше булуына басым ясап, ул болай яза: «Менә гыйбрәт күзе илә кара, сән безем авылның хәзердәге халенә вә илле ел мокатдәм улан халенә... Ул вакытта хәзердәге кеби авылымызда мәйханәләр юк иде. Шимде исә унбиш-егерме яшьлек угланнан алтмыш-җитмеш яшькә кәлмеш картларымыз да, аллаһ сакласын, аракы өчен җанын фида кылыр вә карендәшен үлтерер, атасын кыйнар... Әмма гөнаһ кәбаир улан бу яманлык вә фәсадымыз бердән кәлеп өстемезә дөшмәделәр. Ана карыныннан бөйлә искрек вә сәрхуш тугмадык» (З. Бигиев. Гөнаһ кәбаир. Казан. 1890 ел. 6 бит). Әгәр хәзер җинаять һәм бозыклыклар күп таралган икән, моңа кешеләр үзләре түгел, ә бәлки алар яшәгән тормыш шартлары — капиталистик цивилизация шартлары гаепле. Әсәрдәге Ибраһим һәм Якуп Галиевләр, Маһруй Агиева һәм акушер карчык, Мамай һәм Габделгафур кебек персонажлар — нәкъ менә шул цивилизация җимешләре. З. Бигиевнең кыска гына иҗат юлы әлеге зур гөнаһларны — капиталистик цивилизация җимешләрен фаш итүгә багышланган һәм аның әсәрләре кешеләрне шул гөнаһлардан арынырга өндиләр.

Ләкин, урта гасырчылык богаулары белән бәйле бер халыкның вәкилләре буларак, татар мәгърифәтчеләре буржуаз көнбатыштагы чын кимчелекләрне, андагы каршылыкларның экономик нигезләрен күрмәгәннәр һәм күрә дә алмаганнар. Шуңа күрә дә аларның тәнкыйте ярым-йорты характерда, социаль-экономик характердан бигрәк, әхлакый характерда булган. Алар, беренче чиратта, капиталистик мөнәсәбәтләрнең әхлак өлкәсенә үтеп керүен гаеплиләр, ләкин әлеге мөнәсәбәтләр китереп чыгара торган социаль каршылыкларны күрмиләр. Аерым кулларда байлыкның артык күп тупланууын тәнкыйтьләү белән бергә, алар һич кенә дә хосусый милекчелеккә каршы чыкмыйлар, киресенчә, аның изгелеген алга сөрәләр. Шундый карашларын үткәрү өчен, К. Насыйри хәтта дини китапларга таяна. Җәмгыятьтәге хезмәт

иясе массаларның мәнфәгатьләрен яклаучылар буларак, алар комсызлыкны, карунлыкны һәм башка юллар белән байлык җыюны тәнкыйтьлиләр. Әмма шул ук вакытта алар, К. Насыйри сүзләре белән әйткәндә, намуслы хезмәт белән тапкан хосусый милекне яклыйлар, аны арттырырга, әрәм-шәрәм итмәскә өндиләр. «Тәдбир белән тотсаң вә сарыф кылсаң аз нәрсә дә бәрәкәтле буладыр вә тәдбирсез тотып исраф кылсаң күп нәрсә дә җитмидер... Көненә ун тиен файда итсәң, җиде-сигез тиенен хәраҗәтеңә тотып, калганы сәрмаяңа кушылсын, гомердә фәкыйрь булмассың вә мохтаҗлык күрмәссең, әгәр ун тиен файда итеп тә унбер-унике тиен хәраҗәт тотсаң тиз эштән чыгарсың. Файда итмәгән көн икмәк белән су ашап торсаң да ярар... Гакыллы кеше шулдыр ки, кулындагын саклар» (К. Насыйри. Тәрбия китабы. 1895 ел. 19—20 битләр). Бу очракта күренекле мәгърифәтченең карашларында вак буржуаз чикләнгәнлек ярылып ята. Хосусый милекчелек мөнәсәбәтләре өстенлек иткән җәмгыятьтә гадел хезмәт белән баеп булмаячагын да, социаль тигезсезлекне бетерү мөмкин түгеллеген дә алар аңлап җиткермиләр.

Социаль каршылыкларның тирән сәбәпләрен аңламау да, яңа күтәрелеп килгән сыйныфның — пролетариатның тарихтагы урынына һәм роленә төшенеп җитмәү дә татар мәгърифәтчеләре алга сөргән социаль идеалның чикләнгән булуына китерә. Артык байлар да, артык хәерчеләр дә булмаган, һәркемнең байлыгы шәхси хезмәте белән тәэмин ителә торган җәмгыять аларның идеалы булган. Бу — вак товар житештерүчеләр — крестьяннар һәм һөнәрчеләр җәмгыяте. Мондый җәмгыять хосусый милекчелекне бетерми генә түгел, киресенчә, аны үзе тудыра. Мондый җәмгыятьтә бәхетле булу өчен белем алу, берәр төрле һөнәргә өйрәнү, чын күңелдән хезмәт итү һәм шул юл белән табылган малга канәгать булып яшәү җитә. «Гыйлем һөнәре,— ди К. Насыйри,— уку һөнәре кебек, һәр һөнәрне бер камил остаздан өйрәнмәк лаектыр... Нитәк ки гыйлем укып, остаздан фатихасыз чыккан кеше мәнфәгать күрмидер... һөнәр иясе бай булмаса да, мохтаҗ булмыйдыр. һөнәрсезлек мәзмүм эштер» (К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. 381 бит).

Караңгы татар авылында яшәгән Ш. Көлтәси «Мәктәп баласы яхут Сәхилә әби» исемле әсәрендә үзе өчен идеал булган җәмгыятьне сурәтли. Бу җәмгыятьтәге барлык кешеләр — ирләр дә, хатын-кызлар да, аларның уллары һәм кызлары да яхшы белемле, киң мәгълүматлы кешеләр. Алар нигездә игенчелек һәм терлекчелек белән көн күрәләр, кулларыннан башка һөнәр дә килә. Биредә яшәүчеләр ачлыкны, мохтаҗлыкны белмиләр. Алар житеш яшиләр, ләкин артыгын кимиләр, артык ашамыйлар, араларында ялкаулар бөтенләй юк. Ялкаулык бу илдә хәерчелекнең төп сәбәбе санала, шуңа күрә ялкауларга көн күрсәтмиләр. Әмма хезмәткә яраксыз гариплэр, картлар һәм карчыклар бәладә калдырылмый, алар хакында җәмәгать кайгырта. Хәерчеләр һәм мөлкәтсез кешеләр булмагач, хәер сорашу, караклык та юк. Кешеләр ифрат тату һәм тыныч яшиләр.

Мондый идеалның чикләнгәнлеге күренеп тора. Аңарда крестьян массаларының гаделлек һәм тигезлек хакындагы примитив идеаллары чагыла. Шул ук вакытта ул хыялый һәм утопик характерда. Чөнки хосусый милекчелек мөнәсәбәтләре хакимлек иткән җәмгыятьтә социаль гаделлек тә, тигезлек тә була алмый. Мондый рухтагы карашлар татар мәгърифәтчеләренең шәһәрдәге һәм авылдагы хезмәт массаларының авыр хәленә кызганып караулары, аларны мохтаҗлыктан коткару өчен янып яшәүләре, ләкин иҗтимагый тормышның үсеш закончалыкларын, төрле сыйныфларның хәлен һәм ролен белмәүләре, социаль изелүдән һәм гаделсезлектән котылуның, халык массаларының тормыш шартларын яхшырту юлларын белмәүләре хакында сөйли.

Шулай да татар мәгърифәтчеләре алга сөргән карашлар массаларга гамәлдәге иҗтимагый тәртипләрнең яраларын ачып салганнар, кешенең бәхете өчен башка социаль системаның зарур һәм мөмкин булуын күрсәткәннәр һәм шул юл белән якынлашып килгән зур вакыйгалар алдыннан кешеләрнең аңнарын агартканнар. Заманында аларның тәгълиматы социаль изүгә һәм гаделсезлеккә каршы актив чакыру булып яңгыраган. Аңарда мәгърифәтчеләрнең кешеләрне һәртөрле изүдән азат итеп, экономик яктан да, политик яктан да тигез хокуклы итеп күрү теләге гәүдәләнгән. Алар хыял иткән җәмгыятьтә акыл һәм гаделлек, ә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә югары мораль принциплар җиңәргә тиеш була. Бу җәмгыятьтәге кешеләрнең бәхете һәм иминлеге байлык белән дә, биләгән урыны белән дә түгел, ә кешенең шәхси хезмәте һәм халыкка хезмәт итүе белән билгеләнергә тиеш була.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ

*Мәгълүм булганча, 24 һәм 25 май көннәрендә республикабыз башкаласы Казанда Татарстан язучыларының VIII съезды булып үтте. Съездга СССР Язучылар союзы һәм РСФСР язучылар союзы идарәләре вәкилләре, «Литературная газета», «Литературная Россия» газеталарының, Мәскәү нәшриятларының җаваплы хезмәткәрләре, союздаш һәм автономияле республикаларның язучылар союзы вәкилләре, аерым алганда, Мәскәүдән РСФСР язучылар союзы идарәсе председателе, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое С. Михалков, РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре В. Тельпугов, союздаш һәм автономияле республикаларның язучылар союзы вәкилләре — Украинадан Ф. Гарин, Белоруссиядән О. Савицкий, Әзербәйҗаннан И. Ароз, Үзбәкстаннан Б. Байкабуев, Төркмәнстаннан А. Алиев, Кыргызстаннан А. Айтбаева, Каракалпак АССРдан К. Мамбетов, Башкортстан АССРдан Ә. Мирзаһитов һәм Р. Низамов, Чувашия АССРдан Н. Дедушкин, Мордовия АССРдан И. Пиняев, Мари АССРдан С. Вишневский, Удмуртия АССРдан Г. Сабитов иптәшләр килде.*

*Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге мөдире урынбасары А. А. Беляев, партиянең өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, партия өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. И. Демидов, партия өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, республиканың киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.*



*С. В. Михалков Казан вокзалында.*

*Язучылар иҗаты һәм союз идарәсенең оештыру эшчәнлеге турында отчет докладын Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури ясады.*

*Съезд проза әсәрләре буенча язучы Гариф Ахунов докладын, поэзия буенча шагыйрь Илдар Юзеев докладын, драматургия, әдәби тәнкыйть һәм балалар әдәбияты буенча драматург Т. Миңнуллин, тәнкыйтьче Р. Мостафин, балалар язучысы Л. Ихсанова докладларын тыңлады. Рус язучыларының иҗаты хакында язучы Тихон Журавлев сөйләде.*

*Ревизия комиссиясенең отчетын язучы Г. Гобәй ясады.*

*Докладлардан соң фикер алышуда язучы Ф. Хөсни, РСФСР язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков, ТАССР журналистлар союзы идарәсе председателе Ш. Хамматов, драматург Р. Ишморат, язучы Ә. Баянов, ТАССР Культура министры Ә. Миндубаев, Татарстан нефть берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү. Саттаров, шагыйрь С. Хәким, Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин, Татарстан композиторлар союзы идарәсе председателе Н. Җиһанов, тәнкыйтьче*

*Г. Кашшаф, Буа районының «Коминтерн» колхозы механизаторы И. Гәрәев, язучы Нәби Дәүли, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре З. Бохараев, Казан дәүләт университеты профессоры Х. Госман, КамАЗ төзүчеләрнең комплекслы бригада бригадиры В. Филимонов, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары А. Әхмәдуллин, Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншина, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин, Татарстан художниклар союзы идарәсе председатель урынбасары Ә. Тумашев иптәшләр катнашты.*

*КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев съездда речь белән чыкты.*

*Съезд Татарстан язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады.*

*Идарә составына Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким, М. Әмир, А. Расих, Г. Ахунов, И. Юзеев, Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, М. Шабаев, Т. Миңнуллин, З. Нури, Ә. Маликов, Г. Рәхим, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, М. Зарипов, М. Маликова, Г. Паушкин, Ш. Рәкыйпов, А. Әхмәдуллин иптәшләр сайланды.*

*Ревизия комиссиясенә Ш. Бикчурин, Р. Даутов, К. Тимбикова иптәшләр сайланды.*

*Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе итеп язучы, Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Гариф Ахунов, аның урынбасары итеп шагыйрь Илдар Юзеев сайланды. Идарә секретарьлары итеп Р. Фәйзуллин һәм М. Хәбибуллин сайланды.*

*«Казан утлары» журналының баш редакторы итеп З. Нури билгеләнде.*

*Журналның бу санында без съезд материалларын урнаштырабыз.*

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

Татарстан язучыларының VIII съезды совет халкы, КПССның XXIV съезды карарларын тормышка ашыра барып, бишьеллыкның күтәренке йөкләмәләрен үтәү өчен үз-үзен аямыйча фидакарьләрчә эшләгән, халык хуҗалыгы һәм культура төзелешенең барлык тармакларында яңа уңышларга ирешкән истәлекле көннәрдә уза. Съездыбыз тагын шул ягы белән истәлекле, ул илебез тормышындагы иң зур вакыйгага — СССР Верховный Советына сайлауларга хәзерлек барган көннәргә туры килде.

Узган съездыбыздан соң алты ел вакыт узды, һәм ул елларның һәркайсы безнең республика тормышына да зур үзгәрешләр алып килде. Совет халыкларының бердәм гаиләсендә Татарстан хезмәт ияләре туган ягыбызның йөзен үзгәртәләр, яңа калалар һәм заводлар төзиләр, продукциянең мөһим төрләрен җитештерүне арттыралар, культура өлкәсендә яңа биеклекләр яулыйлар. Бүген Татарстан җирендә илебездәге барлык милләт вәкилләренең көче белән тугызынчы бишьеллыкның иң зур объекты — Кама автомобиль комплексы төзелә.

Республика тормышындагы бу зур вакыйгаларның һәммәсе безнең язучыларның әсәрләрендә дә чагыла. Замандаш образы татар әдәбиятының төп героена әйләнде, бүгенге эшченең акылына һәм аңына фәнни-техник революциянең тәэсирен күрсәтү, төрле милләт эшчеләренең интернациональ дуслыгын сурәтләү аның төп темасы булды. Татар совет язучылары үзләренең төп бурычларын социалистик чынбарлыкның байлыгын һәм күп төрлелеген, аның үсешенең төп процессларын дөрес сурәтләүдә күрәләр.

Социалистик реализм методы нигезендә совет әдәбиятының иң яхшы традицияләрен үстерә барып, бүгенге татар язучылары тематик диапазоннарын киңәйтәләр һәм замандашыбызның характерын, аның эчке дөньясын ачып бирү өчен яңадан-яңа сәнгатьчә сурәтләү чараларын табалар. Язучыларның тормыш, предприятие коллективлары, авыл хуҗалыгы эшчәннәре, хезмәтчел интеллигенция белән бәйләнешләре ныгыды.

Республика язучылары идея эчтәлегенең байлыгы ягыннан гына түгел, ә сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да камил әсәрләр иҗат иттеләр. Соңгы елларда татар әдәбиятының барлык жанрларында традиция һәм новаторлык өлкәсендә кызыклы эзләнүләр барды.

Ике съезд арасындагы чор эчендә Татарстан китап нәшрияты 168 исемдәге проза әсәре, 154 шигырь җыентыгы, 36 сәхнә китабы һәм 47 публицистика китабы дөньяга чыгарды. Татарстан язучыларының күп кенә әсәрләре Мәскәү нәшриятларында басылды һәм бөтен союз укучысының ихтирамын казанды.

Съезд, күп милләтле совет әдәбиятының иң яхшы традицияләренә турылыклы калган хәлдә, татар язучылары алга таба да заманның актуаль мәсьәләләрен күтәргән яңа сәнгать әсәрләре язарлар, үз әсәрләрендә бүгенге көн кешеләренең масштаблы һәм тулы канлы образларын иҗат итәрләр, дип ышана. Шул максат белән Татарстан язучылары социалистик реализм методын тагын да тулырак һәм тирәнрәк үзләштерерләр, тирән, зур эчтәлекнең камил формалардан башка була алмавын күздә тотып, даими төстә профессиональ осталыкларын чарлый барырлар.

Яшь язучылар белән эшләү Татарстан язучылар союзы оешмасының иң мөһим бурычларыннан санала, чөнки әдәбиятыбызның киләчәге алар кулында. Яшь язучыларыбызның идея һәм эстетик дәрәҗәләре югары булырга тиеш. Язучылар союзы идарәсенең бурычы — яшь әдәбиятчыларны тәрбияләү өчен идея-политик эшнең бөтен форма һәм чараларыннан оста файдалану, аларны иҗат эшенә югары җаваплылык хисе белән карарга өйрәтү, аларның әдәби осталыкларын чарларга ярдәм итү. Яшь алмашка әхлак тәрбиясе бирү, аларның иҗтимагый активлыгын көчәйтү мәсьәләләрендә Язучылар союзы идарәсе аеруча зур кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш. Иҗат союзларының яшь иҗат көчләрен үстерү мәсьәләләренә багышлап уздырылган берләштерелгән пленумы зур яңгыраш тапты, пленум карарлары уңышлы төстә тормышка ашырыла.

Съезд Татарстан язучылар союзы идарәсен яшь язучылар белән активрак эш алып барырга, яшьләрнең «Идел» альманахын даими төстә чыгаруны тәэмин итәргә, «Казан утлары» журналы һәм «Идел» альманахы редколлегиясен яшь язучылар иҗатын тагын да тулырак яктыртып барырга мәҗбүр итә.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә югары казанышлар өчен көрәштә әдәбият-сәнгать тәнкыйте хәлиткеч роль уйный. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында: «Тәнкыйтьнең бурычы бүгенге әдәби күренешләрне, тенденцияләрне һәм закончалыкларны тирән анализлаудан, ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык принципларын ныгытуга һәр яктан булышлык итүдән, совет сәнгатенең югары идея-эстетик дәрәҗәсе өчен көрәшүдән, буржуаз идеологиягә каршы эзлекле чыгыш ясаудан гыйбарәт, — диелә. — Әдәби тәнкыйть художникның идея кругозорын киңәйтүгә һәм аның осталыгын камилләштерүгә ярдәм итәргә тиеш».

Үзәк Комитетның әлеге карарын кулланма итеп алып, күп кенә татар тәнкыйтьчеләре, партияле, принципиаль позицияләрдән торып, бүгенге әсәрләребезгә тирән һәм төпле бәя бирәләр. Шуның белән бергә, күренекле әдәбият белгечләренең үзәк газета һәм журналлар битендә тиешле дәрәҗәдә актив катнашмауларын билгеләп үтәргә кирәк. Съезд Язучылар союзы идарәсенә яшь тәнкыйтьчеләргә игътибарны көчәйтергә, «Казан утлары» журналы каршында оешкан яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенә көндәлек ярдәм күрсәтеп барырга тәкъдим итә.

Съезд хезмәт ияләренә әхлак һәм эстетик тәрбия бирүдә прозаиклар, шагыйрьләр һәм драматургларның нәтиҗәле эшләвен билгеләп үтә. Шуның белән бергә, съезд татар драматургларының пьесалары бүгенге тамашачыны һәр вакытта да канәгатьләндереп җиткермәвенә, татар театрлары сәхнәләрендә, актуаль темаларга язылган драма әсәрләре белән бергә, вак темаларга караган спектакльләр дә урын алуына басым ясый.

Үсеп килүче яшь буынга коммунистик тәрбия бирүдә балалар һәм яшьләр әдәбияты искиткеч зур роль уйный. Шуны истә тотып, съезд Татарстан язучылары союзы идарәсенә балалар әдәбияты мәсьәләләренә тагын да игътибар бе-

ләнрәк карарга, яшь буын турында язучы авторларның иҗади үсенә булышырга тәкъдим итә.

Съезд Татарстан язучылар союзы идарәсенә Татарстан китап нәшрияты белән элемтәләрне тагын да ныгытырга, матбугатка иң лаек, халыкка кирәк әсәрләрнең генә чыгуына ирешергә тәкъдим итә.

Съезд шулай ук Татарстан язучылар союзы оешмасының союздаш һәм автономияле республикалар, край һәм өлкәләр язучылары белән иҗади элемтәләрне киңәйтү юнәлешендәге зур, нәтиҗәле эшен билгеләп үтә. Тугандаш әдәбиятларның үзара дуслыгын үстерә, бу күркәм эшне ныгыта һәм камилләштерә барырга кирәк, чөнки төрле милләт язучыларының үзара иҗади элемтәләре аларның иҗатларын баета.

КПССның XXIV съезды резолюциясендә: «Әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрендә партия ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык принципларыннан чыгып эш итә. Партия социалистик реализм нигезендә эшләнгән күп төрле бай формалар һәм стильләр ягында тора. Ул художникның талантына, аның иҗатының идея ягыннан коммунистик юнәлештә булуына, безнең алга баруыбызга комачаулый торган бөтен нәрсәгә карата килешмәүчән булуына югары бәя бирә. Безнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте партия линиясен актив төстә үткәрергә, зур принципиальлек белән чыгыш ясарга, таләпчәнлекне такт белән, әдәби кыйммәтләр иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләргә тиеш», — диелә.

Татарстан язучылары Коммунистлар партиясенең менә шушы югары идея-эстетик таләпләрен үзләренең иң мөһим эшләре, сугышчан программалары дип кабул итәләр.

Съезд Татарстан язучылары союзы идарәсен съезд материалларын җентекләп өйрәнергә һәм алдагы елларга республика язучылары оешмасының конкрет эш планнарын төзергә мәҗбүр итә.

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ**

## Зәки Нури

# ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ

Житез адымнар белән иҗади тормышыбызның тагын алты елы үтеп китте. Ул еллар, һәр вакыттагыча, уңышлы һәм җимешле булдылар, аларны без, эш киемнәре кигән килеш, ил белән, халык белән бергә атладык. Татарстанда, туган илебездә, бөтен дөньяда яңгыраган зур бәйрәм тантаналары, безгә илһам көче биреп, иҗат юлыбызда якты маяклар булып балкыдылар.

1970 елның апрелендә бөтен илебез һәм планетаның барлык хезмәт ияләре бөек юлбашчы һәм остаз, Коммунистлар партиясенә һәм Совет дәүләтенә нигез салучы, даһи фикер иясе һәм бөек революционер Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулган көнне гаять тантаналы шартларда, зурлап билгеләп үттеләр. Тормышыбызны тагын да көчлерәк идеялелек һәм гражданлык нуры белән балкытып, Ленин юбилее әдәби иҗат өчен зур этәргеч булды.


Шушы ук елны Совет Татарстанының 50 еллык бәйрәмен үткәрдек. Республикабыз күкрәгенә Ватан, Ленин ордены белән янәшә, Октябрь революциясе ордены такты.

1971 елның язы совет кешеләре хәтерендә бик озак сакланыр, бу язда Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең тарихи XXIV съезды булды. Съезд документларындагы һәр сүз — марксистик-ленинчыл идеяләр кояшының якты нуры ул. Тугызынчы бишьеллык

планның һәр саны — илебезне тагын да куәтлерәк, тагын да гүзәлрәк итәргә булышачак батырлык биеклеге ул. Съезд массаларга партия йогынтысы ясауда язучы сүзенең зурлыгын һәм кыйммәтен тагын бер кат бөтен тулылыгы белән күрсәтте. Матур әдәбият әсәрләренең совет кешесенең дөньяга карашын, аның әхлакый сыйфатларын, рухи культурасын формалаштырудагы зур роленә аеруча нык басым ясады. «Әдәбиятның һәм сәнгатьнең нәтиҗәле үсеше барлык союздаш республикаларыбызда, СССР халыкларының уннарча телләрендә, күп төрле милли формаларда бару факты зур канәгатьләнү хисе тудыра»,— диде Леонид Ильич Брежнев.

Иҗатыбызга бирелгән мондый зур бәяне без халык тормышына актив катнашып кына, илнең экономик куәтен арттырырлык, совет кешеләренең тормышын баетырлык рухи хәзинәләр тудырып кына аклый алабыз.

1972 елда СССР төзелүгә 50 ел тулды. Бу бәйрәм совет кешеләренең идея бердәмлеге, рухи туганлык тантанасы, социалистик милләт һәм халыклар культурасының үзара тагын да якынаю бәйрәме булды. Зур истәлекле бүтән вакыйгаларны каршылагандагы кебек үк, совет кешеләре бу бәйрәмгә дә яңа хезмәт бүләкләре белән килделәр һәм аны яңа казанышлар белән билгеләп үттеләр. Хезмәтенә күрә хөрмәте, ди халык. Татарстан республикасы байрагына өченче орден — Халыклар дуслыгы ордены тагылды. Без бу югары бүләккә СССР халыклары арасындагы туганнарча дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытудагы зур уңышларыбыз, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура өлкәсендәге казанышларыбыз өчен лаек булдык. Республикабыз күтәрелгән биеклекне ачыграк күз алдына китерү өчен, кайбер саннарга мөрәҗәгать итик. 1973 елда Татарстан промышленность продукциясе җитештерүнең күләме буенча революциягә кадәрге дәрәҗәне 461 тапкыр узып китте. Моннан илле ел элек бездә 84 предприятиене берләштергән 20 промышленность тармагы булса, хәзер индустриябезнең 500 дән артык эре комбинатны, завод һәм фабриканы берләштергән 100 дән артык тармагы бар. 1913 елда Казан губернасы ел буена җитештергән продукцияне хәзер безнең промышленность предприятиеләре бер көндә эшләп чыгара. Быел нефтьчеләребез илгә тагын 103 миллион тонна нефть, 4 миллиард кубометрдан артык газ бирәчәк...



*Шагыйрь Зәки Нури.*

Шунысы аеруча куанычлы, республикабызның халык хуҗалыгы өлкәсендә ирешелгән бу казанышларда безнең өлеш — язучылар өлеше дә шактый гына. Иҗат өчен тормыш безгә әнә нинди бай материал бирә! Илебезнең киң колачлы эшләре, соңгы елларда халыкара хәлне сизелерлек яхшыртуга китергән тынычлык программабыз, әлбәттә, әдәбиятта да чагылмый калмады. VII һәм VIII съездлар арасындагы алты ел вакыт кыю эзләнүләр, киеренке хезмәт, күп төрле җәмәгать эшләрендә янып яшәү белән үтте. Бөтен талантыбызны, көчебезне, иҗади дәртебезне без шуңа бирдек. Язучылар коллективының төп игътибары әдәбият әсәрләрендә чорның бөеклеген гәүдәләндерергә, көрәшче, тормышны яңабаштан үзгәртеп коручы хезмәт кешеләренең тулы канлы образларын иҗат итүгә юнәлдерелде.

Безнең иҗат эшебезгә партия өлкә комитеты даими тәстә ярдәм итеп килде. Республиканың иҗат интеллигенциясе белән принципиаль һәм эшлекле, кайгыртучан һәм таләпчән мөнәсәбәт булдырылды. Партия өлкә комитеты талантларны саклау, аларны идея ягыннан чыныктыру, инициативаны, һәртөрле файдалы башлангычны яклау, иҗат союзлары эшчәнлегенә көндәлек юнәлеш бирү юлында конкрет чаралар күрде. Безнең белән эшләүнең, икенче төрле әйткәндә, тәрбиячеләрне тәрбияләүнең күп кенә отышлы һәм нәтиҗәле юллары табылды. Өлкә комитетында очрашулар һәм әңгәмәләр, төрле семинарлар, язучылар җыелышларындагы докладлар һәм чыгышлар һәм башкалар, һәм башкалар... Мондый зур игътибар һәм кайгыртучан мөнәсәбәтне без югары идеяле, сәнгатьчә камил әсәрләр иҗат итү, актив төстә җәмәгать эшләрендә катнашу белән акларга тырыштык.

Һәм менә без башкарылган эшләргә, әдәби иҗат һәм оештыру эшләре өлкәсендә тупланган тәҗрибәгә йомгак ясау өчен җыелдык. Съездны тагын да биегрәк иҗат үрләренә менү өчен старт мәйданчыгы итеп карарга мөмкин. Үткән алты елның һәркайсы, һичшиксез, безне ничәдер баскычка югары күтәрде. «Биектә торган күбрәкне күрә», дигән мәкаль бар. Әйе, без хәзер бер нәрсәне бик яхшы күрәбез һәм аңлыйбыз: союзнигыбыз һәм тәрбиячебез буларак, вакыт безне тагын да ныграк дисциплинага, оешканлыкка, дуслыкны тирәнрәк тоярга, үз иҗатыбызга карата таләпчәнрәк һәм тыйнаграк булырга, һәр язучының иҗади үсеше, бөтен коллективның иҗади үсеше өчен бик тә кирәкле һәм файдалы булган тәнкыйть сүзенә колак салырга өйрәтте. Съезд вакытындагы фикер алышуларыбыз КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында әйтелгән зур таләпләр югарылыгында барыр, дип ышанырга кирәк.

Ә фикер алышыр һәм сөйләшер нәрсәләр күп.

1968 елның башыннан 1973 елның ахырына кадәр Татарстан китап нәшрияты, кабат басылган әсәрләрне исәпләмичә дә, 168 исемдә проза китабы, 154 шигырь китабы, 36 сәхнә җыентыгы, 47 очерк һәм әдәби-документаль әсәрләр җыентыгы басып чыгарган. Моннан тыш, безнең әсәрләребез 58 коллектив җыентыкка һәм 68 музыкаль җыентыкка кертелгән. Шулар янына тәрҗемә китапларын китереп кушарга кирәк.

Күпме байлык, күпме тормыш материалы, күпме кеше язмышы ул китапларда! Аларның геройлары, тарихның авыр сынауларын үтеп, сугыш утларында көйгән, җимерек хуҗалыкны торгызышкан һәм менә бүген килеп данлы бишьеллыклар постында торган батырлар белән янәшә яши. Күпне күргән, күңелләре аша күпне кичергән, әмма һәр вакыт киң күңелле булып кала белгән мәхәббәтле һәм мәрхәмәтле кешеләр алар.

Отчет чорында, халыклар бәхете һәм хәзерге яңарыш символы буларак, Ленин темасы иҗатта аерым бер урын алды. Язучылар, тәрҗемәчеләр һәм китап нәшрияты хезмәткәрләренең күмәк көче белән татар әдәбияты тарихында моңарчы күрелмәгән зур хезмәт — алты томлык ленинианаы бастырып чыгару тәгәлләнде. Ул томнарда үз әдәбиятыбызның, СССР халыклары һәм дөнья халыклары әдәбиятларының бөек юлбашчыбызга багышланган иң яхшы үрнәкләре тупланган. Татар язучыларының В. И. Ленин яшәгән һәм эшләгән урыннарда булып, Ильич васыятьләренең ничек тормышка ашуын күрсәтү максаты белән язылган публицистик әсәрләрен куанычлы яңалык дип бәяләргә кирәк. Вакытында «Казан утлары» журналы оештырган бу башлангычны күп санлы укучыларыбыз чын күңелдән хуплап телгә алды һәм телгә алачак.

Сибгат Хәким берничә еллар дәвамында шигырь һәм поэмаларында үз ленинианасын иҗат итте. Соңгы вакытта ул әсәрләргә шагыйрьнең:

> Таулар, таулар, мәһабәт зур таулар,
> Әйт, кешелек, ашып күкләрдән:
> Әллә таулар аны, әллә Ленин тауны
> Җилкәсенә биек күтәргән? —

кебек, тирән фәлсәфи фикерле яңа шигырьләре өстәлде.

Укучы Габдрахман Әпсәләмовның Ленин турындагы хикәяләрен дә яратып кабул итте. Язучының узган ел «Казан утлары» журналында басылган «Күк күкрәр» исемле яңа романында

юлбашчыбызның безнең шәһәр белән бәйле тормыш һәм көрәш юлын сурәтләүгә киң урын бирелгән. Роман остасының зур тәҗрибәсе, фидакарь хезмәте бу чиксез җаваплы һәм кыен теманы нигездә уңышлы башкарып чыгарга ярдәм иткән. Хәзерге көндә авыру булуына карамастан, язучы, аерым китап итеп чыгару өчен, романның яңа вариантын әзерли. Әдәбиятыбызның ару-талу белмәс шушы эшчән кешесенә ныклы сәламәтлек, озын һәм бик озын иҗат яшьлеге телик!

Ике съезд арасындагы алты ел вакыт эчендә ленинианабызга Нури Арслановның «Җилкәнче», Рөстәм Мингалимовның «Минем дәүләтем» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Соңгы гыйнвар»ы кебек үзенчәлекле яңа поэмалар өстәлде, татар шагыйрьләре бик күп яңа шигырьләр һәм җырлар иҗат иттеләр. Габдрахман Минский белән Виктор Байдеринның Владимир Ульяновның Кокушкино чоры турындагы хикәяләре аерым китап булып чыкты. Әмма укучы зур дулкынлану һәм түземсезлек белән бөек якташыбыз Ленин турында элеккеләренең барысыннан да яхшырак язылган яңа әсәрләр, образлы яңа сүз көтә.

Әдәбиятта беркайчан да барлык жанрлар бер дәрәҗәдә тигез үсмәгән. Бер чорда бер жанр, икенче чорда икенче жанр алданрак барган. Жанрлар үсешенең бик тә катлаулы һәм үзенчәлекле эчке хасиятләре бар. Әмма барлык жанрдагы әсәрләр алдына куела торган төп бер таләпне истән чыгарырга ярамый. Совет язучысы бары тик югары идеяле, сәнгатьчә камил эшләнгән әсәрләр, социалистик реализмны расларлык, укучыларда актив гражданлык хисләре һәм югары әхлак сыйфатлары тәрбияләрлек әсәрләр иҗат итәргә тиеш. Бу исә язучыдан халыкчан һәм партияле карашларда торуны, чынбарлык күренешләренә сыйнфый ноктадан карап бәя бирә белүне сорый.

Тематик колачның киңлеге, әдәби алым һәм стильләрнең байлыгы, болардан да бигрәк, бүгенге көн мәсьәләләрен, бүгенге кешеләр тормышын гәүдәләндерергә омтылышы белән әдәби хәрәкәтнең алгы сафында прозабыз атлый. Проза әдәбияты йөз белән заман темасына, хезмәт кешеләренә борылды. Ә хезмәткә дан җырлаган китаплар кешеләргә шатлык китерә, аларда иҗади тынгысызлык, батырлыкка омтылыш уята, аларны яңа уңышларга әйди. Конкрет мисалларга мөрәҗәгать итик. Прозаикларыбыз тарафыннан соңгы елларда иҗат ителгән 15 яңа романның 9 ы, 80 нән артык повестьның дүрттән өче диярлек бүгенге көн проблемаларына, хезмәт темасына багышланган.

Элеккерәк елларда хезмәт темасына караган әсәрләр коры, рәсми тел белән язылa, производство мәсьәләләре, техник процесслар җанлы кешеләрне, аларның хис-кичерешләрен күмеп китә иде. Менә шуңа күрә дә «производство» романнары үз вакытында каты һәм җитди тәнкыйтькә очрады. Хәзер андый әсәрләр акрынлап онытылып бара, ул заманнар артта калды. Хезмәт темасына багышланган әсәрләрнең күпчелегендә без тулы канлы характерлар белән очрашабыз, ул әсәрләр сюжет-композиция һәм конфликтларның бөтенлеге белән аерылып торалар. Хезмәт темасына караган әсәрләрдә «иҗтимагый як» белән «шәхси якны», производство процесслары белән кеше хисләрен дөрес бәйли белү һәр вакыт җитди проблема булып килде. Һәм бу мәсьәләнең бүген дә актуальлеген югалтканы юк. Билгеле, әдәби характерның асылын аның нинди профессия кешесе булуы гына билгеләми. Аннан соң без теге яки бу профессия кешеләре өчен кулланма әсбаплар да язмыйбыз. Әмма «Хуҗалар» романындагы Арслан Гобәйдуллинны үз стихиясеннән, нефтьчеләр тормышыннан, нефть чыгару эше белән бәйле мәсьәләләрдән аерып карагыз, ул чагында бу романтик герой күп мәртәбә кечерәеп, төссезләнеп калыр иде. Гариф Ахуновның башка әсәрләрендә дә хезмәт кешеләрен сурәтләүгә киң урын бирелә, ул — безнең прозаны хезмәт кешеләренең кызыклы образлары белән баеткан язучы. «Зәңгәр чәчәк — гашыйклар төсе» әсәрендәге маляр кыз, «Чиклəвек төше»ннән коммунист Халикъ Саматов һәм, ниһаять, Урал төзелешләренең берсендә фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәткән Мирсәет Ардуанов («Ардуан батыр») — әнә шундыйлар. Соңгы повесте белән язучы хезмәт темасының тарихи әһәмияткә ия булган тагын бер мөһим ягын ача — ул бүгенге яшьләрне беренче бишьеллыклар чоры батырла-

рының күркәм традицияләре белән таныштыра.

Г. Ахуновның «Ардуан батыр»ындагы кебек үк, Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» исемле повестенда да, бер тамчы суда чагылган кояштай, халкыбызның хезмәт биографиясе күз алдына килә: эштә ару-талуны белмәс татар егетләре Донбасста күмер казыйлар, Днепрогэс плотинасына бетон салышалар, Магнитканы күтәрешәләр һәм Төрксиб юлына рельсләр сузышалар.

Билгеле булганча, язучыларның Беренче Бөтенсоюз съездында татар совет әдәбияты турында махсус доклад тыңлана. Персонажлары хезмәт сөючән һәм эшчән кешеләр булган өчен, М. Горький татар язучыларының әсәрләренә югары бәя бирә. Дөрес, ул чактагы әсәрләребезнең күпчелек персонажлары авыл кешеләре булган. Бу бик табигый дә, чөнки заманында республика халкының гомуми составында эшчеләр 22 процент кына исәпләнә иде. Җәмгыятьнең бу авангарды хәзер Татарстан халкының яртысыннан күбрәген тәшкил итә.

Мондый хәл әдәбият-сәнгать әсәрләрендә хезмәт кешесен, эшче образын тагын да тулырак, тагын да калкурак итеп күрсәтүне таләп итә.

Бу мәсьәләгә аерым басым ясау, беренчедән, иҗатыбызның төп нигезен — тормышны ныклап һәм тирәнтен өйрәнүнең никадәр мөһим эш икәнлеген тагын да киңрәк аңлау өчен кирәк булса, икенчедән, әдәби алмашыбыз билгеле бер хезмәт биографиясе булган сәләтле художниклардан әзерләнергә тиеш, дигән фикерне куәтләү өчен дә кирәк булды. Ахыр килеп, без үз геройларыбызны кеше эшчәнлегенең күп төрле сфераларында, күп милләтле зур коллективларда, төрле географик киңлекләрдә сурәтли белергә тиешбез.

Сыек ягулыкның тирәндә яткан катламнарына төшеп җитәр өчен, нефтьчеләргә җир ятмаларының каты токымнарын бораулап үтәргә туры килә. Шуның кебек үк, кеше рухының тирәнлекләренә үтеп керү өчен, «Каты токым» романының авторы Шамил Бикчуринга да гаять зур тырышлык, күп хезмәт куярга кирәк булгандыр. Нефтьчеләр, дөресрәге, нефтьче-разведчиклар турындагы бу әсәр төрле холыклы, төрле язмышлы кешеләрдән, төрле милләт вәкилләреннән торган бригаданың бердәм коллектив булып туплануын күрсәтүгә багышланган. Татар образлары белән бергә, автор башка милләт вәкилләренең әдәби образларына да күп урын биргән, аларны тулы канлы, тормышчан итеп эшләүгә күп көч куйган. Бик кирәкле һәм мактауга лаек башлангыч бу! Халыклар дуслыгын көчәйтү, интернационализм традицияләрен үстерү безнең төп бурычыбыз булып тора һәм дөньяга карашыбызның, тормышыбызның асылын билгели.

«Интернационализм» һәм «миллилек» төшенчәләрен, бер-берсен тулыландырып килгән бу ике сыйфатны образлы төстә бер көймәнең ике ишкәге белән чагыштырырга мөмкин. Бер генә ишкәк белән ишкәндә, дөрес маршрут белән алга барып булмый. Менә шуның өчен дә безнең язучылар, тугандаш халык вәкилләренең фикерләү үзенчәлеген, аларның гореф-гадәтләрен һәм милли традицияләрен тирәнтен һәм конкрет өйрәнеп, интернациональ коллективлар тормышында нинди кыенлыклар килеп чыгуын, аларны ничек җиңәргә кирәклеген, төрле милләт кешеләре арасында патриотизм һәм интернационализм хисләренең ничек тәрбияләнүен, коллективның шәхескә ничек йогынты ясавын ышандырырлык итеп күрсәтеп бирергә тиешләр.

Ике съезд арасындагы иҗат эшчәнлегебезнең тематик юнәлеше турында сөйләгәндә, КамАЗ төзелеше турындагы әсәрләргә аерым тукталу урынлы булыр. Халык энтузиазмы, халык көче һәм халык акылы белән төзелә торган бу гигантның әдәби елъязмасы 1969 елларда ук, әлеге төзелешкә беренче казыклар кагылган көннәрдә үк языла башлады. Тормышның алгы сызыгында булырга яраткан художникны тынгысыз йөрәге бүгенге көннәр пульсы ныграк типкән, конфликтлар зуррак һәм ачыграк, хисләр тыгызрак булган, олы характерлар формалашкан урынга тартты. Һәр вакыттагыча, бу өлкәдәге беренче адымнар очерклар, репортажлар, шигъри зарисовкалардан башланды. Язучылар төзелеш тормышыннан дулкынландыргыч яңа фактлар эзләп таптылар, аларны билгеле бер проблемалар белән бәйләделәр, кечкенә булса да

кызыклы һәм үзенчәлекле ачышлар ясадылар. Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романы, Геннадий Паушкинның хикәя һәм очерклар китабы, Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм Барлас Камаловның повестьлары, Хисам Камалов, Рөстәм Мингалимов, Роберт Әхмәтҗанов, Сибгат Хәким шигырьләре һәм поэмалары әнә шул билгесез яңалыкның беренче карлыгачлары булып саналырга тиеш.

Югарыда исемнәре саналган әсәрләр арасыннан Диас Вәлиевнең «Дәвам» пьесасы бер безнең генә түгел, бөтен союз тамашачыларының да игътибарын казанды. Әсәрдә кеше һәм ул башкара торган эш, кешенең үзе башкара торган эшкә мөнәсәбәте, хәзерге зур төзелешләрдә эшне оештыру һәм төзелеш белән идарә итү кебек мәсьәләләр күтәрелә. Ул мәсьәләләрне хәл иткәндә төрле характерлар бәрелешә, кызыклы язмышлар очраша. Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романында ике инженерның эшкә һәм тормышка төрлечә карашы күрсәтелә, бүгенге төзелеш белән бәйле кызыклы мәсьәләләр күтәрелә.

КамАЗ турында ике коллектив җыентык язылды. Берсе проза, икенчесе поэзия әсәрләреннән торган ул җыентыклар озакламый басылып чыгачак. КамАЗда безнең язучыларның даими посты бар. Актив эшләүче берничә яшь язучы яңа шәһәрдә бөтенләй төпләнеп калды. Без анда КамАЗга шефлык итүче «Новый мир» журналы хезмәткәрләре белән янәшә эшлибез, төзелеш мәйданнарында тугандаш республикалардан килгән күпләгән язучылар белән очрашабыз.

Шул рәвешчә, съезд канәгатьләнү белән билгеләп үтә ала: без төп рубежга чыктык — эшче темасына кыю борылыш ясадык. Моңа эшче коллективлары белән бәйләнешләребезнең киңәя баруы да, язучыларга бирелә торган иҗат командировкаларының идарә тарафыннан рациональ бүленүе дә һичшиксез зур ярдәм итте. Язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләре яңа кулъязмаларны таләпчәнрәк килеп, сыйфат мәсьәләсен беренче планга куеп тикшерә башладылар. Иҗат секцияләренең хокуклары киңәйтелде, аларга тагын да зуррак эшләр йөкләнде, һәм секцияләр үз бурычларын шактый әйбәт үтәп киләләр, дияргә була. Турыдан-туры производствода эшләүчеләр — нефтьчеләр янында иҗади киңәшмәләр үткәрү, «Социалистик Татарстан» газетасы һәм «Казан утлары» журналы битләрендә бүгенге көн герое, бүгенге проза мәсьәләләре һәм, шуларга бәйләп, язучының осталыгы турында иҗади бәхәсләр уздыру безне бүгенгә көнгә шактый якынайтты.

Соңгы елларда язылган иң яхшы әсәрләр замандашыбыз образын тудыруга багышланды. Ул әсәрләрдә сурәтләнгән образлар егерменче гасыр героеның җыелма портретын күзалларга ярдәм итәчәк. Бу геройлар — иң җитди мәсьәләләрне дә мөстәкыйль төстә хәл итәргә сәләтле, гражданлык җаваплылыгын тойган, эчке дисциплиналы кешеләр. Алар — югары аңлы һәм инициативалы, үз эшләренең мөһимлеген һәм кирәклеген аңлап эш итә торган кешеләр, ә бу, үз чиратында, авыр минутларда аларга көч һәм дәрт бирә. Алар — инанган идеяле, зур фикер һәм хис кешеләре, мещан бәхетеннән һәм вак буржуаз психологиядән һәр вакыт өстен тора торган кешеләр. Хезмәт — алар өчен шатлык һәм бәхет китерә торган иҗат чыганагы. Алар — шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне оста берләштерә белгән, әмма үзләренең индивидуаль йөзләре булган намуслы геройлар. Эштә тәгәллек, тәвәккәллек, вакытлы кыенлыклар алдында каушап калмау, алар алдында тез чүкмәү аларны кыю рәвештә билгеләнгән максатка алып бара. Һәм, әлбәттә, алар техниканы яхшы белүләре, профессиональ осталыклары, югары культурага омтылулары белән аерылып торалар.

Кайчандыр А. И. Герцен, тирән ачыну белән: «Кеше барлык сыйфатларда йөрде, ә кеше сыйфатында йөргәне юк әле»,— дип язган иде. Ә безнең көннәр герое тормышта да, әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендә дә, барыннан да элек, үз иленең хуҗасы, рухи яктан бай иҗтимагый шәхес булып яши. Шушы елның март аенда чирәм җирләрне үзләштерүчеләрнең Алма-Ата шәһәрендә үткәрелгән зур бәйрәмендә андый кешеләр турында олы сүзләр әйтелде. «Әмма без, чирәм җирләрнең кешеләрне үстерүе турында сөйләгәндә, аларның үсешен кайда һәм кем булып эшләүләре белән генә үлчәмибез. Кеше өчен үсешнең шундый ук әһәмиятле һәм күркәм тагын бер төре бар. Мин



*Президиум өстәле артында.*

рухи чыныгуны, үз эшеңнең остасы булуны, әхлакый яктан өлгерүне күздә тотам»,— диде иптәш Л. И. Брежнев.

Соңгы елларда язылган әдәбият әсәрләрендә һәм театрларыбыз сәхнәләрендә барган спектакльләрдә саф күңелле, принципиаль, киң эрудицияле, башкаларны үз артыннан ияртә ала торган нык рухлы коммунистлар образлары күбәйде. «Чикләвек төше»ндәге Саматов, «Дәвам»дагы горком секретаре Саттаров, Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» повестендагы райком секретаре Кадергулов һәм авыл темасына багышланган әсәрләрдәге башка парторглар һәм колхоз председательләре — әнә шундый геройлар.

Хезмәттән соң, җир, бик хаклы рәвештә, икенче герой дип йөртелә. Җирдә бар нәрсәдән кыйммәт һәм кадерле икмәк үсә. Муллык һәм байлык символы буларак, башак дәүләтебезнең гербын бизи. Рафаил Төхфәтуллин («Агымсу»), Фатих Хөсни («Мәйдан»), Вакыйф Нуруллиннарның («Күпер чыкканда») яңа әсәрләре ару-талуны белмәс җир кешеләренә тирән хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Р. Төхфәтуллинның «Агымсу» повестенда игенче белән нефтьче хезмәте, авыл кешеләре белән нефтьчеләрнең үзара мөнәсәбәтләре турында сүз барса, Фатих Хөсни белән Вакыйф Нуруллинны кайчандыр артта калган хуҗалыкны ничек итеп аякка бастыру, алдынгылар рәтенә чыгару кебек мәсьәләләр борчый. Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Икмәк кадере» повесте җирне санга сукмаучыларга, аны әрәм-шәрәм итүчеләргә каршы язылган. Сарманда яшәүче яшь язучы Хәниф Хәйруллин («Канатлар талмасын») бүгенге авылны индустриализацияләү һәм хезмәтне специальләштерү белән бәйле проблемаларны күтәрде. Авыл темасына язылган әсәрләргә нәкъ әнә шул нәрсәләр җитми иде һәм хәзер дә җитми. КПССның XXIV съезды документларында әйтелгәнчә, җитештерү көчләрен үстерү, авылда көнкүрешне үзгәртеп кору һәм культураны күтәрү буенча партия һәм хөкүмәт күргән эшлекле чаралар игенченең

социаль йөзен һәм психологиясен танымаслык итеп үзгәртә килә. Авыл темасына караган әсәрләребездә бүгенге авылның объектив тормышы җитәрлек чагылмый әле. Авылның йөзен үзгәртә, кешеләр алдында яңа горизонтлар ача торган яңалыкларның авыл тормышына тиз үтеп керүенә әдәбият активрак ярдәм итәргә тиеш.

Игенче хезмәте турында кайчандыр актив язган авторларыбыз сафы табигый тестә сирәгәя бара. Съездда сайланачак яңа идарә язучылар иҗатын күбрәк «икмәк фронтына», кыр һәм ферма эшчеләренең характерларын ачуга юнәлдерергә тиеш, дип уйлыйм. Бездә авыл интеллигенциясенең эшләре һәм уй-хисләре турында да яңа китаплар күбрәк чыгарга тиеш. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романында, Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» һәм Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» пьесаларында, мәсәлән, педагоглар хезмәте, һәм укытучыларның бүгенге авыл тормышында катнашулары шактый уңышлы һәм тәэсирле итеп сурәтләнә.

Бу уңайдан, гомумән, драматургларыбызның яңадан-яңа темаларга тотынуларын, бүгенге көннең дулкынландыргыч проблемаларын күтәрү буенча шактый актив эшләүләрен билгеләп үтәсе килә. Әсәрләр сан ягыннан да аз түгел. Республика театрлары 1968 елдан башлап тамашачыларга 95 оригинал, 54 тәрҗемә әсәре буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәттеләр. Качалов исемендәге Зур драма театры, Яшь тамашачылар һәм Бөгелмә шәһәр театрлары, кызганычка каршы, татар драматургларының әсәрләрен сәхнәләштерү эшенә әле һаман да җитди игътибар биреп җиткермиләр.

Бүгенге драматургиябез хакында сөйләгәндә, бу өлкәдәге бер куанычлы яңалыкны билгеләп үтәсе килә: театрлар һәм драматурглар хәзер тормышка тирәнрәк үтеп керәләр, җитди һәм катлаулы проблемалардан курыкмыйлар, конфликтларны иҗтимагый позицияләрдән торып чишәргә омтылалар. Тамашачының актив фикер йөртүенә, үзендә зур җаваплылык хисе тәрбияләвенә ирешергә тырышалар. Театрларыбызга халыкның күп йөрүен әнә шуның белән аңлатырга кирәк. Әмма семья низагларына гына корылган сай эчтәлекле әсәрләр дә шактый әле, чын драмалар аз языла, трагедияләр бөтенләй юк диярлек. Театрлар белән драматурглар арасындагы бәйләнешләрнең тагын да тыгызрак, нәтиҗәләрәк һәм иҗадирак булуын телисе кала. Нурихан Фәттахның «Кол Гали» трагедиясе күрсәткәнчә, авторның стилен тоеп, авторның максатын аңлап, аңа ярдәм итү, драматургларга иҗади заказлар бирү, аларның фикерен кирәкле мәсьәләләргә юнәлтү матур нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Бүгенге тормыштагы һәр яхшы китап — зур һөҗүмдә яңа җиңү ул. Ә бу эштә һөҗүмнең «давыл хәбәрчесе» һәм эз салучысы булган разведкадан башка җиңеп булмый. Әдәби очерк һәм публицистика фундаменталь әсәрләр язарга нигез хәзерли торган әдәби разведка булып исәпләнә. Алар ярдәмендә без иҗатыбызның беренче юлларын салабыз, алар ярдәмендә илебез биографиясенең бер өлешен тәшкил иткән бишьеллыклар биографиясе языла. СССР Язучылар союзының, «Язучы һәм бишьеллык» дигән темага багышлап, 1973 елда үткәрелгән пленумында һәркемнең исендә калырлык шундый бер чагыштыру китерелде. «Әдәбиятны сәгать механизмы белән чагыштырып карасак, роман, пьеса, поэма кебек жанрларны сәгатьнең акрын гына хәрәкәт итә торган кечкенә теленә, хикәя белән шигырьне минутларны күрсәтә торган зур теленә, публицистиканы секундларны күрсәтә торган теленә тиңләргә мөмкин...» диде бер оратор. Секундлардан минутлар һәм сәгатьләр җыелган кебек үк, очерк белән публицистика да әдәбиятның эре жанрларын иҗат итәргә нигез әзерли.

Безнең заманның сәнгатьчә хроникасын, халыкның героик биографиясен иҗат итү буенча гүзәл традицияләребез һәм бай тәҗрибәбез бар. Пушкин һәм Герцен, Толстой һәм Короленко, Фатих Әмирхан һәм Галимҗан Ибраһимов үзләре яшәгән чор тормышына иң актив катнашу чараларын эзләгәннәр һәм тапканнар. Алар «көнкүреш ыгы-зыгысында» көндәлек тормышның тирән процессларын, күп төрле вакыйга һәм күренешләрнең асыл мәгънәсен ачканнар. Башка күренекле язучыларыбыз да турыдан-туры хезмәт коллективлары тормышына үтеп керергә, замандаш-

лары йөзендә киләчәк кешесенең образын күрергә омтылып яшәгәннәр. «Матур туганда» дигән романын язу өчен, Шәриф Камалга, мәсәлән, авыл хуҗалыгы коммуналары оештырып йөрергә туры килә. «Лирика җепләре», шагыйрьнең күкрәк читлеге төрмәсеннән котылып, җанлы тормышның иреклә ярларына сузылсын» өчен, Һади Такташ шахтерлар янына китә. Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин.

Г. Әпсәләмов, Г. Минский, Ф. Хөсни, Т. Журавлев, М. Садри, Н. Дәүли, А. Расих, М. Зарипов кебек очерк һәм публицистика жанрында актив эшләгән авторлар сафына Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова, Җәмит Рәхимов, Равил Вәлиевләр шикелле сәләтле яшьләр килеп кушылды. Алар күп санлы тормыш вакыйгалары арасыннан иң мөһимнәрен сайлап ала беләләр, күзгә бәрелеп торган эффектлы хәлләр артыннан куып азапланмыйлар. Бу жанрда шагыйрьләребез дә күбрәк һәм активрак эшли алырлар иде.

Безнең күптәннән нигезе салынган һәм вакыт сынавын уңышлы узган зур поэтик традицияләребез бар. Аларны киңәйтү, тирәнәйтү һәм үстерү юнәлешендә яңа эзләнүләр алып барыла, тәҗрибәләр эшләнә. Без формалар, стильләр төрлелегенә омтылабыз һәм еш кына уңышка да ирешәбез. Поэзиядә фәлсәфи-лирик һәм психологик башлангыч көчәеп килә.

Трибун шагыйрьләребездән Һади Такташ, Гадел Кутуй һәм Муса Җәлил, замандашыбыз Хәсән Туфан һәм башкалар үз иҗатлары белән безгә поэзиядә олы гражданин булу, лириканы политика белән бәйләү, матбугат битләрендә, радиода һәм телевидениедә шигырь ярдәмендә көндәлек пропаганда эшен алып бару һәм заманның истәлекле вакыйгаларын һәм казанышларын зурлауның, ә эшкә комачаулаган әшәке җаннарны аяусыз камчылауның матур үрнәкләрен күрсәттеләр. Шундый актив гражданлыкны безнең коллектив һәр вакыт һәм һәр язучыда тәрбияләргә тиеш. Җыеп әйткәндә, зур проблемаларны чишәргә ярдәм итәрлек вакыйгалар турында, заман сулышын чагылдырган яңа традицияләр турында сугышчанрак төстә язарга һәм шул юл белән кешеләр аңындагы иске гадәтләрне, аларның көнкүрешендәге чатак йолаларны тизрәк һәм активрак җиңәргә кирәк. Шулай эшләмәсәң, әйтик, Әнвәр Давыдов башлаган поэтик симфонияне ничек ахырга кадәр илтеп җиткерергә, тормыш биргән бай материалны ничек үзләштерергә мөмкин дә, ничек аны миллионнар йөрәгенә ятышлы гади һәм матур җыр итәргә ди?!. Бу очракта безне борчый торган тагын бер фактны әйтми үтеп булмый: зур тормыштагы зур характерлар бәрелешен күрсәтер өчен, сюжетлы һәм вакыйгалы поэмалар мөмкинлегеннән нигәдер елдан-ел азрак файдаланабыз. Тормышның үзеннән кискен сюжетлар эзләмәсәң һәм тапмасаң, әсәрдә күтәрелгән проблемаларны да үгет-нәсыйхәт, шомарып беткән купшы сүзләр ярдәмендә хәл итүдән башка чара калмый.

Хезмәт коллективлары тормышы белән эшлекле һәм нәтиҗәле төстә танышу өчен барыбызга да зур мөмкинлекләр бар. Соңгы елларда төрле коллективларның Язучылар союзы белән бәйләнеше аеруча ныгыды һәм киң колач алды. Бу бәйләнеш Питрәч районының Вахитов исемендәге колхоз члennары белән иҗади дуслыктан башланды. Алар авыл темасына язылган әсәрләрне җентекләп өйрәнделәр һәм конкурска тәкъдим ителгән ике әсәрне колхозларының дипломы белән бүләкләделәр. Быел әдәби смотр-конкурслар тагын өч коллективта үткәрелә. Мондый бәйләнешләрне һәртөрле чаралар белән ныгытырга һәм тагын да киңәйтә төшәргә кирәк.

Сүз дә юк, бүгенге тормыш ифрат катлаулы һәм күп кырлы. Аны тиз генә аңлау һәм сәнгать әсәрләрендә чагылдыруның читенлеге һәркемгә ачык аңлашылса кирәк. Әмма халыкның хезмәт батырлыгы иҗат батырлыгына чакыра, һәм без алга өндәп кенә калмаска, ә заман геройлары белән бергә хезмәт мәйданына барырга, күңелебезне яңа тәэсирләр белән баетырга, теманы йөрәк аша уздырырга, эмоциональ тәэсир көченә ия булырлык әсәрләр иҗат итәргә, тормыш биргән тәэссоратларны мөмкин хәтле укучыга тулырак кайтарып бирергә тиешбез. Димәк, бөтен эшне актуаль темага кайтарып калдыру, иҗат эшендәге бракны оперативлык белән акларга тырышу ярамый

да, кичерелми дә. Художникның осталыгы, хезмәт сөючәнлеге һәм таланты гына уңыш китерә. Сыйфат мәсьәләсе һәр вакыт иҗат эшенең үзәк проблемасы булды. Чөнки начар сыйфатлы эш белән теләсә нинди матур башлангычны харап итәргә мөмкин. Идеялелек художестволылыктан башка яшәмәде һәм яшәми.

Әдипләребезнең осталыгын күтәрү һәм аларны укыту буенча нинди конкрет эшләр эшләнде соң?

Идарә утырышларында һәм партия җыелышларында, даими һәм планлы төстә, язучыларның иҗат отчетлары тыңланды. Безнең язучыларның иҗаты, шулай ук РСФСР язучылар союзы секретариатында, Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия семинарларында тикшерелде. Татарстан язучыларыннан биш кеше М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы икееллык югары әдәби курсларга җибәрелде. Шул ук әдәбият институтын 4 яшь автор тәмамлады. Хәзерге көндә институтның көндезге һәм читтән торып уку бүлегендә 10 кешебез укый, шуларның сигезе — тәрҗемә бүлегендә.

Идея-сәнгатьчә дәрәҗәләре югары булган әсәрләр республиканың Г. Тукай исемендәге премияләре белән бүләкләнде: алты ел эчендә бу бүләккә 6 иптәшебез лаек булды. Ә өч кеше Җәлил исемендәге комсомол премиясе белән бүләкләнде. Шагыйрь Сибгат Хәким Ленин турындагы поэмалары һәм соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре өчен РСФСРның М. Горький исемендәге премиясен алды. Бу еллар эчендә, әдәбият өлкәсендәге уңышлары һәм иҗат юбилейлары уңае белән, бер әдип Ленин ордены, өч кеше Октябрь Революциясе ордены, 5 кеше Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, 4 кеше «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән 30 язучыга «Хезмәттәге батырлык өчен» медале тапшырылды. Коллективыбыздан 6 язучы КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамоталары, тагын алты кеше ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләнде. Драматурглардан Хәй Вахит белән Юныс Әминевкә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, тагын өч язучыга Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Булачак китапларның кульязмаларын тикшергәндә, әдәби әсәрнең теленә зур таләпләр куела. Шул мәсьәләләрне хәл итү, тел турында конкрет һәм эшлекле сөйләшү өчен махсус җыелыш үткәрелде. Әгәр яңа чыккан кайбер әсәрләребез турында «күңелдә җылы тәэсир калдырды» дигән сүз әйтелми калган икән, моны тәнкыйтьнең һәм бүгенге укучыларның әдәби әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешенә аеруча зур таләпләр югарылыгыннан торып якын килүләре белән генә аңлатырга мөмкин. Чамасыз ашыгып язылганлыктан, Мәхмүт Хәсәновның «Саумы, кояш!» дигән тарихи романы, мәсәлән, укучылар арасында әллә ни зур яңгыраш тапмады. Гөлбану, Камил һәм Мохтар кебек образларның потенциаль мөмкинлекләрен автор тулысынча ачып бетерә алмаган. Автор үз геройларының күңеле түренә үтеп керә һәм шунда ачыш ясый алмаса, андый әсәр бармак белән баскач тавыш чыгара торган курчакка охшап кала. Нишлисең, ашыккан суларның күбесе зур диңгезләргә барып җитә алмый диләр бит.

Бик күп әсәрләрдә күзгә бәрелеп торган охшашлыкка, «игезәклеккә» дә чик куясы иде. Үзебез дә сизмәстән, кайбер әдәби алымнарны тәмам шомарып беткәнче, кабат-кабат файдаланырга яратабыз. Тыштан караганда, «Күпер чыкканда» һәм «Мәйдан» повестьларындагы охшашлыкны тою читен, әмма ул охшашлылык бар. Ни өчендер инде ничә әсәрдә төп герой сабан туйда көрәшеп, яки «Галиябану» спектаклендә Хәлил ролен уйнап сынала. Б. Камаловның «Урамнар киңәя» повестендагы Яфиз Шәйхаттаров белән «Язгы күкрәү» повестендагы Нурзат Ханов — икесе дә сигезенче класс укучылары. Беренчесе мәктәп-интернаттан КамАЗга кача, икенчесе, әнисе белән ызгышканнан соң, өен ташлап китә. Яфизга да, Нурзатка да тормышларын рәтләргә киң күңелле кешеләр булыша. Геройларның соңгы язмышлары да бер төсле үк: Яфиз «туры юлга» чыга, Нурзат мәктәпкә, үзе яраткан спортка кире кайта. Сәләтле, актив эшләүче, ике съезд арасында «Күршеләр» дигән әйбәт повесть язган Барлас Камаловыбыз, күрәсең, гади бер хакыйкатьне истән чыгар-

ган: ширпотреб товары кебек кулдан-кулга күчеп йөргән әдәби алым үзе дә ямьсезләнә, әдипне дә бизи алмый.

Осталыкны даими күтәрү, талантны иҗат дисциплинасы, хезмәт культурасы белән ныгыту турында күбрәк кайгыртырга кирәк. Гомумкешелек культурасының бу таләпләре безнең барыбыз өчен дә табигый норма булып әверелсен. Язучының бер генә минутны да исраф итәргә хакы юк, чөнки бушка үткән гомерне берничек тә кире кайтарып булмый. Бездә талантка туктаусыз үсәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар, әмма талантган күп сорала да. Бу турыда яшьләр белән әңгәмә вакытында совет әдәбиятының күренекле язучысы Леонид Леонов бик матур фикер әйткән иде. Менә аның сүзләре: «Талант белән традиция кешегә мораль расписка белән бирелә. Һәм Ватан, милли казнабыз саекмасын өчен, аларны законлы процент белән кире кайтарып бирүне дә таләп итә ала». Һәр көнне, һәр сәгатьтә киеренке, нәтиҗәле эш — заман таләбе әнә шундый.



*Съезд залында. Нури Арсланов, Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Гайнуллин.*

«Шик юк ки, әгәр дә безнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте партия линиясен тагын да активрак үткәрсә, таләпчәнлекне такт белән, әдәби хәзинә иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән чыгыш ясаса, совет әдәбиятының һәм сәнгатенең уңышлары тагын да зуррак булыр, ә кимчелекләре тизрәк бетерелер иде». Бу сүзләр партиянең XXIV съезды трибунасыннан әйтелде. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы шуннан соңгы карарында күп милләтле совет культурасын тагын да үстерү, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең идея-сәнгатьчә дәрәҗәсен күтәрүдә тәнкыйтьнең роленә югары бәя бирелде. Партиянең бу кайгыртучанлыгы әдәбият белеме һәм тәнкыйть хезмәтләренең сыйфатын яхшыртуга этәрде, тәнкыйтьнең иҗтимагый абруен күтәрде. Соңгы елларда татар тәнкыйтьчеләре һәм әдәбият белгечләре дә әдәби хәрәкәтнең актуаль проблемаларына багышланган байтак хезмәтләр яздылар. Теге яки бу язучыны я гел мактаган, я гел хурлаган, я булмаса вульгар социологизм күсәге белән эш иткән еллардан аермалы буларак, тәнкыйтьчеләребез хәзер бүгенге әдәби күренешләрне һәм тенденцияләрне җентекләп тикшерә, әдәби әсәрләрнең үзенчәлеген һәм нечкәлеген тирәнрәк тоеп эш итә башладылар. Шул ук вакытта талантка таләпчән һәм сак мөнәсәбәт белән килү дә күренә. «Казан утлары» журналы каршында яшь тәнкыйтьчеләрнең даими төстә эшли торган семинары оештырылды. Матбугатта, телевидение һәм радиода тәнкыйть-библиография эшенең куелышы яхшыра бара. Әмма безнең әйдәүче һәм юнәлеш бирүче көчебез, иҗтимагый фикер командиры булган тәнкыйтькә әле күп кимчелекләрне узарга, җитди бурычларны хәл итәргә кирәк. Беренчедән, аерым авторларның урта кул әсәрләрен күпертеп мактап, таләпчәнлекне киметмик һәм укучыга эстетик тәрбия бирү эшенә зыян салмыйк. Икенчедән, һәр яна әсәрне сыйфатына карап бәялик, язучыларның төп массасының иҗаты турында дәшми калу практикасын бетерергә вакыт. Өченчедән, гүзәллекне бәяли, иҗатның партияле курсын тормышка ашыру өчен көрәшә, бер ук вакытта социолог та, галим дә, педагог

та булып чыгыш ясый торган тәнкыйтьченең үз стиле һәм үз теле төгәл дә, саллы да, бар кешегә аңлаешлы да булырга тиеш. Дүртенчедән, әдәбиятыбызның иң яхшы казанышларын тагын да киңрәк пропагандалау өчен, тәнкыйтьчеләребез үзәк матбугатта чыгыш ясасыннар, теге яки бу әсәрнең рус укучылары тарафыннан ничек кабул ителүе белән кызыксынсыннар иде. Һәм, ниһаять, бишенчедән, чама белән генә язылган, комплиментарь, әдәби әсәрне дистиллированный су белән юа торган рецензияләр, язучыга, бигрәк тә яшь авторга, дөрес юнәлеш күрсәтми, безгә кимчелекләрдән арынырга ярдәм итми торган рецензияләр беркайчан да булмасын иде.

Безнең коллективта балалар язучыларының шактый зур отряды эшли. Бозылган олы кешене дөрес юлга бастыруга караганда, балада изге хисләр тәрбияләү җиңелрәк, диләр. Бу бәлки шулай күренә генә торгандыр. Нәниләрне яки балаларны, үсмерләрне яки өлкән класс укучыларын тәрбияли торган китаплар язу — аеруча җаваплы эш. Ул китаплар тормыштагы гүзәллекне танырга өйрәтергә, балаларны батырлык үрнәкләрендә тәрбияләргә тиешләр. Шул ук вакытта батырлык эшләү өчен ниндидер фаҗигале хәлләрнең, әйтик, сугышлар башлануның мәҗбүри түгеллеген, моның өчен көндәлек тормышыбызда адым саен мөмкинлек булуын, бары тик файдалы эшкә бөтен күңелеңне бирү генә кирәклеген ышандырырлык итеп күрсәтү сорала. Болар өстенә, Горький таләп иткәнчә, балалар китаплары тормышчан һәм кызыклы булырга тиеш. Язучылар иҗатын балаларда хезмәткә мәхәббәт тәрбияли торган, балалар тормышын һәм аларның эшчәнлеген коллектив эчендә күрсәтә торган китаплар язарга юнәлтү кирәк. Балаларга адресланган иң яхшы китаплар һәр вакыт шушы максатны күздә тотып язылды һәм шулай язылырга тиеш. Безнең һәркайсыбыз балалар өчен яза ала һәм язарга тиеш. Әмма бу темага көчләрне туплау, иҗатны тематик яктан координацияләү җитми.

Хәрби-патриотик темага язылган әсәрләр турында да берничә фикер әйтеп үтик. Фашизмны җиңүнең 25 еллыгын бәйрәм иткән һәм җиңүнең 30 еллыгына әзерләнгән чорда хәрби батырлык темасы өстендә элекке армеецлар һәм фронтовиклар, һәрвакыттагыча, тугрылык һәм активлык белән эшләделәр. Габдрахман Әпсәләмов Бөек Ватан сугышының өч герое турында өч повесть язды. Геннадий Паушкин «Ләкләкләр, кайтыгыз» исемле повесть, Хисам Камалов «Һәркемнең гомере бер генә» дигән роман, Юрий Белостоцкий «Утлы давыл» һәм «Кук тә, тормыш та бер генә» дигән документаль повестьлар төгәлләделәр. Ә. Еникинең «Без дә солдатлар идек», Ә. Маликовның «Яшьлек утравым» повестьларында, М. Садриның «Мин Берлинны алдым» дигән язмаларында һәм С. Хәкимнең «Дуга» поэмасында совет солдаты тормышының төрле яклары сурәтләнә. Муса Җәлил кебек үк, фашистларның үлем лагеренда һәлак булган шагыйрь, хәрби командир Мөҗәй Хәйретдинов турында Самат Шакир яңа документаль әсәр тәмамлады. Хәрби тема өстендә эшләүче язучылар отряды бүген дә сугышчан постта тора, хәрби-патриотик китаплар күбрәк булсын өчен алар көчләрен кызганмыйлар. Тик шунысы кызганыч, безнең тәнкыйть сугыш турындагы китапларның уңышлы һәм җитешсез якларын бик аз өйрәнә. Бөек Ватан сугышында җиңү дөньяда социализм системасын тудырды һәм капитализм дөньясының хакимлек итү мәйданын тарайтты. Сугыш әле хәзер дә бара, ул безнең тәннәрдәге, йөрәкләрдәге яраларда яши һәм ул һәркемне үлгәннәрнең якты истәлегенә лаеклы булыгыз, дип искәртеп тора. Үткән сугышның бүгенге тормышка йогынтысы чиксез зур. Җир йөзендә әле баштанаяк коралланган империализм яшәгәндә, без, язучылар, моны бер генә минутка да истән чыгарырга тиеш түгелбез.

Бу темага инде яшьләргә, сугыштан соң туган буынга да кыюрак тотынып вакыт. Безгә сугышчан әсәрләребезне һөҗүмнәр арасындагы кыска минутларда язу читен булды. Ә яшьләргә исә бу теманы эшкәртү тагын да читенрәк һәм катлаулырак булачак. Чөнки аларга икенчел материалларга: я сугышта катнашучыларның истәлекләренә яки архивлардан эзләп тапкан чыганакларга таянып эш итәргә туры киләчәк. Шамил Рәкыйпов, шулай эзләнеп, Ватан сугышы батырлары (татар егете

Батыршин, очучы Сыртланова, украин улы Чернопятко, белорус егете Кабушев) турында өч әдәби-документаль повесть язды. Аларның «Таңнар һаман матурмы?» дигән берсе рус телендә Мәскәүдә дә басылды. Мондый эзләнүләрне киңәйтергә һәм игътибар үзәгенә куярга кирәк. Гитлер фашистларының ерткычлыгын сурәтләп, без укучыга бүгенге дошманнарны аңларга булышабыз, ә фашистик көчләр әле бүген дә җирнең һәр почмагында диярлек яши. Безнең яңа идарә Совет Армиясенең бүгенге тормышына багышланган әсәрләр турында да күбрәк кайгыртырга тиеш. Хәрби бүлекчәләрдә һәм частьларда булырга, Ватаныбыз чикләренең ничек саклануын күрергә һәм укучыга сөйләп бирергә бездә барлык мөмкинлекләр бар. Мондый әсәрләрнең беренчесе—Рәфкат Кәрамиевның «Капитан Хәкимов» повесте белән без озакламый очрашачакбыз, аның артыннан башкалары да күренсен иде.

Хәзер тарихи-революцион әсәрләр турында берничә сүз. Тормышны үткән көннәрдән калган истәлекләрсез, тарихсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Безнең Татарстан җирендә бик күп күренекле ленинчылар, революция геройлары көрәшкән һәм эшләгән. А. Луначарский аларны, бик образлы итеп, Ленин маршаллары дип атаган иде. М. Свердлов, С. Киров, Н. Тихомирнов, Камил Якуб, Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов һәм башка бик күпләр әнә шундый кешеләр. Ленинның көрәштәшләре булган, аңардан бетмәс энергия алган бу ленинчылар турында әдәби-биографик очеркларны һәм тарихи-әдәби әсәрләрне бездән башка кем иҗат итсен! Билгеле, күп көч һәм энергия салуны сорый торган бик авыр һәм җаваплы бу эш архивларда казынуны, документлар белән эш итә белүне таләп итә. Кыскасы, бик тә четрекле, катлаулы һәм авыр эш бу. Мәрхүм Павел Евгеньевның чекистлар турындагы «Раифадагы обелиск», Атилла Расихның Урта Азиядә басмачыларга каршы геройларча көрәшкән татар бригадасы тарихыннан язылган «Каһарманнар юлы» романы, шушы ук авторның «Хөсәен Ямашев» романы, кайбер бәхәсле урыннары булуга да карамастан, әдәбиятны яңа казанышлар, яңа тәҗрибә белән баетты. Бу тәҗрибә, әйтик, геройларны зур вакыйгалар эчендә күрсәтү, тар офыклы, кечкенә мәйданлы әсәрләрдән киң колачлы эпик полотноларга күчү, революция героеның уй-теләкләре, өметләре белән күбрәк кызыксыну, үткән чорлардан торып бүгенге көнгә карый белү кебек мәсьәләләргә кайтып кала. Ахыр чиктә, тарихи әсәрләр үткән көннәр белән бүгенгене тоташтыру, бердәм сулышлы итү өчен языла да бит. Илдар Юзеевның «Таш диварлар авазы» поэмасындагы Пугачев көрәштәше Мәсәгут Гомәровтан безне күп еллар аерып тора. Әмма ул бүген дә исән, син аның белән янәшә атлыйсың, бер һаваны сулыйсың кебек. Чөнки персонажның киләчәккә омтылышы көчле итеп күрсәтелгән. Җәвад Тәрҗемановның «Көмеш дага» исемле тарихи романы күренекле математик һәм Казан университетының ректоры Лобачевскийның тормыш юлына һәм фәнни батырлыгына багышланган. Әмма без анда Совет Россиясе халыкларының хәзерге какшамас дуслык чыганагын да күрәбез: бөек математикның безнең якташыбыз, галим һәм шагыйрь Нигъмәт Ибраһимов белән иҗади дуслыгын сурәтләүгә әсәрдә киң урын бирелгән. Фатих Хөснинең татар хатынының катлаулы язмышына багышланган «Гыйльмениса» повесте шушындый ук дуслыкның тагын бер яңа авазы булып яңгырады. Яисә балалар әдәбиятыннан тагын бер мисал алыйк. Ләбибә Ихсанованың «Очкын» һәм «Гөлләр кояшка карый» повестьларында сурәтләнгән Хәдичә ханым әле дә исән. Язучы аны, реаль тормыштан алып, гражданнар сугышы вакыйгаларын сурәтләгән китапларына керткән һәм халык батырлары, ул батырларның халык бәхете өчен, гөлләр һәр вакыт кояшка карасын өчен көрәшләре турында сөйли торган әйбәт әсәрләр иҗат иткән. Шулай итеп, төрле китапта төрлечә, әмма төп максатка юнәлешле рәвештә төрле заманнарның үзара бәйләнешенә ирешелә.

Тәрҗемә мәсьәләләрен юлга салу халыкларны һәм әдәбиятларны якынлаштыра, үзара баета торган эшне оештыру — идарә тарафыннан башкарылырга тиешле иң җаваплы һәм төп эшләрнең берсе. Бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү ифрат киң колач алган безнең илдә, бу эш, тәҗрибә ал-

машу чарасы һәм күп милләтле әдәби процессның табигый яшәү формасы буларак, политик мәсьәлә биеклегенә куелган. Татар әдипләре рус әдәбиятының һәм дөнья халыклары әдәбиятларының классик үрнәкләрен тәрҗемә итү белән Октябрь революциясенә хәтле үк шөгыльләнгәннәр. Хәзер бу эш системалы рәвештә, план буенча һәм шактый киң масштабта алып барыла. Татар әдәбиятын күп буын әдипләренең зур хезмәте белән үстерелгән бакчага тиңләсәк, туган телебезгә тәрҗемә ителгән әсәрләрне шул бакча уртасына куелган һәйкәлләр дип санарга мөмкин. Алар бик күп: Пушкин һәм Толстой, Щедрин һәм Гоголь, Шекспир һәм Гейне, Руставели һәм Навои, Шевченко һәм Мәхтүмкули, Токтогул һәм Райнис, Колас һәм Ауэзов, Шолохов һәм Фадеев, Маяковский һәм Твардовский, Даут Юлтый һәм Константин Иванов... Соңгы елларда алар сафына тагын 63 яңа һәйкәл өстәлде. Араларында Бальзак белән Хименгуэй да, Майн Рид белән Марк Твен да, Куприн белән Назыйм Хикмәт тә, Маршак белән Михалков та бар. Шул ук вакытта татар язучыларының 118 китабы рус теленә, 20 әсәре СССР халыклары телләренә тәрҗемә ителде. Татар әдәбиятын рус телендә аеруча актив пропагандалаганнары өчен, Мәскәү шагыйрьләре Михаил Львов белән Рувим Моранга күптән түгел Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде, Җәмил Мостафин белән Вадим Кузнецов Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Тәрҗемәче кадрларны табу, алар белән безнең авторлар арасындагы иҗат элемтәләрен тагын да ныгыту буенча киләчәктә конкрет чаралар күрергә кирәк.

Тормышның кырыс хакыйкатен рәхимсез һәм үткен сүз белән сөйләп анлатырга да, халыкны усал елмаю белән дә шатландырырга һәм куандырырга мөмкин һәм кирәк. Үзенең ярты гасырлык бәйрәмен уздырган «Чаян»ыбыз «гаепле» булса кирәк, безнең укучы юморны һәм сатираны бик ярата. Дөресрәге, тормышта безнең кәефне кыра торган кешеләр яки күренешләргә каршы юнәлтелгән чәнечкеле китапларны күп укый. Андый әсәрләр һәр ел саен диярлек чыгып килә торган «Күңелле сәхнә» җыентыклары бик тиз таралып бетә. Димәк, алар укучыны кимчелекләргә тәнкыйть күзлегеннән карарга гына түгел, ә бүтәннәрнең көлке язмышыннан сабак алырга һәм нәтиҗәләр ясарга да өйрәтә.

Габдрахман Минский, Мирсәй Әмир, Әхмәт Исхак, Габдулла Шамуков, Зәки Нури, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Вахит Монасыйпов кебек язучыларыбыз ике съезд арасында кимендә бер яки берничә сатира-юмор китабы чыгардылар. Көлке осталарының саны болар белән генә чикләнми. Журналларыбыз, китап нәшрияты һәм Язучылар союзы идарәсе безне тагын да активрак эшләтергә, сатира-юмор әсәрләренең сыйфаты турында күбрәк кайгыртырга тиешләр.

Әдипләрнең иҗат тормышын оештыручы идарәбез тормышка ашырган тагын берничә практик чарага тукталып үтик.

Яшьләргә — яшел урам! Иҗади яшьләр белән эшләнгән эшләрнең төп эчтәлеген шушы сүзләр белән билгеләргә мөмкин. Әдәби түгәрәкләр яки берләшмәләргә барып (ә алар бездә 30 дан артык), яисә яшьләрне Казанга чакырып, күп төрле индивидуаль семинарлар үткәрелде. Тәнкыйтьчеләрнең коллектив семинары һәм әдәби берләшмә җитәкчеләренең семинары уздырылды. Нәшрият ел саен диярлек Союзга керергә әзерләнүчеләрнең кимендә 6—7 җыентыгын чыгарып килә. Атна саен әдәбият-сәнгать сәхифәсе биреп барган һәм ул сәхифәләргә яшь язучыларның әсәрләрен дә бик теләп урнаштырган өлкә газеталарына рәхмәтебез чиксез зур. «Социалистик Татарстан» газетасы, мәсәлән, 1956 елдан башлап 600 әдәби сәхифә чыгарды инде. Бу — дистәләгән томнарга җитәрлек әдәби байлык дигән сүз бит! Әдәбиятыбыз үсеше өчен искиткеч зур ярдәм бу!

Нәтиҗәдә, ике съезд арасында без СССР Язучылар союзына 42 яңа член кабул иттек. Хәзер бездә Союз членнарының саны 143 кә җитте. Шуларның 91 е — коммунистлар, икесе — ВЛКСМ члены. 20 язучының фәнни дәрәҗәсе бар, аларның бишесе — фәннәр докторлары. Әмма яшь ягыннан мәсьәлә шактый катлаулы төстә тора. Безнең коллективта 30 яшьтән дә яшьрәк ни-

бары 3 язучы бар. 40 ка кадәргеләр — 29, 50 гә кадәргеләр — 45, 60 ка кадәргеләр — 18, ә калган 49 каләмдәшебезнең яше 60 ның өске ягында. Моннан шундый нәтиҗә килеп чыга: әдәбиятның яшь көчләрен үстерү, Союз членнары санын барлык жанрлар буенча тигез үстерү иң мөһим бурычларның берсе булып кала. Иҗат союзларының яшьләр белән эшләүне яхшыртуга багышланып үткәрелгән берләштерелгән пленумы да әнә шул мәсьәләләргә басым ясады. Бу пленум 1973—1975 еллар өчен конкрет эш планы кабул итте. Төп игътибарны әдәби алмашыбызның идея ягыннан тәрбияләүгә, яшьләрдә иң югары мораль-этик сыйфатлар булдыруга юнәлдерергә кирәк. Бу урында Николай Островскийның: «Яшь язучы чын кеше, көрәшче булып үскәндә генә язучы була ала»,— дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр.

Язучы социаль климатны тоймыйча, үз эшчәнлегенең бөтен халык өчен кирәкле булуын сизмичә, үзен гомуми эш белән мәшгуль коллективның кирәкле бер кешесе итеп исәпләмичә яши алмый. Җәмәгать эшләрендә катнашу — иҗат өчен кирәк булган иң яхшы тәҗрибә чыганагы. Язучыларыбыз, партиянең өлкә яки шәһәр комитетларына, республикабызның Верховный Советына, шәһәр яки район Советларына сайланып, җирле яки үзәк органнарында, төрле комитетларда, комиссия һәм Советларда эшләп, җәмәгать эшенә күп вакытларын бирсәләр дә, иҗат темпларын һич тә киметмиләр. Киресенчә, нәкъ менә шулар активрак эшли. Димәк, көченңе җәмәгать эшенә бирү сине баета, тормышны башка үлчәү белән үлчәргә өйрәтә. Әмма яшьләрнең энергияләрен җәмәгать эшләрендә активрак файдалану, хөрмәтле аксакалларыбызны мондый эшләрдән бушату өчен, идарә җәмәгать эшләренең тигез бүленүен әледән-әле күзәтеп торырга тиеш. Бер генә яшь кеше дә өлкәннәр тәҗрибәсен әзер килеш ала алмый, аңа тормышта барысын да үз тырышлыгы, үз кыюлыгы белән ачарга, үзенә татырга кирәк.

Актив иҗат итүче язучы әдәбиятны актив пропагандалаучы да булырга, үз әсәрләрен укучының ничек кабул итүен өйрәнергә, һәркайда, һәркайчан каләмдәш дусларының иҗатындагы яңалыклар белән массаларны таныштырып торырга тиеш. Укучыларыбызның әдәбият белән кызыксынуы үскән саен, безнең мондый мөмкинлекләребез дә арта бара. Союзның әдәбиятны пропагандалау бюросы 1968 елда культура университетларында, культура йортлары, клублар, китапханәләр һәм югары уку йортларында уздырылган әдәби кичәләрдә язучыларның 825 чыгышын оештырса, 1973 елда мондый чыгышлар 2976 га җитте. Авылда культура шефлыгын яхшы оештырган өчен, 1972 елда Татарстан язучылары союзына, илебездә беренче буларак, СССР Культура министрлыгы һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл байрагы тапшырылды. Республиканың 22 районында татар әдәбияты атналыклары уздырылды. Рус һәм чуваш иптәшләр шундый атналыкларны 8 районда үткәреләр.

Туганлаш республикаларның язучылары белән элемтәләрне киңәйтү эшенә дә күп көч куелды. Безнең язучыларыбыз 130 тапкырдан артык төрле республика, өлкә һәм крайларда булдылар, ә Татарстанда башка милләт вәкилләре 151 тапкыр булды. 1971 елда кыргыз китабы көннәре, 1973 елда кыргыз әдәбияты атналыгы, үзбәк әдәбияты һәм сәнгате декадасы, союздаш һәм автономияле республикаларның комсомол премияләре лауреатлары фестивале, чуваш әдәбияты көннәре, Ворошиловград язучыларының иҗади отчет бәйрәме үткәрелде. Казанда РСФСР язучылар союзының күчмә секретариаты утырышы булып, анда Идел буендагы автономияле республика язучыларының иҗаты тикшерелде. Татар әдәбияты көннәре һәм атналыклары Мордовиядә, Мәскәү шәһәрендә һәм Мәскәү өлкәсендә, Куйбышев шәһәрендә, Украинаның Ворошиловград өлкәсендә уздырылды. Язучыларыбыздан 18 кеше чит илләрдә булып кайтты.

Һәр елны үткәрелә торган әдәби ел йомгакларын да җентекләп әзерләргә тырыштык. Аерым авторлар иҗатына, аерым әсәрләргә җитди һәм төпле анализ ясау безне тормыштагы яңа үзгәрешләргә тигезләнергә, артык мактанмаска, перспективалы тенденцияләрне кыю якларга, кемнең кем булуына карамастан, кимчелекләрне вакытында күрсәтеп барырга, заман сулышын тоеп

иҗат итәргә өйрәтте. Иң мөһиме шул, без үз-үзебезгә һәм иптәшләребезгә карата таләпчәнрәк була барабыз. Безнең бу башлангыч бөтен союз күләмендә яклау тапты һәм СССР Язучылар союзы секретариаты тәкъдиме белән мондый сөйләшүләр инде илебезнең күп кенә башка оешмаларында да үткәрелә башлады.

Идарә «Казан утлары» журналында һәм «Идел» альманахында басылган материалларны системалы һәм планлы төстә тикшереп бара. Бу журналларның һәр икесе әдәби процессны дөрес формалаштырырга, һәр язучыга таләпчән игътибарлылык күрсәтергә, яңа исемнәр ачарга һәм аларны үстерергә тиеш. Киләчәктә алардан тормыш һәм әдәбият тәҗрибәсен тагын да тирәнрәк гомумиләштерүне, иң яхшы каләм осталарының казанышларын өйрәнү һәм пропагандалауны, әдәби хәрәкәтнең мөһим проблемалары турында бәхәс алып баруны, гомум эстетик мәсьәләләрне киңрәк яктыртуны таләп итү урынлы булачак.

Россия Федерациясендә иң зурлардан саналган Татарстан китап нәшрияты турында сөйләгәндә, без аның елданел яхшыра барган гаять катлаулы эшен рәхмәт хисе белән билгеләп үтәргә тиешбез. Кәгазь белән тәэмин итүдәге зур кыенлыкларга карамастан, язучыларыбызның бер һәм күп томлы сайланма әсәрләре ныклы план буенча чыгарыла. Бүгенге көн темасына караган яхшы әсәрләрнең берсе дә басылмый калмады. Союз нәшрият белән тыгыз элемтәдә эшли. Без кирәкмәгән кабат басмалардан һәм артык дубляжлардан котылырга тырышабыз, актуаль серияле әсәрләр планын бергәләп билгелибез. Әмма шул ук вакытта безне бер нәрсә борчый: әдәби әсәрләр чыгару әле һаман 1968 ел күләменнән арта алганы юк. Директив органнар ярдәмендә күләмне арттыру юнәлешендә чаралар күрелә. Бу мәсьәләдә Язучылар союзына да зуррак тырышлык күрсәтергә кирәк. Нәшриятның редакцион советы яңартылырга һәм ул нәтиҗәле эшкә керешергә тиеш. Бүгенге тормышның мөһим мәсьәләләрен иңләү, әдәби процессны тагын да җанландыру максатыннан чыгып, язучыларның социаль заказ буенча эшләүләрен оештыру һәм төрле конкурслар үткәрү эшен көчәйтә төшәсе иде. Кол Галидән башлап безнең совет классикасы әсәрләрен татар һәм рус телләрендә чыгару мәсьәләләрен хәл итәргә тиешле авторитетлы комиссиядән дә конкрет эш таләп итәргә вакыт. Бу комиссия моннан алты ел элек Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты каршында оештырылган иде. Ләкин, кызганычка каршы, аның әле кыл да кыймылдатканы юк.

...Безнең съездыбыз, эшләнгән эшләргә йомгак ясау һәм алдагы көнгә бурычлар билгеләү буенча коллектив эшебез, язның иң матур вакытында, туган җиребездә җир яшәргән һәм гөлләр чәчәк аткан, җир өстеннән кыю адымнар белән игенче узган көннәрдә бара. Моның бик зур мәгънәсе бар. Чөнки игенче уңышны аерым бер тырышлык куеп үстерә, аның һәр минуты — яңа икмәкнең бер кисәге. Ул ел буе көч куеп үстергән икмәге белән генә данлыклы да. Безнең съездыбызның конкрет карарлары да халык тормышының туфрагына бәрәкәтле бөртекләр булып ятсын. Ул бөртекләр тигез булып шытсыннар һәм зур әдәби уңыш бирсеннәр. Безнең халык батырлыгын, хезмәт кешесе образын коммунистик идеялелек, эстетик таләпчәнлек белән гәүдәләндерүдән дә мөһимрәк һәм мактаулырак эшебез юк.

Илебез язучыларының V съезды КПСС Үзәк Комитетына адреслаган хатта бик дөрес әйтелгәнчә, тормыш бездән заманыбызга тиң кыю эзләнүләр, яңа сәнгать казанышлары көтә. Җәмгыять алдындагы зур бурычыбызны үтәү, партия һәм халык ышанычын аклау өчен, без, ару-талуны белмичә, бөтен көчебезне һәм тырышлыгыбызны куеп эшләрбез.

## Гариф Ахунов

# ТАТАР СОВЕТ ПРОЗАСЫНЫҢ ОФЫКЛАРЫ

Миңа проза өлкәсендәге әдәби хуҗалыгыбызга күз ташларга, сезнең белән бергәләп, прозаикларыбызның табышлары һәм ачышлары, проза әдәбиятының уңышлары һәм кимчелекләре хакында уйланырга, аның төп тенденцияләрен күздән кичерергә, кыскасы, татар совет прозасының офыклары хакында сүз алып барырга туры киләчәк.

Ике съезд арасындагы алты ел вакыт эчендә 15 роман, 43 повесть, 15 ләп хикәя һәм очерк җыентыгы дөньяга чыккан. 73 китапның исемен генә санап чыгу өчен дә күп вакыт, зур урын кирәк булыр иде. Шуңа күрә алдан ук гафу үтенеп куям һәм мине дөрес аңлавыгызны сорыйм: соңгы елларда язылган роман, повестьлар, хикәя, очерклар һәм ул әсәрләрнең авторлары мәкаләдә кузгатылган аерым мәсьәләләргә бәйле төстә генә искә алыначак.

### 1

...Шулай итеп, ике съезд арасында 73 исемдә яңа китап чыккан. Азмы бу, күпме?

Әле әдәби тәнкыйть эшчәнлеге белән генә шөгыльләнгән заманнарда миңа, З. Бигиевнең «Зур гөнаһлар» романыннан башлап, татар әдәбиятындагы барлык роман-повестьларны укып чыгарга туры килгән иде. 1870 елдан 1953 елга кадәр, ягъни туксан елга якын вакыт эчендә татар язучылары тарафыннан 100 ләп роман һәм повесть язылган булган. Бу — 90 ел вакыт эчендә шул кадәр. Ә ике съезд арасында, ягъни нибары алты ел вакыт эчендә, 73 исемдәге яңа китап дөнья күргән. Мондый зур үсеш каян килә соң?

Әдәбиятыбыз узган юлга күз салыйк. Октябрь революциясенә кадәр реалистик татар прозасы илле елга якын (ягъни Совет власте чорындагы кадәр үк) үсеш юлы уза. Бу өлкәдә, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек, әдәбиятыбызның алтын фондына керерлек әсәрләр биргән әдипләр эшли. Шулай да татар совет прозасын чынында гражданнар сугышы мәктәбен узган кызылармеецлар башлап җибәрә. Аларның бер кулында — мылтык, икенчесендә — китаплар, бер кулында — ил язмышы, икенчесендә татар әдәбиятының киләчәге була. Татар совет әдәбиятының нигезе салынган ул елларда хәзерге өлкән буын язучыларыбызның күпчелеге әдәбият кануннарын яхшы белеп түгел, эчке сизенүгә таяныбрак эшли. Кешелек җәмгыяте гасырлар буена тудырган әдәби байлыкны үзләштерү һәм «йотып җибәрү» өчен күп көч куярга туры килә, һәм өлкән буын язучылар шуны эшлиләр: эшләмәсәләр — сүзнең сихри көченә төшенә алмаслар, шул кадәр үзенчәлекле язучы булып өлгерә алмаслар иде. Ихтимал, иске дөньяның барлык әшәке якларын үз күзләре белән күреп, барлык авырлыгын үз җилкәләрендә татыгангадыр, бу буын язучылар иҗат иткән әсәрләрдә ирекле хезмәтнең һәм гасырлар буена килгән коллыктан азат ителгән кешенең могҗизалар тудырырга сәләтле булуы аеруча көчле, аеруча тәэсирле итеп сурәтләнелә. Аларның яңа буын прозаиклар алдындагы төп хезмәте менә шул. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан һәм М. Галәүнең роман-повестьлары, К. Нәҗминең «Язгы җилләр»е, А. Шамовның «Рәүфә»се һәм гражданнар сугышы чорына караган башка повестьлары, И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе, Г. Бәшировның «Сиваш»ы һәм «Намус» романы, Ә. Фәйзинең «Тукай»ы, М. Әмирнең «Агыйдел»е һәм «Саф күңел»е, Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» һәм «Утызынчы ел»ы, Г. Әпсәләмовның



*Проза турындагы докладны Гариф Ахунов сөйли.*

«Алтын Йолдыз»ы һәм «Сүнмәс утлар»ы, Ә. Еникинең сугыштан соң язылган кыска повестьлары, Г. Гобәйнең балалар өчен язылган әсәрләре, А. Расихның «Ике буйдак» романы безнең әдәбиятның мөһим казанышлары булып әверелделәр. Һәм вакыт, әлеге иң рәхимсез судья, илле ел эчендә иҗат ителгән әсәрләрнең иң яхшыларын нык кул белән сайлап алып, олы юл баганалары кебек, күренекле урынга тезеп куйды.

Без горурланып әйтә алабыз: өлкән буын прозаикларыбыз совет классикасына керерлек әсәрләр иҗат иттеләр, кыйммәтләрен мәңге югалтмаслык җәүһәрләр тудыра алдылар. Дөрес, заманга һәм халыкка кирәкле әсәрләрне алар көткәннән азрак бирделәр, ләкин моның өчен аларны гаепләп булмый, чөнки алар вакытларының күп өлешен, яңа тормыш күренешләрен гомумиләштерүдән бигрәк, үзлекләреннән белем алуга, Бөек Октябрь казанышларын саклауга бирергә мәҗбүр булдылар. Әдәбиятка шуннан соң килгән буыннар совет властен әзер килеш, фашизм афәтеннән коткарып калынган хәлдә алдылар, ләкин моннан чыгып кына алар алдында бернинди кыенлыклар булмаган икән дип уйларга ярамый.

Татар прозаикларының Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Л. Ихсанова, М. Хәсәнов, Х. Сарьян, Э. Касыймов, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Баянов, Ш. Бикчурин, Б. Камалов, Ш. Рәкыйповлар кебек сугыштан соңгы буыны илленче елларда әле, мөстәкыйль әсәрләр тудырудан да бигрәк, өйрәнү чоры уздылар, үзебезнең әдәбиятта һәм башка әдәбиятларда тупланган байлыкны үзләштерү һәм шул юл белән әдәбиятның асылын, бурычларын һәм максатларын аңлау югарылыгына күтәрелделәр. Алар гомеренең икенче ун елы мөстәкыйль әсәрләр язуга китте, аларның иҗади мөмкинлекләре елдан-ел ачыла барды һәм ике съезд арасында узган алты ел вакыт эчендә алар инде үзләрен өлгергән прозаиклар итеп таныттылар. Ике съезд арасында роман, повесть, хикәя һәм очеркларның күпләп иҗат ителүе әнә шуннан килә.

Әгәр ике съезд арасындагы прозаның иң характерлы төп сыйфатын ачыкларга теләсәк, без бер дә икеләнмичә: узган алты ел эчендә прозаикларыбызның игътибары башлыча хезмәт

кешеләренең образларын иҗат итүгә юнәлде, дип әйтә алыр идек. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы — нефтьчеләр, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романы һәм М. Хәсәновның «Кама таңнары» романы — төзүчеләр, Э. Касыймовның «Һаваларда тургай» романы — химиклар, Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын»ы — авыл эшчәннәре, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы укытучылар турында. Бу исемлекне С. Рафиковның «Тын елга буенда», Г. Әпсәләмовның «Яшел яр» романнары исәбенә тулыландыра төшәргә мөмкин. Монда әйтелмәгәннәрен дә кертеп исәпләсәң, хезмәт кешеләре турында 9 роман! Республикабызның хезмәт тормышы роман кебек камил, күп сыйдырышлы жанрда беркайчан да шул кадәр тулы, шул кадәр күп яклы чагылганы юк иде. Әгәр бу романнарның һәркайсында республика тормышының төп агы — аның социализм төзелешендәге зур уңышлары көзгедәге кебек чагыла икән, бу — сугыштан соңгы елларда, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең зирәк җитәкчелеге астында, Совет Татарстаны куәтле индустриаль республикага әйләнгән дигән сүз, димәк, тормыш үз таләпләрен язучылар алдына бик ныклап куйган дигән сүз.

Һәммәбезнең хәтерендә, соңгы елларда роман жанрының язмышы хакында кайнар бәхәсләр барды. Чит илләрдәге белгечләр жанр буларак роман үлә дип лаф ордылар, «антироман»ның ничәмәничә төрле модельләрен тәкъдим иттеләр. Әмма вакыт мәсьәләне башкача хәл итте, роман жанры, үлемгә йөз тотмау гына түгел, киресенчә, илебезнең барлык төбәкләрендә гөрләп чәчәк атты, яңа үрләр яулап, дөньядагы иң революцион иҗат методы — социалистик реализм белән коралланган художниктан яңа ачышлар ясауны таләп итеп, тормышчан көч, яңа буяулар белән тулылана барды. Димәк, роман жанрының кирәклеге ап-ачык нәрсә. Инде шулай икән, безнең бурыч жанрны тагын да үстерүгә, камилләштерүгә кайтып калырга тиеш.

Әдәбият кешене төрле аспектта — иҗтимагый, сәяси, фәлсәфи, тарихи хәлләрдә сурәтли, болар, үз чиратында, язучыдан халык тормышының тирән катламнарын кузгатуны таләп итә. Шул таләпне үтәү өчен, иҗат кешесенең тормышны бөтен тулылыгында белүе һәм табигый талантка ия булуы сорала. Игътибарыгызны тормыш тулылыгы, тормышны аңлау дәрәҗәсе, әдәби талант кебек төшенчәләргә юнәлтәсем килә.

Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы ни өчен «Казан утлары» журналында басылып чыгу белән үзебезнең әдәби җәмәгатьчелекнең генә түгел, хәтта башкала язучыларының да игътибарын җәлеп итте дисез? Ш. Бикчурин тормышны китаптан өйрәнгән кеше түгел. Ул Әлмәт шәһәрендә озак еллар төзүче булып эшләде. Лениногорскига күчеп килгәч, бораулау бригадалары белән дуслашты, көне-төне шулар янында ятты, нефтьчеләрнең үз кешесенә әйләнде. Романын нык материалга таянып язганга күрә дә, автор безгә талантлы булуын күрсәтә алды, шулай булмаганда ул әле һаман да уртачалар рәтендә йөргән булыр иде. Хезмәт кешеләрен шәп белгән рус язучысы В. Чивилихин тарафыннан бик әйбәт тәрҗемә ителеп, роман «Москва» журналында басылып чыкты һәм үзенә лаек бәяне алды.

«Производство романнары» дип яманаты чыккан кайбер әсәрләрнең төссез, укыр өчен күңелсез булуын тәнкыйтьчеләр авторларның «шәхси як» белән «иҗтимагый якны» тиешле пропорциядә бирә белмәүләреннән күрәләр. Мондый фикер ышандырып җиткерми. Хикмәт «иҗтимагый як» белән «шәхси як» арасында дөрес пропорция табуда гына түгел кебек. Минемчә, хикмәт шунда, производство темасына караган кайбер төссез романнарның авторлары үзләре сайлаган өлкәне я тиешенчә өйрәнергә, күңелләре аша үткәрергә өлгермәгән булалар, яки аларда әдәби талант булмый.

Э. Касыймовны талантсызлыкта гаепли алмыйбыз. «Кояш көн дә чыга», «Бир кулыңны, дустым», «Сорбонна профессоры һәм без», «Көмеш язулы кылыч» кебек повестьлары, «Гомер ике килми» һәм «Томан аша» дигән романнары белән ул укучы алдында сынауны уңышлы үтте. Ә менә республикабыз химикларына багышланган «Һаваларда тургай» романы баштагы әсәрләреннән төссезрәк булып чыккан. Нидән бу? Э. Касыймов талантын югалтканмы

әллә? Һич юк. Язу стиле элеккечә үк, кеше характерларын аңлау дәрәҗәсе дә үз урынында, ә әсәр дулкынландырмый. Күпме генә гаҗәп тоелмасын, ничә еллар химиклар арасында яшәсә дә, Э. Касыймов шул кешеләрнең тормышын якынча гына белә, дөресрәге, ул тормышны тирәнтен өйрәнмәгән, «Һаваларда тургай» романында алынган материал аның үз җырына, үз моңына әйләнеп җитмәгән. «Хуҗалар» исемле романында бу юлларның авторы үзе дә шундыйрак язмышка дучар булган иде. Унике еллар чамасы нефтьчеләр арасында яшәгән авторны бик хаклы рәвештә шул тормышны белмәүдә гаепләделәр, әсәрнең байтак кына башка кимчелекләрен ачып салдылар. Каләмдәш дустым Э. Касыймов (без аның белән бергә университетта укыдык, бер чорда яза башладык) язучылар һәм укучылар тарафыннан әйтелгән тәнкыйть сүзен ничек кабул иткәндер, ул кадәресен белмим, әмма «Хуҗалар»ның авторы, тормышны белмәүдә гаепләп тәнкыйть иткәне өчен, Ф. Хөснигә бик нык үпкәләп йөрде, берничә ел узгач кына үзенең хаксыз булуын аңлады һәм өлгереп җитмәгән әсәрен яклап матбугатта чыгыш ясамый калуына шатланды. Бактың исә, тормышны белү аның тышкы билгеләрен күрү белән генә чикләнми икән, тормышны белү дигәнебез ул әле язучыдан чынбарлыкның төп процессларын тирәнтен һәм кыю рәвештә өйрәнүне сорый, гадәти фактларны һәм гадәти характерларны белү белән генә чикләнмәскә, тагын да югарырак даирәләрне өйрәнергә чакыра икән. Илленче еллардагы нефтьчеләр турында язганда, ихтимал, борынгы авылларның ничек итеп нефть шәһәрләренә әйләнүләрен, иске гадәтләр белән көрәштә характерның ничек формалашуын күрсәтү дә җиткәндер. Әмма инде җитмешенче еллардагы инженер-нефтьче, инженер-химик образын иҗат итү өчен без бүгенге фәнни-техник революция югарылыгында булырга, аларның эшчәнлек даирәсен үз республикабыз масштабында гына түгел, ә бөтен ил, алай гына да түгел, бөтен дөнья масштабында белергә тиешбез. Безгә бер хакыйкатьне һич кенә дә онытырга ярамый: тормышны өйрәнү мәсьәләсе һәр вакыт, һәр дәвердә беренче дәрәҗәдәге бурыч булып килде һәм шулай булып калачак та.

Социаль каршылыкларга һәм сыйнфый көрәшләргә корылып языла торган романнар чоры узып бара. Бүгенге каршылыклар үзгәрәк төс алды, алар катлаулырак, нечкәрәк, күзгә бәрелми торганрак була баралар. Аларны кеше мөнәсәбәтләренә һәм кеше характерына тирәнтен үтеп кергән сурәттә генә ачып бирергә була. Шуңадыр, күрәсең, соңгы елларда психологик роман турында күп сөйләнелә. Мондый романның аеруча матур үрнәкләрен без латыш әдәбиятында күрәбез. Мондый типтагы роман бездә дә бар. Э. Баяновның «Ут һәм Су», А. Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» романнары аерым персонажларга тирәнәйтелгән характеристика бирүләре белән аерылып торалар. Беренчесендә, әйтик, производствода эшләүче Филинның КамАЗ кебек гигант төзелештәге яңа мөнәсәбәтләр комплексы хакындагы газаплы уйлары, икенчесендә — журналист Искәндәрнең уйланулары, аның Идел буенда элекке немец солдаты белән очрашуы, шуның аша илебез халыклары семьясында үз бәхетен тапкан татар халкының яңа тормышын күрсәтү, укучыга эмоциональ-психологик тәэсир ясау. Фикерләрен төрле алымда белдерүче бу ике язучы кызык уйланылган, әмма эшләнешләре ягыннан камилләшеп җитмәгән романнар иҗат иттеләр. Тәнкыйть бу әсәрләр турында төпле фикер әйтмәде, төрлечә фикер йөртүләргә урын калдырырлык күзәтүләр белән чикләнде. Миңа, мәсәлән, кайбер тәнкыйтьчеләрнең, хәтта прозаикларның да Э. Баянов романындагы Кама-Камилә кебек символларга мөнәсәбәте аңлашылмый, миңа калса, ул символлар гүзәллек төшенчәсен шигъри итеп ачарга булышалар һәм язучы стиленең үзенчәлекле бер сыйфаты булып торалар. Минем уемча, сүз мондый алымнарны кире кагу турында түгел, ә язучы стилендәге эпик һәм лирик агымнарны бергә кушу хакында барырга тиеш, хәзергә Э. Баянов әсәрендә алар аерым-аерым яши.

Үзенең күп планлы кызыклы романын Мәскәүдә чыгарганда А. Гыйләҗев талымсызлык күрсәткән. Романның русча тәрҗемәсе артык юкарып һәм йолкынып, кызганыч хәлдә дөньяга

чыкты, өстәвенә тәрҗемәнең сыйфаты да әллә ни шаккатырлык түгел. Без Мәскәү нәшриятлары татар әдәбиятына битараф карыйлар дип зарлана алмыйбыз, әсәрләребезнең иң уңышлы дигәннәрен бастырып чыгарырга гел әзер торулары өчен без аларга рәхмәт әйтәбез. Ләкин хәзер безне теләсә нинди тәрҗемә канәгатьләндерми. Н. Евдокимов, Н. Богданов, Н. Шундик, Е. Мальцев, А. Иванов кебек үз эшләренең зур осталары булган чын язучылар безгә яхшы тәрҗемәләр бирә алырлар иде, без үз әсәрләребез белән аларны кызыксындырырга, аларның безнең республикада булуларына, халкыбызның тормышын, психологиясен өйрәнүләренә ярдәм итәргә тиеш. Татар прозасы яхшы тәрҗемәчеләр белән эшләгәндә генә союз күләмендә әйбәт яңгыраш табачак.

Проза мәйданында М. Мәһдиевнең күренүен ике съезд арасындагы кызыклы күренеш дип саныйм. Прозаик булarak, ул нәкъ менә ике съезд арасындагы елларда формалашты. «Без — кырык беренче ел балалары» безнең арага үткен фикерле, күзәтүчән, юморга бай прозаик килүен хәбәр итте. «Фронтовиклар» романы бу карашны тагын да ныгытты. Нәрсә хакында бу роман? Аны кыскача гына болай аңлатырга була: сугыштан кайткан фронтовик укытучылар, каты кул белән, фронтта алган тәҗрибәләренә таянып, мәктәп һәм колхоз эшләрен рәткә салырга керешәләр. Бөтенесе менә шул. Монда артык бормалы сюжет та, шаккатырлык композиция дә юк, әмма тере кешеләр, характерлар бар, укучы өзлексез шуларны күзәтә. Бу безнең әдәбиятта мәктәп тормышын һәм укытучылар образын зур итеп сурәтләгән беренче роман, дип әйтә алабыз. М. Мәһдиев чорның рухын, сугыштан соңгы елларның атмосферасын төгәл бирә алган, ил һәм халык алдындагы изге бурычларын дөрес аңларлык образлар иҗат итә алган — әсәрнең төп кыйммәте шунда. Күпчелек авторларыбызның әсәрләрендәге кебек үк, романда, аерым алып караганда, шәп язылган, әмма романның идеясенә һәм образларның характерларына әллә ни яңалык өсти алмый торган озын урыннар бар иде, матбугатка чыгарганда алар кыскартылды. Тасвирчылык, озакка сузып аңлату — безнең прозаның төп чире, аңа каршы иң эре калибрлы пушкалардан ут ачарга вакыт. Миңа калса, үзенә зур өметләр баглаткан М. Мәһдиевкә сюжет-композиция төзү осталыгына ирешү җәһәтеннән дә совет әдәбияты классикларыннан өйрәнер нәрсәләр бар әле.

Татар әдәбиятында хәрби-патриотик роман күп еллар буе ару-талуны белмәс язучыбыз Г. Әпсәләмов тарафыннан үстерелеп килде. Хәзер Г. Әпсәләмов авырый, бу өлкәдә эш туктальш тора, ике съезд арасында бу жанр әллә ни үсмәде, дияргә була. Бу темага караган бары бер әсәрне — Х. Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» дигән романын телгә алырга мөмкин. Үзе дә фронтта булган автор зур күләмле беренче проза әсәрендә үк ышандырырлык картиналар һәм характерлар иҗат иткән, шул чорның кырыслыгын, ныклы, чын солдат дуслыгын күрсәтә алган. Беренче тәҗрибә буларак, роман кимчелекләрдән дә азат түгел — теле бераз кытыршы һәм авыррак, аннан соң автор хәрби начальниклар арасындагы ызгышларга кирәгеннән артык күп урын биргән. Матбугатта чыгарырга әзерләгәндә әсәрне ул кимчелекләрдән арындырырга тырыштык, әмма аерым җитешсезлекләр һаман да калган. Тормышны бөтен тулылыгында сурәтләү кебек изге теләктән чыгып эшләнсә дә, мондый характердагы тайпылулар, ягъни хәрби җитәкчеләрнең низагларын җәелеп сурәтләү, совет солдатының фашизмны тар-мар итүдәге ролен, героизмның чыганакларын аңларга комачаулый — автор буларак Х. Камалов менә шуны яхшы аңларга тиеш.

Татар совет романы үсү, камилләшү юлында — ике съезд арасында язылган әсәрләрне тикшерү шуны күрсәтә. Без роман жанрының тармаклана төшүен, яңа формаларның барлыкка килүен күрәбез һәм күп планлы, масштаблы эпос тууын көтәбез. Безнең прозаикларның андый әсәрләр иҗат итәргә хәзерлекләре җитәрлек — тәҗрибә шуны күрсәтә. Кыюлык кирәк, йөрәксенеп тотынырга кирәк!

2

Ике съезд арасындагы чорда безнең әдәбиятта повесть жанры әйбәт үсеш алды, бу — әдәбиятка яңа исемнәр килү-

гә һәм танылган прозаикларның актив эшчәнлек алып баруларына бәйләнгән. Күләме өч табактан алып алты табакка кадәр булган тыгыз, күп сыйдырышлы повесть формасын язучыларыбыз әйбәт үзләштерделәр. Моны бигрәк тә Ф. Хөснинең бүгенге авыл тормышына багышлап бай тел белән язылган «Гыйльмениса» һәм «Мәйдан» повестьларыннан ачык күрергә мөмкин, әлеге повестьларның беренчесе өчен автор Тукай премиясенә лаек булды. М. Әмирнең «Балыкчы ялганнары» исемле шаян повестенда җылы, йомшак юмор аша табигатьне, аерым алганда, Иделне саклау белән бәйле җитди мәсьәләләр күтәрелә. Халыкчан үткен тел белән язу, безнең тормышта очрый торган аерым кимчелекләргә борчыла белү әсәрне тормышчан һәм файдалы иткән. Повесть Л. Ленчның әйбәт тәрҗемәсендә «Волга» журналында басылды һәм, аерым китап булып, Мәскәүдә чыкты. Бөек Ватан сугышында катнашкан Р. Төхфәтуллин, совет халкының туган илебезне азат итү өчен героик көрәшен сурәтләүгә багышлап, «Акбүз ат» исемле лирик яңгырашлы җылы повесть язды.

Ике съезд арасындагы алты ел вакыт безнең прозага яңа исемнәр дә алып килде. «Канатлар талмасын» дигән җитди повесте белән Х. Хәйруллин үзен яхшы яктан таныгты. Мирсәй Әмирнең «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсендә бу әсәр роман дип бәяләнде, рецензент әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендәге күп кенә уңай якларны күрсәтеп үтте. Әсәргә М. Әмир биргән бәя белән килешми мөмкин түгел. Чыннан да, автор күләме белән артык зур булмаган әсәрдә кеше күңеле тибрәнешләрен, кешенең физик һәм рухи халәтен ышандырырлык итеп күрсәтә алган, әле моңарчы күрелмәгән яңа образлар иҗат иткән.

Элеккеге шофер, монтер һәм тагын башка күп төрле һөнәрләр иясе Мөсәгыйть Хәбибуллинны да мин яңа исемнәр рәтенә кертәм. Читтән торып университет тәмамлагач, ул «Унсигезенче яз», «Икмәк кадере», «Тау белән тау очрашмаса да» кебек повестьлар язып, безнең коллективка килеп кушылды. Совет кешесенең хезмәттәге фидакарьлеген сурәтләүгә багышланган бу повестьларның өчесе дә Мәскәүнең «Современник» нәшриятында басылып



*Балалар язучысы С. Б. Радзиевская.*

ята. В. Нуруллин моннан алты ел элек «Шинельсез солдатлар» дигән үзенчәлекле повесть язып танылды, шуннан соң «Күпер чыкканда», «Әгәр син булмасаң...» дигән повестьлар язып, язучылык абруен тагын да күтәрде. Шагыйрь Ф. Яруллин «Җилкәнне җилләр еккач» дигән исем белән бүгенге замандашыбызның какшамас ихтыяр көче турында сөйли торган көчле, эмоциональ тыгыз повесть язды. А. Ганиев белән Гөлшәһидә яшь художниклар тормышына багышланган кызыклы яңа повестьлар иҗат иттеләр. «Казан каласы — таш кала» дигән повесте белән М. Маликова җитди темаларны күтәрергә сәләтле язучы булуын раслады. Д. Зөбәерова, элеккерәк елларда поэзия әсәрләре язу белән шөгыльләнеп, бу өлкәдә үзен әллә ни таныта алмаган иде, соңгы елларда язылган лирик повестьлары белән ул яңадан әдәбиятка кайтты. Танылган прозаик Б. Камалов берсе икенчесенә охшамаган өч повесть язды: «Күршеләр» дигәне бүгенге шартлардагы каруннар турында, «Ялыкмаслар»да коммунист җитәкченең мәнә дигән образы бирелә, ә мәнә Камадагы гигант төзелешкә кайткан якташлары-

быз хакында сөйли торган «Урамнар киңәя» дигән әсәре, болай кызыклы гына уйланылган булса да, тормыш тулылыгы, тирәнлеге ягыннан баштагы икесеннән йомшаграк чыккан. А. Гыйләҗевнең «Урталыкта» повесте хезмәткә намуслы мөнәсәбәт, буыннар арасындагы эзлеклелек һәм бәйләнеш турында. Игътибар иткәнсездер, күпме тематик байлык, күпме характерлар! Бу исемлекне тагын өч әсәр — Р. Ишморатованың «Милиция лейтенанты», М. Маликованың «Адашканга юл кайда?» һәм М. Насыйбуллинның «Телсез шаһитләр» дигән повестьлары белән тулыландырырга мөмкин. Әлеге әсәрләрнең өчесе дә маҗара жанрына карый, аларның өчесе дә яшь буынга тәрбия бирү кебек изге темага багышланган. Сүз дә юк, мондый әсәрләрнең чыгып торуы һәр яктан хуплауга лаек, ләкин, шуның белән бергә, маҗаралы әсәр язучы прозаиклар, мавыктыргыч сюжет, вакыйга төзү белән бергә, кеше характерларын тирәнрәк ачып бирү кебек таләпне дә онытмасыннар иде дигән теләк белдерәсе килә, моннан ул әсәрләр отарлар гына иде!

Әдәби осталык хакында сүз башлагач, бу мәсьәләгә киңрәк тукталырга рөхсәт итегез. Тормыш материалын өйрәнүнең катлаулы булуы һәм кирәклеге хакында сөйләштек, партиялелек, югары идеялелек — социаль категорияләр, һәм аларның җитешмәве иҗади уңышсызлыкларга китергәнен дә беләбез. Зур идея үзенә лаек форма таләп итә. Әйдәгез, әдәбиятның төп төзү материалы булган тел турында сөйләшик.

Татар совет прозасы һәр вакыт күп милләтле халыклар семьясының сулышын тоеп, шул ук вакытта үз йөзен саклаган хәлдә үсте. Безнең бәхеттер инде, татар прозаиклары заманга аеруча кулай дип саналган «телеграф» стиле йогынтысына бирелмәделәр. Тәнкыйтьчеләр арасыннан кайбер кешеләр, телеграф стилендә язучыларны күздә тотып, безне бик кыстап яңа формалар эзләргә өндәсәләр дә, картларның бишмәт чабуына тотынып йөрүдән котыла алмыйлар, дип гаепләсәләр дә, прозаикларыбызның берсе дә бу кармакка эләкмәде. Эләкмәде, чөнки безгә Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек классикларыбызның традицияләре якын һәм кадерле, без бөек рус язучыларының, совет классикларының һәм дөньядагы прогрессив язучыларның традицияләренә хөрмәт белән карыйбыз.

Иҗаттагы новаторлыкны тышкы эффектта, әйтик, токмач кебек тураклап ташланган җөмләләрдә күрү дөрес булмас. Новаторлык «эчтән», әдәбиятның бурычларын, кешене, аның искиткеч катлаулы рухи дөньясын дөрес аңлаудан килә. Новаторлык, билгеле, формага мөнәсәбәттә дә, телебезнең байлыкларына ифрат сак, игътибарлы килүдә, аның күп сыйдырышлы булуын, нәфис һәм музыкальлеген кайгыртуда да чагыла.

Тәнкыйтьчеләребезгә инициатива җитми, алар осталык мәсьәләләрен кузгатмыйлар диярлек. Әйтик, ни өчен иҗат секцияләрендә тормыш материалын оештыра белү, геройның истә калырлык портретын бирү, һәр фразаның мәгънә байлыгын, тыгызлыгын кайгырту кебек мөһим мәсьәләләр турында сөйләшмәскә. Сүз җаеннан әйткәндә, әдәби әсәрдәге фразаларның тыгызлыгы хакында А. Фадеев күп кайгыртты, ул даими төстә яшьләрне тыгыз җөмләләр белән язарга өйрәтте. Мәсьәлә аңлашыла төшсен өчен бер мисал китерәм. Ф. Гладковның «Цемент» романында элеккеге эшче Глеб Чумалов гражданнар сугышыннан кайтып килә. Менә ул җимерек завод хәрабәләрен күреп катып кала. «Хәзер аны бәләкәй Нюрканы җитәкләгән хатыны Дашка каршы алыр, шатлыктан нишләргә белми кычкырып җибәрер дә күкрәгенә килеп капланыр. Даша көтми аны, Глеб та аңардан башка узган өч ел эчендә хатыныниләр кичергәнне белми. Илдә кеше канына буялмаган юл-сукмаклар калмады бит: үлем монда эшчеләрнең бәләкәй, тар куышларын читләтеп узганмы, әллә ут һәм давыл өермәсендә аның куышын да туздырып атканмы — Глеб әле үзен ни көткәнен белми иде». Бер абзацта һәммәсе: Глебның өйләнгән кеше булуы һәм кызы барлыгы да, өч ел сугышта йөрүе һәм алдагы нүрешү күренеше дә, эшче кешенең җаны аша узган ифрат авыр шәхси һәм иҗтимагый фаҗига да әйтелгән. Ф. Гладков фразаны шулай күп сыйдырышлы, тыгыз итеп төзи алмаса, боларның һәммәсен бирү өчен кимендә өч бит урын китәр, ә тәфсилле

тасвир, үзегез беләсез, роман героеның алдагы тормышын якын итеп кабул итәргә комачаулар иде. Моннан тыш, әсәрнең башында ук бирелгән мондый киеренкелек бөтен әсәргә үзгә бер яңгыраш өсти, герой хәрәкәт итәчәк атмосфераны күз алдына бастыра.

Мондый мисалларны үзебезнең әдәбияттан да китерергә мөмкин. Тик, нигәдер, безнең тәнкыйтьчеләр андый мисалларны өйрәнергә һәм күрсәтеп бирергә ашыкмыйлар, ә бит аларны барлау яшь буын прозаикларны тәрбияләү өчен дә кирәк.

3

Үзебездәге хәлне белеп тору һәм кабатланудан котылу өчен, мин М. Әмирнең Татарстан язучыларының VII съездында сөйләгән докладын белән танышып чыктым. Ул чагында докладчы төп игътибарын тарихи романнарга юнәлткән булган. Моны ул бездә заман темасына багышланган әсәрләр булмаудан түгел, ә бәлки нәкъ шул елларда А. Расихның «Ямашев» романы, И. Газиның күп еллык хезмәт куеп язган һәм нәтиҗәдә Тукай премиясенә лаек булган «Онытылмас еллар» трилогиясе, Ш. Маннурның «Муса» романы, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле автобиографик повесте тәмамланган бер чорга туры килгәнгә эшләгән. Боларның һәркайсы югары сәнгать таләпләреннән чыгып язылган җитди әсәрләр иде. Бу юлы бүгенге көнгә багышланган, замана темасына караган роман-повестьлар һәм хикәяләр өстенлек итсә дә, ике съезд арасында тарихи-революцион жанр да үсешен дәвам иттерде.

Н. Фәттах борынгы бабаларыбыз болгарлар турында роман язды. Авторның күп еллык тырыш хезмәт нәтиҗәсе булган әсәргә язучыларның гомуми җыелышында төпле бәя бирелде, романның күп кенә уңышлы яклары һәм кайбер кимчелекләре күрсәтелде. Н. Фәттах бабаларыбызның тарихын өйрәнүне дәвам итәргә уйлый, авторның эрудициясен һәм ниятенең җитди булуын искә алып, аңа үзе сурәтли торган чорга хас сыйфатларга, социаль хәлләрнең дөреслегенә күбрәк игътибар бирергә, тарихилык принципларына турылыклы булырга киңәш итәсе килә. Язучылар җыелышында әйтелгәнчә, Н. Фәттахның зур һәм җитди әсәрендә легендалар өскә калкып чыга, күрәсең, аларның лирик ягы авторны сокландырган. Күптән түгел Татар дәүләт академия театрында Н. Фәттахның «Кол Гали» исемле тарихи трагедиясен карадык. Бу әсәрендә автор каләмдәш дусларының киңәшен истә тоткан булса кирәк, трагедия тарихи яктан ышандырырлык, шул ук вакытта заманча яңгырашлы булып чыккан. Автор, күрәсең, сыйнфый караштан килми торып тарихи әсәр булмавын һәм була да алмаячагын аңлап эш иткән.

Г. Әпсәләмов тарихи-революцион темага күп планлы зур роман тәмамлады. Аның «Күк күкрәр» романы татар халкының, рус халкы белән бергәләп, унтугызынчы гасыр ахырындагы революцион көрәш тарихын сурәтләүгә багышланган. Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, моңарчы язылган аерым әсәрләрдә мишәрләр комик персонажлар булып кына йөри һәм асылда тел үзенчәлекләрен сиздерү өчен генә кертелә иде, Г. Әпсәләмов мишәрләр тормышының тирән катламнарын күтәрә. Роман ике кисәктән тора. Әсәрнең мишәрләргә, аларның тормыш һәм көнкүрешенә, Мәскәү шартларындагы революцион эшчәнлегенә багышланган беренче кисәге уңышлырак чыккан. Безнең прозада беренче тапкыр Ленин образын сурәтләүгә багышланган икенче кисәге бераз кайтышрак. Монда да барлык логик категорияләр дөрес бирелгән, ләкин дөнья пролетариатының булачак юлбашчысын сурәтләү, мина калса, беркадәр иллюстратив. Нәтиҗә ясыйк: Владимир Ильич Ленинны сурәтләүдә Г. Әпсәләмов кебек зур тәҗрибәле язучы да иҗади уңышка тулысынча ирешә алмаган икән, Ленин образын иҗат итүнең никадәр җаваплы һәм җитди эш булуы моңардан ачык аңлашылса кирәк.

«Янар таулар аша» дигән повестенда Ә. Шамин XX йөз башындагы үзбәк халкының тормышын ярыйсы ук яхшы белүен күрсәтте, тугандаш ике халыкның — татар һәм үзбәк халыкларының интернациональ дуслыгын ышандырырлык итеп бирә алды. Моңа кадәр әдәбиятта сүлпәнрәк эшләп килгән язучының үзбәк халкының телен, көнкү-

решен, гореф-гадәтләрен әйбәт белүе аңардан тарихи-революцион темага җитдирәк әсәрләр күтәргә өмет уята.

Безне проза өлкәсендәге беренче җитди әсәре — Муса Җәлил турында язылган романы белән шатландырган Ш. Маннур ике съезд арасында «Агымсуларга карап» дигән автобиографик повесть язды. Ике әсәрне чагыштырып карасак, соңгысы Ш. Маннур иҗатында алга таба бер адым булып саналырга тиеш. Материалга бик бай һәм язылышы ягыннан яңача булса да, «Муса» романында озынгарак сузылган, ялыктыргыч эпизодлар күп иде. Авторның яңа әсәре күп тапкыр камилрәк һәм җыйнаграк чыккан. Әсәр өчен сайлап алынган материалның бай булуы, күп нәрсә хакында сөйләргә теләү тасвирлауның иркенрәк формасын сайлауны сораган. Автор әсәрен жанр ягыннан повесть дип билгеләгән. Фикерне гомумиләштереп әйткәндә, болай дияргә була: «Агымсуларга карап» повестенда Ш. Маннур бер кеше биографиясенә ике зур чорны сыйдыра алган — әсәрнең уңышын әнә шул билгели. Ике чор, ике контраст. Бер яктан, Себер рудникларында хөкем сөргән күңел өшеткеч салкынлык, хаерчелек, ачлык, законсызлык күренешләре, царизм шартларында хезмәт кешеләренең җәберләнүе, икенче яктан, Днепрострой төзелешендәге бетончыларның күтәренке, поэтик хезмәт күренешләре әсәргә искиткеч киеренкелек биргән; зур дөреслек хакына автор үзен дә, якыннарын да җәлләп тормаган. Бераүгә дә сер түгел, безнең кайбер мемуарчылар төп геройларын һәр җирдә, һәрнәрсә хакында дөрес уйлый, бер дә ялгыша белми торган изге фәрештә итебрәк бирергә яраталар. Ш. Маннурда мондый гөнаһ юк. Әмма аның үз йомшаклыгы бар. Повесть ахырына таба автор, әдәби әсәр язуын онытып, уртак ихтирамыбызга лаек аерым әдипләр белән публицистик бәхәскә кереп китә. Менә шул чагында инде тарихи күренешләрнең асылын билгеләүдә марксистик-ленинчыл караш йомшап китә, повестьның баштагы бүлекләрендәге объектив геройны авторның рәнҗешләре алмаштыра башлый.

Бер нәрсәне онытырга ярамый: хикәяләү хәтта өченче заттан барган очракта да, безнең китапларның төп герое булып барыбер автор үзе кала, чөнки, ахыр чиктә, әсәрнең яңгырашын ул билгели, симпатия һәм антипатияләрне ул билгели. Язучының дөньяга карашы, тирә-юньдә барган вакыйгаларга мөнәсәбәте, партияле принципиальлеге — әсәрнең яңгырашын әнә шул билгели. Ш. Маннур беренче карашка тиз төзәтерлек кайбер кимчелекләре дә булган ике әйбәт әсәр язды, әсәрләрендәге кимчелекләрне төзәтүнең кирәклеген үзе аңласын, алардан котылу юлларын үзе тапсын иде, шул чагында бу ике әсәр татар совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре белән бер рәткә басачак.

Тагын ике әсәр мисалында мемуар әдәбиятның үсеше хакында берничә сүз әйтәсе килә. Аларның беренчесе — Г. Иделленең егерменче еллар ахырында бер төркем язучыларның Советлар Союзы буйлап зур сәяхәте турындагы әсәр. Анда ул, бай материалга таянып, безнең илнең шул чактагы хәлен, сыйнфый көрәш киеренкелеген, яңа тормыш төзү сулышын күрсәтә. Икенчесе — Ә. Маликовның «Яшьлек утравым» исемле әсәре, соңгысында солдат язмышы аша илнең зур биографиясе сурәтләнә.

*

* *

Менә без прозабызның ике съезд арасындагы хәлен күздән кичердек, аның көчле якларын һәм аеруча игътибар итәлергә тиешле йомшак якларын күрдек. Ихтимал, алга таба да роман һәм повесть жанрларындагы прозабыз нигездә заман темаларын яктырту, безнең көннәрнең уңай героен иҗат итү юнәлешендә үсәр. Алда әйтелгәнчә, моны бездән XXIV съезд карарларын тормышка ашыру максаты белән яңып-ялкынланып яшәгән хезмәт ияләре таләп итә. Халык тормышын дөрес итеп, коммунистик кайнарлык һәм сәнгатьчә тулылык белән сурәтләү, зур сәнгать көче белән коммунистик идеяләрне раслау — партиянең күрсәтмәләре шундый; һәм ул күрсәтмәләр совет язучыларының ихтыяҗларына, иҗади таләпләренә тулысынча туры киләләр.

Әгәр без тугандаш әдәбиятлар прозасына мөрәҗәгать итсәк, Урта Азия һәм Балтик буе республикаларында тарихи-революцион роман жанрының,



*Фикер алышулар тәнәфестә дәвам итә. Гомәр Бәширов һәм Шамил Бикчурин.*

Украинада һәм Белоруссиядә хәрби-патриотик теманың көчле үсеш алганын күрербез. Заман темасына караган роман һәм повестьларны күбәйтү белән бергә, безгә революция көннәре белән бәйле вакыйгаларны да истән чыгарырга ярамый. Без А. Расихның беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев турында роман язуын хуплыйбыз, шуның белән бергә, безнең әле күренекле революционер, Ленинның көрәштәше Мулланур Вахитовның тормышына багышланган роман укыганыбыз юк; Камил Якубның революция идеалларына багышланган тормышы үз авторын көтә; революционер, галим, әдип Галимҗан Ибраһимовның һәм башка көчле шәхесләрнең фидакарьләрчә эшчәнлеге романга лаек. Халык бездән гражданнар сугышының зур вакыйгаларын сурәтләгән киң колачлы романнар көтә. Аз булганмыни безнең җирдә сугыш вакыйгалары? Идел һәм Кама дулкыннарына кан аз коелганмыни? Татарстан җиреннән легендар Азин һәм Маркиннар узмаганмыни? Донның бәхете шунда, анда заманыбызның бөек язучысы М. Шолохов туып үсә. Әгәр безнең арадан моңарчы татар Шолоховы чыкмаган икән — көтеп торыргамы? Рус совет әдәбияты соңгы елларда «Даурия», «Вечный зов», «Тени исчезают в полдень» кебек әсәр авторлары бирде. Иванов белән Седых Себер материалында М. Шолохов башлаган эшне дәвам иттерделәр. Башкорт язучылары З. Биишева, Ф. Исәнголов, Я. Хамматов, Урал тауларыннан алып Кызыл Питерга хәтле җәелгән революция вакыйгаларын иңләп, башкорт халкының гражданнар сугышы елларындагы героик көрәше хакында трилогияләр яздылар. Мин инде украин халкының көрәш тарихыннан монументаль әсәрләр иҗат иткән М. Стельмах, О. Гончар, А. Головко кебек күренекле украин язучылары турында сөйләп тә тормыйм.

Илебез халыклары, беренче чиратта, рус әдәбияты ирешкән казанышларга мөрәҗәгать итү безне һәр вакыт көчле итте, әдәбиятыбызның дәрәҗәсен күтәрде, алга таба да башкалар тәҗрибәсеннән өйрәнү йомшармаска, ә көчәергә тиеш. Эстетик җәүһәрләрдән

өйрәнүдә генә түгел, практик эшләрдә дә кочәергә тиеш.

Украинада, Язучылар союзы идарәсенең инициативасы белән, Октябрьның 40 еллыгына «Украина совет прозасы китапханәсе»н чыгару планлаштырылган иде. Бу китапханә 50 ел буена язылган иң яхшы романнар, повестьлар, хикәяләрне үз эченә ала. «Днiпро» нәшрияты шул сериядән Украина прозасы осталарының 50 ләп китабын чыгарды инде. Шундый ук серияләр Уралда һәм Себердә, Башкортстанда планлаштырыла. Әгәр без үз проектыбызны акыллы итеп төзесәк, китап нәшрияты белән Язучылар союзы арасында әйбәт мөнәсәбәтләр урнашкан бүгенге көндә планнарыбызны тормышка ашыру әллә ни кыен булмас дип уйлыйм.

4

Хикәя һәм очерк турындагы сүзне аңлы рәвештә ахырга калдырдым. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек әдипләр безгә реалистик хикәянең югары үрнәкләрен мирас итеп калдырдылар. Аларның ул хикәяләре үзе бер мәктәп, ләкин нигәдер соңгы вакытларда без алар турында аз сөйлибез. Соңгырак буын татар совет язучыларының хикәяләре ил тормышындагы борылыш моментларын чагылдыралар, ул хикәяләрдәге геройларның биографиясендә ил биографиясе гәүдәләнә. Прозаның хикәя һәм очерк кебек сугышчан жанрлары гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышында көрәште, күмәк хуҗалыклар төзеште, җимерелгән хуҗалыкны торгызышты. А. Шамовның гражданнар сугышы чоры хикәяләрен, И. Гази, К. Нәҗми, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, Г. Галиев, Г. Минский, Ә. Еники, М. Шабай хикәяләрен, сугыштан соңгы елларда Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Г. Мөхәммәтшин хикәяләрен хәтергә төшерик. Әйе, бар иде заманнар, безнең әдәбият — хикәя әдәбияты иде. Югары таләпләр ноктасыннан карап якын килгәндә, соңгы елларда хикәя нык бирешге. Хикәя бөтенләй юк дип булмый, яшь авторларның хикәяләреннән газета-журналларның папкалары тулып тора. Әмма бөтен бер дәверне бирердәй хикәяләр юк, «Нәфрәт фәне» һәм «Кеше язмышы» юк, «Рус характеры» һәм «Өченче ул» юк, «Зәңгәр сукмак» һәм «Яр буендагы учаклар» юк, Г. Бәшировның «Ана»сы, Ф. Хөсninең «Йөзек кашы», Ә. Еникинең «Тауларга карап», М. Әмирнең «Мөстәкыйм карт», Р. Төхфәтуллинның «Авылым хикәяләре» юк.

Гыйбрәт өчен Ф. Хөснинең «Ана хикәясе»н алыйк. Нибары берничә бит. Ана авыллары аша отряд белән узарга тиешле улын, кызылармеец Батталовны көтә, улын ул үгетләп үзе янында калдыру нияте белән көтә. Көтә-көтә, лампасында керосины бетә. Ниһаять, Батталов кайта, улын көткән ана ай яктысында аның шинель төймәсен тага һәм сүзсез генә тагын озата — авыр юлга озата. Бар булганы менә шул! Әмма анда һәр сүзгә күпме мәгънә салынган, ана образында күпме җылылык, күпме заманны аңлау хисе! Мин инде фразаның тыгыз булырга тиешлеге хакында сөйләдем. Әлеге хикәя: «Күгәрченнәр тынычлык эзләп урманнарга очалар, авыл картларның тынычлык теләп укыган догалары белән пышылдый» дигән сүзләр белән башлана. Бер фразада шомлы, дәһшәтле унсигезенче елның төп рухы бирелгән.

Сүз дә юк, хикәя жанры безнең әдәбиятта бар, бар гына түгел, яши, өлкәннәргә алмашка яшьләр килә, әмма хәзергә яңалык алып килүчеләр азрак шул. Ике съезд арасында бу өлкәдә Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян, М. Рафиков, А. Гыйләҗев, Б. Камалов, Р. Батулла, М. Маликова, К. Тимбикова, С. Сөләйманова кебек язучылар актив эшләде, чын мәгънәсендә юмористик хикәяләре белән драматург Т. Миңнуллин, шагыйрь Г. Афзал катнашты, өлкән әдипләребездән И. Гази хезмәте хакында аеруча җылы сүз әйтәсе килә. Аның «Сарбай — сары эт», «Тургай картаямы икән?» дигән хикәяләре — кечкенә мәйданда зур характерлар ачып биргән чын сәнгать әсәрләре. Алар янына чын материалга нигезләнеп, көчле гражданлык мотивлары белән сугарылган хикәяләр язучы М. Зариповны өстәргә була. Яшьләрдән А. Ганиев белән Ә. Гафаров үзләрен яхшы яктан күрсәттеләр. Сәяхәтчеләр тормышын шәп белүче М. Юныс турында да җылы сүз әйтми кала алмыйм. Үзе белгән шул материалга таянып, ул «Энҗе эзләүче-

ләр» дигән, социаль яктан үткен, җыйнак һәм төзек хикәя язды.

Ихтимал, киләчәктә хикәя жанры, аның үсеш юллары һәм тенденцияләре хакында махсус бер сөйләшү уздырырга кирәк булыр.

*
* *

Татарстан язучыларының VII съездыннан соң СССР төзелүгә 50 ел, Татарстан төзелүгә 50 ел, В. И. Ленинның тууына 100 ел кебек зур тарихи вакыйгаларга бай алты ел гомер үтте. Ул еллар безнең әдәбиятка яңа уңышлар, яңа хикәяләр һәм очерклар, яңа повестьлар һәм романнар алып килде, иң мөһиме — кызыклы яңа исемнәр һәм яңа геройлар алып килде. Хәрәкәттә — бәрәкәт, ди халык. Тырыш хезмәт иҗади шатлыклар китерә. Прозабызның офыклары турындагы сүземне рус әдәбиятының бөек остасы, укытучыбыз М. Горький сүзләре белән тәмамлыйсы килә. 1928 елда, татар язучыларына мөрәҗәгать итеп, ул болай дип язды: «Мин татар поэзиясе һәм прозасының чәчәк атуын чын күңелдән телим, ләкин моңа әдәбият алдында торган бурычларга үтә җитди караганда гына ирешергә мөмкин».

Әдәбият алдында торган бурычларга үтә җитди карау — татар совет прозасының офыкларын әнә шул киңәйтәчәк, әнә шул җитдилек безне яңа уңышларга алып киләчәк.

## Илдар Юзеев

# ТУКАЙ, ҖӘЛИЛЛӘР БИЕКЛЕГЕНӘ

Ике съезд арасында басылып чыккан шигъри әсәрләрне тагын бер тапкыр укыганнан соң, төрле буын шагыйрьләрен чагыштырып карадым. Тавышлары, алымнары, тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан бер-берсеннән нык аерылып торган шагыйрьләр бер ноктада очраштылар. Очрашу ноктасы — Тукай.

Бөтенләй башка чор, бүтән укучы... Ә Тукайның рухы шигъриятебезнең җанында, эчке һәм тышкы табигатендә, новаторлыгында һаман яши. Ул рух «Тукайдан алып Бакырганига кадәр булган шигъри өслүб җимерелергә тиеш» дип чыккан Такташ иҗатында да, коммунистик иман өчен үлемгә барганда елмаерга көче җиткән, шагыйрь шәхесен дөнья алдында тагын бер тапкыр раслаган Җәлил иҗатында да яшәгән. Ул рух яңа шартларда тагын да югары баскычка күтәрелгән. Без бүген Тукай, Такташ, Җәлил кебек «рухи Алыплары» булган олы поэзиябез белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Барыбызга да билгеле: Владимир Ильич Ленин, 1921 елда Татарстан делегациясен кабул иткәндә, поэзиябезнең иң югары биеклеге булган Тукаебыз белән кызыксынып: «Шагыйрьнең эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр бармы?» дип сораган. Юлбашчыбызның бу соравына Такташча, Җәлилчә, Кәримчә, Фәйзичә, Туфанча иҗат белән генә җавап бирергә мөмкин иде.

Хәзер инде изге мираска әверелгән Тукай поэзиясе, иң беренче чиратта, чорның хәлиткеч проблемаларын халыкка җиткерүе һәм сәнгатьчә бөеклеге белән кадерле. Үзенә кадәр булган мирас нигезендә Тукай поэзиябезне новаторларча яңа юнәлешкә — халыкчан юнәлешкә бора. Ул үзенең зур эрудициясе, алдынгы фикере белән барлык укучыларны, халыкны үз артыннан ияртә алды. Шунлыктан бүген тәнкыйтьтә барган «кайсы укучы өчен язарга» дигән бәхәсне Тукайча язып кына хәл итәргә мөмкин. Гадәттә, шигъриятнең тәэсире турында сөйлә-

тәндә, паникага төшкән гаскәрләрне, шигъри сүз белән күтәреп, дошманнарга каршы алып киткән мифологик грек шагыйрен мисалга китерәләр. Ә дошманның мәкерле тырнагыннан, йогышлы идеологиясеннән йолып, меңнәрләгән әсирләрне туган илләренә кайтаруда хәлиткеч роль уйнаган Муса Җәлилнең көче бу миф геройларыныкыннан киммени? Чит идеологиягә каршы килешмәс көрәштә бүгенге поэзиябезнең тәэсир итү көче Җәлил шигърияте югарылыгында булырга тиеш. Бөек фикерләрнең сәнгатьчә табигый яңгырашын тапкан новатор шагыйрьнең иҗаты аннан соң килгән шагыйрьләр өчен традиция мәктәбе булды.

Бүгенге шагыйрьләребез, үз әдәби мирасыбызны маяк итеп алу белән бергә, дөнья поэзиясе казанышларына да таяналар икән, бу — бик табигый. Рус шагыйре А. Твардовскийның да, төрек Назыйм Хикмәтнең дә, узган гасырда яшәгән америкалы Уитменның да, шотланд Роберт Бернсның да, Балтик буе шагыйрьләренең дә поэзиябезгә уңай йогынты ясавы яхшы билгеле. Мостай Кәрим, Нәҗәр Нәҗми кебек башкорт шагыйрьләренең дә яшьләр поэзиясенә билгеле бер дәрәҗәдә тәэсире бар. Үз чиратында татар поэзиясенең дә тугандаш халыклар поэзиясен үстерүдә катнашы бар дип уйлыйбыз. «Бар нигезләр буталган, халыклар аралашкан» чор татар шагыйрен дә шигырьдә көч сынашырга ил мәйданына, дөнья мәйданына чакыра.

Ләкин бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк, әгәр синең үз сабан туеңда ишетерерлек тавышың юк икән, үз халкыңны сокландырырлык итеп җырлый алмыйсың икән, зур мәйданга чыгудан әллә ни мәгънә юк... Үз халкыңның күңел кылларын чиртү, халык күңеленә юл табу... Кешенең күңел түренә яшеренгән уен, моңын, шатлыгын, хыялын, сагышын тоя алуга ирешкән шагыйрь — бәхетле. Әмма моңа шагыйрь зур фикер-хис, кыю эзләнүләр аша гына килә ала.

Соңгы елллар поэзиясендә нинди яңа тенденцияләр, нинди яңа сыйфатлар күрәбез соң?

Республикабыздагы, илебездәге зур үзгәрешләр шагыйрьләребез иҗатын яңа эчтәлек, яңа темалар белән баетты. Сыйфат яңарышы, иң беренче чиратта, поэзиябезнең тормышка якынаюында, чынбарлыкның катлаулы үсеш процессына үтеп керергә омтылуда, заман сулышын сизгер тоюда күренде. Элек керосины да булмаган, көндезен үк чыра телеп куя торган Татарстан хәзер, нефть тәяп, дөньяга, океаннарга чыкты... Күкрәгенә Муса Җәлил исеме язылган теплоход җиде диңгез артларында дөнья гизә. Без белгән «Шүрәле», Кырлай урманыннан чыгып, Канада урманнарын яктыртты. Поэзиябез Татарстанның данын бар җиһанга ишеттергән, тормышны үзгәрткән һәм үзе дә үзгәргән гади хезмәт кешесенә борылды.

Фәнни-техник революция дулкыны авылга иң тугрылыклы Гамил Афзалны да нефтьчеләр шәһәренә күчерде. Бу үзгәреш шагыйрь иҗатында каршылыклы чагылды, әмма авыл җирлегендә тамырланган гөл асфальт урамда да үсеп китте. Гомер буе авыл турында язган шагыйрь илгә нефть бирүче яңа тип кешеләрнең дә күңеленә үтеп кerә башлады.

Нәби Дәүли, шахтерлар тормышын өйрәнеп, «Донбасс токымы» исемле цикл язды. Хисам Камалов, иҗатында борылыш ясап, шәһәр ритмнарын эзләргә тотынды. Әхсән Баянов «Сәяхәтнамәсе»ндә яңача яшәешкә күчүнең драматик ноктасын тотып ала белгән. Чиләбе шәһәрендә яшәүче Камил Мостафинның шигырьләрендә бүгенге көн инженерының үзенчәлекле интеллектуаль дөньясы чагыла. Тормышны яңартучы хезмәт кешесе турында Ә. Исхак, З. Нури, М. Садри, Г. Латыйп, Ә. Маликов, Ф. Шәфигуллин, Т. Камалиев, Ш. Маннапов һ. б. яздылар. Заман шагыйрьләрне яңача уйларга, заманча фикерләргә мәҗбүр итте. Заман... Киң колач, тиңе күрелмәгән тизлек, хыял җитмәс биеклекләр... һәм, ниһаять... шуларның конкрет символын гәүдәләндергән КамАЗ... Зур төзелеш алдында шагыйрьләребез, бәхеткә каршы, югалып калмадылар. Аны данлап күп шигырьләр, җырлар язылды. КамАЗның үзе белән бергә сулыш алган, аны үз куллары белән төзешкән Мәхмүт Газизовның шигырьләре яңача, конкрет һәм тормышчан булулары белән укучыны җәлеп итте.

Гигант төзелеш үзе шикелле масштаблы әсәр язуны, фәлсәфи тирәнлекне, сәнгатьчә гомумиләштерүне таләп



*Олы бәйрәмдә ике буын очрашты. Идрис Туктаров һәм Илдар Юзеев.*

итә иде. Рөстәм Мингалимов «Күз карасы» исемле поэмасында, төзелеш панорамасын күрсәтеп, КамАЗ капкасын ачуда матур гына омтылыш ясады. Бу поэмасы өчен авторга КамАЗ премиясе бирелү — поэзиябезнең тормыш белән бергә баруын күрсәткән бер дәлил. Тәҗрибәле шагыйрь С. Хәким исә, КамАЗ капкасын тагын да киңрәк ачып, аны татар халкының олы язмышы, тарихы, киләчәге белән, ил язмышы, үз язмышы белән бәйләде.

Поэзиябезнең эчтәлеге, сулышы, масштабы, горизонты киңәйде, тирәнәйде — шагыйрьләребез иҗатында соңгы елларда барлыкка килгән асыл сыйфатларның берсе әнә шул. Киң колачлы заман үзеннән-үзе эпик жанрга мөрәҗәгать итүне сорый. Ерак тарихтагы «Йосыф-Зөләйха»ны искә төшерсәк, поэма өлкәсендә мең еллык мирасыбыз барлыкны күрербез. Нинди поэмалар әдәбиятта торып калган? Үзе яшәгән чорның көрәшен, сулышын, фикерен, хисен, героен иң калку гәүдәләндергән поэмалар... Совет чорыннан Такташ, Җәлил, Кәрим, Фәйзи, Хәким поэмалары шундый. Арабыздан вакытсыз киткән талантлы шагыйрь Әнвәр Давыдов поэма жанрының яңа мөмкинлекләрен ачуда онытылмаслык эз калдырды. Аның «Йокысыз төннән соң» дип исемләнгән соңгы әсәре үзе үлгәннән соң басылды. Роман-симфония... Әйе, чыннан да симфония кебек бөтен, күп планлы, күп тавышлы, киң колачлы, тормышның үзе кебек катлаулы әсәр. Авылның төрле чорлары «бер күңелгә тыгызланып тулган». Роман вакыйга сюжетына корылган. Әмма вакыйгалар авторның чор турында уйланулары белән үрелеп бара. Гайни образы Такташның Мохтар карты, Ш. Маннурның Гайҗан бабайлары янында урын алырлык. Поэзиябез тарихында икенче шигъри роман. Димәк, бу эпик жанрның үз традицияләре барлыкка килде. Вакыйгага нигезләнгән зур шигъри әсәрнең яшәргә хакы бармы? «Евгений Онегин» чоры уздымы? Бу поэзиябез өчен артта калган этап түгелме? Вакыйга сюжетына корылган поэма шәбрәкме, әллә ул фикер-хис композициясеннән генә торырга тиешме? Бу хакта күп еллар инде бәхәс бара. Чыннан да, соңгы елларда поэманың табигатендә кызыклы үзгәрешләр барлыкка килде. Ю. Марцинкявичюс, А. Вознесенский, М. Каноат, Н. Нәҗми поэмаларында вакыйга сю-

жетына табыну юк, алар язган поэмаларның нигезендә — нинди дә булса бер вакыйгадан туган фикер композициясе. Татар поэзиясендә дә шул ук хәл. С. Хәкимнең «Васыятьләр», «Кырыгынчы бүлмә», Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн», «Керәшчеләр», Р. Харисның «Мулланур», Р. Мингалимовның «Минем дәүләтем» поэмалары вакыйга сөйләү белән түгел, ә заман, шәхес, ил-җиһан турында тирән уйланулары, фикер композициясенә корылулары белән яңалык алып килделәр. Поэманың монолог, диалог, фантазия, симфония, цикл, повесть, роман, лирик, сатирик кебек төрләре, формалары туды. Тәнкыйтьчеләр бәхәсенә кушылып, боларның кайсына өстенлек бирергә, киләчәктә поэманың кайсы төре үсеш алыр? Миңа калса, поэма катып калган жанр түгел, аның ачылган һәм ачылмаган мөмкинлекләре чиксез. Ул, чор һәм шагыйрь ихтыярына буйсынып, үзгәрә тора. Бер үк шагыйрьдә без поэманың әллә ничә төрен очратабыз. Димәк, вакыйгага корылган повесть-романнар да, фикер композициясенә нигезләнгән поэмалар да бер-берсе белән ярышып яши алалар. Бары тик шагыйрь үз чорын кабатланмас итеп, бөтен бөеклеге, катлаулыгы, авырлыгы, каршылыгы белән ачып бирсен, эчтәлек һәм форма әһәмиятле булсын, кыскасы, шагыйрь чорның поэтик монументын килер буынга калдырырлык көчкә ия булсын! В. Маяковскийның «Во весь голос»ы, Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар»ы, Х. Туфанның «Урал эскизлары» кебек... Такташның язылып бетмәгән хатлары безнең чорга килеп җитте, бүгенге көн шагыйрьләре ул хатның дәвамын яңача язып, киләчәккә юлларлык көчкә ияләрме? Бу өлкәдә эшләргә сәләтле көчләребез югарыда әйтелгән исемнәр белән генә чикләнми. Поэма жанрын үстерерлек шагыйрьләребез шактый: Ә. Маликов, Х. Камалов, Ә. Баянов, М. Шабаев, Д. Сирай, Ә. Рәшитовларны атау да җитә. Хәзер безгә бу өлкәдәге уңышларыбызны үстереп, чорыбызга тиң булырлык монументаль әсәрләр һәм психологик тирән образлар тудыру юнәлешендә эшне дәвам итәргә кирәктер. Тормыш көзгесе дип аталган поэзиябездә әлегә чор бөтен тулылыгы, катлаулыгы, драматик каршылыклары белән тиешле дәрәҗәдә күрсәтелмәгән, кешенең рухи яңаруы җитәрлек чагылыш тапмаган.

Һәр заман үзенә хас образлы фикерләүне таләп итә. Әгәр шагыйрь моннан егерме ел элек язган дәрәҗәсендә калса, поэзия орбитасыннан төшеп кала, аны заманның зәвыклы укучысы кабул итмәячәк.

Борынгы шагыйребез Сәйфи Сараиның:

Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли,—

кебек юллары хәтта бүгенге көн укучысы өчен дә кызык. Ә шул заман өчен нинди кыю, көтелмәгән чагыштыру! Бу ике юл безгә шул чорның тәвәккәл фикерләвен генә түгел, хәтта «Җир әйләнә кояш тирәли» дигән фәнни ачыш Коперникка кадәр билгеле булган икән дигән хакыйкатьне дә җиткерә. Шуңа таянып, бүгенге көн шагыйре Нури Арсланов шигырь язган һәм Сәйфи Сараига заман биеклегеннән караган:

Мөмкинме шик тоту Коперникка,—
Тел тидерү аның кебеккә!
Тик гыйбрәтле шунысы — кайчак серләр
Соң ачыла, элек белеп тә...

Кайчан гына авыл белән шәһәр арасында йөрүче шагыйрьләребез Җир, Ай, Кояш орбитасына менделәр, туган җиргә, космонавт шикелле, зәңгәр ераклыктан карадылар. Образлы фикерләүнең офыгы киңәйде. Берәүләргә Җир зәңгәр йомгак, икенчеләргә карбыз, өченчеләргә сабый бала булып күренде. Кинәт кенә Җир кечерәеп, Кеше зураеп калды. Шагыйрь хәзер ил уртасында, дөнья уртасында, чорлар чатында. Ул вак темалар, кечкенә идеаллар белән яши алмый. Аны «кешелек кая бара», «кыл өстендә торган Җирне ни көтә», «табигатьне саклап калырбызмы?» кебек гомумкешелек проблемалары борчый. Поэтик лексиконга «мизгел», «лазер», «неон», «ракетодром» кебек сүзләр килеп керде. Яңару сурәтле фикерләүдә дә, формада да, заманча чагыштыруларда да, телдә дә күренде.

Җимерелгән империяләр, чорлар
Җилкәсенә басып иттем ял...

Сибгат Хәким.

Һәр мизгелдә мәгънә,
Бер мизгелдә
Гөл ава ала,
Ил ава ала...

Равил Фәйзуллин.

Ургып чыккан тирән чишмәләр дә
Корый икән суын эчмәсәң...

**Рәшит Гәрәй.**

Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?

**Рәшит Әхмәтҗанов.**

«Планета изүләрен чиште», «заман аягүрә» басты, туган җир төшенчәсе зураеп, киңәеп дөнья, галәм белән бәйләнештә сурәтләнде. Әмма туган туфрагында басып торган шагыйрь барыннан да элек үз халкының улы, үз иленең гражданины. Ул үзенең җилкәсендә, йөрәгендә ил йөген, аның мәшәкатен, борчуын, шатлыгын, матур хыялын алып бара. Ул илдә, җирдә булган бер генә вакыйгага да битараф карый алмый.

Хиросима, син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның?

**З. Насибуллин.**

Ренат Харисовның Фатих Кәримгә багышланган циклында шагыйрь-гражданин образы ил язмышын, Шиллер ватанының язмышын хәл итүче итеп бирелә.

Поэзиябездәге горурланып әйтерлек уңай күренешләрнең берсе — гражданлык лирикасының сыйфат үсеше. Чын лирика «гражданлык» киеменә төренгән образсыз-төссез, купшы риториканы артка кысрыклап чыгарды. Заман шагыйрьдән яңача образлылык, тирән фикер һәм хис таләп итте. Поэзиябезнең үсеш тенденциясен характерлый торган тагын бер күркәм сыйфат — фәлсәфи лириканың көчәюе. Бу — С. Хәким, Х. Туфан, Н. Арслан, Ш. Галиев, Г. Афзал, Х. Камалов, Ә. Баянов, Роберт Әхмәтҗанов, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Ш. Мәхмүдов, Г. Рәхим, Р. Миңгалимов, Зөлфәт, М. Әгъләмов әсәрләрендә бигрәк тә ачык күренде.

Талантының төп юнәлешен таба белгән шагыйрь үзен дә, поэзияне дә күтәрә. Кырыс та, матур да чынбарлыкны реалистик төгәллек белән бирүне иҗатына нигез итеп алган С. Хәкимнең тирән хис-фикерле лирикасы хаклы рәвештә ил аренасына күтәрелде. Н. Дәүли каләменә публицистик лирика якын. Фәнис Яруллин үзен лирика һәм юморда тапты. «Казан утлары»ның быелгы 4 нче санында басылган шигырьләре аның җитди үсеен күрсәтә. С. Сөләйманова, К. Булатова, Э. Мөэминова, Л. Шакирҗанова, Ф. Гыйззәтуллиналар хатын-кыз күңелен тирән тоеп язган шигырьләре белән укучыны җәлеп итәләр. Төрле юнәлешләрнең табигый синтезына ирешү Н. Арслан иҗатын яшәртеп, баетып җибәрде. Укучы аның тормышчан шигъриятендә фәлсәфә дә, публицистика да, рәссам сурәте дә, интим хисләр дә, драматизм да, юмор да, сатира да, җыр да, эпиклык та таба һәм аларның аерылмас бердәмлеген тоя. Г. Афзал һәм Ш. Галиевләргә сирәк очрый торган үзенчәлек: лирика белән юморның бердәмлегенә омтылу хас. Шигырьләренең табигый җыр ритмында язылулары аларның иҗатын халык күңеленә тагын да якынайта.

Шигъриятебездә шундый бер кимчелек тә күзгә ташлана. Бертөрлелек, алымнар ярлылыгы күп кенә шагыйрьләрнең иҗатын чикләүгә китерә. Кайбер шагыйрьләребезгә Тукайча киңлек, иҗат алымнарының байлыгы, аларның аерылмас бердәмлеге җитми. Димәк, халыкның рухи байлыгын тирәнрәк, тулырак бирү турында сөйләгәндә, без синтезлау процессының әйбәт нәтиҗә бирәчәген дә истә тотарга тиешбез.

Чиксез киңлекләр, биеклекләр, колач заманы романтик шагыйрьләрне сорый. Поэзиябездә бу юнәлешнең бай традицияләре бар. Тукай, Такташ, Җәлил романтикасы... Тормышчан, актив, революцион, оптимистик, дәртле, ашкынулы шигырь... Романтик алымны файдалануның уңышлы үрнәкләрен Роберт Әхмәтҗанов, Рәдиф Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрендә дә күрәбез. Бу алым зур төшенчәләр, фикерләр, эре, колачлы образлар белән эш итүне ярата. Романтиканың куркыныч бер ягы бар: сак эш итмәгәндә, буш риторикага алып китә, вакланууны күтәрми. Реаль чынбарлыктан аерылдыңмы — романтика үзен акламый. Иҗатын романтик ашкыну белән башлап җибәргән Рәдиф Гатауллинның соңгы елларда сүрелә төшүе нәкъ шул зур романтикадан читкә китүендә, ваклануында түгел микән? Роберт Әхмәтҗанов та конкрет чынбарлыкны романтик биеклеккә күтәргән шигырьләрендә көчле, ләкин вакыт-вакыт ул, җирдән аерылган фәлсәфәдә үзен югалтып, түманга кереп киткәли. Рәшит Әхмәтҗанов, бер

үк традицион образлар белән артыграк мавыгып, диапазонын тарайта, шунлыктан иҗатының яңа баскычка күтәрелүен тоткарлый шикелле. Әмма романтик рухлы шагыйрьләр вакытлы кыенлыкларны җиңеп чыгарлар һәм бу юнәлешне яңа сыйфатлар белән баетырлар дип уйларга нигез бар. Бөтен җаны-тәне белән романтик рухлы Зөлфәт бу ышанычны тагын да ныгыта. Аның «Тимерче турында» һәм «Гармунчы турында»гы балладалары поэзиябезгә үзенчәлекле шагыйрь килүен хәбәр итә. Кайчак мин Зөлфәт шигырьләрендә бик яшьли дөньядан киткән шашкын шагыйрь Ш. Бабич тавышын ишетәм. Зөлфәтнең замандашы М. Әгъләмов исә поэзиягә җирдән, Татарстан туфрагыннан, халык җырыннан, аның тарихыннан, сабан туйларыннан килә. Ул ныклап җиргә ябышкан. Беренче җыентыкларын чыгарган Зиннур Насибуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Разил Вәлиевләр... Алар артыннан килүче Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Фәннур Сафиннар... Бу өметле көчләр киләчәктә ничек ачылырлар, поэзия йөген озак-озак җигелеп тартырга аларның гайрәтләре җитәрме, киләсе җыентыкларында яңа сыйфатлар белән безне шатландырырлармы? Бу сорауга алар тик үзләренең иҗатлары белән генә җавап бирерләр. Кайбер яшь авторларның вак темалар тирәсендә әйләнүләре, тормышка актив мөнәсәбәте булмаулары безне бик борчый. «Идел» альманахында басылган күпчелек шигырьләрдә гражданлык хисенең олылыгы, чор сулышын, тормышның тирән агымын нечкә тою җитми, бертөрлелек, ясалмалылык күзгә ташлана. Кызганычка каршы, бу кимчелек кайбер өлкән шагыйрьләребезгә дә хас.

Шунысы характерлы, яшь һәм урта буын шагыйрьләре Туфан һәм Хәким шигърияте йогынтысында һәм аларның конкрет ярдәме белән поэзия мәйданына килделәр. Елдан-ел гүзәл гамьнәр, яңа урләр ачуны бөтен гомерләре белән раслаган өлкән дусларыбызның принцибы шуннан гыйбарәт: сәләтле яшьләргә — даими игътибар, зур таләп һәм кыю эзләнүләрне яклау.

Эчтәлекне бирүнең төрле формалары тирәсендә кузгалган дискуссия һәммәгезнең хәтерендәдер. Хәсән ага Туфан яшьләр газетасында «Юкны эзләмәскә, барны үстерергә» дигән тезис белән чыкты. Тәвәккәл эзләнүләр ягында торган яшь шагыйрьләр моңа «юкны булдырырга, барны үстерергә» дигән декларация белән дә, үз иҗатлары белән дә җавап бирделәр. Дөрес, аларның шигърияте өлкән шагыйрь кисәткән формалистик мавыгулар да булгалады, әмма татар шигыренең яңа мөмкинлекләрен табуны максат итеп алган шагыйрьләр нигездә хаклы иде. Татар шигъриятендә иркле форманың яшәргә хаклыгын иҗат тәҗрибәсе белән Хәсән ага Туфан үзе үк раслады. Бездә иркле форманың ераклардан килгән үз традициясе бар, аның чиксез мөмкинлекләрен Такташ ачты. Әлбәттә, яшьләр эзләнүләрендә милли һәм дөнья классикасы мирасына таяндылар. Бу юнәлеш бигрәк тә Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харис иҗатында ачык күренде. Алар поэзиябезгә һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан яңалык алып килделәр, иркле форманың заманча мөмкинлекләрен ачтылар. Эзләнүләр, ачышлар бертөрле һәм тигез бармады. Кайвакыт фәлсәфи фикерле, кыска формалы, рифмасыз шигырьнең аһәңе, гармониясе табылмады. Кайвакыт акыл һәм хис бердәмлегенә, телнең халыкчанлыгына, форма табигыйлегенә ирешә алмау комачаулады. Шулай да алар күпчелек шигырьләрендә эчтәлек һәм форма, акыл һәм хис бердәмлеген табуга ирештеләр. Равил Фәйзуллин җыентыктан-җыентыкка үзгәрде, үсте, «Наз» җыентыгында инде ул тирән фикере белән генә түгел, күңел җылылыгы, назы, аһәңе белән дә укучыны җәлеп итә.

Бер заман башлап язучылар, Р. Фәйзуллинга ияреп, барысы да иркле шигырь язарга тотындылар, поэзиянең киләчәге бары шунда гына дип уйладылар, күрәсең... Әмма тора-бара ияртүчеләр барысы да бер-берләренә охшап, дөрес юл таба алмыйча адашып калдылар. Димәк, эш теге яки бу формага өстенлек бирүдә түгел, ә шагыйрьнең талант дәрәҗәсендә, көчендә икән. Шул үк Равил дә, Ренат та төрле формаларга мөрәҗәгать итәләр, ә Равил исә соңгы вакытта канунлашкан формаларга кайтты. Әмма моның белән без һич тә иркле формада эзләнүләр туктар дип уйламыйбыз, киресенчә, аның чиксез мөмкинлекләрен яңа талантлар



*Шигърият дөньясы уйландыра да, шатландыра да. Сибгат Хәким һәм Равил Фәйзуллин тәнәфес вакытында.*

да ачар дип көтәбез. Төрле чор шагыйрьләре ачкан, борын-борыннан килгән һәм, минемчә, бүгенге көн өчен дә искермәгән бер хакыйкать бар: шагыйрь табигате белән философ та, композитор да булырга тиеш. Эзләнүләрнең, новаторлыкның төп максаты — яңа эчтәлек ачу, фикерне сәнгатьчә матур итеп бирүгә ирешү. Эзләнүләре менә шул юнәлештә барганга күрә дә, укучы Равил Фәйзуллин шигырьләрен үз итеп кабул итә. Шамил Мәхмүдов та яңача эзләнүләре белән кызыксыну уятты. Ул, һичшиксез, масштаблы образлар белән эш итә алучы, үзенчәлекле шагыйрь. Аның «Прага дәфтәре» циклы, «Чирек гасыр — аналарның кипми күз яше» кебек әйбәт шигырьләре бар. Әмма, инде күп кенә җыентыклар чыгаруга карамастан, Ш. Мәхмүдов укучы күңеленә юл табуда авырлык кичерә. Сәбәп нәрсәдә? Эш иректә яки канунлаштырылган формада язуда гына да түгел: шагыйрьдә тегесе дә, монысы да бар. Минемчә, сәбәп фикерләү формасының матурлыгын, аһәңен табып бетерә алмауда... Аның кайбер шигырьләре йөрәк аркылы узмаган, акыллы фикер булып кына кабул ителәләр. Шуңа күрә дә, кайбер мәкаләләрдәге кебек, Шамил Мәхмүдовны новатор дип атап, аңа әлегә кирәгеннән артык бәя бирергә ашыкмыйк. Минем аңлавымча, новаторлык үз халкының туфрагыннан, теленнән, җырыннан күтәрелеп киткәндә генә, халык күңелендә сыналганда гына үзен аклый. Кайбер шагыйрьләр, бигрәк тә яшьләр, халыкның җанлы сөйләм телен өйрәнүгә игътибар итмиләр, шунлыктан шигырьләрдә күпшы шаблон, ясалма тел... Телнең нечкәлекләрен үзләштермәү ритмның музыкальлегенә дә зыян итә. Новаторлык ул — миллионнарны дулкынландырган олы фикер-хисне яңача һәм халыкка барып җитәрлек алым-формаларда әйтеп бирү. Һәр шагыйрь, талантының көченә карап, яңалыкны үзенчә һәм төрле дәрәҗәдә алып килә. Маяковский, Такташ — һәм эчтәлек, һәм форма новаторлары. Әмма аларны эпигоннарча кабатлаган шагыйрьләр поэзиядә эз калдырмадылар. Новаторлыкның көче — кабатланмас булуында. Яңа заман шагыйре классик поэзиядәге зур ачышларны үстерү, баету юнәлешендә генә новаторлыкка ирешә ала. Кайвакытта новаторлык форма ягыннан күзгә бәрелеп тормаска да мөмкин. Традицион формада язуларына карап, без С. Есенин, А. Твардовскийны новатор түгел дип әйтә ала-

бызмы? Һич юк! Хәсән Туфан ирекле формада язылган әсәрләрендә генә түгел, халык җыры үлчәвендә язылган шигырьләрендә дә новатор булып кала. С. Хәкимнең яңалыклары да болай тыштан кычкырып тормый. Димәк, кайвакыт новаторлык әсәрнең эчендә, күзәнәгендә, тирәндә яшеренгән була. Новаторлыкны форма яңалыгы гына дип аңлап ялгышучы шагыйрьләрнең фаҗигасен поэзиябез тарихы әле дә онытмый. Шагыйрь — камил формасы табылган яңа фикер, яңа хис, образлар новаторы.

Поэзиябездә яңачыл хәрәкәт традицион формаларны үстерү юнәлешендә дә дәвам итте. Шагыйрь, меңәр ел кулланган форманы да, яңа фикерехисе белән терелтеп, яңартып җибәрә ала. 8—7 үлчәве борынгы халык җырларына да, Мәүла Колыйга да, Г. Тукайга да, бүгенге көн шагыйрьләренә дә хезмәт итә ала икән. Безнең шагыйрьләребез ул үлчәүне кыска фәлсәфи шигырьгә дә, лирик шигырьгә дә, хәтта романга да җигәләр. Ә иске дип уйланган форма моңа риза, уйлый, моңлана, җырлый — шагыйре генә талантлы булсын. Әгәр шагыйрь, шушы кысага сыймыйча, шашып, дулап яңа формалар эзли икән, бу максатка да шатланып хезмәт итә.

Гәрәй Рәхим «гел бер тонга, гел бер моңга» көйләүдән канәгать булмыйча, ритмиканың яңа төрләрен эзли һәм ача икән, бик дөрес эшли. «Әниләр зары», «Вәгъдә», «Болыннарны атлар табырлаган» кебек шигырьләрендәге уңышлы табышларны үстерсә, шагыйрь, һичшиксез, поэзиябезне тагын да зуррак ачышлар белән баетыр.

Заманында Шекспир кулланган сонетны без Ш. Мөдәррис иҗатында күргән идек. М. Хөсәен дә берничә йөз сонет бастырып чыгарды. Арада уңышлы гына язылганнары да бар. Әмма күпчелек сонетларның эчке табигатендә үзенчәлекле яңа фикер-хис, драматизм, логик үсеш булмаганлыктан, беренче планга, кычкырып, форма чыга. Димәк, классиклардан өйрәнгәндә безгә сан ягыннан түгел, бәлки сыйфат ягыннан өйрәнергә кирәк. Хәлбуки, без эчтәлекнең яңа формаларын эзләүдә артыгы белән тыйнакбыз. Поэзиябездә онытылмас эз калдырган Әнвәр Давыдовның яңачыл эзләнүләре, кызганычка каршы, ярты юлда өзелде. Төрле юнәлештә, төрле формаларда шигъриятнең чикләнмәгән мөмкинлекләрен һәм серләрен ачу юлыннан барганда гына, поэзиябез яңа биеклеккә күтәрелер.

Бер үк форманы күп кабатлау кайчак шагыйрьнең иҗатын чикли. Бу кимчелек «Юлдашым булсаң иде» дигән әйбәт җыентык чыгарган Рәшит Гәрәйнең шигырьләрендә дә сизелә.

Тар, җыйнак кысага зур фикер сыйдыру омтылышы соңгы елларда шигырьнең кыска формаларын җанландырды. Без соңгы елларда икеюллыклар, дүртьюллыклар, сигезьюллыклар, уникеюллыкларның хәрәкәткә килүен күрәбез. Сатира-юмор жанрында эшләүче шагыйрьләребез кыска формаларны аеруча яратып кулланалар. Юмор һәм сатира турында сүз барганда, Ә. Исхак, Г. Афзал, Ш. Галиев, З. Нуриларның актив эшләүләрен әйтми китә алмыйбыз. Ләкин игътибарның җитәрлек булмавы нәтиҗәсендә, реалистик поэзиянең иң катлаулы, мөһим бу жанры баю, тирәнәю юнәлешендә үсеп китә алмый тора. Әлегә безгә искелекне камчылауда Тукайча кыюлык, хакыйкатьне вакланмыйча, туры, усал әйтү җитми. Поэзиябезнең сәләтле яшь кадрларын шушы традицияне үстерү юнәлешендә җитәрлек тәрбияләмибез.

Поэзия һәм музыка... Әдәбиятыбызны шушы мәңге аерылмас ике дустан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Без шагыйрь табигате белән композитор булырга тиеш дип әйтәбез икән, композиторның да җаны белән шагыйрь булуын уйлыйбыз... Борынборыннан җыр белән яшәгән халкыбыз оптимистик рухлы, дәртле, «дусларны иркәли, дошманны җиңә» торган җыр сорый. Шулай ук халкыбызга күңелне сафландыра торган тирән сагыш, сагыну мотивлары да ят түгел. Шигъриятнең югары үре дәрәҗәсендә иҗат ителгән «Киек казлар», «Өзелгәнсең сиреньнән», «Өченче көн тоташ кар ява», «Солдатлар», «Аккошлар» әсәрләре таш бәгырьләрне дә тыныч калдырмый икән, димәк, бу шигырьләрне җырга әйләндерүчеләр, әсәргә ачкыч тапкан илаһи минутларда үзләрен шагыйрь итеп тә хис иткәннәр дигән сүз. Минә шундый иҗади аңлашу булганда гына озын гомерле җырның тууы мөмкин.

Безнең кочләрен бары тик җыр язуга багышлаган һәм шул жанрда уңышлы эшләгән М. Ногман, Г. Зәйнашева кебек шагыйрьләребез бар. Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Зөлфәтләрнең музыкага мөрәҗәгать итүләре җыр жанрында кызыклы яңалыклар вәгъдә итә. Ләкин бу өлкәдә һаман да әле «җыр язу өчен шагыйрь булмасаң да ярый, музыкасы яхшы икән — шул җиткән» дигән зарарлы караш яши. Шуның аркасында кайвакыт ягымлы көйгә төренгән, поэзиягә мөнәсәбәте булмаган мәгънәсез сүз тезмәләре халыкка тәкъдим ителә. Талантлы композиторларыбыз кайчак шигърияттән ерак торган мөнаҗәтчеләрнең текстларына музыка язып, үзләрен дә, көйләрен дә уңайсыз хәлгә калдыралар. Халык күңелендә озак еллар саклана торган җырның тууы өчен музыканың да, шигырьнең дә профессиональ югарылыкта булуы шарт. Текстлар ташкынында мәк чәчәге белән чүп үләннәре барысы бергә буталган, җыр бакчасына кереп чүп үләннәрен утыйсы килә...

Туган якка багышлап җыр язу халкыбыз иҗатында күптәннән бар. «Сарман» җырын туган ягын, сөйгәнен өзелеп яраткан кеше — билгесез бөек шагыйрь — халык иҗат иткән. Сарман яшьләре дәртле заман ритмына үзләре тагын бер яңа җыр чыгарганнар икән — бу да бик әйбәт! Әгәр дә инде шагыйрьләр, композиторлар «кызлары матур, егетләре батыр», «бу — минем туган ягым» дип, һәр районга, һәр авылга атап, бер-берсеннән исемнәре белән генә аерылган җырлар язалар икән, бу инде сәнгать рамкаларына сыймый башлый... Җыр жанрының берьяклы үсүе дә үзен нык сиздерә. Мәхәббәт сагышы, аерылышу, сагыну турында язарга өйрәндек шикелле. Ә совет кешесенең гражданлык хисләрен җырга әйләндерүдә безнең уңышларыбыз бик аз. Шулай ук Җәлилләр безгә ышанып тапшырган либретто жанрының һаман да аяныч хәлдә булуы һәммәбезне борчырга тиеш.

Шагыйрьнең зур мәйданнарга, сәхнәгә, радиога, телевидениегә чыгуы ялкынлы шигъри сүзне күбрәк аудиториягә һәм тизрәк җиткерергә ярдәм итә. «Эстрада поэзиясе кирәкме, юкмы?» дигән бәхәсләргә без: «Әйе, кирәк, әмма ул Такташча, Җәлилчә трибун булып, чын поэзияне пропагандаларга тиеш»,— дип җавап бирәбез. Тамашачыларны арзан кул чабуга исәпләнгән, кычкырып торган, төче, вак поэзиядән аралап, укучыларның зәвыгын үстерергә сәләтле югары шигърияетнең активлыгын көчәйткәндә генә, без зур традицияләргә тугрылыклы икәнне расларбыз.

Халыклар багланышка кергән зур чорда шагыйрьнең аудиториясе үз халкы белән генә чикләнми, ул башка тугандаш халыклар телендә дә сөйли башлый. Үз халкының күңеленнән күтәрелгән Җәлилнең аудиториясе — бөтен дөнья; аны һәр милләт үз шагыйре итеп таный. Соңгы елларда поэзиябезнең ил мәйданына активрак чыгуы — әдәбиятыбызның үсешен раслый торган факт. Ләкин русчага тәрҗемә ителгәндә кайбер китаплар поэзиябезнең үсеш дәрәҗәсен күрсәтү таләбеннән чыгып сайланмыйлар. Бу мөһим эшне нигездә авторның шәхси инициативасына гына калдыру кайчак очраклы әсәрләрнең чыгуына китерә. Әлегә кадәр Һ. Такташ, Х. Туфан, Ф. Кәрим, Ә. Давыдов, Н. Арслан, Ш. Галиев, Г. Афзалларның рус укучыларына тиешенчә тәкъдим ителмәве нормаль хәл түгел. Кави Латыйповтан алда менә кемнәрне чыгарырга кирәк иде... Башка милләт укучыларына бер үк авторның гына күпләп тәкъдим ителүе шулай ук поэзиябезнең байлыгын күрсәтә алмый. Бу өлкәдә дә Тукай, Җәлил традицияләренә тугрылыклы булу — югары сыйфатлы поэзия белән генә башка халыклар алдына чыгу — изге бурычыбыз.

Әлбәттә, шагыйрьнең төп аудиториясе — иң беренче чиратта — туган телендә укучылар. Шигъри продукцияне укучыларга иң башлап җиткерүче газет-журнал тиражларының елдан-ел артуы — күңелле хәл. Моннан берничә еллар элек шигырь китапларының тиражы 10 мең белән басылып тарала иде. Соңгы вакытта шигырь китапларының 2—4 мең тираж белән генә чыгуы безнең барыбызны да борчый торган факт. Нәшрият, Таткниготорг һәм Республика китапханәсе, шагыйрьләрнең ничек һәм нинди укучылар тарафыннан укылуы белән кызыксынып, ниндидер формада социологик тикшерү үткәрсәләр, аңа фәнни анализ ясасалар, шактый гыйбрәтле хәлләр



*Яшь әдипләр өлкән дуслары белән. Рәзил Вәлиев, Зөлфәт Мәликов, Нури Арсланов, Фаил Шәфигуллин, Ренат Мөхәммәдиев, Зирәк Йосыпов, Нур Әхмәдиев.*

күрерләр, тираж бирү мәсьәләсендә бәлки башкачарак уйларлар иде. Кайбер китаплар китапханә тузанына күмелеп хәрәкәтсез ята, кайберләре тетелеп беткәнче укыла. Моны университет дипломантлары тарафыннан берничә районда үткәрелгән социологик өйрәнүләре раслый. Шулай ук тәнкыйть яхшы белән начарны аерып бирергә укучыга ярдәм итәргә тиеш.

Татарстан китап нәшрияты авторларга таләпне сизелерлек арттырды, хәзер без узган съездда телгә алынган, поэзиядән ерак торган китапларның басылып чыгуы турында сөйләмибез. Без бу таләпне яшь шагыйрьнең беренче китабын чыгару мисалында күрәбез. Зөлфәт, З. Насибуллин, К. Сибгатуллин китапларының җәмәгатьчелек тарафыннан әйбәт кабул ителүе — шул таләпнең нәтиҗәсе.

Яшь шагыйрьгә хәерле юл теләп фатиха биргәндә, аеруча игътибарлы һәм сак килергә, аны ялгыш юлга җибәрүдән сакланырга кирәк. Шулай да була: шигырьне матур гына үрергә өйрәнгән автор бер-бер артлы китап та чыгара, Союз члены булып та китә... Әмма аның шигъри гомере фаҗига белән тәмамлана — аның үзенчәлеге, шагыйрьлек чаткысын үстерерлек көче булмаган икән. Таләпчәнлекне киметеп, ялган шагыйрь ясауның аяныч нәтиҗәсен редакция һәм нәшриятта эшләүчеләр яхшы беләләр. Андый автор тавыш-гауга чыгару белән танылса башлый. Башка профессия сайларга инде соң, үз уңышсызлыклары өчен ул башкаларны гаепли, шәхес буларак вакланa. Китап арты китап чыгарып та, үз иҗатына таләп белән карамау аркасында, үсешнең башлангыч ноктасында поэзиябезнең бүгенге дәрәҗәсеннән төшеп калган авторлар да яшьләргә гыйбрәт булсын. Үз-үзеңә таләп куймау сан артыннан кууга, шигырь инфляциясенә китерә. Журналга олау-олау шигырьләр бирү туктата алмаслык бер хәлгә әйләнде. Әлбәттә, сүз талантлы язылган шигырь бәйләмнәре турында бармый. Заманында «Безнең юл» журналында Тукташның бер шигыре чыгуы зур вакыйга булган. Хәзер син шушылары гына басарга ярый дип, авторның бер-ике шигырен генә сайлап кара — тавыш чыгуын көт тә тор! Аның өчен иң мөһиме сыйфат түгел, шигырьнең саны гына күп булсын!

Яшь шагыйрьләр авызыннан кайчак: «Шигырь яза белү бик җиткән, җәмәгать эшләрен бүтәннәр эшләсен»,— дигән фикер ишетергә туры килә. Әгәр матур гына шигырьләр язып та, шәхес буларак вак булып каласың икән — син әле чын мәгънәсендә шагыйрь түгел.

Кайбер яшь шагыйрьләребезнең гражданин буларак бик акрын өлгерүләре — барыбызны да борчый торган аяныч факт. М. Әгъләмов кебек сәләтле егетләрнең җәмәгать эшләреннән читләшүләре, эрудицияләрен күтәрү турында аз уйлаулары иҗатларына кире йогынты ясамас микән? Шигъри матурлыкка шәхес каһарманлыгын кушканда гына шагыйрьнең сүзе тормышчан көчкә әверелә.

«Шагыйрь нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавапны безгә «саф, коеп куйган поэт кына түгел, дипломат, политик, общественный деятель дә» булган шигъри даһиебыз Г. Тукай бирә. Бу сорауга җавапны безгә үлгәндә дә Тукайча җырлый-җырлый үлгән Муса Җәлил, унҗиде яшендә кулаклар тарафыннан үтерелгән ялкынлы комсомолец Шамун Фидаи, коммунистик иман өчен утта дөрләп янган Хәйретдин Мөҗәй бирә. Бу сорауга җавапны безгә арабызда Такташларны хәтерләтеп, гүзәл гам булып яшәүче өлкән дусларыбыз бирә.

Поэзиябезнең үткәне горурланырлык... Коммунистик идеаллар өчен көрәш поэзиясе, Матурлык һәм Батырлык поэзиясе! Шул югарылыктан карaганда, бүгенге поэзиябезнең йөзе нинди? Шигъри даһиларыбызның изге рухы алдында, заман алдында кызарырлык түгелме? Ул бүген нинди хәлдә?

Минемчә, классикларыбызның олы традицияләренә нигездә тугрылыклы калган хәлдә, поэзиябез яңа сыйфатлар белән баю, эчтәлек һәм форма ягыннан тирәнәю-яңару, социалистик реализмның мөмкинлекләрен тулы көчкә файдалану юнәлешендә үсеш хәрәкәте кичергән. Югары таләп куеп, үзендәге күркәм сыйфатларны киләчәктә тагын да баетса, үсешкә комачаулаган факторларга каршы кыю көрәшсә, поэзиябезнең киләчәктә Тукай, Җәлил менгән биеклекләргә күтәрелүе бәхәссез! Ә бөек Заман моны таләп итә.

«Шагыйрьнең эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр бармы?» Владимир Ильичның кайгыртучан соравы билгеле биеклекләргә ирешкән аксакалларга да, поэзиягә яңа килүче яшьләргә дә карый. Һәм без юлбашчыбызның таләпчән сүзләренә идея-художество ягыннан югары сыйфатлы әсәрләр белән генә җавап бирергә тиешбез.

Халкыбыз, партиябез Ленин сүзләре белән үз шагыйрьләренә:

— «Димәк, базда дары бетмәгән әле!» — дип әйтерлек булсын!

## Туфан Миңнуллин

# ШАТЛЫКЛАР ҺӘМ БОРЧУЛАР

VII съезддан соң узган алты ел вакыт эчендә республикабыз театрлары татар язучыларының 45 оригиналь әсәрен сәхнәгә куйганнар. Моңа балалар өчен язылган һәм курчак театры сәхнәсендә дөнья күргән 5 пьесаны өстәсәк, Академия театрында барган 4 инсценировканы кушсак, ике съезд арасында драматургларыбыз шактый ук актив эшләгәннәр икән, дигән фикергә килергә мөмкин.

Ләкин безнең эшнең нәтиҗәсен саннар гына түгел, сыйфат билгели. Сыйфат мәсьәләсенә килгәндә дә артык зарланырга урын юк шикелле. Татар драматургиясенең бөтен союз аренасына чыга алмавы безне күптәннән борчып килә иде. Соңгы өч-дүрт елда, ниһаять, Мәскәү һәм илебезнең башка театрлары сәхнәсендә татар драматургларының байтак әсәрләре куелды. Диас Вәлиевнең «Дәвам» пьесасы Мәскәүнең Ермо-

лова исемендәге театрында һәм тагын утызлап театрда уңыш белән бара. Ул украин, белорус телләренә тәрҗемә ителде. Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасы шулай ук, русчага тәрҗемә ителеп, берничә театрда куелды. Һәр ике әсәр үзәк матбугат битләрендә уңай бәя алды. Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» исемле комедиясе Әзәрбайҗан театры сәхнәсендә барды.

1972 елның ноябрь аенда РСФСР язучылар союзы, РСФСР Культура министрлыгы һәм Бөтенроссия театр җәмгыяте оештырган семинарда Татарстаннан өч драматург катнашкан иде. Аларның пьесалары семинарда югары бәя алды.

Республикабыз театрларының репертуарына күз салсак та, куанычлы эшләр шактый. Бүген өздереп әйтә алабыз: театрларыбыз әдәби эшләнеше ягыннан зәгыйфь, аннан-моннан гына оештырылган пьесаларны куймыйлар. Драматургларга таләп көчәйгәннән-көчәя бара.

Соңгы вакытта тагын бер шатлыгыбыз артты: мин балалар өчен язылган драма әсәрләренең күбәя баруын күздә тотам. Күптән түгел Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегендә режиссер һәм драматургларның бер киңәшмәсе булган иде. Шунда Казан курчак театры портфелендә бүген тотып сәхнәгә куярлык унга якын оригиналь әсәр булуы әйтелде. Бу — курчак театрының кырык еллык тарихында күрелмәгән хәл.

Ниһаять, драматургия өлкәсенә килүче яшьләр турында берничә сүз. Театр афишаларында яңа исемнәр сирәк күренсә дә, берничә күңелле фактны әйтмичә калып булмый. Моңарчы әдәбиятның башка жанрларында эшләп язучылар, драматургиягә мөрәҗәгать итеп, уңышлы әсәрләр яздылар. Талантлы прозаик Нурихан Фәттахның курчак театрында «Энҗеле үрдәк» пьесасы һәм Академия театры сәхнәсендә «Кол Гали» трагедиясе куелды. «Кол Гали» — халкыбызның ерак тарихы турында сәхнә телендә сөйләгән беренче әсәр дисәм, ялгыш булмастыр. Шагыйрь Илдар Юзеев «Янар чәчәк»тән соң шактый дәшми торды да «Бөркетләр кыяга оялый» исемле менә дигән комедия иҗат итте. «Гомернең алты сәгате», «Сандугачлар килгән безгә» дип аталган әсәрләр язып бетерүен дә беләбез без аның һәм озакламый аларны сәхнәдә күрербез дип ышанабыз. Сәләтле шагыйрьләребездән Фәнис Яруллин да «Әнә килә автомобиль» исемле комедия язып бетерде. Татар дәүләт академия театрының бу әсәр буенча куелган яңа спектаклен тамашачы җылы каршылады.


Сәхнә законнарын яхшы белгән Роберт Батуллин, әдәбиятның төрле жанрларында көчен сынап караганнан соң, үз кыйбласының кай якта икәнен төшенеп, бер-бер артлы ике пьеса язды. Әсәрләре хәзергә бәлки күккә чөеп мактарлык та түгелдер. Ләкин Роберт Батуллинның бик яхшы пьесалар яза алырлык көч-куәте бар.

Инде драматургия жанрында төпкә җигелеп эшләүче иптәшләрнең ике съезд арасындагы иҗатларына күз салыйк.

Сүзне Риза ага Ишмораттан башлыйсы килә. Риза аганың бөтен иҗатына тулы бәя бирергә җыенмыйм. Һәркемгә мәгълүм: драматургиягә ул — бөтен тормышын багышлаган кеше. Өлкән яшьтә булуына карамастан, ял итәргә ашыкмый, һаман иҗат уты белән яна. Соңгы вакытта аның «Хикмәтле Сәйфи» исемле комедиясе Минзәлә театрында куелды. Әсәрне драмсекциядә укыгач, Риза аганың яңа форма табу юнәлешендә яшьләрчә эзләнүен күреп сөендек. Югыйсә, безнең драматургиядә форма бертөрлелеге шактый туйдыра башлаган иде.

Риза аганың «Хикмәтле Сәйфи»ендә кире адәм Сәйфинең «Җен»е безнең күзгә күренеп сәхнәдә йөри һәм үзенең хуҗасы Сәйфи белән дөньяда ничек яшәү мәсьәләсендә бәхәскә керә. Ләкин, кызганычка каршы, автор шушы бик кызыклы алымнан ахырга кадәр файдалана алмаган. Драматург ни өчендер үзе уйлап тапкан «Җен»нән үзе курка, кирәгеннән артыгын әйтеп ташламасын дигәндәй, «Җен»нең авызын томаларга ашыга. Сәйфи үзе дә сүзен логика кануннары таләп иткәнчә сөйләми. Нәтиҗәдә, әсәрнең ни өчен язылганлыгы аңлашылмый, фикере арзаная, конфликты йомылып кала, чишелми. Ә бит сәхнә әсәре алдына куела торган шундый бер таләп бар, әгәр конфликт туган икән, ул хәл ителергә тиеш.

Тормышчан конфликтлар таба бел-



*Ике чордаш, ике дус: Бакый Урманче һәм Абдулла Шамуков.*

мәү һәм аны хәл итүдәге төгәлсезлек — барыбыз өчен дә уртак бәла. Күп вакыт горзинең иң авырын күтәрәбез дә, кемгә яки нәрсәгә дә булса ору нияте белән, баш очыбызда озак итеп болгарга тотынабыз. Болгый торгач, аны нинди ният белән күтәргәнебезне үк онытып җибәрәбез.

Риза агадан кала, иң өлкән һәм актив драматургыбыз — Хәй Вахит. Хәй Вахит иҗаты турында төрле сүз әйтелде, бәхәсләр дә чыккалап торды, бәхәсләрнең тупаскраклары да булды. Болар барысы да табигый хәл, күп эшләгән кеше турында күбрәк сөйләнә.

Хәй Вахит — дистәләгән еллар буе театр репертуарын үз җилкәсендә күтәреп килгән кеше. Бу — күпертеп әйтү түгел. Театр драматургтан туктаусыз яңа әсәр таләп итеп торды, драматург өлгерергә тырышты. Кайчакларда пьесаларын сәнгать югарылыгына җиткереп шомартырга вакыты да җитми кала иде. Бара-тора мондый хәлгә Хәй Вахит күнегә башлады һәм, ниһаять, каты тәнкыйтькә очрады. Тәнкыйтьне авыр кичерсә дә, драматург иҗатына җитдирәк, җаваплырак карый башлады. Ике съезд арасында язылган «Туй алдыннан», «Мәхәббәтең чын булса» кебек пьесалары бу хакта сөйли. Драматург бу әсәрләрендә җитди проблемалар күтәрә; геройлары — тере кешеләр, алар чынлап торып уйланырга өйрәнеп киләләр, үзләренә күрә шатлыклары, хәсрәтләре дә бар. Хәй Вахит турында сөйләгәндә, шуны да әйтергә кирәк, ул — сюжет төзү остасы. Ләкин шушы осталык кайвакыт юкка сарыф ителеп куйгалый. Мин, мәсәлән, татар драматургиясенең уңышлы саналырлык «Күк капусы ачылса» дигән комедия язган авторның «Илһамия», «Кияүләр» кебек йомшак әсәрләр язуын һәм шуларны театрларга тәкъдим итүен һич аңлый алмыйм. Хәй Вахит үз тамашачысын киләчәктә югалтмасын иде, бик яхшы әсәрләр язып, аларны шатландырсын иде.

Аяз Гыйләҗев — прозада да, драматургиядә дә актив эшләүче язучыларыбызның берсе. Ике съезд арасында аның «Шомырт чәчәк атканда», «Син дөньяда берәү генә» һәм «Эңгер-меңгер» исемле пьесалары куелды. Аяз Гыйләҗев кызыклы һәм бәхәсле драматург. Кайберәүләр аның пьесаларын мактыйлар, икенче берәүләр Аяз Гый-

ләҗевнең драматурглык сәләтенә шикләнебрәк карыйлар һәм моны драматургның пьесалары буенча куелган спектакльләрне тамашачының салкынрак кабул итүе белән аңлаталар. Мин үзем соңгы дәлил белән килешмәс идем. Мәсәлән, шул ук А. Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә» драмасы Академия театрында ике йөздән артык уйналды, «Син дөньяда берәү генә» йөздән артык куелды. Драматургның кайбер пьесалары, чыннан да, озак гомерле булмады. Ләкин, минемчә, моңа Аяз Гыйләҗев кенә гаепле түгел. Ул — җитди, уйланучан әдип. Драматург еш кына социаль әһәмияте булган проблемаларга мөрәҗәгать итә. Һәм ул аларны үзенчә чишә. Драматург куйган проблемалар коймасыз, капкасыз өй сыман, урам чатында шыраеп, күзгә бәрелеп тормый. Шуңа күрә әллә соң кай вакытта театр Аяз Гыйләҗевне аңлап бетермиме, шуның аркасында драматургның фикерләре тамашачыга барып җитмиме, дигән шик туа. Мисалга драматургның Татар дәүләт академия театрында куелган «Әңгерменгер» пьесасын алыйк. Миңа калса, пьесада бүгенге көннең шактый актуаль мәсьәләсе күтәрелгән, драматург тамагым тук, өстем бөтен дип тирә-як тормыштан читләшеп, аңа битараф караучы кешеләрне фаш итә. Кызганычка каршы, театр авторның фәлсәфәсен тамашачыга тулысы белән җиткерә алмады, әсәрдә куелган проблеманың җитдилеген тамашачы аңлап бетермәде. Килер вакыт, драматург, театр, тамашачы берсен-берсе яхшырак аңларлар һәм Аяз Гыйләҗевнең элек язылган кайбер әсәрләре дә сәхнәгә яңадан кайтырлар дип уйлыйм.

Алты ел эчендә сәхнәгә куелган пьесаларның иң уңышлысы кайсы? дип сорасалар, һич икеләнүсез, Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасын атар идем. Бер караганда катлаулы да түгел бу әсәр: вакыйга бер гаилә эчендә генә бара, сюжеты да, исеме дә гап-гади. Ләкин әсәргә салынган мәгънә вакыйганы бер гаилә рамкасыннан киңрәк дөньяга алып чыга, аны фәлсәфи югарылыкка күтәрә. Без күп вакыт киң полотнолы әсәрләр кирәк дип сөйләргә яратабыз, әмма киң полотно дигән төшенчәне аңлап бетермибез бугай. Берәр зур вакыйгага багышлап, күп кешеле пьеса язабыз да шуны киң полотнолы әсәр дип атыйбыз. Сәхнәдә шау-шу күп була, газета битләрендә дә андый әсәрләргә мәдхия укыла, тик спектакльнең файдалы эш коэффициенты, акылга, йөрәккә тәэсир итү көче генә әллә ни зур булмый.

Яшьләрне патриотизм рухында тәрбияләү хакында сүз чыктымы, минем күз алдыма «Әни килде» спектакле килеп баса. Туган анасына хөрмәте булмаган кешенең туган илен яратуына ышануы кыенрак. «Әни килде» спектаклендә шул фикер ачык чагыла, һәм аның уңышы да әнә шунда. Димәк, ул киң полотнолы әсәр. Мондый әсәрне бары тик талантлы кеше генә иҗат итәргә мөмкин. Ләкин, кызганычка каршы, шушы талантлы драматург сирәк яза.

Ниһаять, Әлмәт якларында күзгә-башка күренми генә яшәп яткан, тәнкыйтьчеләр тарафыннан мактау сүзен аз ишетсә дә, күңелен төшермичә уңышлы пьесалар иҗат иткән Юныс ага Әминов турында берничә сүз. Алты ел эчендә драматургның өч пьесасы дөнья күрде. Академия театрында «Гөлҗәннәтнең җәннәте», Минзәләдә «Кеше күңеле», Әлмәттә «Минем җинаятем». Мин бу әсәрләрнең өчесен дә бүгенге татар драматургиясенең уңышы дип әйтер идем. Кызганычка каршы, театр белгечләре тарафыннан аларга тиешле бәя бирелмәде. Хәер, бер рецензия язып «Гөлҗәннәтнең җәннәте»н кемдер тәпәләп алды. Ләкин ул рецензия Юныс аганың иҗат юнәлешен белмичәрәк язылган иде. Мин театр тәнкыйте турында аерым сөйләргә җыенам. Шулай да Юныс Әминов иҗаты уңае белән театр тәнкыйтьчеләренә үпкәмне башта ук белдереп китим. Юныс Әминов иҗатын аерым алып сөйләргә күптән вакыт. Стандарт рецензияләр язып кына түгел, ныклап торып өйрәнеп, тикшереп язарга вакыт. Кеше күңеленең бөтен нечкәлекләрен тоеп, аңлап яза Юныс Әминов. Аның пьесаларындагы геройлар, авторның үзе кебек, нечкә күңелле, хәтта тискәре геройлары да без күрергә өйрәнгән типларга охшамаган, бәләкәй генә ярамаган эш эшләсәләр дә оялалар, үкенәләр. Юныс Әминов әсәрләрендә кычкырып торган, маңгайга-маңгай килерлек конфликтлар юк дип әйтерлек. Ләкин моңа карап драматург

конфликтсыз әсәр яза дип әйтеп булмый. Конфликт тирәндә, күңелләрнең берсен-берсе аңламавында.

Тәнкыйтьчеләр күзеннән читтә булуы драматургның иҗатында сизелми калмый. Ул кайвакыт кабатлана, сюжет төзүдә примитивлыкка, тапталган сукмакларга кереп киткәли, тормышчанлыкны гади көнкүрешне сурәтләү белән буташтыргалый, күп сүзләнә.

Драматургия өлкәсендәге уңышларыбыз да, ялгышларыбыз да алда исемнәре аталган барлык авторлар иҗатында чагыла. Әлбәттә, театрларыбызның алты еллык репертуары алар язган әсәрләрдән генә тормаган. Комедия остасы, өлкән драматургыбыз Зәйни ага Шәһиморатов «Әй, әшнәләр, әшнәләр» дигән водевиль язып безне шатландырды. Сәет ага Шәкүровның дүрт пьесасы Минзәлә һәм Татар дәүләт академия театрларында куелды. Сәет Шәкүров соңгы елларда бик актив эшли. Тик кайвакыт, кирәгеннән артык активлашып китеп, кабалана, пьесаларын тиешле кондициягә китереп җиткерми, алар авторның сәләтеннән түбәнрәк килеп чыгалар. Рәйсә Ишморатова яшьләр тормышыннан «Шамил» дигән уңышлы гына әсәр язды, Минзәлә театры Әхсән Баяновның «Һәйкәл» исемле драматик поэмасын ярыйсы ук кызыклы итеп сәхнәләштерде.

Драматурглар турында сөйләүне шушында туктатып торып, театр тәнкыйтенә килик. Театр тәнкыйте дигәндә мин гомумән театр фәне турында сөйләргә җыенмыйм. Мине борчыган нәрсә бүгенге театр тәнкыйте. Билгеле, яңа спектакльләргә рецензияләр чыгып тора. Рецензияләр, әлбәттә, кирәк. Ләкин алар гына җитми. Юныс Әминов турында сөйләгәндә әйттем: безгә теге яки бу драматургның яки режиссерның, я булмаса театрның иҗат принципларын анализлаган мәкаләләр дә, аерым драматургларның иҗаты мисалында теоретик мәсьәләләр күтәргән хезмәтләр дә бик кирәк. Кирәк кенә түгел, аларның булмавы безнең үсешне тоткарлый. Мәсәлән, уртага салып сөйләшәсе, ачыклыйсы бер нәрсә бар. Сүз комедия жанрының драматургиябездәге урыны хакында бара. Әгәр кем дә булса комедия бөтенләй кирәкми дисә, билгеле, аңардан көләчәкбез. Ләкин практикада комедиягә караш салкынрак икәнлеген драматурглар яхшы беләләр. Академия театры «Диләфрүзгә дүрт кияү» дигән комедияне куйгач, комедия авторына мыскыллы сүзләрне шактый ишетергә туры килде. Һәм «Диләфрүзгә дүрт кияү», әсәр буларак түгел, жанр буларак хәкарәт ителде. Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» исемле шәп комедиясе сәхнәгә куелгач, театр җиңел әйберләргә йөз тота дип сөйләнүчеләр шулай ук булмады түгел. Җиңел дигән сүз мыскыллап әйтелде. Яки Зәйни ага Шәһиморатовның «Уеннан уймак» дигән уңышлы комедиясе хакында җитди итеп сөйләүне кирәк тә тапмадылар. Ни өчен мондый фикер яши, аңа кем гаепле? Бер жанрны өстен куеп, икенчесен кимсетеп карау ялгыш кына түгел, зарарлы да. Иң аяныч шул. Мондый жанрга таләп кими, аны теләсә кем яза ала дигән фикер туа. Һәм, кызганычка каршы, теләсә кем яза да башлый. Чөнки тәҗрибәле драматурглар, мыскыллы сүз ишетүдән куркып, ул жанрдан читтәрәк йөрүне уңай саныйлар.

Театр тәнкыйтьчеләре алдында тагын бер зур эш тора. Безнең республикада дүрт дәүләт театры һәм дистәләгән халык театрлары эшли. Академия театры турында аз булса да сөйләнелә. Ә калганнар хакында анда-монда чыккан бер рецензиядән, яки информациядән башка нәрсә язылмый дисәм дә ялгыш булмас. Шуңардан файдаланып, кайбер театрларыбыз репертуар булдыруда шактый ук талымсызлык күрсәтәләр. Дәүләт театрлары, билгеле, әллә ни узынмыйлар, ә халык театрларының репертуары шактый чуар. Дөресен әйтергә кирәк, бу театрларда куелган әсәрләргә ташлама да ясыйбыз. Ләкин ул театрларның тамашачы зәвыгын тәрбияләвен онытып җибәрәбез.

Тәнкыйтьчеләр без эшләгән эшне күрергә теләми, безнең адреска бер генә җылы сүзе дә булмады, дип үпкәләмәсеннәр. Минем максатым бәйләнү түгел. Теләгем шул гына: тәнкыйтьчеләрне читтән карап күзәтеп торучы контролерлар, яисә гади статистика белән шөгыльләнүчеләр итеп кенә түгел, әдәби процесста турыдан-туры катнашучы иҗат кешеләре итеп күрәсе килә.

Драматургларның төп йорты — театр. Шулай булгач, театрларыбыз әше турында бер-ике авыз сүз әйтмичә яра-



*Прозаиклар Абдулла Шәрәфетдинов, Фатих Хөсни һәм драматург Сәет Шәкуров.*

мас. Минемчә, бүгенге театрыбызга күз генә тимәсен! Безне иң куандырганы — режиссерларыбыз. Марсель Сәлимҗанов, Равил Тумашев, Мулланур Мостафин кебек режиссерлар булганда, пьесаларыбызның язмышы өчен борчылмаска мөмкин. Алар таләпчән кешеләр. Күп вакыт әсәрләребезне каткат эшләтеп безне интектереп бетерәләр, нәтиҗәдә яхшы спектакльләр дөньяга килә. Гомумән, әгәр татар драматургиясе үсте, алга китте, дип әйтәбез икән, иң беренче чиратта, режиссерларыбызга мактау сүзе әйтергә тиешбез. Чөнки чын драма әсәре театрда, бары тик театрда гына туа.

Әйе, театрларыбыздан да, режиссерлардан да без нигездә канәгать. Әмма безне Әлмәт театрының язмышы нык борчый. Мәнә дигән артистлар коллективы булган бу театрда баш режиссерлар еш алышынып тора. Шуңа күрә, соңгы елларда Әлмәт театрында туган яхшы оригиналь пьесалар юк дәрәҗәсендә. Безне Качалов исемендәге театр җитәкчеләренең татар драматурглары әсәрләренә мөнәсәбәте дә борчый. Әгәр без бүген татар драматургиясе бөтен союз сәхнәсенә күтәрерлек югарылыкта булсын дибез икән, аны пропагандалау турында сүз алып барабыз икән, Качалов театры бу эшне үзенең төп бурычы дип санарга тиеш түгелме? Бу мәсьәлә күптәннән хәл ителүне көтә. Театр җитәкчеләре белән бу хакта конкрет сөйләшүләр дә булды. Тик Качалов театрының репертуарында бүгенге татар драматургларының әсәрләре һаман дә күренми.

Театрлардан кала, безнең әсәрләрнең язмышы Культура министрлыгы белән бәйләнгән. Чөнки безнең пьесалар турында соңгы сүзне Культура министрлыгы әйтә. Бу мәсьәләдә әле ачыклыйсы, аңлашасы нәрсәләр бар. Шулай да соңгы вакытта безнең контактлар якыная, иҗади форма алып бара. Язучылар союзының драмсекциясе хәзер министрлык белән тыгыз элемтәдә эшли башлады. Иң куанычлысы, бу элемтә министрлык инициативасы белән барлыкка килде.

Сүзне йомгаклап әйткәндә, ике съезд арасында куанычлы эшләребез шактый булган. Шуның иң әһәмиятлесе — безнең соңгы еллардагы иҗаты-

бызны, драматургиябезнең йөзен билгеләгән төп юнәлешнең табылуы, ачыклана, конкретлаша баруы. Бүгенге драматургларның күзәтү, тикшерү объекты — кеше. Бүгенге көннең катлаулы кешесе, аның уй-фикерләре, тормышка актив мөнәсәбәте. Аерым бер вакыйганы мавыктыргыч сюжетка салып сөйләп бирүгә караганда, кеше турында сәхнәдән сөйләве — шактый катлаулы. Ләкин безнең бүгенге драматургларның көче моңа җитәрлек. Җиң сызганып тагын да ныграк эшләргә генә кирәк. Ни әйтсәк тә, бүгенге заман кешесе каршында драматурглар әле бурычлылар, бүгенге көн герое, хезмәт кешесе безнең әсәрләрнең түрендә хуҗа булып утырмый әле. Шуңа күрә театрлар вакыт-вакыт ул геройны эзләп прозага, тәрҗемә пьесаларга мөрәҗәгать итәләр.

Эшләнәсе эшләр турында сүз барганда, безгә профессиональ осталыгыбызны күтәрү өлкәсендә туктаусыз уйланырга кирәк. Бүген моннан унбиш-егерме еллар элек язган кебек язарга ярамаганны кайберләребез һаман да аңлап җиткерми. Кешеләрнең, тормышның интенсив үзгәрүен әйтеп тормастан, кечкенә генә бер фактка күз салыйк. Заманында драма әсәрләре биш әр пәрдәле булганнар. Аннан дүрткә, өчкә калган. Хәзер ике пәрдәле пьесалар языла. Хәтта бер пәрдәле әсәрләрне зур театрлар куйгалый. Бу — тиз үтеп китә торган мода гына түгел. Моның төбендә закончалык ята. Чөнки бүгенге тамашачы сүз боткасы тыңларга яратмый, бер җөмлә үзенең саллылыгы, фикернең тыгызлыгы белән ун җөмләне алыштырырга тиеш. Икенчедән, бүгенге режиссерлар, артистларның күбесе югары белемле осталар. Алар — автор сүзен ничек язылган шулай кабатлаучылар түгел.

Димәк, бүгенге көн драматургиясен билгели торган икенче фактор — җыйнаклык, фикер тыгызлыгы. Шулай булгач, безгә әсәрләребезне караучы тамашачыдан, безнең пьесаларыбызны куйган режиссерлардан, уйнаган артистлардан белем ягыннан да, осталык ягыннан да, гражданин буларак та түбән торырга ярамый. Бүгенге заманның төп проблемаларын тотып алып, шуны сәнгатьчә чишә алмаган драматургка авыр бүген.

Ләбибә Ихсанова

# МАТУРЛЫК ҺӘМ БАТЫРЛЫК ДӨНЬЯСЫНДА

Моңа кадәр Татарстан язучыларының бер генә съездында да балалар әдәбияты турында аерым доклад куелганы юк иде. Татар әдәбияты кебек, зур традицияле, бай тарихлы әдәбиятның балаларга караган өлкәсендә дә соңгы елларда күп кенә әсәрләр язылды. Балалар әдәбиятының да күзгә күренерлек уңышлары, үз проблемалары, хәл ителәсе мәсьәләләре бар. Болар барысы да балалар әдәбияты турында аерым тукталып сөйләшү кирәклеген көн тәртибенә куйды.

Соңгы елларда балалар язучылары безнең әдәбиятка яңа темалар, яңа геройлар алып килделәр. Әдәбият дөньясына яңа исемнәр өстәлде. Дөрес, башка жанрларда эшләүчеләр кебек, балалар язучылары Союзга дистәләп кабул ителмәде. Ике съезд арасында бары тик Зәкия Туфайлова, Хәкимҗан Халиков, Гарәфи Хәсәнов һәм Миргазиян Юныс кына член итеп алынды. Алты елга дүрт кеше күп түгел. Балалар әдәбиятына язучылар акрын һәм азлап килә.

Бу өлкәнең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Шуңа күрә теләсә нинди язучының, хәтта ул бик талантлы булса да һәм олылар әдәбиятында зур

уңышы белән эшләсә дә, балалар өчен китап яза алмавы мөмкин. Язучыга баланың уй-фикерен, холкын-гадәтен, аның тормышын яхшы белү генә җитми, аның үзенең дә бала кебек самими, тиз ышанучан, мавыгучан, күзәтүчән булуы кирәк, шул чагында гына ул катлаулы вакыйгаларны да, кешеләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне дә бала булып кичерә, аларга бала күңеленнән чыгып карый һәм олы кеше булып бәя бирә ала. Шушы сыйфатларга ия булганда гына ул балаларга үтемле, кызыклы китаплар язарга мөмкин. Чөнки олылар әдәбиятындагы кебек үк, балалар язучылары да әсәрләрендә үз җаннарын, эчке дөньяларын чагылдыралар. Язучы әсәрләрендә бала булып кыланмасын, ә баланың нәкъ үз характерын бирә алсын өчен, аның күңелендә, җанында балалык сыйфатларының беркадәре сакланган булырга тиеш. Белинский, нәкъ менә шул сыйфатларны күздә тотып, балалар язучысы булып туарга кирәк, дип әйткән дә.

Бәхеткә каршы, балалар телендә сөйләшә белгән язучыларыбыз элек-электән шактый булган. Нәниләр өчен үлмәс әсәрләр калдырган Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовларга ук китмичә, утызынчы еллар әдәбиятыннан Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Мирсәй Әмир, Нәкый Исәнбәт кебек язучыларны искә алу да җитә. Алар, олы әдәбиятның талантлы вәкилләре булу белән бергә, балалар өчен «Кара борынның дусты», «Джим», «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Калку кырга кар ява», «Рөстәм маҗаралары» кебек әсәрләр бирделәр. Иҗатларын гел балалар әдәбиятына гына багышлаган язучыларыбыз да булмаган түгел. Абдулла Алишның сокланкгыч әкиятләре, Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы», «Каланча»сы, Дәрҗия Аппакова хикәяләре, Абдулла Әхмәт пьесалары, Әминә Бикчәнтәева һәм Җәвад Тәрҗемановның нәниләр өчен язган шигырьләре балалар әдәбиятының ныклы нигезен тәшкил иттеләр. 30нчы еллар татар балалар әдәбиятының гөрләп үсеп киткән, әдәбият мәйданында тулы канлы тормыш белән яшәгән чоры булды.

Илленче елларда хәл бераз үзгәрде. Беренчедән, Ватан сугышы кырларыннан Абдулла Алиш һәм Кави Хәмит кебек танылган балалар язучылары һәм дистәләгән яшь каләмнәр кайтмады. Бари Рәхмәт, Дәрҗия Аппакова, Әнәс Карилар иҗатларының иң активлашкан вакытында, балаларга бирәсе бик күп китапларын яза алмый, безнең арадан китеп бардылар. Шул елларда әдәбиятка килгән өч-дүрт язучы гына бу югалтуны тутыра алмады. Икенчедән, балалар әдәбиятында булып алган авангардизм, коры дидактика һәм иллюстрациячелек чире татар балалар әдәбиятының үсешенә дә сизелерлек зыян ясады.

Алтмышынчы еллардан башлап, бигрәк тә соңгы елларда, әдәбиятыбыз күтәрелеш чорын кичерә башлады. Хәзер безнең төрле яшьтәге балалар өчен төрле жанрларда эшләүче авторларыбыз бар. Аларның язу стильләре төрле-төрле, һәм күбесенең яхшы өйрәнгән, яратып яза торган темалары бар. Шәүкәт Галиевнең үзе мәзәк, үзе акыллы шигырьләрен, Шамил Рәкыйповның Бөек Ватан сугышы геройлары тормышыннан язган повестьларын, Адлер Тимергалинның маҗаралы китапларын, Миркасыйм Госмановның фәнни-популяр әсәрләрен, Гаптелхәй Сабитовның мәктәп, пионер тормышына багышланган хикәяләрен, Роберт Батуллинның әкиятләрен, Зәкия Туфайлова, Хәкимҗан Халиковның нәниләр өчен язган шигырьләрен генә искә алсак та, язучыларыбызның иҗат йөзләре никадәр төрле икәнен күрәбез. Балалар өчен язылган китапларыбыз хәзер рус, украин, казакъ, эстон, үзбәк, чуваш, мари һәм башка милләт телләренә тәрҗемә ителә.

Әдәбият — тәрбия коралы. Балалар әдәбияты укучыларда гражданлык тойгылары һәм эстетик зәвык тәрбияләргә тиеш. Бу — бик җаваплы бурыч. Чөнки бала матур әдәбият китапларын характеры формалашкан елларда, дөньядагы һәм яхшыны, һәм яманны зиһененә, канына тиз сеңдерә торган вакытта укый. Мондый яшьтә балада әдәби геройларга ышану көчле була. Көчле характерлы кешеләр, гадәттән тыш вакыйгалар һәм маҗаралар бала күңелен тиз җәлеп итә. Шуңа күрә дә алар сугыш һәм хезмәт геройлары турындагы талантлы китапларны йотлыгып укыйлар. Мондый әсәрләр балада патриотлык хисләре тәрбияләүдә зур урын тота.

Язучылар соңгы елларда партия һәм Ватанга мәхәббәт темасын, коммунистик әхлак һәм табигатьне саклау мәсьәләләрен җитди итеп күтәрделәр. Утызынчы еллардан башлап, татар балалар әдәбиятына илебезнең көрәш юлын, үсеш этапларын чагылдырган әсәрләр гел өстәлә торды. Соңгы елларда язучылар Ленин темасын да кыюрак күтәрә башладылар. Бу исә язучыдан юлбашчының бөеклеген яңа яктан ачып бирерлек зур белем, фәлсәфи фикер һәм әдәби осталык таләп итә. Ленин темасына язган авторлар арасында Нури Арсланов, Габдрахман Минский, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова кебек талантлы язучыларның булуы куандыра. Бу авторларның хикәя һәм поэмаларында Ленин исеме үзебезнең республика җирендә барган вакыйгаларга, халыклар дуслыгына, тынычлыкка бәйләп языла.

В. И. Ленин беренче революцион чыныгуны Казанда ала, аның беренче сөрген урыны — Кокушкино. Шул ук Кокушкино Ленинның балалык истәлекләре белән дә бәйле. Шунлыктан татар балалар ленинианасына кергән әсәрләрнең байтагы юлбашчының бала вакытына багышланган булуы бик табигый.

Н. К. Крупская, Ленинның балалык шуклыкларын язып артык мавыкмаска, күбрәк аның революцион көрәшче булып формалашу моментларын бирергә, дигән иде. Мостафа Ногманның «Кокушкино таңнары» поэмасында, Габдрахман Минскийның «Чын дуслар» һәм Рафаил Төхфәтуллинның «Давыл чәчәге» хикәясендә Володяның Ушнә суында балык тотуы, Апакай малайлары белән ат сакларга йөрүе, төрле уеннар уйнавы турында гына язып канәгатьләнүләре дә мөмкин иде. Ләкин алар үзләренең бурычларын киңрәк аңлаганнар һәм, нәкъ Надежда Константиновна әйткәнчә, Ленинның бала вакыттан сыйнфый каршылыкларны күреп үсүенә, шул нигездә туган күп сорауларга җавап табарга омтылуына басым ясаганнар. Бу язучыларның һәркайсы Володяда, сизелер-сизелмәс кенә булса да, беренче революцион аң чаткылары кабына башлавын үзләренә хас формалар аша балаларга җиткерә алдылар. Нури Арслановның «Җилкәнче» поэмасында вакыйгалар алга таба үстерелә, автор революция корабын җиңүләргә илтүче юлбашчының беренче революцион адымнарын сурәтли.

Ленин темасы республикабызның үсешенә багышланган китапларда, Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләрдә һәм, ниһаять, бүгенге балалар тормышыннан язылган проза һәм поэзия китапларында дәвам иттерелә. Болар барысы да Бөек Җилкәнче идеяләренең тантанасы турында язылган әсәрләр.

Узган ел институтка керү сынаулары барган көннәрдә бер абитуриент белән сөйләшеп торырга туры килде. «Республикабызның үсеш юллары» дигән темага сочинение язуын әйтте ул. Син бу теманы шулай яхшы беләсеңмени? дип сорыйм. «Канатлар кая илтә?» дигән китап ярдәм итте, болай гына ачкан идем, кызык булып китте, укып чыкканны сизми дә калдым, ди. Бик кадерле вакытыңны бүлеп укырлык кызыксыну уяткан һәм сиңа рухи азык биргән китап бәхетле китап ул. Гариф Ахуновның бу китабы Казанда һәм Мәскәү балалар нәшриятында күп тиражлар белән басылып чыкты. «Канатлар кая илтә?» китабы — балалар публицистикасының иң уңышлы үрнәкләреннән берсе. Рафаэль Мостафинның «Герой шагыйрь эзләре буйлап» китабы да шундый бәхетле язмышка дучар булды. Исеменнән үк күренгәнчә, бу китап Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең ил алдында гражданлык һәм патриотлык бурычларын үтәүләре турында.

Әмма болар әле балалар публицистикасының беренче карлыгачлары гына. Республикабызның революцион тарихы, бүгенге казанышлары, фән, сәнгать эшлеклеләре һ. б. турында бик күп китаплар язарга мөмкин. Бу мәсьәлә балалар өчен публицистик әсәрләр бирергә сәләтле авторларны уйландырырга тиеш.

Укучыларда илгә мәхәббәт, патриотлык хисләре тәрбияләү юнәлешендә Шамил Рәкыйпов күп эшләде. Ул элегрәк бөртекләп җыйган архив материаллары нигезендә очерклар яза иде. Соңыннан бу материалларны повестьлар язганда файдаланды. Моны әдәби материалның зуррак формалар таләп итүе дип кенә түгел, язучының әдәби

осталыгы үсә төшүе дип тә кабул итәргә кирәк. Соңгы биш елда Шамил Рәкыйповның татар һәм рус телләрендә «Кызлар — йолдызлар», «Кайда син, Жан?» «Таңнар һаман матурмы?» кебек зур күләмле документаль повестьлары басылып чыкты. Аның геройлары — Казан трамвайчысы Иван Кабушкин, атаклы очучылар Ольга Санфирова һәм Мәгубә Сыртланова, Гыйльфан Батыршин һәм Иван Чернопятколар. Тормышны, якты дөньяны чын ярату белән яраткан һәм шушы бөек мәхәббәтләре хакына, матур тормышның иминлеге хакына һәлак булган геройлар алар. Шамил Рәкыйпов әсәрләрендә геройларның шушы сыйфатын ышандырырлык итеп бирә алган.

Балалар сугыш турындагы китапларны укырга гомумән яраталар. Аларны көрәш һәм батырлыклар романтикасы әсир итә. Батырларның бала вакытларын, бай тормыш юлларын да күрсәткән әсәрләр исә кызыксынуны икеләтә арттыра. Гадәттә бик үк дөрес булмаган бер караш яши: янәсе, көтелмәгән хәлләр алдында калса, кискен бер карарга килергә кирәк булса, теләсә кем батырлык эшли. Хәлбуки, батырлык кинәт тумый. Кеше күңеленә бала вакыттан ук салынган әйбәт сыйфатлар үсә-үсә билгеле бер вакытта аны герой итә. Шамил Рәкыйпов әсәрләрендә әзлекле рәвештә шушы фикерне үткәрергә тырыша. Моның беренче чагылышын без авторның Бари Шәвәлиев турындагы повестенда күргән идек. «Кайда син, Жан?» китабында исә бу фикер ачыграк, әдәби яктан нигезләнгәнрәк детальләр ярдәмендә җиткерелә. Казан малае Иван Кабушкинның характеры, гражданнар сугышы елларында атасыз калган күп балаларныкы кебек үк, авыр формалаша. Ләкин аның ялгышулары әчке тупаслыктан, явызлыктан түгел, бары тик тормышны кыенлык белән төшенүдән, кешеләрне таный белмәүдән килә. Тормыш каршылыкларын җиңеп үскән, эшчеләр коллективында чыныгу алган егетнең Бөек Ватан сугышы елларында илбасарларга каршы батырларча көрәшеп һәлак булуы һәм шул батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелү Иван Кабушкин биографиясенең логик үсеше һәм кульминацион ноктасы буларак кабул ителә. Үзенең әсәрендә автор менә шуны ышандырырлык итеп бирә алган.

Кешенең ныклыгын сугыш кына сынамый. Һәркемнең тормышы катлаулы каршылыклар белән тулы. Шул шартларда үзеңнең дөньяда яшәвеңне раслау һәм яхшы яктан раслау үзе бер батырлык ул. Андый каршылыклар унөч-ундүрт яшьлек малай алдында торганда, бу бурыч бигрәк тә авырая. Балалар әдәбиятында бу проблема әхлак темасына язылган әсәрләрдә күтәрелә. Барлас Камаловның яңа китабы «Язгы күкрәү» дип атала. Бик әйбәт семьяда үскән, бик әйбәт укучы, бик акыллы малай Нурзат башына кинәт килгән авырлыклар аңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итә. Нурзатның иң якын кешесе, идеал итеп табынганы әтисе була. Нурзат үзе дә әтисе кебек уңган, гадел, яхшы күңелле кеше булып үсәргә тели. Ул яхшы укый, спорт белән шөгыльләнә, космонавт булырга хыяллана. Кинәт бу бәхетле семьяга кара кайгы килә. Суга баткан кешене коткарганда малайның яраткан әтисе һәлак була. Күп тә үтми, әнисе чит бер кешене йортка кертә. Бер кайгысыз яшәгән малай башына бере арты бере ишелеп бәхетсезлек килә. Күтәрә алырмы ул аны?..

Аяз Гыйләҗевнең «Кызлар хатлары» повестендагы Раушания дә шундый ук хәлне кичерә. Тик аны үз кайгысы түгел, яшьтәше Лenaның хәсрәте тетрәтә. «Бер Лenaның гына тормышы челпәрәмә килмәде ич, бу кара вакыйгадан соң безнең дә, аның дусларының да күңел тирәнлегендә башкаларга ышану тетрәде, гомер онытылмаслык җәрәхәт эзләре сызылып калды», ди повесть герое.

Барлас та, Аяз да тормышны әле рәтләп белмәгән, белсә дә, күбрәк аның әйбәт якларын гына күргән, тормыш турында дәресләрдән, уку китапларыннан алган мәгълүматлар буенча гына фикер йөрткән, буыны ныгып өлгермәгән үсмер баланың гомерендә беренче тапкыр катлаулы мәсьәләләр алдында калуын сурәтлиләр. Бәхеткә каршы, һәр ике автор, геройның ныклыгын күрсәтәм дип, вакыйгаларны юри катлауландырмыйлар, яки геройларын кызганып, чынбарлыкта булган кыен хәлләр алдына куюдан курыкмыйлар, каршылыкларны йомшартып бирмиләр.



*Балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов, яшь прозаик Мәгъсум Хәбибуллин.*

Әмма бер хакыйкатьне укучының исенә төшереп торалар: нинди генә әйләнеч, хәтәр сукмаклардан барсаң да, ышанычлы юлдашларың булганда, якты зур аланга килеп чыгасың икән ул. Ике автор да үзләренең әсәрләрендә менә шушы фикерне раслыйлар.

«Кызлар хатлары» повестеның төп вакыйгалары урта мәктәпне бетереп, ВУЗга керергә әзерләнеп йөргән Раушаниянең кайчандыр бергә ял иткән дусларыннан килгән хатларны, аларның әле пионер вакытларында язган хатларын, укуга бәйләп сурәтләнә. Бу алым авторга хат авторларын үсештә бирү өчен кирәк. Бу алым һәрбсрсе үзенчә омтылыш белән яшәгән, үзенчәлекле характерлы, үзенчәлекле язмышлы кызларның пионер чакларын һәм инде буй җиткән көннәре яңадан күеп карау өчен җайлы. Шунысы куанычлы, Аяз аларның пионер чакларын да, җиткән кыз вакытларын да яшьләренә хас детальләр белән күрсәтә алган.

Барлас Камалов «Язгы күкрәү» повестенда бер ел эчендә булган хәлләрне сөйли. Геройларның язмышы шул вакыйгалар фонында ачыла. Бу кыска гына вакыт эчендә аларның төс-буйлары да, яшь үзенчәлекләре дә әллә ни үзгәрми. Әмма эчке үзгәреш сизелә. Укучы балаларның дөньяга карашлары җитдиләшә баруын, аларның рухи яктан олыгая төшүләрен тоя.

Ләкин Барлас Камаловка кайбер очракларда образларны сурәтләүдә төгәллек җитеп бетми. Ул вакыт-вакыт геройларының яшь үзенчәлекләрен, аларның үзләренә хас сөйләм телләрен онытып җибәрә. Барлас — сәләтле язучы, балалар өчен дә яхшы әсәрләр бирергә мөмкинлекләре булган әдип. Ә менә героен ахырынача өйрәнеп, төшенеп җитмәү аркасында, бу тәҗрибәле язучы да кайвакытта ясалмалыктан котыла алмаган.

Мондый төр җитешсезлекләр яшьрәк язучылар иҗатында тагын да ныграк сизелә. Миргазиян Юнысның бик кызыклы, чыгарга бөтен мөмкинлекләре булган «Занзибар зәңгәр диңгезләр артында» дигән повестена да шундый җитешсезлекләр хас. Моннан берничә еллар элек Миргазиян Юныс, океаннар гизгәндә күргән-белгәннәрен кыланмыйча, төчеләнмичә язып, яшь укучының да, өлкәннәрнең дә игътибарын яулаган иде. Сүз дә юк, әдәбиятка үзенчәлекле, зур белемле, дөнья күргән кеше килде. «Занзибар зәңгәр диңгезләр артында» повестенда ул көньяк суларында йөзгән совет диңгезчеләренең тормышын сурәтләү белән матур гына башлап китә.

Әсәрнең буеннан-буена килгән кызыклы идеясе сиземләнә: балаларның ерак җирләргә китәргә ашкынуы, дөньяны авыллары янындагы тау башыннан гына түгел, ерак диңгезләргә китеп күрергә теләүләре һәм авыл малайларының соңыннан шушы балалык хыялларына ирешүләре.

Кызганычка каршы, автор бу якны тиешенчә биреп җиткерә алмаган. Әсәрдә балаларның характерын ачарлык кызыклы вакыйгалар бар. Ләкин алар, диңгез уртасындагы утрау кебек, бер-береннән аерым торалар, алга таба үстерелмиләр, повестьның төп идеясен ачарга җитәрлек хезмәт итмиләр. Мәсәлән, малайларның ат сараенда күргәннәре, браконьерларны фаш итеп йөрүләре, ындыр табагындагы маҗаралар кебек вакыйгаларның кайберләрен төшереп калдырганда, ә калганнарын төп вакыйгага ныграк бәйләп, тиешенчә үстереп биргәндә әсәрнең композицион бөтенлеге көчәя генә төшәр иде. Барлас Камалов кебек үк, Миргазиян да балаларның яшен төгәл генә ачыклап бирә алмаган. Бер караганда, алар 7—8 яшьлек бала тәэсирен калдыралар, икенче караганда, ак сакаллы карт кебек фикер йөртәләр.

Китапның бик самими, тормышчан язылган урыннары бар. Алар бигрәк тә повестьның ерак сәяхәтләргә омтылуны сурәтләгән битләрендә ачык күренә. Автор үзе кичергәннәрне, үз йөрәгеннән үткәннәрне балаларга балалар телендә, әмма җитди итеп әйтә алган. Бу урыннар авторның балалар өчен яза алуын күрсәтә. Ләкин Миргазиян бу әсәрендә тормышчанлыкны, ихлас күңеллелекне ахырга кадәр саклый алмаган.

Бала характерын төшенмәгән, аның күңелен аңлый алмаган, бала башыннан үткән хәлләрне үзе дә бала булып күңеленнән кичерергә сәләтсез авторларның китапларында исә ясалмалык, бала булып кылану үзен аеруча нык сиздерә. Рәкыйп Шәйхетдинов «Мәхмүт кая бара?» повестен язганда изге бер теләкне күз алдында тоткан. Начар укучы, тәрбиясез бер малайның иптәшләре ярдәмендә төзәлә бару процессын, файдалы эшләр эшли алуын күрсәтергә теләгән.

Әсәрнең сюжет сызыгы, схемасы мондый. Мәктәпкә килгән яңа укытучы тәрбиясез балаларны яхшы мөгамәлә белән кулга алырга тели. Аларның өйләренә йөри, алай да булмагач, начар малайларны стена газетасына язып тәнкыйтьлиләр, ветераннар белән очраштыралар. Нәтиҗәдә начар балалар төзәлә, әйбәт укый башлыйлар, колхозчыларга булышалар.

Миңа шушы нәрсәләрне психологик тирәнлектә ача белмәү аркасында повесть схематик булып чыккан. Билгеле, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның барысы да тормышта булырдай хәлләр. Балаларның авыру хатынга булышып йөрүләре дә, спекулянт Җамалины фаш итүләре дә бик мөмкин. Хикмәт шунда, бу мәсьәләләрне хәл итүдә балаларның роле ни дәрәҗәдә? Һәрхәлдә, аларның роле өлкәннәрнекеннән дә зуррак булмаска тиеш иде. Чаманы югалту яхшы гына уйланылган әсәрне дә ясалмалыкка алып килгән. Автор үзе тасвирлый торган вакыйгаларны әдәби факт дәрәҗәсенә күтәрә алмаган. Ә кайбер вакыйгалар исә башка әсәрләрдә сурәтләнгән нәрсәләрнең йомшак вариантлары гына булып чыккан. Бер генә мисал: Мәхмүтләрнең тимурчылар командасы, яшерен штаб ясыйбыз дип, авыл читендәге җимерек өйне рәтлиләр. Ишегенә «Тимурчылар штабы» дип язып та куялар. Бөтен кешенең күз алдындагы бу өйнең серлелеге юкка чыгуын укучы искә дә алмасын, ди. Ләкин моның Гайдар әсәренә бик уңышсыз ияру икәнен ул шунда ук төшенәчәк. Гайдарның тимурчылары үзләренең штабларын чарлакта ясаганнар икән, шәһәр читендәге дачаларда шуннан да аулак урын булмаганга ясаганнар. А. Гайдар әсәрендә караңгы почмаклар, җимерек подваллар романтикасының эзе дә юк. Штабның сере дә әсәрнең ахырына кадәр ачылмый кала. Гайдар тимурчыларының эшләре, уеннары, аларның төсе-бите, холкыфигыле, уе-фикере шул кадәр тормышчан бирелгән ки, укучылар бу әсәрне шунда ук үз иттеләр, алай гына түгел, автор сурәтләгән вакыйгалар миллионлаган балаларны үзенә ияртеп, илдә тимурчылар хәрәкәте дигән хәрәкәтне тудырды. Кырык елга якын инде ул балалар арасында яшәп килә. Төрле җирләрдә аның төрле яңа формалары туды. Тырышып эзләнсә, балалар дөньясын ныклап өйрәнеп, чын-чынлап

иҗат газабы кичерсә, Р. Шәйхетдинов та аның үз республикабызда булган формаларын таба алыр иде. Кызганычка каршы, бу очракта да ул уңышсыз иярүче генә булып калган. Шул уңай белән рус язучысы Борис Пильнякның гыйбрәтле бер сүзен искә төшерәсе килә. «Әтәч булып кычкыра белгән актер балаларны шаккаттыра. Әгәр инде балалар актер үзе түгел, аның итәк чабуы астында чын әтәч кычкырганын белеп алсалар, алар мондый актерны куралмас хәлгә киләләр. Чөнки ул балаларны да, үзен дә алдаган булып чыга. Ә балалар алдауны кичерә алмыйлар», ди ул.

Балалар үзләре турында язылган китапларны аеруча зур таләпчәнлек белән укыйлар. Балалар дөньясына багышланган әсәрләрдә язучының осталыгы да, «гөнаһ»лары да ачык күренә. Мәктәп темасына язылган китапларның, пионер тормышын сурәтләгән әсәрләрнең бик аз язылуы шуннан да килмиме икән әле? Ике съезд арасында Гариф Галиевнең «Күңелле хикәяләр», Хәләф Гардановның «Су астында сукмаклар»ы, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Атадан бала яшь кала», Газиз Мөхәммәтшинның «Саумысез, аккошлар», Газиз Нәбиуллинның «Яшел эстафета» исемле әсәрләре һәм Рәкыйп Шәйхетдинов, Аяз Гыйләҗев, Миргазиян Юныс, Барлас Камаловларның югарыда телгә алынган повестьлары һәм тагын берничә шигырь китабы гына бүгенге көн балалар тормышыннан алып язылган. Алты елга бу күп түгел. Ә бит укучыларның үз яшьтәшләре, пионер лагерьларында ял итүчеләр, спорт ярышларында катнашучылар, колхозчыларга булышып йөрүчеләр, космонавт булырга хыялланучылар, командир булырга әзерләнүчеләр турында әйбәт китапларны укыйсылары килә.

Әкият шикелле мавыгып укырлык кызыклы маҗараларга корылган, балаларга табигать гүзәллеген, туган як матурлыгын күрсәтеп биргән китаплар да язылды бу елларда. Гәрәфи Хәсәновның «Унике матур», «Җирем-суым», Марс Шабаевның «Салда сәяхәт», Газиз Мөхәммәтшинның «Саумысез, аккошлар» повестьлары, Ренат Харис, Энҗе Мөэминоваларның кошлар һәм агачлар турындагы шигырь китаплары әнә шундыйлар.

Г. Мөхәммәтшинның «Саумысез, аккошлар» повесте Гайдарның «Ерак илләр» әсәрендәге романтиканы хәтерләтә. Автор Ык буеның матурлыгына нәкъ балаларча сокланып, әз генә хыялга да бирелеп яза бу әсәрен. Язучының хыялы чынбарлыктан аерылмаган, ул хәтта хыял да түгел, авторның бары тик берничә ел алга каравы гына. Повестьта сурәтләнгән вакыйгаларның бүген булмаса иртәгә тормышка ашачагына бик рәхәтләнеп ышанасың. Повестьтагы яктылык, күтәренкелек, укучы күңеленә дә күчеп, аны сөенеч белән тутыра, аның рухын баета.

Соңгы елларда татар балалар әдәбиятында юмористик әсәрләрнең матур үрнәкләре шактый күренде. Татар балалар әдәбиятының алтын фондына керерлек әсәрләрне алтмышынчы елларда мәрхүм Бари Рәхмәт язып калдырган иде. Шәүкәт Галиев, аның традициясен дәвам иттереп, ике съезд арасында зур уңыш белән эшләде. Балалар поэзиясендәге уңышлары өчен 1972 елда Шәүкәт Галиевкә Тукай премиясе бирелү татар балалар әдәбиятының зур уңышы булды. Бу вакыйга хөкүмәтебезнең, республикабыз җәмәгатьчелегенең, язучылар коллективының балалар әдәбиятына зур игътибары, аның уңышларын тану билгесе дә иде. Шәүкәт Галиев — балалар өчен күп язучы, яхшы язучы автор. Ул классик язучыларның, балалар әсәрләре мавыгып укырлык һәм белем дә бирерлек булсын, дигән таләпләрен истә тотып эш итә. Аның күп шигырьләрен укучылар күңелдән беләләр, Шәүкәт тудырган Шәвәли образы татар халык әкиятләрендәге Шомбай, Шүрәлеләр кебек, укучылар арасында йөри. Ул аз сүз, кыска юллар, кечкенә штрихлар белән бөтен бер образны гәүдәләндерә ала.

> Башыңны ник эшләтмисең?
> Онытылган, өйдә калган.

Һәр сорауга механик җавап бирергә гадәтләнгән, уйларга иренүчән, ялкау малайның характерын моннан да остарак итеп сурәтләргә мөмкинме?

Хәкимҗан Халиков, Зәкия Туфайлова, Мәхмүт Газизов, Җәүдәт Дәрзамановларның иҗатында да матур табышлар күп. Бу өлкәдә бигрәк тә Хәкимҗан Халиков белән Зәкия Туфайлова уңышлы эшли. Идрис Туктар,

Вахит Монасыйпов, Гәрәй Рәхимнәрнең кечкенәләр өчен язган хикәяләреннән балаларга хас тапкырлык, шаянлык бөркелеп тора. Аларның нәни геройлары кайчагында үзләре көлке хәлләргә калалар, кайвакытта хәйләкәрлекләре белән укучыны таң калдыралар. Рөстәм Мингалимовның үзенә генә хас язу алымы бар: вакыйганы гади генә сөйләп килә дә шигырьнең ахырында бер хикмәт чыгарып куя. Шуның белән һәркемгә таныш вакыйганың бөтенләй яңа ягын ачып бирә. Мәхмүт Газизовның татар халык иҗатына тартым шигырьләре авторның зур мөмкинлекләре барлыгына өмет уята. Саҗидә Сөләйманова һәм Энҗе Мөэминовалар сирәк язсалар да, уңышлы гына әсәрләр бирәләр. Заһидә Гомәрованың самими шигырьләре белән әдәбиятта күренә башлавына байтак вакыт үтте, ул уңышлы гына китаплар да чыгарып өлгерде. Ләкин соңгы вакытта шагыйрә иҗатында күтәрелеш күренми. Ул бер дәрәҗәдәге, бер төрле шигырьләр язып канәгатьләнә башлады. Бәлки аның Казан, Әлмәт, Чаллы кебек әдәбият үзәкләреннән ерак яшәве, каләмдәшләре белән сирәк аралашуы моңа сәбәптер. Ә менә Казанда яшәүче Марзия Фәйзуллинаның әдәбияттан читләшүе сәеррәк. Вакытында «Ике йөрәк», «Чебиләр», «Айны кем йоткан» кебек әйбәт шигырьләр яза алган Марзия соңгы бер-ике ел эчендә бөтенләй язмас булды. Ул балалар әдәбияты секциясе утырышларында катнашмый, каләмдәшләре белән аралашмый. Коллективтан читләшү авторга файда китермәде.

Балалар әдәбиятында күренгән һәр авторны газета-журнал редакцияләренең, китап нәшриятының хуплап каршы алуы күңелле хәл. Соңгы елларда Роза Хәлиуллинага да шундый яшел урам ачылды. Тик авторга әйтергә кирәк: шигырьнең мәгънәсенә, фикер логикасына күбрәк игътибар итсен иде. Юкса, аның шигырьләре колакка ятышлы, әмма фикер ягыннан буталчык булалар. Резеда Вәлиева — күп кенә китаплар авторы, үзе белгән, үзе кичергән нәрсәләр турында ул матур гына шигырьләр иҗат итте. Соңгы вакытта Резеда зур формалар белән мавыга башлады. Әмма поэмаларын, әкиятләрен тормышның үзен өйрәнеп



*КамАЗ төзүчесе А. Филимонов та әдәби сөйләшүне зур кызыксыну белән тыңлый.*

түгел, әдәбияттан алган белемне файдаланып язды. Бу исә авторга уңыш китермәде.

Хәзер әкиятне гомумән күп яза башладылар. Бигрәк тә яшь каләмнәр әкият язу белән мавыга. Күрәсең, алар моны җиңел эш дип уйлыйлар. Балалар әдәбияты секциясе үзенең утырышларында күп кенә авторларның әкиятләрен тикшерде. Әмма уңышлы дип табылганнары аз булды. Бу хәл балалар язучыларын борчымый калмады, әлбәттә. Алар секция утырышларының берсендә балалар әкиятләре турында зур сөйләшү куелырга тиешлеген әйттеләр.

Безнең халык иҗатыннан килгән бай мирасыбыз бар. Шуның өстенә татар балалар әдәбиятында яңа төр әкиятләргә нигез салган, үзе дә гүзәл әкиятләр иҗат итеп калдырган Абдулла Алишыбыз бар. Әхмәт Фәйзинең бал корты, Җикмәргән һәм болан кызы турындагы онытылмас әкиятләрен беләбез. Үз вакытында Җәвад Тәрҗеманов

та бал кортлары, тукран малае Шуктуганнар турында матур әкиятләр язды. Әкиятчеләребезгә кайдан, кемнән өйрәнергә дип аптырап йөрисе юк. Тик шушы традицияләрне үстереп, алга таба дәвам итүче әкиятчеләребез генә күренми, әкиятләр языла, әмма уңышлылары аз була. Авторлар әкиятләрдәге вакыйгаларны яхшы һәм яман көчләрнең тартышына, яхшыларның начарларны җиңеп чыгуына коралар. Тормыш проблемаларын бары шушы мотивка гына кайтарып калдыру бертөрлелеккә китерә, бер-беренә охшаган, бер ананың игез балалары сыман әкиятләр дөньяга туа. Шуның өстенә аларда көрәш моментлары рәтләп ачылмый, яисә логик яктан акланмый. Хәйдәр Гатинның «Сылучәчәк һәм Алкояш» әкиятендә Суыкбай белән Алкояш арасындагы көрәш турында сүз бара. Әкияттәге явыз көч Суыкбай Сылучәчәкне кыерсыта, аны үтерергә теләп, үзенең кар бураннарын җибәрә. Алкояш исә Суыкбайны җиңеп, Сылучәчәкне коткарырга тиеш. Ләкин автор бер нәрсәне истән чыгарган, ә бураннар бит калын кар катлаулары китерә. Кар астында Сылучәчәк тереклеген дәвам итә, җылынып ята. Халык та карлы, буранлы кышларны ярата. Шулай булгач, Алкояш Суыкбайга нигә кизәнә соң әле? Алар арасындагы көрәш нигә кирәк булган?..

Соңгы елларда Роза Хафизованың Кураймалай һәм Талчыбыкларның маҗаралары турында бере арты бере ике китабы чыкты. Бу әкиятләрдәге вакыйгалар да явыз һәм яхшы көчләрнең үзара көрәшләре тирәсендә бара. Геройларның кара урманда күргәннәре дә, су асты патшалыгында кичергәннәре дә, суыклар илендәге маҗаралары да — барысы да бер үк мотивка корылган вакыйгаларның төрле вариантлары булып чыккан. Бу вакыйгаларны тагын шулай уннарча вариантта кабатларга мөмкин. Әмма моңа карап кына Талчыбык белән Кураймалайның образын баетырлык башка бернинди сыйфат та өстәлмәс иде. Ә бит татар халкының мәкерле Шүрәлесе, тапкыр Шомбае, хәсрәтле Айсылуы бер-берсенә һич тә охшамаган, төрле мотивларга корылган әкиятләрнең батырлары алар.

Әсәрнең уйлап җиткерелгән ачык фикере, төзек композициясе булмау аның стиль бөтенлегенә дә зыян иткән. Автор халык әкиятләре стилен дә, язучылар тарафыннан тудырылган, табигатьне таныш-белүгә корылган әкиятләр стилен дә файдаланырга тырышкан. Хәтта чын реаль тормышка кайтып калган урыннар да бар. Кураймалайның җиденче сәяхәтен сурәтләгән битләр, мәсәлән, нәкъ шундый. Тормыштагы теләсә нинди әйберне җанландырып, геройларны төрле кыен хәлләргә куеп кына әкият язып булмый. Бу эшкә нинди максат белән тотынуыңны да уйларга кирәк.

Әкият җыр кебек яңгырарга тиеш. Ул, укудан бигрәк, сөйләү өчен языла. Югары әдәби осталыкка ия булган авторлар моңа аеруча әһәмият бирәләр. Хәтта рифмалап язылган әкиятләр дә бар. Мәсьәләнең бу ягына безнең әкият язучыларыбыз да әһәмият бирергә тиеш булсалар да, әле моңа ирешкәннәр дип әйтеп булмый. Образлар да бер укыганда истә калырлык итеп коелмыйлар.

«Кураймалай»ның беренче сәяхәтендә шушындый бер урын бар:

«Шул чак сафларның башында нәни генә ике арба күренде. Арбаларның берсе яшел, тәгәрмәч урынында ике баш суган. Икенчесе ап-ак, тәгәрмәчләре коңгырт таш. Һәр ике арба өстендә гаскәр башлыклары утырган. Шырпылар башлыгының кул-аяклары шырпыдан ясалган, башы йоп-йомры күкерт ташы. Күзләре елкылдап янып тора. Ә суганнар хуҗасының кул-аяклары кыяк суганнан тора, башы йоп-йомры баш суганнан ясалган. Анысының да күзләре бар». Әдәби осталык җитмәү аркасында, әлеге тәфсилле тасвир гади информациягә әйләнеп кала. Ә бит Дагстан шагыйре Нуретдин Юсуф, күгәрченне сурәтләү өчен, аяклары кызыл, түше күгелҗем дип тормаган. Ут тоткан да: «...очты-очты да салават күперен алып муенына чолгады»,— дип әйткән.

Балалар әсәрләрендәге тел кытыршылыкларына мисалларны төрле әсәрләрдән, бигрәк тә яшь һәм башлап язучыларның китапларыннан күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Әмма мин аларны Барлас Камаловның нигездә әйбәт язылган «Язгы күкрәү» әсәреннән алырга телим. Чөнки Барласның теле үзенең җитешсезлекләре белән дә

башкалардан аерылып тора. Бу игътибарсызлыктан, я булмаса телне сиземли белмәүдән килгән җитешсезлек түгел. Ул Барласның телне шулай кабул итүеннән килә. Кайвакытларда автор кирәкмәгәнгә катлауландырып яза, төчеләнә, купшылана башлый. Ул, мәсәлән, «серкәсе су күтәрми» дип кенә калмый, «серкәсенә су тия язды» ди. «Хурлык тотене белән үтәли ысланган», «аякларына дәрт итеп карады», «күңел эчкәресендә җыр кытыгы кузгалды», «кәеф градуслары» кебек гыйбарәләр яшүсмерләрнең образлы уйлау сәләтенә файда китерә алмас, билгеле. Фикеремне раслау өчен, Твардовскийның: «Бик озак вакытлар без әдәби осталыкка икенче дәрәҗәдәге эш итеп карадык. Әсәрләребез эчтәлек ягыннан кешелек өчен кыйммәтле булса, яки тормыш материалының яңалыгы белән аерылып торса, формасының камил булмавын җиңел гафу иттек. Ләкин күптәнге бер хакыйкать һәр вакыт үз көчендә кала: «язучының формага игътибарсызлыгы ахыр чиктә эчтәлеккә игътибарсызлыкка алып килә» дигән сүзләрен искә төшерәсе килә. Тел дә язу осталыгының бер чарасы.

Татарстан язучылар союзы каршында балалар әдәбияты секциясе эшләп килә. Аның утырышларында тәҗрибәле, өлкән буын язучылар һәм күп кенә яшь язучылар катнаша. Биредә теоретик мәсьәләләргә кагылышлы бәхәсләр куела, аерым язучыларның әсәрләре тикшерелә. Шунысы аянычлы, әлеге утырышларда чыгыш ясарлык, гомумән, балалар әдәбиятын әйдәп, күзәтеп барырлык тәнкыйтьчеләр генә юк. Юк дип турысын әйтергә туры килә. Егермеләп Союз члены булган бу өлкәгә бердәнбер балалар тәнкыйтьчесе Фатыйма Ибраһимова гына күз төшереп өлгерә алмый. Алты еллык әдәбиятка газета битләрендә һәм «Казан утлары» журналында бер-ике генә рецензия язылуы шуны күрсәтмимени? Д. Зөбәерованың «Кичер, сөеклем», Б. Камаловның «Күршеләр», Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» повестьлары, Р. Мингалимов, Р. Харисов, Г. Рәхим кебек шагыйрьләрнең китаплары тәнкыйть бәясе алу бәхетенә ирешкән икән, бу бит аларның олылар әдәбиятына бик якын булуыннан гына килә. Балалар язучыларын гына түгел, бала күңелен аңлый белгән, балалар әдәбиятының спецификасы белән хисаплаша торган тәнкыйтьчеләр дә әзерләү мәсьәләсен көн тәртибенә куярга күптән вакыт. Кызганычка каршы, партиябезнең «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте» турындагы карарыннан соң да язучылар Союзы, матбугат органнары һәм югары уку йортлары бу турыда уйланмадылар.

Тәрҗемә турында берничә генә сүз. Соңгы вакытларда татар балалары өчен тәрҗемә китаплары чыгару кирәкмеюкмы дигән сүзләр дә йөрде. Бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү элек-электән килгән яхшы гадәт. Соңгы елларда төрле милләт язучыларының үзара очрашулары күбәеп китте. Балалар язучылары СССР һәм РСФСР язучылары союзы идарәләренең Мәскәү, Махачкала, Минск, Куйбышев, Төмән һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән пленумнарында катнаштылар. Хәзер без берберебезнең әсәрләрен яхшы беләбез. Әсәрләребезнең иң яхшыларын, Мәскәүдә чыкканнарын көтеп ятмыйча да, тәрҗемә итешеп бастыра алабыз.

Без үз китапларыбызның төрле телләрдә басылып чыгуы белән горурланабыз. Ә бит шул ук украин, үзбәк, молдаван, чуваш, мари язучыларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп чыгарсак, ике халыкка да бик матур бүләк булыр иде. Бәйрәм ашы кара каршы, ди татар халык мәкале.

...Ике съезд арасында иҗат ителгән әдәби продукциянең барын да бергә җыеп күз салганда, язучыларыбызның шактый ук актив эшләүләре күренә. Без инде татар балалар әдәбияты республикабыз чикләрендә генә калмыйча олы әдәбият мәйданына чыга башлады дип әйтә алабыз. Ә бу хәл бездән, балалар язучыларыннан, тагын да зур җаваплылык тоеп иҗат итүне сорый.

## Рафаэль Мостафин

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

КПСС Үзәк Комитетының партиягә, совет халкына мөрәҗәгатендә турыдан-туры безгә, социалистик культура хезмәткәрләренә, адресланган сүзләр бар:

**«Совет кешеләренең тормышын баетырлык рухи хәзинәләр тудырырга!»**

Шул рухи хәзинәләрне тудыруда әдәби тәнкыйтьнең роле нинди соң? Күптән түгел көндәлек матбугат битләрендә җанлы әдәби процесста тәнкыйтьченең урыны хакында кызу бәхәсләр булып узды. Берәүләр тәнкыйтьче ул, әдәби процесска өстән карап, тыныч кан һәм гаделлек белән әдәбият әсәрләренә хөкем чыгаручы судья, дигән карашны алга сөрделәр. Икенче кешеләр тәнкыйтьче, яңа әсәрләрнең мәгънәсен аңлата һәм аларны пропагандалый-пропагандалый, әдәбият белән укучы арасында элемтә урнаштырырга ярдәм итә-итә, әдәби процессның артыннан барырга тиеш, дип карадылар. Өченче берәүләр исә, тәнкыйтьченең бурычы алдан, әдәби процессның авангардында барудан гыйбарәт, диделәр. Боларның һәркайсында күпмедер дөреслек булса да, берсе белән генә дә тулысынча килешеп бетеп булмый. Әдәби тәнкыйтьнең урыны әдәби хәрәкәтнең алдында да, артында да түгел, ә аның үз сафларында. Әдәби тәнкыйть — совет әдәбияты дип йөртелгән мәңге яшел, мәңге үсештәге агачның бер тармагы, тәнкыйтьче исә — әдәби тормышның тулы хокуклы бер члены. «Бәя куючы», «аңлатып бирүче» генә дә түгел, ә чын иҗатчы, эстетик байлыклар тудыручы. Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Писарев хезмәтләре, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ә. Фәйзи мәкаләләре кебек әсәрләр иҗат итүче...

Шул ук вакытта тәнкыйть әдәбиятның башка җанрлары арасында аерым урын алып тора. Бөтен әдәбиятның идея-сәнгать дәрәҗәсен тәнкыйть билгели дип уйлау урынсыз кыюлык һәм үз көченә артык ышану булыр иде Талантның, бигрәк тә даһиның кайчан туачагын алдан планлаштырып булмый һәм тагын да яхшырак, күчлерәк әсәрләр язарга чакыру белән дә мәсьәлә әллә ни үзгәрмәячәк. Халык бик дөрес әйткәнчә, «бал, бал, бал» дип күпме генә тәкърарлама, моңардан авызда бал тәме булмаячак. Әмма әдәби әсәрләр хакында җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру, тулы канлы, талантлы әсәрләр иҗат итәргә булышырлык иҗат атмосферасы булдыру тәнкыйтькә бәйле. Шул рәвешчә, тәнкыйть бөтен әдәби хәрәкәтнең уңышларын уртаклаша, кимчелекләре өчен җавап бирешә.

Татарстан язучыларының VII съездыннан соң узган елларга күз ташласак, күрербез: тәнкыйтьчеләр кул кушырып тик утырмаган. Бу вакыт эчендә Казанда, Мәскәүдә, илебезнең башка шәһәрләрендә әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә караган 60 тан артык яңа китап, 8 библиографик белешмә, татар әдәбияты буенча күп кенә дәреслекләр һәм кулланмалар, йөзләрчә тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр, аннотацияләр басылган. Тәнкыйтьчеләр әдәбиятыбызның уңышлары белән горурлана алалар, шуның белән бергә, татар совет әдәбиятындагы кимчелекләр, ялгышлар һәм күңелсез хаталар өчен үзләрен гаепле итеп тә сизәргә тиешләр.

Соңгы елларда тәнкыйть мәсьәләләренә аерым игътибар бирергә этәргән мөһим бер вакыйга булды. 1972 елның гыйнварында КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» махсус карар кабул итте. Партиянең XXIV съезды трибунасыннан әйтелгән фикерләрне органик төстә дәвам иттереп һәм үстереп, бу карар соңгы еллардагы бөтен әдәби хәрәкәткә тирән эз салды. Партия безнең кулга казанышларыбызны һәм кимчелекләребезне үлчәргә яраклы, озак елларга исәпләнгән һәм киң хәрәкәт программасы бирде. Карар бер нәрсәне ачык күрсәтте, партия әдәби тәнкыйтьне халык һәм



*Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин белән язучы Юрий Белостоцкийның әңгәмәсе бик җитди, күрәсең.*

партия карашларын яклый торган, җәмгыятьнең эстетик аңына юнәлеш бирерлек, иҗаттагы алдынгы тенденцияләрне вакытында күреп алып яклап чыгарлык, чит идеология күренешләренә, халтурага һәм кәсепчелеккә кискен отпор бирерлек реаль көч дип саный.

Әлеге карардан соң ике елдан артык вакыт узды. Әдәби тәнкыйть өлкәсендәге нindидер тирән, мөһим үзгәрешләр хакында сөйләү өчен бу күп вакыт түгел. Әмма мәгълүм бер үзгәрешләр күз алдында. Әйтик, 1971 елның ахырларына кадәр «Казан утлары» журналында елына күп дигәндә 5—6 тәнкыйть мәкаләсе чыгып барган булса, 1972 елда 14, ә 1973 елда 20 дән артык мәкалә басылган. Әгәр 1972 елда Татарстан китап нәшрияты әдәбият белеме һәм тәнкыйтькә караган 2 генә китап (гомуми күләме 21 табак чамасы) чыгарган булса, 1973 елда гомуми күләме 60 табак чамасындагы 4 китап, 1974 елда гомуми күләме 75 табактан артык 6 китап чыгарды. 1975—76 елларда тәнкыйть китапларын тагын да күбрәк чыгару күздә тотыла. Республикадагы башка матбугат органнары да тәнкыйтькә игътибарны сизелерлек яхшырттылар. «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарының бу юнәлештәге эшен аерым билгеләп үтәсе килә. Һәр ике газета атна саен әдәбият һәм сәнгатькә багышланган махсус сәхифә биреп бара. Безнең республика партия газеталарының уңай тәҗрибәсен хәзер илебезнең башка өлкә һәм республикаларында да үзләштереп киләләр.

Боларның һәммәсе Үзәк Комитет карарыннан соң тәнкыйтьчеләрнең үз эшчәнлекләрендә генә түгел, тәнкыйтьнең ролен һәм иҗтимагый бурычларын аңлау юнәлешендә дә уңай үзгәрешләр барлыкка килүе хакында сөйли. Тәнкыйть ул, барыннан да бигрәк, әдәби процесс белән партия җитәкчелеген тәэмин итә торган корал бит. КПСС Үзәк Комитеты карарының әһәмияте берничә ел белән генә чикләнми. Әлеге карар яктылыгында татар тәнкыйте һәм әдәбият белеменең ике съезд арасындагы бөтен хәле ачык күренә.

Республикада әдәби тәнкыйть фикерен үстерү мәсьәләләре Татарстан язучылар союзы идарәсе, партия оешмасы һәм матбугат органнарының даими игътибар үзәгендә булды. Татар совет тәнкыйтенең торышы Язучылар союзы партия оешмасының 1971 елның ноябрь

аенда уздырылган ачык җыелышында каралды. Сүз анда тәнкыйть һәм бүгенге әдәби процесс, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть, яңа китапларга рецензияләр язу, әдәби бәхәсләр уздыру кебек иң төп, хәлиткеч мәсьәләләр турында барды. Партия җыелышы һәм СССР Язучылар союзы идарәсенең 1972 елның 28 январь карарлары нигезендә Татарстан язучылар союзы идарәсе, тәнкыйть секциясе белән берлектә, әдәби тәнкыйтьне үстерү буенча күп төрле чаралар билгеләде. Әлеге план буенча Татарстан китап нәшриятында әдәби тәнкыйтькә һәм әдәбият белеменә караган китаплар чыгаруны нык арттыру, газета һәм журнал редакцияләре каршында танылган тәнкыйтьчеләр исәбенә авторлар коллективы булдыру, күренекле тәнкыйтьчеләрне һәм әдәбият галимнәрен дәреслекләр һәм кулланмалар язуга тарту һәм башка төрле эшләр күздә тотылган иде. Ахырдан тәнкыйть секциясе җитәкчесе бу планның ничек үтәлеше хакында язучыларның гомуми җыелышында отчет ясады.

1971 елдан «Казан утлары» журналы иң яхшы тәнкыйть мәкаләләре өчен махсус премия булдырды. Аеруча сугышчан һәм үткен язылган мәкаләләргә бирелеп килгән бу премия тәнкыйтьчеләрнең кыен һәм авыр хезмәтен стимуллаштыруда шулай ук уңай роль уйнады. Дөресен әйтергә кирәк, әгәр эзлекле төстә тормышка ашырылсалар, конкрет практик чаралар иртәмесоңмы уңай нәтиҗәләрен бирми калмыйлар. Әйтик, моннан ун еллар элек, тәнкыйть секциясенең инициативасы белән, безнең республикада беренче тапкыр әдәби ел йомгаклары уздырылган иде. Соңга таба әлеге җыелышлар рәсми төс алды һәм ел саен уздырыла торган иң мөһим бер чарага әйләнде. Шунысы аеруча игътибарга лаек, аерым жанрлар (проза, поэзия, драматургия, балалар әдәбияты, тәнкыйть, очерк һәм публицистика) буенча ясала торган докладлар әдәби хуҗалыгыбызның торышына төпле бәя бирү белән генә чикләнеп калмадылар, алар бик тә мөһим булган тәнкыйть жанрының — әдәби күзәтүләрнең үсү һәм формалашуына булыштылар. Ф. Миңнуллинның «Прозаның гражданлык йөзе» (сүз уңаеннан шул кадәресен дә әйтеп китәргә кирәк, мәкалә «Казан утлары» журналының махсус премиясенә лаек булды), Н. Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика — хәрәкәттә», Ф. Әгъзамовның «Чорның елъязмасы» дигән мәкаләләре, җитди проблемалар күтәргән күп кенә башка мәкаләләр әдәби ел йомгакларында ясалган докладлар нигезендә тудылар.

Безнең тәнкыйтьнең соңгы елларда җанлана төшүен тагын бер факт күрсәтә. Татарстан китап палатасы мәгълүматларына караганда, 6—7 ел элек Татарстан китап нәшрияты чыгарган һәр биш китапның берсе генә рецензия күреп барган булса, 1972 елда инде һәр ике китапның берсенә рецензия язылган. Сүз дә юк, бу да әллә ни мактанырлык күрсәткеч түгел, чөнки безнең нәшрият чыгарган китап продукциясенең яртысы һаман әле рецензияләнми кала килгән. Әгәр инде ил күләмендә барлык китап продукциясенең 10—15 проценты гына рецензияләнә баруын исәпкә алсак, бу — алай ук аз да түгел.

Бердәнбер калын журналыбыз «Казан утлары»ның тәнкыйть бүлеге үзенең эшен сизелерлек яхшыртты. «Литературное обозрение» журналының быелгы беренче санында басылган баш мәкаләдә тәнкыйть материалларының сыйфатын яхшыртуга ирешкән өч журнал телгә алына, алар — «Знамя», «Сибирские огни» һәм «Казан утлары» журналлары.

Безнең тәнкыйть, партияле позицияләрдән чыгып, тагын да активрак төстә әдәби процесска тәэсир ясый, укучыларның карашларын, фикер һәм зәвыкларын формалаштыра. Тәнкыйть, социалистик реализмның төп принципларын аклап һәм яклап чыгып, әдәбиятның партиялелек һәм халыкчанлык принципларын актив һәм эзлекле төстә тормышка ашырырга булышты. Бу әдәби тәнкыйть өлкәсендә бөтенесе эшләнгән, борчылырга урын юк, дигән сүз түгел, әлбәттә. КПСС Үзәк Комитеты карарында әдәби тәнкыйть совет әдәбиятының үсеш процессларын тиешле дәрәҗәдә тирән өйрәнми, сәнгать күренешләрен халык тормышы белән бәйләп карый белми, дип күрсәтелде. Бу сүзләр тулысы белән татар тәнкыйтенә дә карый. «Марксистик-ленинчыл эстетика традицияләрен үстерә барып, совет әдәбият тәнкыйте идея ягыннан булган бәяләрнең төгәллеген, социаль

анализның тирәнлеген эстетик таләпчәнлек, талантка сак, игътибарлы караш, нәтиҗәле иҗади эзләнүләргә сак мөнәсәбәт белән бәйләп алып барырга тиеш», диелә карарда. Бу фикер дә җитди әһәмияткә лаек. Шуңа күрә аңа киңрәк, тәфсиллерәк тукталырга рөхсәт итегез. Сүз биредә нигездә тәнкыйтьнең методологик принциплары хакында бара. Идея ягыннан булган бәяләрнең тирәнлеге, социаль анализның тирәнлеге... Бу таләпләргә тулы җавап бирү өчен, тәнкыйтьче тормышны язучыдан да ким белмәскә, ул социолог, философ, экономист һәм тарихчы да булырга тиеш. Шуның белән бергә, ул җаны белән художник булырга, әдәбиятны яратырга һәм нечкә зәвыклы кеше булырга тиеш. Бары шул чагында гына ул эстетик таләпчәнлекне талантка сак, игътибарлы мөнәсәбәт белән бәйләп бара алачак. Әле утызынчы елларның башларында ук язылган мәкаләләрнең берсендә Ә. Фәйзи болай ди:

«Бездә тәнкыйть берьяклы гына булмасын. Гадәттә безнең тәнкыйтьчеләргә язучының уңышы түгел, ә аның кимчелеге каләм тотып язарга «илһам» бирә... Менә моннан тәнкыйтьнең язучыларга әлеге төрле ярлык тагып утыру кебек берьяклылыгы килеп туа. Тәнкыйть, киресенчә, язучының бөтен ягын үлчәп бәя бирә торган, аңардагы актив һәм пассивның принципиаль дөрес учеты булырга тиеш. Тәнкыйтьче язучының (бигрәк тә яшь язучының) кимчелеген бик тиз күреп ала белгән кебек, аның җитешлеген — кечкенә җитешлеген дә күреп, эләктереп ала белергә тиеш».

Күренекле әдипнең бу сүзләре бүген дә актуаль яңгырый, ул елларда исә алар аеруча урынлы булган. Чыннан да, ул елларда чыккан тәнкыйть мәкаләләре белән танышканда бәхәсләрнең кискенлеге, фикерләрнең кырыс һәм рәхимсез булуы гаҗәпкә калдыра. Шуның белән бергә, вульгар социологизм позицияләреннән торып, тупас һәм дәлилсез төстә туздырып ташлаулар да аз булмаган.

Еллар узу белән мондый берьяклылыктан акрынлап котылдык. Тәнкыйть язучы хезмәтенә хөрмәт белән карарга, объектив һәм тынычрак тонда язарга өйрәнде. Әмма, шуның белән бергә, безнең тәнкыйтькә икенче бер кимчелек — чамасыз мактау, җитешсезлекләргә искитмәү чире үтеп керде. Чын мәгънәсендәге талантлы китаплар турында да, төссез, талантсыз әсәрләр хакында да бер төрле тон, еш кына бер төрле үк фразалар белән яза башладык. Мактамаган да, тиргәмәгән дә, төссез-чырайсыз рецензияләр язу гамәлгә керде. Андый рецензияләр белән танышкач, аптырап каласың, сүз яхшы китап турындамы, әллә начар китап турында барамы, автор нинди дә булса яңа сүз әйтә алганмы, әллә күптән билгеле хакыйкатьләрне кабатлау белән чикләнәме — берни аңлашылмый.

Мин һич кенә дә безнең бөтен тәнкыйтьне тешсезлектә гаепләргә җыенмыйм. И. Нуруллин татар прозасында зур урын алган күпсүзлелек хакында чын борчылу һәм ачыну белән язды. Поэма жанры һәм җыр текстлары өлкәсендәге кимчелекләрне Н. Юзиев ифрат кискен итеп һәм принципиаль төстә күтәрде. Г. Халит, Т. Галиуллин, М. Мәһдиев, Ф. Миңнуллин кебек тәнкыйтьчеләрнең, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ш. Маннур кебек язучыларның туры сүзле, гадел фикерле мәкаләләре истә калган. Әмма ни генә булмасын, комплиментарлык дигән нәрсә безнең тәнкыйтьтә дә шактый киң таралган иде. Моңа төрле бәйрәмнәр уңае белән язылган мәдхияләр нык ярдәм итте. Аерым язучылар менә шундый чамасыз мактау һәм мәдхияләргә шул кадәр ияләшеп киттеләр, матбугат битләрендә әйтелгән кечкенә генә тәнкыйть сүзен дә шәхси һөҗүм итеп кабул итә һәм югары инстанцияләргә жалобалар язарга гадәтләнеп киттеләр. Билгеле, моның өчен бер тәнкыйтьчеләрне генә гаепләргә ярамый. Еш кына язучылар үзләре үк бер-берләренә булган таләпчәнлекне нык киметтеләр, каләмдәш дусларының урта кул әсәрләрен дә «күренекле», «талантлы», «искиткеч» кебек эпитетлар белән күмеп ташладылар (мин Б. Камалов, М. Садри кебек язучыларның кайбер мәкаләләрен күздә тотам). КПСС Үзәк Комитеты карары нәкъ менә шундый чыгышларга каршы юнәлдерелгән иде. Бу карар комплиментарлыкны, чамасыз мактауны кискен төстә гаепләп чыкты һәм бездән эшлекле, принципиаль, объектив тәнкыйть хезмәтләре язуны таләп итте.

Үзәк Комитет карарыннан соң бу юнәлештә дә күпмедер алга китеш сизелә. Агымдагы тәнкыйтебез, таләпчәнлекне талантка игътибарлы мөнәсәбәт белән чиратлаштыра барып, әдәбият күренешләрен бәяләү эшенә таләпчәнрәк, объективрак төстә якын килә башлады. Тәнкыйтьчеләр, матбугат органнары иҗади бәхәсләр, карашлар бәрелеше һәм полемикадан курыкмаска өйрәнеп киләләр. 1972—73 елларда «Казан утлары» журналында барган сөйләшү, мәсәлән, шул хакта сөйли. Бүгенге проза мәсьәләләренә багышланган бу сөйләшүгә төрле буын тәнкыйтьчеләр һәм язучылар катнашты. Алар соңгы елларда дөнья күргән бик күп әсәрләргә төпле анализ ясадылар, татар совет прозасының бүгенге хәленә һәм үсеш тенденцияләренә караган мөһим мәсьәләләрне кузгаттылар. Бәхәс үткен һәм туры сүзле күп кенә мәкаләләр язылуга сәбәпче булды. Дөрес, ул озынгарак сузылды һәм таркаурак чыкты, аңа эзлеклелек һәм максатка юнәлгәнлек җитеп бетмәде.

Вульгар социологизм заманнарында киң таралган кимчелекләрдән тәнкыйть уңышлы төстә арынып килә. Шуның белән бергә, 60 еллар азагында һәм 70 еллар башында башка характердагы берьяклылык көчәя башлады. Без хәзер, дөрес эстетик позицияләрдән торып, әдәби форма турында сөйләргә өйрәндек. Шул ук вакытта әле сәнгать күренешләре артында реаль тормыш мәсьәләләре торуын күрмибез, алар хакында тирәнтен фикер йөртә белмибез. Соңгы еллар тәнкыйтенә әйбәт мәгънәсендәге социальлек җитми.

Үзәк Комитет карарында укучыларны интернационализм рухында тәрбияләүдә, социалистик милләт әдәбиятларының бердәмлеген ныгытуда, төрле әдәбиятларның бер-берләренә булган йогынтысын үстерүдә әдәби тәнкыйтькә зур роль йөкләнә, диелә. Совет әдәбият белеме, тулаем алганда, бу яктан нык алга китте, бу өлкәдә зур уңышларга иреште. Партиянең кешеләрнең тарихи яңа гомумилеге булган совет халкы турындагы, совет кешесенең гомум милли горурлыгы турындагы тезисы эстетик фикерне тагын да баета төште, безнең әдәбиятның интернациональ рухын көчәйтте. Бу юнәлештә безнең республикада да күпмедер алга китеш бар. 1973 елның язында башкалабыз Казанда өлгергән социалистик җәмгыятьтәге милли әдәбият һәм сәнгатьләрнең үзара йогынтысын һәм бер-берләренә тәэсир ясавын өйрәнүгә багышланган фәнни-теоретик конференция булды. Конференция кызыклы һәм нәтиҗәле узды, алга таба уйлану һәм гомумиләштерүләр ясау өчен бай материал бирде. Бу — беренче адымнар гына дип уйларга кирәк. Киләчәктә әлеге юнәлештәге эзләнүләр, һичшиксез, дәвам иттерелергә һәм үстерелергә тиеш. Алай гына да түгел, хәтта үз әдәбияты турында сүз алып барганда да тәнкыйтьче бөтен ил күләмендәге әдәби процессны күз алдында тотарга тиеш. Бөтен ил күләменнән торып фикер йөртү — бүгенге тәнкыйтькә аеруча кирәкле һәм аның позицияләренең ныклыгын билгели торган төп нәрсә әнә шул. Ил күләмендә барган әдәби процессларны аңлау һәм белеп тору, тугандаш әдәбиятлардагы яңалыклардан хәбәрдар булу тәнкыйтьчегә үз әдәбиятының казанышларын һәм йомшак якларын ачыграк күрергә, критерийлар мәсьәләсендә төгәлрәк булырга мөмкинлек бирә.

Бездә чыккан күпчелек тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләрнең төп кимчелеге шунда, аларда теге яки бу әдәби әсәр еш кына гомуми процесстан аерым, аңа бәйләнешсез хәлдә карала. Ләкин бүгенге укучы үз язучыларыбызның әсәрләрен уку белән генә чикләнми, ул Ч. Айтматов, К. Симонов, Р. Гамзатов, А. Твардовский, К. Кулиев, М. Кәрим һәм башка бик күп, бик күпләрнең иҗаты белән дә танышып бара бит. Ул чагыштыра, янәшә куеп карый ала. Һәм җирле, тар критерийлардан гына чыгып эш итүче тәнкыйтьче мондый укучының абруен казана алмаячак.

Дөрес, бездә гомум союз югарылыгында торган әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр дә аз түгел. Мисал төсендә И. Нуруллинның «Өлгергәнлеккә юл» («Путь к зрелости») исемле монографиясен атарга була. Авторның мәгърифәтчелек реализмы хакындагы фикерләре бөтен ил күләмендә яңгыраш тапты. Филология фәннәре докторлары Х. Госман, Г. Халит һәм Й. Нигъмәтуллиналарның хезмәтләре тирән һәм төпле язылган булулары белән аерылып

торалар. Н. Юзиевның «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык», «Шигырь гармониясе» дигән хезмәтләре һәм бигрәк тә «Хәзерге татар поэтикасы» исемле китабы татар совет әдәбият фәне өлкәсендә зур вакыйга булды. Тирән һәм катлаулы фәнни мәсьәләләрне гади һәм аңлаешлы итеп яза белү, авторның әдәбиятка мәхәббәте, әдәбият үсешенең иң хәлиткеч мәсьәләләре белән кызыксынып яшәве һәм киң эрудицияле булуы — бу хезмәтләрнең төп уңай сыйфатлары әнә шулар. Н. Юзиев хезмәтләренә Тукай премиясе бирелү — бигрәк тә күңелле факт. Тукай премиясе беренче мәртәбә әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәткә бирелә, бу — безнең тәнкыйтьнең иҗади өлгерүе һәм җитлегүе хакында сөйли, бу — кайчандыр иң артта сөйрәлгән әдәбият белеме алгы планга чыгып килә, дигән сүз.

Дөрес, тәнкыйтьчеләребезнең җирле матбугатта үзләрен бик шәп яктан күрсәткәннәре дә бөтен союз аренасына кыюсызрак чыгалар. Хәзер әдәби тәнкыйтьнең яңа плацдармы — «Литературное обозрение» журналы бар. Әмма, бер-ике чыгышны исәпләмәгәндә, безнең тәнкыйтьчеләр анда басылмыйлар диярлек. «Литературная газета» һәм «Литературная Россия» битләрендә, шулай ук башка үзәк матбугат органнарында безнең тәнкыйтьчеләр сирәк күренә. Ә бит шагыйрьләрнең, прозаикларның һәм драматургларның китаплары бөтен союз аренасына елданел күбрәк чыга бара. Дөрес, ул китапларның күбесе зур таләпләр югарылыгыннан торып һәм күп милләтле совет әдәбиятының гомуми үсеше белән бәйләп тикшерүне сорый. Тәнкыйтьчеләрнең бөтен союз аренасына чыгулары, татар совет әдәбиятындагы яңалыкларны пропагандалаудан тыш, аларга таләпләрне киметмичә, бөтен союз тәнкыйтенә хас булган принципиаль положениеләргә таянып фикер йөртергә мөмкинлек бирер иде.

Безнең тәнкыйтьчеләр хезмәтендәге иң йомшак урын (мин агымдагы газета-журнал тәнкыйтен күздә тотам) — әдәбиятның үсеше закончалыкларын күрә һәм аларга төпле бәя бирә алмау. Әгәр аерым әсәрләргә артык юмарт, яки, киресенчә, артык түбән бәя бирелә икән, бу тәнкыйтьнең өлгереп җитмәгән булуы хакында сөйли. Аерым жанрларның үсеше һәм төп закончалыкларын ачыклау эше исә тагын да начаррак тора. Дөрес, бездә теге яки бу аерым жанрларны өйрәнүдә специальләшкән тәнкыйтьчеләр бар (Т. Галиуллин, әйтик, даими төстә поэзия өлкәсендәге яңалыкларны күзәтеп бара, Ф. Мусин бүгенге проза мәсьәләләре, Б. Гыйззәт белән А. Әхмәдуллин драматургия хакында язалар), ләкин алар язган мәкаләләргә еш кына тирәнлек һәм объективлык җитеп бетми. Аерым күренешләр арасындагы бәйләнешне тотып алу һәм үсеш перспективаларын күрсәтеп бирү өчен, тәнкыйтьчедә тарихилык хисе булырга тиеш. Заманга игътибар, нечкә зәвык һәм төпле теоретик хәзерлек үткән мирасны белү белән чиратлашырга тиеш, чөнки бүгенге күренешләр үткәннән үсеп чыга, аның логик дәвамы булып тора. Бу яктан караганда, әдәбият белеме белән тәнкыйть арасында үтеп чыкмаслык чикләр юк. Кагыйдә буларак, әдәбият күренешләренә иң төпле һәм тирән бәяне әдәбият галимнәре бирә. Шулай булгач, безгә алга таба да тәнкыйтьчеләрнең галим, ә галимнәрнең актив тәнкыйтьче булуларын теләргә кала.

Бүгенге әдәбият буш урында үсеп чыкмаган. Шуңа күрә үткәндәге культура күренешләренә кимсетеп карау тегеләйме-болаймы бүгенгегә китереп суга, бүгенге әдәбият үсә торган базаны тарайта, аның традицияләрен ярлыландыра. «Хәрәкәттәге эстетика — хәрәкәттә» исемле мәкаләсендә Н. Юзиев бу хакта бик дөрес яза.

Безнең әдәбият фәне узгандагы культура мирасын өйрәнүдә мәгълүм уңышларга ирешә. Г. Тукай (И. Нуруллинның күп кенә мәкаләләрен һәм китапларын телгә алырга мөмкин), Һ. Такташ (Г. Халитның «Шагыйрь, герой, чор» исемле монографиясен искә төшерегез), М. Җәлил, Г. Ибраһимовлар (М. Хәсәновның рус һәм татар телләрендә чыккан капиталь хезмәтләре аерым игътибарга лаек) иҗаты турында кызыклы хезмәтләр бар. Татар әдәбиятының биш томлык тарихын язу гамәлгә ашырылып килә. Әмма, шул ук вакытта, безнең әдәбият белеменең тапталган юллардан атлавын, күптән билгеле исемнәр белән генә чикләнеп килүен дә билгеләп үтми булмый, әдәбият тарихының аерым чорлары, әдәбият та-



*Өлкән буын әдипләр Хәмит Ярми, Афзал Шамов, Габдрахман Минский.*

рихында билгеле бер эз калдырган язучылар иҗаты тигез өйрәнелми.

Соңгы елларда безнең тәнкыйть язучыларның индивидуаль йөзен, кабатланмас үзенчәлеген өйрәнү эшенә күбрәк игътибар бирә башлады. Әдәби портретлар жанрының беркадәр җанлана төшүе, татар язучыларының иҗатына багышланган күп кенә монографияләрнең басылып чыгуы әнә шул хакта сөйли. Әйтик, 1968—73 еллар арасында гына да шундый 16 монография язылган. Алар арасында М. Гафури, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Бурнаш кебек классик әдипләр иҗатына һәм И. Гази, Ф. Хөсни, С. Хәким, Г. Әпсәләмов кебек бүгенге язучыларга багышланганнары да бар. Югарыда телгә алынган монографияләрнең яртысы рус телендә язылган. Бу — татар язучыларының иҗаты рус укучыларын да кызыксындыра дигән сүз һәм моны уңай факт дип билгеләп үтми булмый. Тагын шул кадәресе куандыра, татар язучылары турындагы монографияләр хәзер Казан белән Мәскәүдә генә түгел, Чиләбе шәһәрендә дә (Н. Альтов. «Муса Җәлилнең яшьлеге».), Уфада да (Р. Паль. «Ахырга кадәр барам».) һәм илебезнең башка шәһәрләрендә дә чыгып килә.

Шулай да, аерым очракларны искә алмаганда, татар язучыларының иҗатына багышланган монографияләрнең шактый төссез һәм бертөрле стильдә язылуларын билгеләп үтәргә туры килә. Ул китапларның композицион төзелешләре дә хәтта ике тамчы су кебек бер-берсенә охшаган була (кереш, язучының биографиясе, иҗатына күзәтү ясау һ. б.). Авыр тел, фәнни булырга тырышу, корылык һәм формальлек укучыны биздерә генә. Безгә язучы иҗаты, әдәбият турында матур һәм образлы итеп, әдәби итеп язарга вакыт. А. Толстой, тәнкыйтьчедә художник темпераменты булырга тиеш, дип язган. Ихтимал, нәкъ менә шуңа күрәдер укучылар язучылар каләме белән язылган мәкаләләрне яратыбрак укыйлар. Еллар узу белән андый мәкаләләрдән әдәби процессны тирәнрәк һәм төгәлрәк аңларга, гади укучыны иҗат эшенең серләре белән таныштырырга ярдәм итәрлек һәм әдәбият сөючеләрнең эстетик зәвыгын тәрбияли торган кызыклы җыентыклар төзелә. С. Хәкимнең «Үз тавышың белән», М. Әмирнең «Үзебез турында», Г. Ахуновның «Әдәби язмышлар» дигән җыентыклары шул төркемгә карый. Ә. Фәйзинең «Әдипнең эрудициясе» исемле китабын без һәммәбез шатланып каршы алдык.

Узган съездларда без еш кына ачыну һәм әрну хисләре белән аннан-моннан әвәләнгән чи әсәрләр, халтура

әсәрләр хакында сөйли идек. Бүген без зур канәгатьләнү белән әйтә алабыз: соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты үзе чыгара торган китап продукциясенең сыйфатын сизелерлек яхшыртты, нәшриятка килгән кулъязмаларны рецензияләү эшенә аеруча квалификацияле, уйлап эш итәргә яратучы тәнкыйтьчеләрне һәм язучыларны тарта башлады. Әчке рецензентларның фамилияләрен күрсәтеп бару да билгеле бер роль уйнады, дияргә була. Сүз дә юк, бу чараларның һәммәсе ачыктан-ачык халтурага каршы кискен көрәш ачарга ярдәм итте. Ләкин төссез, соры китаплар, кызганычка каршы, хәзер дә еш басыла. Күрәсең, хәзер безнең тәнкыйть үзенең төп көчен нәкъ шундый китапларга — тыштан карагандa чын әдәбият әсәрләрен хәтерләткән, әмма укучының җанына да, аңына да берни өсти алмый торган әсәрләргә каршы юнәлдерергә тиештер.

Башка жанрлардагы кебек үк, әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә даими төстә яңару процессы бара. Узган алты ел вакыт эчендә әдәбият турында язылган мәкалә һәм рецензияләре белән әдәби хәрәкәткә актив катнашып килгән өлкән буын тәнкыйтьчеләрнең кайберләре элекке темпларын шактый сүлпәнәйттеләр. Берәүләре (мәсәлән, Н. Гыйззәтуллин) бөтенләй язмый башлады, икенчеләре әдәбият белеменә күчеп бетте (Х. Госман, Г. Кашшаф, Г. Халит һ. б.). Сүз дә юк, узган мирасны өйрәнү дә бик мөһим һәм кирәкле эш. Ләкин тәнкыйтьче инде актив эшчәнлектән, бүгенге әдәби процесстан читләшә икән, бу, минемчә, әлеге иптәшләрнең гражданлык хисләре сүрелүе турында сөйли.

Ике съезд арасындагы еллар эчендә Т. Галиуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Урманчеев, Ф. Мусин, Ф. Хатипов, Ш. Әхмәдуллин, М. Вәлиев кебек яшь һәм урта буын тәнкыйтьчеләр үсеп чыкты. Матбугат битләрендә талантлы тәнкыйтьче И. Ахунҗановның нык уйланып һәм төпле итеп язылган рецензияләре яңадан күренә башлады. Күптән түгел Союзга кабул ителгән тәнкыйтьче һәм галим Ә. Кәримуллин библиография өлкәсендә уңышлы эшләп килә. Яңа исемнәр һичшиксез бар, шулай да тәнкыйть өлкәсенә килүче яшьләр саны һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Яшьләрнең күбесенә иҗат активлыгы җитми. Бер-ике уңышлы мәкалә яки рецензия язуга алар ничектер тынып калалар. (Мин И. Саттар, М. Маннурова, Р. Лотфуллин кебек иптәшләрне күздә тотам). Ә бит үзен тәнкыйтькә багышларга уйлаган кеше даими төстә эшләргә, әдәби хәрәкәтнең сулышын тоеп, аның уңышлары өчен сөенеп, кимчелекләре өчен көенеп яшәргә тиеш — шунсыз аңардан чын тәнкыйтьче чыкмаячак. Икенче бер кешедә эшләргә теләк тә, иҗади активлык та бар, ләкин тәнкыйтьче әле үз йөзен табарга, үз концепцияләрен булдырырга өлгермәгән була. Ахыр чиктә андый тәнкыйтьче я күренеп торган йомшак әсәрләрне яклап чыга, я талантлы, тормышчан әсәрләр өстенә ташлана (Ф. Мусинның тәнкыйть эшчәнлегендә мондый хәлләр булгалады). Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Ф. Хатиповның байтак мәкаләләренә һәм рецензияләренә полемик дәрт, кайнарлык җитми.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирелә. Татарстанда бу юнәлештә нидер эшләнә. Әйтик, соңгы 2—3 ел эчендә, Язучылар союзының эш практикасында беренче мәртәбә яшь шагыйрьләр, прозаиклар һәм драматурглар семинары белән бергә, яшь тәнкыйтьчеләр семинары да үткәрелә башлады. Танылган тәнкыйтьчеләр белән очрашу, яшьләрнең беренче мәкалә һәм рецензияләрен җентекләп тикшерү, сүз дә юк, яшь тәнкыйтьчеләрнең әдәби осталыкларын үстерергә нык ярдәм итә. Яшьләр андый семинарларны рәхмәт хисләре белән искә алалар. «Казан утлары» журналы каршында яшь рецензентлар түгәрәге (җитәкчесе Ф. Миңнуллин) эшләп килә. Семинарга йөрүче яшьләрдән М. Вәлиев, Р. Абдулина, Н. Гамбәров, М. Галиевләрнең беренче рецензияләре укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Билгеле, бу гына бик аз. Тәнкыйть кадрлары, беренче чиратта, югары уку йортларында тәрбияләнергә тиеш, ләкин аларда агымдагы тәнкыйть мәсьәләләренә тиешле игътибар бирелми. Алай гына да түгел, хәзергә кадәр татар тәнкыйтенең тарихы үк өйрәнелмәгән. Ә үткәндәге традицияләрне өйрәнми, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди,

Г. Рәхим, Җ. Вәлиди кебек кешеләрнең иҗат эшчәнлеген белми торып, бүгенге тәнкыйтьне үстерү турында сөйләшү файда бирмәячәк. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә җитди игътибар бирүне сорый торган өлгергән мәсьәләләр аз түгел. Шуларның кайберләренә генә тукталып узам.

Беренчесе, балалар әдәбиятындагы тәнкыйтьнең хәле. Балалар өчен чыгарылган китапларның зур күпчелеге тәнкыйть игътибарыннан читтә калып килә. Ике съезд арасындагы 6 ел вакыт эчендә татар балалар әдәбияты турында нибары бер китап дөнья күргән. Мин Ф. Ибраһимованың «Заман белән бергә» дип исемләнгән китабын күздә тотам. Бездә балаларга адресланган китаплар зурлар өчен язылган китапларга караганда да күбрәк басыла, ә бу өлкәдә даими һәм җитди төстә эшләүче тәнкыйтьчеләр юк диярлек.

Икенчесе, әдәбият дәреслекләре һәм кулланмалар мәсьәләсе. Кызганычка каршы, укучының зәвыгын һәм аның эстетик сизгерлеген тәрбияләргә тиешле дәреслекләр фәнни һәм әдәби яктан үзләре дә тиешле югарылыкта язылмыйлар. Дәреслекләрне рецензияләү эше тагын да аянычрак хәлдә. Мәктәп дәреслекләренә төпле бәя бирү өчен әдәби яктан белемле кеше булу гына җитми, билгеле бер педагогик хәзерлек тә, программа таләпләрен белү дә, мәктәп һәм уку йортлары тормышы белән даими бәйләнештә тору да сорала. Бездә бу өлкәдә специальләшкән тәнкыйтьчеләр юк.

Өченчесе, театр рецензияләре мәсьәләсе. Театр рецензияләре гадәти рецензияләр алдына куела торган барлык таләпләргә һәм тагын бер өстәмә таләпкә җавап бирергә — алар зур оперативлык сыйфатына ия булырга тиешләр. Г. Кутуй яңа премьералар уңае белән язылган рецензияләрен икенче көнне үк матбугатта чыгарып барган. Ә бездә алар еш кына премьерадан соң берничә ай вакыт узгач һәм тамашачы әлеге спектакльне онытып бетергәч басылып чыгалар. Дөрес, соңгы елларда И. Илялова, Д. Гыймранова, Р. Усманова, А. Шапиро кебек бу өлкәдә даими эшләүче кадрлар үсеп чыкты. Шулай да яңа рецензияләргә булган ихтыяҗны алар гына канәгатьләндереп җиткерә алмый.

Ниһаять, әдәби тәнкыйть өлкәсендәге тагын бер йомшак участок — ул Татарстанда яшәүче рус язучыларының әсәрләрен рецензияләү. В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе мәгълүматларына караганда, 1968—1973 еллар арасында рус язучыларының төрле характердагы 50 дән артык җыентыгы чыккан. Шуларның унысына гына рецензия язылган. Төрле уку йортларында эшләүче фән кандидатлары, фән докторлары турында сөйләп тә тормастан, Казанда Л. Юдкевич, В. Воздвиженский кебек актив иҗат итүче кызыклы тәнкыйтьчеләр бар. Ләкин алар, нигәдер, рус язучыларының яңа әсәрләрен күрмәмешкә салышалар, тәнкыйть секциясенең эшендә катнашмыйлар. Аларны секция эшенә тарта, кызыксындыра алмаганбыз икән, монда секциянең дә гаебе бардыр, билгеле. Ихтимал, алга таба тәнкыйть секциясе каршында рус тәнкыйтьчеләре группасы төзәргә кирәктер.

Ике съезд арасында тәнкыйть секциясенә җитәкче булып эшләгән кеше буларак, кыскача гына аның эше белән дә таныштырып узыйм. Секциянең бөтен эше Язучылар союзы идарәсе тарафыннан расланган план нигезендә алып барылды. Татарстан тәнкыйтьчеләре СССР Язучылар союзы идарәсенең тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган икенче пленумында, тәнкыйтьчеләрнең 1974 елның январенда уздырылган бөтен союз киңәшмәсендә, РСФСР Язучылар союзының Казан шәһәрендә уздырылган күчмә секретариаты эшендә, әдәбиятта эшче темасына багышлап Тбилисида уздырылган киңәшмәдә һәм ил күләмендә үткәрелеп килгән башка зур киңәшмәләрдә катнаштылар.

Секция утырышларында төп игътибар иҗат мәсьәләләренә бирелде. Соңгы бер-ике ел эчендә генә дә Х. Хисмәтуллин, Ф. Хатипов, Т. Галиуллин, Ф. Урманчеевларның яңа кулъязмалары укып тикшерелде. Авторларга кулъязмаларын камилләштерү юнәлешендә конкрет тәкъдимнәр әйтелде, аерым авторларның китаплары нәшриятка тәкъдим ителде. Секция утырышларында әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрнең яңа чыккан китаплары тикшерелде, теге яки бу тәнкыйтьченең иҗаты нигезендә теоретик мәсьәләләр каралды. Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин-

ның иҗат эшчәнлегенә нигезләнеп, «Тәнкыйть һәм аның агымдагы әдәби процесска тәэсире», Ә. Кәримуллин һәм А. Әхмәдуллин иҗатына нигезләнеп, «Тәнкыйть һәм библиография, аларның үзара бәйләнеше», «Драматургия һәм театр тәнкыйтенең үзенчәлекләре» дигән темаларга зур сөйләшү булды. Тәнкыйтьнең массалар белән бәйләнешен ныгыту юнәлешендә беренче адымнар ясалды. Тәҗрибә төсендә, тәнкыйть секциясе бюросының бер утырышы Теплоконтроль заводында уздырылды.

Күрәсез, аз эшләнмәгән, ә эшләнәсе эшләр тагын да күбрәк. Алда безне зур эшләр, без хәл итәргә тиешле мөһим мәсьәләләр көтә.

## Тихон Журавлев

# РУС ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ИҖАТЫ

Татарстанда яшәүче рус әдипләре елына уртача ике-өч китап чыгарып киләләр. Соңгы елларда дөнья күргән китаплар арасыннан барыннан да элек Геннадий Паушкинның «Чаллы җирендә» («На земле Челнинской») һәм «Кайтыгыз, ләкләкләр» («Вернитесь, аисты») дигән ике китабын, Рөстәм Кутуйның «Уч төбендәге кояш» һәм «Кышкы алмалар» исемле җыентыкларын, Михаил Скороходовның «Щелья»да сәяхәт» һәм «Текә таулар» исемле әсәрләрен, София Радзиевскаяның «Сайланма әсәрләр»ен, Юрий Белостоцкийның «Күк йөзе дә, гомер дә бер» («И жизнь одна, и небо одно») дигән яңа повестен күрсәтергә була.

Рус язучыларының әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге турындагы сүзне иң өлкән язучыбыз София Борисовна Радзиевская иҗатыннан башларга телә идем. Ул укучыларына табигать һәм хайваннар дөньясы турында дистәләрчә мавыктыргыч хикәяләр, Ватаныбызның ерактагы үткәне хакында берничә кызыклы повесть бүләк итте. Аларның иң яхшыларын, мәсәлән, «Батырлык утравы», «Рау белән Гау», «Джумбо», «Сазлык робинзоннары» кебекләрен, Татарстан китап нәшрияты бер томлыкка туплап йөз мең тираж белән дөньяга чыгарды. Актив иҗат эшчәнлегеннән тыш, язучының җәмәгать эшендәге тынгысызлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Олы яшьтә булуына карамастан, София Борисовна Язучылар союзы уздыра торган культура-масса эшләрендә күп катнаша: лекцияләр укый, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый, башлап язучы авторларга практик ярдәм күрсәтергә дә өлгерә, предприятиеләргә, колхозларга укучылар белән очрашуларга йөри.

Үзеннән-үзе аңлашыла ки, безгә халык белән даими аралашырга, тормышны яхшы белергә кирәк, шуннан башка язучы әдәбиятта нинди дә булса җитди әйбер туды-ра алмый. Бу җәһәттән үзенең КамАЗ төзүчеләргә багышланган «Чаллы җирендә» дигән китабы белән язучы Геннадий Паушкин үрнәк бирде. Төзелеш башланган чорда ул озак вакыт бер бригадада яшәде. Эшчеләрнең хезмәт энтузиазмы аны китап язарга рухландырды. Аның комсомол Үзәк Комитеты дипломы белән бүләкләнгән очерклар сериясе әнә шулай туды. Монда, авторның теләген хуп күреп, кыска вакытта китапны дөньяга чыгарган Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләренең дә хезмәте зур. Җыентыкның кайбер урыннары, бигрәк тә ахыргы өлеше ашыгып эшләнү сәбәпле камиллек дәрәҗәсенә ирешеп җитмәсә дә, рус телендә шушы темага язылган беренче китап буларак, аның әһәмияте шиксез.


Г. Паушкинның хәрби темага язылган «Кайтыгыз, ләкләкләр» повесте да авторның иҗади уңышы булып саналырга хаклы. Бу кечерәк кенә повестьның язылу тарихы гыйбрәтле. Яшь солдат Г. Паушкин сугышны чик буенда каршылый. Унике ел үткәч, аңарда бу көннәр хакында яшь буынга сөйләү теләге туа. «Ерак заставада» дигән беренче повесте шулай барлыкка килә. Китап уңыш казана, ләкин автор әсәреннән канәгать булмый. Тагын ун елдан соң «Очты кошлар» («Птицы улетели») дигән яңа исем астында повестен ул яңадан эшли. Ләкин бераздан соң китабын бу юлы да тиешле дәрәҗәдә түгел дип таба — һа-

ман да әле анда күп нәрсә әйтелмичә калган дип саный ул. Дошманның беренче ударларын каршылаган чик сакчыларының батырлыгын хәтердән җуелмаслык итеп сурәтләү өчен автор үзе әдәби батырлык эшләргә тиеш булып чыга. Һәм Паушкин андый батырлыкка сәләтле булуын исбат итте. Шуның белән ул көрәштәшләре алдындагы изге бурычын үтәде. Утыз елдан артыкка сузылган эзләнүләр, уйланулар теләгән нәтиҗәгә—әсәрнең тиешле яңгырашын табуга, ә әдәбиятта исә язучының үз тавышын табуга китерде. Чын илһам сулышы бәреп торган, проза белән язылган поэма шикелле яңгыраучы «Кайтыгыз, ләкләкләр» повесте, шиксез, соңгы елларда сугыш турында чыккан иң яхшы китапларның берсе.

Геннадий Александрович КамАЗ турындагы китабының геройлары янына йөрүендә дәвам итә. Өлгереп җиткән бу язучыдан без хезмәт героизмы турында да чик сакчыларының батырлыкларын сурәтләгән кебек тирән итеп, чын, җылы хисләр белән язылган яңа әсәр көтәбез.

Соңгы елларда иҗади яктан сизелерлек үскән икенче бер язучыбыз—Рөстәм Кутуй. Аның камиллектән шактый ерак торган беренче хикәяләре үз вакытында төрле бәхәсләр тудырды. Менә үткән ел Мәскәүнең «Современник» нәшрияты, аның соңгы елларда язган иң яхшы әсәрләрен туплап, «Уч төбендәге кояш» («Солнце на ладони») исемле җыентыгын дөньяга чыгарды, һәм беркемдә дә әдәбиятка үз каләме булган яхшы художник килүенә шик калмады. Аның төгәл эшләнгән акварель рәсемнәрен хәтерләтүче лирик новеллаларыннан кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендәге эчке яктылык сирпелеп тора.

Рөстәм Кутуй үзенә генә хас тасвирлау ысулын тудыра һәм, шул рәвешчә, чынбарлыгыбызны ачыграк, тулырак гәүдәләндерүгә ирешә. Ул геройларның тышкы кыяфәтләрен сурәтләү белән мавыкмый, аларның кылган гамәлләрен читтән аңлатып торуны өстенә алмый, геройның җанлы сөйләм теле аша үз асылын ачып бирүенә ирешә. Хикәяләрендә аның нииндидер шаккатыргыч хәлләр дә, сирәк очрый торган искитәрлек шәхесләр дә юк. Әсәрләренең геройлары бары да гади кешеләр. Әйтик, әнә ташчы Митрич, яки колхозның ат караучысы Карпей дәдә, солдатка Луша, Нихаль карт—барысы да гап-гадиләр, әмма һәрчак ярдәмгә килергә әзер булган сизгер йөрәкле яхшы кешеләр.



*Хәсән Туфанның бөтен игътибары докладчыда.*

Р. Кутуй әсәрләрендә яшүсмерләр образлары аерым урын алып тора. Зур тормышка кереп килүче ул яшьләр барысы да гүзәллеккә омтылалар, һәр яхшылыкка үтә сизгерләр, тискәре күренешләр исә аларда бик тиз күңел ярасы калдыра. Балалар турындагы бу хикәяләрдә гайдарча җылылык, геройларның язмышын уртаклашу хисе дулкынландыра. Аларда язучының сүз белән әйтелмәгән кисәтүен тоясың: әнә, көрәсезме, кеше формалашып килә, ди ул, без аның өчен җаваплыбыз, аның кем булып үсүе безгә барыбер түгел. Җыентыкка кергән әсәрләрнең барлык әдәби кыйммәтләрен санап тормыйча, шуны гына өстисе килә: яктылык чәчеп торган бу китапны кулга алганда кояшны уч төбеңә салган кебек хис итәсең.

Хәзерге вакытта Рөстәм Кутуй әхлакый тәрбия, гаиләдә һәм коллективта кешенең үз-үзен тотышы темасына «Суд алдында» дигән повесть өстендә эшли. Повестьның без танышкан беренче бүлекләре язучының алга табан үсә баруы турында сөйли.

Язучы Михаил Скороходовның китаплары да шундый ук хуплау сүзләренә лаек. Иҗат мәсьәләләрендә ул үзенә һәм иптәшләренә карата да бик таләпчән. Скороходовның, Архангельск поморы Буторин белән бергә, ал җилкәнле баркаста легендар Мангазеяга ясаган гаҗәеп сәяхәте безнең хәтердә әле. Биш ел үткәч, 1972 елда,

«Советская Россия» нәшрияты аның «Щелья»да сәяхәт» исемле әсәрен бастырып чыгарды. Әдәби тәнкыйть аңа югары бәя бирде. Автор хәзер китапның икенче, тулыландырылган басмасы өстендә эшли. Яшьләргә адресланган бу әсәр, һичшиксез, романтик сәяхәтләр турында хыялланучыларның китап шкафында мактаулы урын алыр.

Инде менә китап кибетләрендә язучының «Текә таулар» исемле яңа романын күрдек. Ул Чистай шәһәре эшчеләренә һәм Диксон атавы полярникларына багышланган. Әсәрнең «Өстенлек иткән көч» («Превосходящие силы») дип исемләнгән беренче бүлеге кайчандыр язучы үзе көйләүчеслесарь булып эшләгән предприятие эшчеләре турында сөйли. «Ак җир хуҗалары» («Белоземельцы») дигән икенче бүлектә автор ерак төньякта эшләүче полярникларның хезмәт батырлыгын күрсәтә. Язучы берничә ел анда «Полярная звезда» газетасының редакторы булган.

Якташлары алдында Скороходовның үзенә бер иҗат отчеты дип саналырга хаклы бу әсәрне алар зур кызыксыну белән каршы алырлар дип уйлыйм.

Ниһаять, Юрий Белостоцкийның яңа гына Казанда чыккан соңгы китабы—«Күк йөзе дә, гомер дә бер» дигән әсәре турында берничә сүз. «Күктә югалган сер» («Небо хранит тайну») исемле баштагы әсәре белән чагыштырганда без аны язучы иҗатында алга зур гына адым дип саныйбыз. Ике ел элек зур тираж белән Татарстан китап нәшриятында чыккан беренче повестенда бик сирәк һәм очраклы, шуңа күрә бөтен авиация өчен характерлы булмаган бер фаҗигале вакыйга хикәя ителгән иде. Шул сәбәпле ул художестволы әдәбиятта түгел, ә гадәттән тыш хәлләр хроникасында гына урын алырга мөмкин иде.

Ю. Белостоцкий, күрәсең, әсәрендәге кимчелекләрне үзе дә аңлаган. Хәзер ул укучыларына яңа повесть тәкъдим итә. Фаҗига монысында да кечкенә түгел, әмма әсәр төзегрәк чыккан, иң мөһиме, аның зур хөрмәткә лаек булырлык герое бар.

Секция бюросы миңа шулай ук Ян Винецкийның «Тамырлар» («Истоки») дигән соңгы китабы турындагы фикеребезне җиткерүне йөкләде. Бу җыентыкта Испаниядә булып үткән һәм автор үзе катнашкан гражданнар сугышы темасына ике яхшы гына хикәя бар. Батыр хатын-кызларыбыздан очучы Мәгубә Сыртланова турында «Зори девичьи» исемле яхшы документаль повесть бар. Ләкин җыентыктагы калган хикәяләрнең әйтерлек әдәби кыйммәтләре юк. Аларда уйлап чыгарылган һәм очраклы нәрсәләр күзгә ташланып тора. Мәсәлән, хикәяләрнең берсендә бер лейтенантның үзе яраткан солдат дустын юк кына гаебе өчен атып үтерүе бәян ителә. Шәфкатьсез һәм ышандырмый торган хикәя бу. Икенче әсәрдә гражданнар сугышының бер героена апалы-сеңелле ике кызның шаккаткыч мәхәббәте сурәтләнә. Соңыннан бу кеше Италиядәге каршылык хәрәкәтенең каһарманы булып танылa һәм, аз да түгел, күп тә түгел, Неаполь шәһәрен азат итә. Чама хисе югалган мондый хикәяләрне укыганда гаҗәпләнеп иңбашны җыерып куясың. Җыентыкта бигрәк тә Ленинга, Горькийга, Пушкинга, Есенинга, грек композиторы Теодоракиска багышланган тарихи новеллалар ризасызлык тойгысы уяталар. Авторның һәркемгә мәгълүм булган тарихи фактлар белән артык иркен мөгамәлә итүе котылгысыз рәвештә тарихи дөреслекне бозуга китерә. «Тамырлар» дигән беренче новеллада автор студент Владимир Ульяновның пешекче Алексей Пешков белән очрашуы хакында сөйли, шунда ук аларның үзара әңгәмәсе дә китерелә. Мондый уйдырма нәшриятны уңайсыз хәлдә калдырган, андый очрашу тарихи яктан исбат ителмәгән, автор бары тик аның булуы мөмкин дип саный, дигән искәрмә бирел, ул китап укучылар алдында акланырга мәҗбүр булган.

Икенче бер новеллада Пушкин Пугачев турында уйлана һәм авыз иҗатыннан Степан Разин хакындагы җырны көйли. Хәлбуки, җыр Пушкинның үлеменнән соң ярты гасыр үткәч, Сембер шагыйре Садовников тарафыннан чыгарылган. Кызганычка каршы, китапта шундый гөман итүләр һәм фараз кылулар җитәрлек. Билгеле, алар укучының авторга булган ышанычын ныгытмыйлар. Бөтен бәла шунда ки, талантттан мәхрүм әдип булмаса да, Ян Винецкий әсәрләрен ашык-пошык яза, каләмдәш дуслары фикереннән башка гына дөньяга чыгара.

Татарстанда яшәүче башка рус әдипләренең иҗаты хакында кыскача гына әйтеп үтәм. Марсель Зарипов «Чужой медовый месяц» исемле беренче җыентыгын чыгарды, аннары Гариф Ахунов белән берлектә республикабыз турындагы «Без Казаннан, Иделдән» дигән очерклар китабын язды. «Советская Россия» нәшриятында



*Шагыйрь Ренат Харисов һәм әзербайҗан язучысы Ибраһим Ароз.*

басылган ул китап «Россиялеләр, туганнар гаиләсендә» дигән китаплар сериясеннән иң яхшысы дип табылды. Әле яңа гына авторның бишьеллык геройларына багышланган «Тугызынчы биеклек» дип исемләнгән тагын бер очерклар китабы басылып чыкты. Өлкән каләмдәшебез Александр Булгаков «Төньяк җиле» дигән җыентыкта Заполярье төзүчеләре турындагы хикәяләрен бастырды.

Соңгы елларда дөнья күргән шигъри җыентыклар арасыннан Николай Беляевның «Чатта» («Перекресток»), Рөстәм Кутуйның «Яшь ай» («Новолуние»), Леонид Топчийның «Үзем өчен яшәмим» («Живу не для себя») дигән китаплары игътибарга лаек. Яшь язучыларның иҗат уңышлары да сөенеч хисе уята. Гани Бикушевның яшьләр тормышыннан алып язылган «Өйгә кайтыйк» («Пойдем домой») һәм «Бәхетле чүмеч» («Самый счастливый ковшик») повестьларын җәмәгатьчелек җылы каршылады. Нонна Орешина «Беренче адым» исемле яңа китабын дөньяга чыгарды, «Правда» газетасында һәм «Крылья Родины» альманахында ике кызыклы очерк бастырды. Хәзер ул хәрби авиация очучылары турында повесть тәгаллләп килә.

Соңгы алты ел эчендә тәнкыйтьчеләребездән Лев Юдкевич «Есенинның лирик герое» һәм Вячеслав Воздвиженский «Муса Җәлилнең Моабит дәфтәре» дигән китаплар бастырдылар.

Рус язучылары секциясенең айга бер мәртәбә үткәрелә торган җыелышларына без Равил Бухараев, Неля Земляниченко, Геннадий Капранов кебек сәләтле яшь шагыйрьләрне һәм Павел Смольников, Дмитрий Сычев, Вахит Монасыйпов кебек инде берничәшәр җыентык чыгарып өлгергән прозаикларны да чакырабыз.

Без үзебезне татар язучылары белән бердәм иҗади семьяда итеп хис итәбез һәм барлык җитди мәсьәләләрне бергәләп хәл итәбез. Күптән түгел рус һәм татар язучылары секцияләренең берләштерелгән җыелышында Абдулла Йосыповның «Акчуриннар» («Господа Акчурины») исемле роман-хроникасының кульъязмасын тикшердек. Бирелгән киңәшләрне истә тотып, автор кульъязманы төзәтеп чыкты һәм нәшрият аны басарга кабул итеп алды.

Безнең республикада рус телендә язучы ике йөзләп авторны берләштерә торган җиде әдәби берләшмә бар. Казанның Горький музее каршындагы берләшмә — шуларның иң өлкәне. Яшь авторлар һәр җомга көнне монда җыелып, шагыйрь Марк Зарецкий җитәкчелегендә яңа әсәрләр тикшерәләр. Рус телендә язучы барлык Казан язучылары диярлек — Г. Паушкин,

Р. Кутуй, Н. Орешина, Г. Бикушев, драматург Д. Вәлиев, Н. Беляев — шушыннан чыккан кешеләр.

Кырыктан артык яшь каләм иясен җыйган икенче зур берләшмә Чаллы шәһәрендә эшли. Аларның иң уңышлы иҗат үрнәкләрен туплаган беренче күмәк җыентык матбугатка әзерләнә. Чаллыда семинар вакытында прораб В. Леонтьев безне автозавод төзүчеләре турындагы кызыклы романы белән таныштырды. Шулай да әсәр җитди тәнкыйтькә очрады. Эш шунда ки, КамАЗга килүче язучылар вакытлы матбугатта кайчак сай язылган бер үк типтагы очерклар бастыралар. Турист язмаларын хәтерләтүче андый очерклар укучыны ялыктыра башлагач, әдипләр гадәти булмаган биографияле кешеләрне эзләү белән мавыга башладылар. Менә мондыйрак схема да барлыкка килде: фәлән фәләневнең тормышы, янәсе, чуалып киткән һәм эшләрен җайга салу, яңа тормыш башлау өчен ул автозавод төзелешенә килгән. Безнең хөрмәтле каләмдәшебез Геннадий Паушкин да «Камадан искән җил» дигән бер хикәясендә шушы шаукымга бирелеп ала. Хикәянең герое болай дип белдерә: «Без һәммәбез монда качып килгән кешеләр. Кем хатыны янынннан, кем хатынының әнисеннән, ә кайсыберәүләр ата-аналарыннан качкан». Әдәби иҗат эшендә тәҗрибәсе булмаган Леонтьевны менә шушындый «үрнәкләр» адаштырган да инде. Төзелешкә биографияләрен төзәтү өчен килгән кешеләр романда күбәеп китә. «Сезнең участокта андый кешеләр бик күпмени соң?»— дип сорадык без автордан. Ул гаҗәпкә калды: «Безнең объектыбыз бик җитди бит,— ди,— андыйларны тотмыйбыз без». «Ә ник аларны романыгызда бергә җыйдыгыз?» «Мин моны эшчеләр коллективында аларның яңадан тәрбияләнүләрен ачыграк күрсәтү өчен эшләдем»,— дип аңлата Леонтьев. Без аның ялгыш юнәлештән киткәнлеген озаклап аңлаттык һәм ул романын яңадан эшләргә булды. Эшчеләр сыйныфы турында аның яхшы әсәр бирәчәгенә без ышанабыз.

Яңа талантның күренүе безнең өчен үзе бер бәйрәм. Союзга килгән кульъязмага карата сак, кайгыртучан мөнәсәбәт һәм югары таләпчәнлек булганда гына ышанычлы әдәби алмаш тәрбияләргә мөмкин. Әлмәттә яшәүче Владимир Мальцев повестеның кульъязмасын алгач, секция члennары аны ике тапкыр үзләренең җыелышларына чакырдылар, һәм автор фронт темасына язылган әсәрен кабат эшләгәннән соң, нәшриятка тәкъдим иттеләр.

Әдәби алмаш тәрбияләү бурычы безне һәрчак борчырга тиеш. Бездә кайчак шулай да була: яшь автор табигый сәләте аркасында укуын тәмамлауга ук профессиональ язучы булып китә, җиң сызганып кешеләрне акылга өйрәтә башлый. Талантлы булу гына язучы өчен аз—аның артында тормыш тәҗрибәсе торырга тиеш, хезмәт кешеләре белән даими аралашып, тормышны ул дөрес аңлый белергә тиеш.

Партия җитәкчелегендә тарихи батырлыклар күрсәткән халкыбыз алдында без бурычлы әле. Безнең иҗат уңышларыбыз, күп милләтле совет әдәбиятының иҗади казанышлары шул бөек җиңешләргә лаек булсын.

**Сергей Михалков,**
Ленин премиясе лауреаты,
Социалистик Хезмәт Герое

# ХАЛЫКЧАН ӘДӘБИЯТ, ТОРМЫШЧАН ӘДӘБИЯТ

Иптәшләр!

Татарстан язучылар союзы — Россия Федерациясенә керә торган республика, край һәм өлкә оешмалары арасындагы иң зур оешмаларның берсе. Мәскәү һәм Ленинградтан кала, ул үзенә лаеклы өченче урынны алып тора. Матур әдәбият өлкәсендә байтак еллар нәтиҗәле эшләп килгән һәм инде берничә җыентык чыгарып

өлгергән яшь авторлар активын исәпләмичә дә, бүген аның сафларында 150 ләп СССР Язучылар союзы члены бар. Шуннан чыгып, республикадагы иҗади тормышның колачын күз алдына китерү артык кыен булмас дип уйлыйм.

Билгеле, иҗат оешмасының эше андагы членнарның саны белән түгел, ә алар биргән продукциянең сыйфаты белән билгеләнә. Һәм шикләнми әйтергә була, зур татар совет әдәбиятының йөзен Габдулла Тукай, Шәриф Камал, Һади Такташ, Муса Җәлил исемнәре, алардан соң әдәбиятка килгән язучы һәм шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Зәки Нури, Гариф Ахунов исемнәре һәм башка бик күп, бик күп язучыларның исемнәре билгели. Аларның иҗаты күп миллионлы совет укучыларының (һәм бер совет укучыларының гына да түгел) рухи тормышының аерылмас өлеше булып китте.

Татар әдәбиятының никадәр тирән, бай борынгы тамырлары һәм традицияләре булу да яхшы мәгълүм. Татар әдәбиятының башка тугандаш республикалардагы күп кенә күренекле каләм осталарының иҗатына нинди зур тәэсир иткәнлеге һәм итеп килүе шулай ук билгеле, бу хакта төрле республикаларның язучылары үзләре сөйләп торалар. Без РСФСР язучылар союзы идарәсендә татар әдәбият белеме һәм тәнкыйтенең бу мәдәни мирасны өйрәнү юлында нәрсәләр эшләвен белеп торабыз. Билгеле, бу өлкәдә һәммәсе дә тиешле югарылыкта һәм төпле фәнни дәрәҗәдә тормый әле. Кызыклы әдәбият галимнәрегездән Н. Юзиев бик дөрес әйткәнчә, «дөнья стандартларыннан» артка калу нык күзгә ташлана. Әмма ни генә булмасын, бер нәрсә ачык, бу мәсьәләләрне уңышлы хәл итү өчен күпмедер вакыт кирәк, бу өлкәгә яңа кадрлар, яңа иҗат көчләре килү кирәк. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары татар әдәбияты фронтының бу тармагында да эшлекле рухи җанлану тудырды. Татар әдәбият белемендә һәм тәнкыйтендә кызыклы сыйфат яңарышлары бара, әдәбият күренешләренә бәя бирү, аларга гомуми анализ ясау тирәнәя. Ләкин бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк, әле бу әдәбият белеме һәм тәнкыйть алдына партиябез куйган гаять зур идеология эшенең башы гына, һәм сезнең идарәнең яңа сайланачак составына ул эшне тайпылышсыз һәм эзлекле төстә гамәлгә ашырырга туры киләчәк.

Һәрбер съезд — барыннан да элек, эшләнгән эшләргә, узылган гомергә йомгак ясау, дигән сүз ул. Менә шуңа күрә дә, сез ирешкән казанышларны тыңлау һәм бәяләү белән генә чикләнмичә, безнең уртак тырышуларны, уртак эшләрне — Россия Федерациясе язучылар союзы идарәсе һәм Татарстан язучылар союзы башкарган эшләрне дә янәшә куеп, анализ ясап карыйсы килә. Бу уңайдан бер кызык факт искә төшә. Россия язучыларының моннан алдагы съезды 1970 елның мартында булды, һәм шул ук елның сентябрь аенда, хәтерегездәдер, башкалабыз Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Бу көннәрдә Татарстан язучылар союзы вәкилләре, әгәр шулай әйтергә яраса, аяк өсте генә булса да, Россия Федерациясе язучылар союзы идарәсенең яңа составы белән танышып алды. Ул очрашу бик тә эшлекле шартларда үтте. Сезгә съездга килер алдыннан, зур кызыксыну белән, мин шул утырышның стенограммасын укып чыктым. Анда тугандаш әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрне көчәйтү, татар язучыларының әсәрләрен Мәскәү нәшриятларында чыгарырга ярдәм итү, тәрҗемә мәсьәләләре, РСФСР язучылар союзы идарәсендә эшлекле фикер алышулар уздыру турында бик күп теләкләр һәм тәкъдимнәр әйтелгән, хәтта сезнең классикларның, аерым алганда, Һади Такташның юбилеен үткәрү буенча да сүз булган. Сез беләсез, бу күренекле шагыйрьнең бәйрәме Мәскәүдә, Союзлар йортының Колонналы залында гаять тантаналы шартларда билгеләп үтелде.

Мәскәүдәге очрашу вакытында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевнең әйткән сүзләре истә калган. Ул болай дигән иде: «Сезгә үпкәбез зур һәм киләчәктә дә булыр, чөнки безнең язучыларның китапларын аз чыгарасыз. Бездә менә дигән шагыйрьләр һәм прозаиклар күп, әмма бер очракта — тыйнаклык, икенче очракта — энергия җитмәү аларга бөтен

союз аренасына чыгарга комачаулый»... Сүз дә юк, татар язучылары — тыйнак халык. Шул ук М. Ф. Вәлиев иптәш сүзләре белән әйткәндә, алар ишекне аяк тибеп ачмыйлар. Шулай да әш бер милли характер сыйфатларына гына бәйләнмәгән иде. Мәскәүдә китап чыгару объектив сәбәпләр аркасында да катлауланды. РСФСР язучылар союзы идарәсе инициативасы белән «Современник» нәшрияты төзелгәч, хәл тамырдан үзгәреп китте. Казанда уздырылган күчмә секретариат утырышында да конкрет саннар да китерелде: 1972 ел планындагы 525 китапның зур күпчелеген автономияле республикаларда яшәүче язучыларның әсәрләре тәшкил иткән, 1973 елгы эш планында аларга тагын да күбрәк урын бирелгән булган. Соңгы айларда гына да безнең нәшриятта А. Расих, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин, М. Әмир, М. Мәһдиев, Ш. Бикчуриннарның яңа китаплары басылып чыкты һәм чыгарга әзерләнеп ята. Исемнәре саналган язучыларның барысы да — зур, кызыклы әсәрләрнең авторлары. Күп кенә татар язучыларының әсәрләре Мәскәүнең башка нәшриятларында басылды, төрле җыентыкларга кертелде, аерым цикллар төсендә барлык үзәк журналларда чыгып килә, башка телләргә тәрҗемә ителә. Менә Бакуда әзербәйҗан телендә чыккан бер китап күрсәттеләр, аңа татар язучыларыннан 35 шагыйрьнең һәм 28 прозаикның әсәрләре кертелгән. Шушы үзе генә дә бөтен союз аренасына күпләп чыгу түгелмени! Көнбатыштагы язучылар моны күз алдына да китерә алмыйлар.

Үз вакытында С. Хәким аерым язучыларның иҗатларын тикшерү, семинар-киңәшмәләр үткәрү кебек чаралар уздыруны яклап чыккан иде. РСФСР язучылар союзы идарәсе бу эшне тайпылышсыз башкарып килде. Яшь язучыларның Бөтенроссия киңәшмәсендә яшь татар драматургы Диас Вәлиев танылды, аның драматург буларак язмышын шушы киңәшмә, аның иҗаты турында А. Сафроновның киңәшмәдә төпле чыгышы ясавы хәл итте. Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, драматурглар өчен уздырылган семинарларның барысына да яшь татар драматурглары аеруча күп тартылды. Икенче кызыклы бер драматург Туфан Миңнуллин әсәрләре дә җитди игътибарга лаек. Ләкин аксакалларыгыз, өлкән драматургларыгыз да үз әсәрләрен тәрҗемәгә оперативрак бирсеннәр иде, дигән теләк белдерәсе килә. Әйтик, сезнең драматургиянең Р. Ишморат кебек күренекле вәкилен зур тамашачы нигә бөтенләй диярлек белми? Хәер, бу мәсьәлә бер драматургларга гына да кагылмый. Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни кебек күренекле татар язучыларының да яңа басмаларын күрәсе иде. Ихтимал, бу мәсьәләдә язучыларның үзләренә дә активрак булырга, сүзгә-сүз тәрҗемәләр хакында күбрәк кайгыртырга кирәктер. РСФСР язучылар союзы идарәсе исә үз ягыннан мондый кирәкле һәм изге эшкә һәр вакыт ярдәм кулын сузачак.

РСФСР язучылар союзы милли республикаларда яңа исемнәр, кызыклы яңа әсәрләр ачу эшенә һәр вакыт зур игътибар биреп килде һәм аларга төрле юллар белән ярдәм итеп торды. Әйтик, Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы әле сүзгә-сүз тәрҗемәдә үк лаеклы бәя алды. Секретариатның Тольятти шәһәрендә уздырылган күчмә утырышында бу әсәр турында җитди сүз булды, ул «Современник» нәшриятына тәкъдим ителде. Күптән түгел РСФСР язучылар союзында ифрат талантлы татар шагыйре Илдар Юзеевның иҗаты тикшерелде. Күрәсең, безнең уртак фикеребез буенча, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев, Ренат Харисов, Марс Шабаев, Әдип Маликов һәм укучыларның ихтирамын казанып өлгергән күп кенә башка исемнәр дә татар поэзиясенең өмете булып саналырга тиештер.

Татарстанда балалар язучыларының зур отряды бар. Эчтәлеге һәм рухы ягыннан гаять халыкчан, үлемсез «Шүрәле» әсәре белән татар балалар әдәбиятының нигезен Г. Тукай салган иде. Балалар һәм яшьләр әдәбияты буенча уздырылган Бөтенроссия киңәшмәсе татар язучыларына да мәгълүм бер файда китергәндер, дип уйлыйм. Балалар әдәбияты турында сүз барганда, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Гариф Гобәй, Сибгат Хәким һәм башка иптәшләрнең исемнәрен телгә алмый узып булмый.

Билгеле булганча, сезнең республикада рус язучыларының да зур бер төркеме эшли. Ул төркемне Тихон Журавлев, Михаил Скороходов, Юрий Белостоц-



*Прозаик Габдрахман Минский белән композитор Нәҗип Җиһановның да уртак сүзләре күп булды.*

кий, Геннадий Паушкин, Ян Винецкийлардан башка күз алдына китерү кыен. Һичшиксез, алар үз иҗатлары белән татар совет әдәбиятын үстерү кебек гомуми эшкә хезмәт итәләр.

Казанда Секретариатның күчмә утырышын уздыру РСФСР язучылар союзы башкарган иң зур эшләрнең берсе булды. Ул, безнең уебызча, Идел буендагы алты автономияле республика әдәбиятын киң рәвештә тикшерүдән тыш, әлеге әдәбиятлар арасында дуслык элементләре урнаштыру һәм ныгыту юнәлешендә дә зур роль уйнады. Бу секретариатта күп кенә яңа әсәрләргә төпле бәя бирелде. Идел буе әдәбиятларына караган төрле проблемалар һәм ул әдәбиятларның үсеш тенденцияләре тикшерелде. Әдәби тәрҗемә мәсьәләләре кебек мөһим проблема да кузгатылды. Шуның дәвамы буларак, 1974 елның башларында автономияле республикалардагы проза тәрҗемәчеләренең Бөтенроссия киңәшмә-семинары үткәрелде. Бу юлы да иң зур группа Татарстаннан иде. Ике генә көн эшләсә дә, киңәшмә нәтиҗәле үтте. Безнең эш практикасында мондый семинар — «беренче карлыгач» кына әле. Күрәсең, мәсьәләләрне тагын да киңрәк иңләп һәм конкрет максатларны күздә тотып, әлеге киңәшмәне ел саен уздырырга кирәк булыр. Сүз җаеннан әйтеп китәргә кирәк, семинарның җитәкчесе, күренекле совет тәрҗемәчесе Николай Любимов татар тәрҗемәчеләреннән А. Бадюгина, Р. Текташ, Н. Мальшаковаларның иҗатына әйбәт бәя бирде. Билгеле, тәрҗемә өлкәсендә хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый, күп төрле кыенлыклар һаман яшәп килә. Ләкин, шушы семинардан башлап, РСФСР язучылар союзы идарәсе бу юнәлештә конкрет чаралар күрергә ниятләп тора.

Бу еллар эчендә турыдан-туры сезнең оешмага кагылган оештыру-административ мәсьәләләр дә хәл ителде. Югарыда сөйләнгәннәрдән артык шәрехләп торуга мохтаҗ булмаган шактый ачык картина күз алдына килеп баса. РСФСР язучылар союзы идарәсе, безнең алга партия, заман, әдәби тормышыбызның нормалары куйган бурычлар яктылыгыннан чыгып, илебездәге бөтен әдәби процессның үсеш ихтыяҗларын истә тотып, өлгергән мәсьәләләрне иң киң аспектта һәм Бөтенроссия масштабында хәл итәргә тырышты һәм хәл

итеп килде. Һәм күп көч сорый торган әлеге тынгысыз эшнең хәлиткеч, төп мәсьәләләрдә куанычлы нәтиҗәләргә китерүен дә күрмәү мөмкин түгел.

Съезд алды елында РСФСР язучылар союзы идарәсе секретариаты, үз иҗат активын җитди генә туплап, Россия киңлекләрендә яңа әдәби исемнәр ачарга ярдәм итәрлек күп мөһим эшләр башкарды. Шул исәптән, Переделкинода яшь тәнкыйтьчеләр һәм яшь очеркистлар семинары, аннары соңгы еллар прозасындагы яңалыкларга багышланган пленум үткәрелде. Шикләнми әйтергә була, безнең сафларга таза рухлы, талантлы яшь алмаш килә, беренче әсәрләре белән үк үзләрен күрсәтеп өлгергән яшьләр турында күбрәк кайгыртырга гына кирәк. Талант иясе булу — халык алдында җаваплы булу дигән сүз. Аны ничек файдалану — тагын да җаваплырак эш. Үсеп килүче алмаш турында хуҗаларча кайгырта, яшьләрне түземле һәм акыллы төстә тәрбияли белергә кирәк. Бер-береңне күралмау, кемнеңдер иҗатын күрмәмешкә салышу һәм икенче берәүне чамасыз мактау, мин-минлек һәм көнчелек кебек нәрсәләр яшьләрне тәрбияләү эшенә зур зыян китерә. Бу хакта кабат исегезгә төшерү һич артык булмас дип уйлыйм.

Иптәшләр!

Тормышта бернинди яңалык та җиңел тумый. Нык үсеш алган социализм шартларында төзелә торган яңа җәмгыять тә үз юлында һәр көнне кыенлыкларга очрый, аны артка сөйрәп һәм үсешен тоткарлап, аяк астында бутала торган нәрсәләрдән җиңел генә котыла алмый. Чынбарлыктагы кимчелекләрдән арыну, кешенең аңын үзгәртеп кору, яшь буынны коммунистик әхлак рухында тәрбияләү процессында безнең җәмгыять әдәбиятының сатира кебек сыналган жанрына мөрәҗәгать итми кала алмый. «Правда» газетасы бер дә юкка гына миңа үз битләрендә сатира һәм юмор мәсьәләләре, аның безнең тормыштагы урыны һәм роле турында мәкалә белән чыгарга мөмкинлек бирмәгәндер, дип уйлыйм. Игътибар итәрлек факт, күптән түгел Болгариядә сатира һәм юмор мәсьәләләре буенча республика киңәшмәсе булды, анда Тодор Живков үзе зур речь белән чыкты.

Зәки Нуриның кызыклы докладында сатира жанры һәм аның бүгенге татар әдәбиятындагы урыны хакында дөрес һәм вакытлы әйтелде, дип уйлыйм. Докладчы әдәбияттагы бу жанрны сәгать теле белән чагыштырды, ә мин аны минерга тиңләр идем. Тегесе дә, бусы да үз эшенең чын остасы булырга тиеш. Әйтик, минер пехотага каршы — танк минасы, танкка каршы пехота минасы куярга ярамаганын белергә тиеш. Әгәр шуны белми һәм өстәвенә аның куллары да дерелди икән, ул, һичшиксез, кайчан да булса үз минасыннан үзе шартлаячак. Сатирик та шулай ук. Партияле позициясе һәм идея ныклыгы гына сатирик язучы әсәренең нәтиҗәлелеген билгели, үзе сайлаган дошманга төгәл һәм дөрес атарга булыша. Татар халкы үткен сүзнең кадерен һәм бәясен шәп аңлый, сокланырлык юмор хисенә ия булган халык, шуңа күрә дә аның барлык жанрларда, беренче чиратта, драматургиядә, тормышны реалый һәм кимчелекләрне камчылый торган көлке әдәбияты булырга тиеш.

Чыгышымның ахырында мин Россия язучылар союзы эшчәнлегендәге төп, генераль юнәлешне исегезгә төшерергә телим. Совет язучылары үзләренең барлык уңышлары, барлык казанышлары өчен иҗатларының төп нигезе булган партиялелеккә бурычлы, дип уйлыйбыз. Партиялелек һич кенә дә, идея дошманнарыбыз расларга маташканча, безгә көчләп тагылган ясалма сыйфат, язучының фикерен, индивидуаль йөзен буып тора торган йөгән түгел. Партиялелек — безнең әдәбиятның җаны. Без ачыктан-ачык, курыкмыйча әйтәбез: совет язучылары буларак, без ленинчыл коммунистлар партиясенә, димәк ки, халыкка хезмәт итәбез. Безнең илдә партия һәм халык ихтыяҗлары тулысынча тәңгәл килә. Менә шуңа күрә дә, совет әдәбиятының партиялелеге — аның халыкчанлыгының иң югары формасы ул, дип әйтә алабыз. Совет язучылары тоткан позиция, аларның гражданлык хисе һәм партиялелеге һәр төрле «белгечләрнең» кискен һөҗүменә очрап килде. Андый һөҗүмнәрнең хәзер дә тукталганы юк, көнбатыштагы мәгълүм даирәләр әле бүген дә Советлар Союзындагы «шәхес ирегә» хакындагы мәсьәләне бик рәхәтләнеп чәйни-

ләр. Мондый шартларда РСФСР язучылар союзы идарәсе әдәбият әсәрләренең идея эчтәлегенә һәр көн даими һәм эзлекле төстә иң җитди игътибар бирелергә тиеш, дип саный. Бу мәсьәләдә компромиссларга барырга ярамый. Безнең әдәбиятка һәртөрле тенденциоз группачылык интересларын яки шикле, буталчык «теорияләр» һәм «теориячекләр» сөйрәп кертергә маташучыларга каршы иҗатлары белән партия, халык эшенә хезмәт итүче язучыларның бердәм ачык, партияле позицияләре каршы куелырга тиеш.

Иптәшләр!

Безнең фикеребезчә, татар совет әдәбияты бүген кызыклы, яңа мәсьәләләрне хәл итү, яңа күтәрелеш, үсешнең яңа юнәлеше алдында тора. РСФСР язучылар союзы секретариаты Татарстан язучылар союзы идарәсенең сез сайлаячак яңа составы тагын да тырышыбрак эшләр, татар әдәбияты яңа казанышларга ирешер, дип ышанып кала. Партия белән, аның ленинчыл Үзәк Комитеты белән кулга-кул тотынып эшләүче язучыларның намуслы хезмәте шуңа нигез булып тора!

## Сибгат Хәким,

М. Горький премиясе лауреаты

# ҖАВАПЛЫЛЫК ХИСЕ


Кичәге докладчыларның Гариф Гобәйдән калганнары барысы да — урта буын вәкилләре. Әмәнә докладлары әйбәт. Безне, өлкән буын кешеләрен, куандыра торган докладлар. Үзебезнең татар әдәбиятының зур традициясенә, тарихына таянып һәм күрше әдәбиятлар, рус әдәбияты ирешкән казанышларга таянып ясалган нигезле, нык докладлар. Бу мине бик шатландыра. Димәк, бездән соң әдәбиятка нык буын килә. Һәм татар әдәбиятының киләчәге әйбәт икән, зур икән дигән ышаныч туа. Минем белүемчә, күзәтеп баруымча, татар әдәбиятына алардан соң да бик күп талантлы яшьләр килә. Киләсе съездларда һәм поэзия, һәм драматургия, һәм проза, һәм тәнкыйть өлкәсендә болардан да әйбәтрәк докладчылар булачагына минем әз генә дә шигем юк. Чөнки мин шул яшьләр арасында эшлим һәм аларның потенциаль мөмкинлекләрен әйбәт беләм. Бу — минем өчен икенче шатлык. Минем шул хакта уйланып йөргәндә язган 3—4 кенә юл шигырем дә бар:

> Һөҗүмгә барган солдатның тылы
> нык булсын икән,
> Шагыйрьнең тылы — тарихы,
> теле нык булсын икән.

Һөҗүмгә барган солдатка тылының нык булуы кирәк булган кебек, шагыйрь өчен дә, алга һөҗүмгә барганда, артында халкы булу, культурасының, мәдәни традицияләренең нык булуы, теленең нык булуы кирәк. Шуңа күрә әдәбият турында, ике съезд арасындагы әдәби мәсьәләләр турында фикер йөрткәндә, мин әдәбиятның үткәнен бүгенгесеннән, бүгенгесен киләчәгеннән аерып куеп уйлый алмыйм.

Безнең алга зур, олы итеп куелган мәсьәләләр һәм безне борчыган әйберләр дә бар. Мәсәлән, бик еш кына без инде 150 гә җиттек дибез, сүз Союз члennарының саны турында бара. Бервдә РСФСР язучылар союзы идарәсенең председателе Сергей Владимирович Михалков утыра. Ул белә: безнең оешма язучыларны Союз члеnлыгына үзе кабул итә. Мондый республикалар өчәү генә: Татарстан, Башкортстан, Чувашия. Бу — безнең язучыларга, безнең әдәбиятка ышаныч дигән сүз. Безнең әдәбиятка зур итеп караганга күрә, бу эшне, үзегез алыгыз дип, безгә ышанып тапшырдылар. Шул ук вакытта, без кайвакытта бу ышанычтан артыграк файдаланмыйбыз микән, дигән шик тә туа. Мине шул нәрсә куркыта. Бу мәсьәлә М. Мәһдиевнең өченче көн «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсендә дә кузгатыла.

Әдәбиятның зурлыгын шәхесләр, индивидуаль үзенчәлекләре булган зур шәхесләр билгели. Шәхес юк икән, әдәбият та юк. Шуңа күрә без Такташ ди-



*Шагыйрь Сибгат Хәким һәм әдәбият белгече Шәраф Әхмәдуллин икесе дә Казан педагогия институты шәкертләре.*

без, Туфан дибез, Җәлил дибез, аннан да алга китеп, Тукай дибез, Әмирхан дибез, Галимҗан дибез. Безнең каршыда бөтен тарих ачыла, аның бөтен зурлыгы, тирәнлеге ачыла — әдәбиятның зурлыгын зур исемнәр ача. Шуңа күрә Союзга члennар алганда бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк, шагыйрь гражданин, үз чорының иң ялкынлы, иң актив гражданины булырга, шәхес булырга тиеш. Үзендә шул сыйфатларның бөтенесен җыйган индивидуаль үзенчәлекле шәхес, әдәбиятны җилкәсендә күтәрә торган һәм алып бара торган, башка милләтләр һәм башка халыклар алдында йөз кызартмый торган шәхес килергә тиеш. Шуңа күрә 150 кеше дип әйтү генә әдәбиятның зурлыгын билгеләми.

Миңа узган елның август аенда, Тольяттида очрашу вакытында, рус прозаигы, «Иду на грозу»ның авторы Даниил Гранин белән сөйләшергә туры килде.

— Сездә күпме язучы бар? — дип сорый бу.

— 150,— дим.

— 150 язучы буламыни? — ди.

Әйе шул, 150 язучы булмый. Киләчәктә Союз члennарының санын үстергәндә, яңа сайланачак идарә таләпләрне киметмәсен, төшермәсен иде.

Шушы ике съезд арасында мине тагын бер әйбер борчыды, аны тоеп, сизеп яшәдем. Үзебезнең идарәнең эшендә тойдым, җитәкчелектә тойдым. Әдәбиятны зур юл белән юнәлтергә мөмкин һәм таләпләрне төшерә-төшерә примитив юл белән юнәлтергә мөмкин. Аны Галимҗаннарча, Фатыйхларча, Мусаларча зур итеп юнәлтергә мөмкин. Һәм аны әдәбиятның бик урта кул әйберләренә ориентация тотып юнәлтергә мөмкин. Мине ике съезд арасында бу нәрсә дә борчыды. Борчылмас идең, мин аның конкрет фактларын күрдем. Безнең әдәбият узганы, бүгенгесе белән мондый нәрсәләргә риза түгел. Һәм хәзер башка халыкларның, башка әдәбиятларның язучылары зур дөньяга чыккан вакытта, шул ук кыргыз әдәбиятыннан Ч. Айтматовлар француз, испан телләрендә басылып килгән вакытта, бу әдәбиятлар инде бөтен дөнья әдәбиятына кирәклек кешеләрен биргән вакытта безгә дә шушы югарылыктан төшмәскә кирәк, игътибарны шуңа юнәлтергә кирәк. Шуңа күрә мин бүген сайлана торган идарәгә шуны аңлый торган, шуңа борчыла торган кешеләр керсен иде дим, шуны телим.

Иң кыены — үзең иҗат итү, үзең тудыру. Мин җәмәгать эшен, ничектер, иҗаттан аерып карый һәм күз алдына китерә алмыйм. Бүгенге тормышның бөтен катлаулылыгына, аның эченә керү — язучы өчен иң авыры, иң кыены шул. Блокның язмаларында шундый сүзләр бар: «Шагыйрь, уйларында, хисләрендә тауның иң биек ноктасына менеп, дөньяга шуннан карарга тиеш. Шуңа ирешә икән, ул инде бу дөнья минеке дип әйтә ала. Ул вакытта аның бөтен хисләре уйный башлый. Һәм ул бернәрсәдән дә курыкмыйм,— ди». Блок шуңа лаек әйберсен—«Унике» поэмасын язган. Аннан соң бит инде 50—60 ел узды, бөтенләй икенче кешеләр килде, икенче дәвер килде, бөтен катлаулылыгы белән килде. Һәм яңа дөньяның эченә керү, аны бөтен катлаулылыгында сурәтләү тагын да кыенрак эш. Блок әйткән югарылыкка күтәрелергә кирәк һәм шагыйрь әле тагын да күбрәк әйберләрне үзенә сеңдерергә тиештер.

Күп еллар буена физиклармы, лириклармы кирәк, дип бәхәсләштеләр. Халык әйтте: мондый проблема юк, безгә чын поэзия кирәк, диде. Һәм хисме, фикерме, дип бәхәсләштеләр. Халык әйтте: хис тә кирәк, фикер дә кирәк, диде. Һәм хәзер безнең тормышка фәнни-техник прогресс, фәнни-техник революция килеп керде, тормышны бик катлауландырды. Шигырьнең урыны — барыбер кеше йөрәгендә. Әгәр шул хисләргә керә алмый икән, җыя алмый икән, барыбер шагыйрь юк, сәнгать кешесе юк, әдип юк. Бөтенесе дә, бөтен яңалыклары да, барысы да — заман сулышында бергә. Һәм шагыйрь аны бер сулыш итеп кабул итә, бер процесс, бер рух, заманның бер рухы итеп кабул итәргә тиеш, шуңа ирешергә тиеш. Иң кыены менә шушы.

КамАЗда йөргәндә мине интернациональ клубка чакырдылар. Анда 270 яшь кеше йөри — һәр милләтнең кызлары һәм егетләре. Яшьләрнең торагын күрсәтеп, мине бүлмә саен алып йөрделәр. Һәр бүлмәгә керәм, маляр кызлар стенага үз куллары белән ясаган Есенин портретын элгәннәр. Кайвакытта уйлыйсың: бу инде КамАЗ булгач, Тольятти булгач, монда бик кычкырып йөри торган, зур тавышлы шагыйрьләр беренче чиратта килеп керергә тиештер, дисең. Юк шул. Есениннар килеп керә, Такташлар килеп керә, батырлыклары белән Мусалар килеп керә, стеналарда аларның портретлары.


Заман үзгәргән, КамАЗ төзергә бөтенләй икенче чор кешеләре килгән. Ә хис кирәк, җылы кирәк, кеше хисе кирәк. Уйлана башласаң, менә шушындый бик нечкә, бик кызык яклары бар сәнгатьнең.

КамАЗда йөри-йөри мин бер поэма да яздым. Ул «Литературная Россия»да басылып чыкты. Зур әйбер түгел, шул әсәрне язу өчен өч-дүрт ел буе КамАЗга йөрергә туры килде. Һәм шушы 3—4 йөз юл әйбергә материал җыю өчен, миңа татар халкының тарихы да, шушы Кама, Идел елгалары да, хәтта Мәләкәс, Шилнә елгаларының язмышы да кирәк булды. Алар турында да уйландым мин, һәм Болгар да килеп керде аңа. Һәм киләчәге, һәм үткәне. Шушы буыннарның аталары, егерменче еллар, утызынчы еллар, Ватан сугышы, бүгенге эшчеләр. КамАЗ — ул үткән буыннарга бүгенге буыннарның җавабы. Мин аны шулай аңладым.

## Нәби Дәүли

# РУХИ КҮПЕР

Кибет киштәләрендә татарчадан рус теленә тәрҗемә ителгән китаплар көннән-көн күбрәк күренә башлады. Соңгы биш-алты ел вакыт эчендә генә дә аларның саны 130 дан арткан. Хәзер татар шагыйрьләре һәм прозаикларының китапларын бик күп милләтләрнең укучылары укый ала. Бу, әлбәттә, куанычлы хәл. Әйтик, моннан 10—15 ел элек кенә бу турыда



*Мирсәй Әмир белән Гариф Гобәй.*

тик хыялланырга гына мөмкин иде. Шулай да моны табигый бер күренеш дип санарга кирәк. Чөнки без моның шулай буласын алдан ук белә, ышана идек. Илебездәге тугандаш халыклар арасында үзара бәйләнешләр нык көчәйгән, Г. Тукай әйтмешли, «тел вә лөгать алмашып» яшәгән чорда әдәби әсәрләрнең бер телдән икенче телгә, бигрәк тә рус теленә тәрҗемә ителүе көтелмәгән эш түгел иде. Без моны заманның реаль күренеше итеп саныйбыз. Без моны ленинизмның, Коммунистлар партиясенең милли политикасының тантанасы һәм казанышы дип карыйбыз.

Яхшы әсәр, ул нинди генә телдә чыкса да, бик тиз рус теленә тәрҗемә ителеп, миллионлаган укучылар кулына килеп керә һәм бөтен халык хәзинәсенә әйләнә.

Әмма тәрҗемә ителгән китапларның сыйфаты турында уйлана башласаң, күңелгә борчу төшә. Дөресрәге, тәрҗемәләрнең сыйфаты да һәм күп очракта тәрҗемә өчен сайланган китапларның үзләре дә укучыларда канәгатьсезлек хисе уята.

Билгеле, бу мәсьәлә аерым сөйләшүгә, ныклап тикшерүгә мохтаҗ. Һәрхәлдә, киләчәктә безнең тәнкыйтьчеләр дә, тел галимнәребез дә бу хакта үз сүзләрен әйтерләр дип ышанасы килә. Мин бу урында тәрҗеманең телен, стилен, гомумән, формасын, шулай ук оригиналдагы фикерләрнең дөрес бирелүен күз алдында тотам. Тәрҗемәдә авторның үзенчәлеген саклау мәсьәләсе дә, билгеле, игътибардан төшеп калмаска тиеш. Минемчә, тәрҗемә эшендә иң мөһиме әнә шул.

Бу мәкаләдә мин рус теленә тәрҗемә итү өчен әсәр сайлап алуның кайбер принципларына тукталып китәргә уйлыйм. Нәрсәдән гыйбарәт соң ул?

Әдәби әсәрне бер телдән икенче телгә, бигрәк тә рус теленә тәрҗемә итү — ул дәүләт күләмендәге җаваплы эш. Рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләр төрле халыкларны үзара якынлаштыра торган рухи күпер ролен үти. Шул күпер аша илебез халыклары бер-берсенең хәлләрен белешәләр, бер-берләренең культурасы, тарихы, традицияләре белән танышалар.

Рус теле кебек үк, безнең үз телебез дә үсә, байый бара. Рус телендә чыккан китаплар аша без бөтен дөнья культурасын, сәнгатен, фәнен, техникасын үзләштерү дәрәҗәсенә күтәреләбез. Моны без үз тәҗрибәбездән дә ачык күрәбез. Башка милләтләрнең рус теленә тәрҗемә ителеп чыккан китаплары барлык совет халыкларының уртак байлыгына, уртак хәзинәсенә әйләнә. Шулай ук рус теле үзе дә безнең яхшы әсәрләребезне, тирән күңел җылылыгы белән, үз культурасының михрабына куя бара. Димәк, рус теле аша азчылык милләт авторларының да китаплары бөтен дөнья культурасының бер өлешенә барып тоташа. Күрәсез, әдәби тәрҗемә әнә нинди җаваплы эш икән.

Югарыда әйткәнемчә, татар язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итү өлкәсендә безнең уңышларыбыз шактый. Бу кадәресе барыбызга да билгеле. Шулай да тагын бер сорау куясы килә: ә нинди әсәрләр тәрҗемә ителергә тиеш соң? Сүз дә юк, халык тарафыннан яратылып укыла торган, халык игътибарын һәм ихтирамын казанган иң яхшы китаплар гына тәрҗемә итүгә лаек. Тәрҗемә өчен әсәр сайлаганда, бу — төп принцип булырга тиеш. Шулай эшләгәндә генә хата адымнар булмас һәм төрле юк-бар сүзләргә урын калмас, дип уйлыйм.

Әлегә кадәр тәрҗемә өлкәсендә башбаштаклык хөкем сөрде дип үк әйтеп булмаса да, әмма монда тиешле тәртипнең булганы юк дип курыкмый әйтергә мөмкин. Монысын без бик ачык беләбез. Кызганычка каршы, шул хәл белән риза булып яши бирәбез. Шушы гамьсезлек аркасында безнең китап киштәләренә кулга алмаслык начар китаплар менеп утыра. Моңа күпме акча тотыла, күпме кәгазь исраф ителә, нәшрият хезмәткәрләренең күпме вакыты әрәм була! Әмма моннан да начаррагы — укучыларның ышанычы белән шаяру түгелме соң бу? Әйе, безнең укучыларыбыз бик күп, алар чиксез зур океан сыман. Әмма шуны истән чыгармаска кирәк, океан күпме генә зур булмасын, корабтан ташланган кечкенә генә чүп-чарны да дулкыннар барыбер ярга китереп ыргыталар. Начар китапны да, хәтта бик яхшы тәрҗемә ителсә дә, шундый ук язмыш көтә. Көн тәртибенә кемне, ягъни кайсы авторны тәрҗемә итү мәсьәләсе түгел, бәлки нинди әсәрне тәрҗемә итәргә, дигән мәсьәлә куелырга тиеш. Без күп очракта менә шул принциптан читкә тайпылабыз. Дөресен генә әйткәндә, халкыбыз күңелендә якты истәлек калдырган күп кенә әдипләребезнең, шагыйрьләребезнең әсәрләре әле һаман күп милләтле укучыларга билгесез булып кала. Туган ил өчен сугышта башын салган солдат шагыйрь Ф. Кәрим иң беренче булып тәрҗемә ителергә тиеш иде ләбаса. Аның иҗаты сокланырлык. Муса Җәлил кебек үк, ул татар совет поэзиясенең горурлыгы.

Саный китсәң, рус теленә тәрҗемә ителергә тиешле һәм моңа үз әсәрләре белән лаеклы, хаклы булган әдипләр бездә әле шактый. Соңгы елларда Һ. Такташ бөтенләй күздән төшеп калды дияргә була. Әнвәр Давыдовның да рус телендә тулы бер җыентыгын чыгарырга күптән вакыт инде. Бу исемлеккә әле байтак шагыйрьләрне, прозаикларны өстәргә мөмкин. Аның каравы, бездә ни өчендер әле үз ана телендә язарга өйрәнеп җитмәгән кайбер яшь шагыйрьләрне рус теленә тәрҗемә итәргә ашыгалар. Һәм кемнәрнеңдер «тырышлыгы» белән аларның китаплары дөнья күрә. Бәла шунда, ул «әсәрләр» китап киштәләрендә саргаеп бетә, ә беркөнне аларның арткы битләренә «бәясе төшерелгән» дип штамп басып куялар.

Хәзергә кадәр тәрҗемә итү эше шәхси «инициативалы», үз мәнфәгате өчен кайгырта белгән авторлар кулында булды диярлек. Бу яхшыга алып бармый, моңардан иң элек рус әдәбияты үзе оттыра, моңардан, укучы буларак, мин дә оттырам. Чөнки рус әдәбияты — ул хәзер минем дә әдәбиятым. Русчага тәрҗемә ителгән начар китаплар минем мәнфәгатьләремә дә кагыла. Мин дөнья каршында ул начар китап өчен йөз кызартырга теләмим. Ә халык моны телиме?

Сүз бөтен бер халыкның культурасы турында бара ич. Тәрҗемә ителгән китап әнә шул җаваплылыкны чагылдырамы? Бу мәсьәләдә җиңел караш гафу ителергә тиеш түгел. М. Җәлил, Р. Гамзатов, К. Кулиев, Д. Кугельтдинов һәм М. Кәрим әсәрләре, рус теле-

нә тәрҗемә ителеп, бөтен ил ихтирамын казандылар. Рус теле аша алар дөнья күләменә дә чыктылар. Ни өчен? Чөнки бу авторлар үз халыкларының сәнгатен, хезмәтен, җирен-суын, гореф-гадәтен, бөтен рухын ачып бирделәр. Ул әсәрләрнең көче шунда. Теге яки бу язучыны тәрҗемә итәргә керешкәндә әнә шундый югарылыктан торып уй йөртергә кирәк. Тәрҗемә өчен сайланган татар китапларына да шундый ук таләп куела. Авторның дәрәҗәсе, исеме, хезмәт урыны да моңа хокук бирми әле.

Сүз уңаеннан тәрҗемәчеләр турында да берничә сүз әйтеп китәсе килә. Әйе, тәрҗемә — авыр хезмәт. Шигырь тәрҗемә итүчеләр, бу эш оригиналь шигырь язудан мең кабат авыррак, диләр. Моның белән килешмичә мөмкин түгел. Үз эшләрен чын күңелдән, ихлас белән башкарган тәрҗемәчеләр рәхмәт сүзенә лаек. Аларны кадерләргә кирәк. Чыннан да, алар халык алдында зур эш башкаралар.

Әгәр заманында С. Маршак Шекспир сонетларын шулай чын ихлас белән, дөрес итеп тәрҗемә итмәгән булса, без әле дә бәлки дөнья күләмендә дан тоткан ул әсәрләрнең кыйммәтен белми яшәр идек. Тәрҗемәчеләр безгә Шиллерның, Беранженың, Гейненың, Байронның һәм тагы йөзләгән бөек шагыйрьләрнең, прозаикларның әсәрләрен алып килделәр. Әгәр Симонов, Тихонов, Гребнев, Липкин, Козловский, Моран-нар һәм башка бик күп тәрҗемәчеләр булмаса, без әле дә заманыбызның атаклы әдипләрен күрми калыр идек. Алар тәрҗемә иткән әсәрләр аша без күпме халыкның тарихын, тормышын, кайгысын-шатлыгын белдек. Тәрҗемәчеләр — халыкларның үзара якынлашуында безнең иң зур булышчыларыбыз.

Билгеле, яхшы тәрҗемәчеләр күп түгел. Ә менә тәрҗемә өлкәсендә «һөнәрчеләр» буа буарлык. Алар теләсә нинди телдән тәрҗемә итәргә алыналар. Сүзгә-сүз тәрҗемә генә булсын. Юк, мин сүзгә-сүз тәрҗемәгә каршы түгел, аңардан башка эшли дә алмас идек. Хәтта тәрҗемәче тәрҗемә телен беркадәр белгән хәлдә дә, сүзгә-сүз тәрҗемә кирәк булачак. Әмма тәрҗемәче сүзгә-сүз тәрҗемә аша авторның алымын, әсәрнең милли формасын бик яхшы чамаларга тиеш. Сүзгә-сүз тәрҗемә ул — морзе әлифбасындагы билгеләр генә әле. Аңа төшенәсе бар. Таралып яткан ул салкын юлларга җан бирәсе бар да яңадан рус телендә шигъри юлларга тезеп чыгасы бар. Билгеле, сәнгатьчә итеп, оста итеп.

Гадәттә, «һөнәрчеләр» моның белән санашып тормыйлар. Алар, һич югында, автор өчен үзләре яңа «шигырь» язалар. Ягъни автор өчен тирләп-пешеп «эшлиләр». Әсәрне тагын да яхшырту теләгеннән чыгып шигырьгә яңа «буяулар» кушалар, яңа «формалар» табалар, хәтта кайвакытта яңа «сюжетлар» да уйлап чыгаралар. Янәсе, рус телендә «башкача мөмкин түгел». Янәсе, шигырь А. Пушкин шигырьләре кебек яңгырап, ялтырап торсын. Мондый тәрҗемәләрне укып хәйран каласың. Болай карап торырга шигырь начар да түгел кебек, әмма син аны кайдадыр укыган кебек буласың. Хикмәт шунда, «һөнәрчеләр» үзләренең «тырышлыклары» белән авторны башка авторларга охшатып калдырганнар икән, ягъни алар, тәрҗемәчеләр, инде ишетелгән, инде укылган әсәрләрдән файдаланганнар. Авторның үзенчәлеге кайда да, формасы кайда?

Тәрҗемәче автор өчен «эшләргә» тиеш түгел. Ул, тәрҗемә сәнгатенә таянып, авторның ачышларын, образларын, фәлсәфәсен китереп җиткерергә, аның иҗади йөзен чагылдырырга тиеш.

**Равил Фәйзуллин,**
М. Җәлил премиясе лауреаты

# ЮГАРЫ ИДЕЯЛЕ ПОЭЗИЯ ӨЧЕН

Съезд — бөтен буын язучылар өчен дә уртак зур вакыйга. Безнең буынга — әдәбиятның чагыштырмача яшьрәк буыны вәкилләренә — съездларда күп катнашырга туры килмәсә дә, бөтен союз һәм республикабыз масштабында үткән соңгы ике-өч съезд һәм аларда булган сөйләшүләр ачык хәтердә. Ул съездларда ил күләмендәге әдәби процесска һәм шулай ук милли әдәбиятлар үсешенә турыдан-туры бәйле байтак актуаль проблемалар күтәрелгән иде. Әйтик, үзебезнең республика съездларында яшьләр өчен махсус әдәби журнал яисә квартал саен чыга торган альманах булдыру, «Казан утлары» журналын РСФСР язучылар союзы органы итеп үзгәртү, безнең язучыларны чит илләргә чыга торган делегацияләр составына даимирәк кертү, Язучылар союзы идарәсенең штатларын арттыру, әдәби музей ачу, Язучылар йорты салу кебек практик мәсьәләләр күтәрелгән иде. Аларның кайберләре уңай хәл ителде, ә икенчеләре исә көн тәртибендә кала бирә.

Татар язучыларының бу съездында, әдәби хәрәкәт башында М. Горький, А. Фадеевлар торган чорларда ук әдәби мәйданга килеп, заманаың күп съездларын һәм тормышның зур вакыйгаларын үз башларыннан кичергән өлкән буын язучыларыбыз да утыра. Янәшә куеп, чагыштырып карарга һәм әдәбиятыбызның бүгенге торышын төплерәк һәм төгәлрәк анализлауга ярдәм итәрлек мәгълүмат алар хәтерендә һичшиксез күбрәктер. Кереш сүздә конкрет мәсьәләләргә тукталуның мәгънәсе шунда: бу съездда да һәм иҗат мәсьәләләренә, һәм оештыру эшчәнлегебезгә караган файдалы һәм кирәкле фикерләр шактый әйтелде. Ләкин аларның байтагы үткән съездларда күтәрелгән мәсьәләләргә бәйләп, аларның үстерелеше юнәлешендә яңгырамады. Алдагы съездларда чыгыш ясаячак ораторлар, бүген без ихлас күңелдән тикшергән мәсьәләләрне, ул мәсьәләләрнең үтәлү-үтәлмәвен «онытып» үтсәләр, мөгаен, барыбызның да беркадәр хәтере калыр иде. Җәмгыять эшчәнлегенең теләсә кайсы өлкәсендә, шул исәптән әдәбият өлкәсендә дә, теге яки бу мәсьәләне хәл итүдә ныклы эзлеклелек булырга тиеш. Бары тик шул чагында гына чын тәрәккъыят — прогресс булырга мөмкин.

Үткән съездда Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре иҗат һәм оештыру эшләре буенча махсус чыгыш әзерләгән иде. Бу юлы андый ихтыяҗ юк. Делегатларга «Татарстан язучылар союзының ике съезд арасындагы эшчәнлеге турында» брошюра таратылды. Ул брошюрада, башка күп кенә материаллар белән бергә, иҗат секцияләренең эше турында да шактый мәгълүмат теркәлгән. Шуңа күрә дә төп сүзем — үземә якын һәм аңлаешлы өлкә булган поэзия турында.

Борынгы һәм мәңге яшь шигърият турында, аерым бер жанр буларак, аның асыл сыйфатлары турында өр-яңа сүз әйтү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер. Ләкин шигъриятнең бүгенге җәмгыять тормышында тоткан роле хакында уйлану зарар итмәс. Шигърият барлык заманнарда хезмәтне һәм батырлыкны, сафлыкны һәм мәхәббәтне — табигатьтә һәм кешедә булган гүзәллекне данлап җырлаган. Рухы-табигате белән гөл кебек нечкә һәм нәфис шигърият, кирәк чакта,— халык язмышының хәлиткеч сәгатьләрендә, үткен кылыч булып та ялтырый алган. Шагыйрьләр заманында гаскәр башлыклары да, идарәчеләр дә булганнар, ач-ялангач, илсез-күзсез хәерче дәрвиш булып та йөргәннәр. Шагыйрьләрне еш кына эзәрлекләгәннәр, үтергәннәр — моны гасыр-

лар һәм еллар хәтерли — әмма шагыйрьләрнең җан кыючы булуларын тарих белми. Чөнки шигърият үлемне түгел, ә яшәүне җырлый, аның асылында бөек гуманистик хис — кешелеклелек ята. Шагыйрьләр, аларның шәхси язмышлары, тормыштагы урыннары нинди булуга карамастан, үзләре исән чакта ук яки үлгәннән соң халыкның рухи юлбашчылары булып танылганнар, халыкның намус һәм горурлык символына әверелгәннәр. Шушындый сүзләрдән соң бүгенге шагыйрьләребезгә якынрак килик.

Без үзебез кемнәр соң? Бүгенге тормышта тоткан урыныбыз һәм яңа җәмгыять төзелешендә кирткән өлешебез нинди? Әлбәттә, җәмгыятьнең үсеш законнарын һәм үзебез яшәгән эпоханы исәпкә алмыйча, социаль-техник прогрессны, сәнгатьнең үз эчендәге бүленешләрне күрмичә, тарихилык принцибы белән исәпләшмичә, артык зур хокукларга һәм миссияләргә дәгъва итү дөрес булмас иде. Ләкин кодрәтле вакыт та, тарихи-социаль үзгәрешләр дә шагыйрьне аның горур һәм бөек исеменнән мәхрүм итми, минемчә. Киресенчә, шагыйрьнең гражданлык активлыгы турындагы сүз хәзер тагын да җитдирәк төс алып бара.

Быел СССР Язучылар союзы идарәсенең поэзиягә багышланган махсус пленум җыярга ниятләнүе, үзәк әдәби журнал һәм газеталарның шагыйрьләр иҗаты турында әледән-әле дискуссияләр оештыруы шул хакта сөйли булса кирәк. Халыкка яңа Пушкиннар, Тукайлар, Есениннар, Җәлилләр, Твардовскийлар кирәк. Шагыйрьләр хәзер болай да күп бит, дип әйтүләре мөмкин. Язучылар союзында член булып торган профессиональ шагыйрьләр илебездә ике мең ярым чамасы, Мәскәүнең үзендә генә ярты меңнән артык шагыйрь исәпләнә. Татарстан язучылар союзында да «саф» шагыйрьләр иллегә якын. Ләкин бу саналган меңнәрнең, йөзләрнең барлык язганы чын поэзия дип аталырга лаекмы соң? Бу сорауга өзеп кенә җавап бирү читен. «Шагыйрь» дигән төшенчә үзе замандашларыбызның кайберләрендә, дөресен әйтик, төрле тойгылар уятуын һәм ул тойгыларда ихтирам хисләре белән бергә беркадәр кѳлемсерәү төсмерләре дә булуын онытмыйк. Нигә алай соң?


Укучыларыбызның бер өлешен мещанлыкта гаепләргә яки шагыйрьләр кавемен купшы респектабельлеккә чакырырга ашыкмыйк. Гади укучының да хәлен аңларга кирәк — шагыйрь саналган күп меңнәрнең тау-тау шигырьләре арасында яхшыны яманнан аеру җиңел эш түгел. Тигез хокуклы шагыйрьләрнең шундый зур армиясе булу үзе генә дә билгеле бер дәрәҗәдә шигъриятнең бәясе төшүгә, аның очсызлануына алып бара. Тигезләү тенденциясе поэтик сәнгатькә зарар китерми кала алмый. Меңләп исәпләнми шагыйрьләр. Зур яки урта кул шагыйрь дип әйтү үзе үк, минемчә, дөрес түгел. Шагыйрь урта кул була алмый. Кайбер тәнкыйтьчеләр әйткәнчә, әдәбиятка алар кѳтүләре белән дә килмиләр. Һәркем үз шигъри йолдызын табып, үз сукмагыннан ялгызы килә. «Әйдә, язсалар язсыннар, вакыт үзе талантлыларны гына сайлап калдырыр әле»,— дип, үз-үзеңне юатудан яки сукранудан да әллә ни мәгънә юк. Кайбер нәрсәләргә менә хәзер, бүген төшенергә мөмкин һәм, кирәк булганда, нигә бөтенесен дә тарих җилкәсенә калдырырга?

Тере материяне фәнни тикшеренүдә кеше акылы фантастик уңышларга ирешсә, әмма кешенең художество талантын танып-белү һәм ачыклауда без элеккечә үк көчсез әле. Бу мәсьәләдә бердәм һәм даими критерийларны алдан билгеләп кую бәлки мөмкин дә түгелдер. Ләкин талантның табигатен өйрәнү кирәк һәм зарури нәрсә икәнлеге көннән-көн ныграк сизелә. Безнең эстетикада бик йомшак өйрәнелгән бу проблема әдәбиятның, гомумән, сәнгать теориясе һәм практикасының иң актуаль мәсьәләләреннән берсе саналырга тиеш. Талант турында фикер йөрткәндә, гадәттә, ике төрле караш барлыгы ачыклана. Кайберәүләр фикеренчә, талант ул иң мөһиме түгел. Белемле һәр кеше, теләге булып тырышса, янәсе, әдип булып китә ала. Икенчеләр, киресенчә, әдәбият-сәнгать кешесе булу өчен югары белем дә, махсус әзерлек тә, системалы рәвештә эшләү дә, ихтыяр көче дә таләп ителми, талантлы затка һәрнәрсә үзеннән-үзе бирелә, дип уйлыйлар. Беренче «теория» тарафдарлары арасыннан коры рифмачылар, графоманнар төркеме барлыкка килә һәм алар, ару-талуны белмичә, әрсез рәвеш-

тә зур дәгъвалар куеп, нәшриятларга һәм иҗат союзларына тынгылык бирмиләр. Әйтергә кирәк, еш кына максатларына ирешәләр дә. Икенче «теория» исә беркадәр табигый сәләте, талант очкыны булган кешеләрне, бигрәк тә яшь иптәшләрне иҗат өчен бик тә кирәк булган уку һәм хезмәт дисциплинасы кебек нәрсәләргә җиңел һәм җавапсыз карауга, рухи оешмаганлыкка, богемачылыкка этәрә. Шулай итеп, талант проблемасының эстетика фәнендә тиешенчә эшләнмәгән булуы аркасында, әсәрнең сәнгатьчәлек дәрәҗәсен билгеләүдә һәм поэтик хәзинәне бәяләүдә тәҗрибәсез кешеләрне, аеруча яшь укучыларны кыен хәлгә куябыз. Дөресен әйтергә кирәк, кайчак теге яки бу кешенең иҗатын бәяләгәндә без үзебез дә чама хисен югалтыбрак җибәргәлибез. Әйтик, күп китап чыгарган берәр шигырьчене хәтта атаклы яки күренекле шагыйрь дип атаудан да тартынмыйбыз, яки талантлы шагыйрьнең дә, Союзга очраклы рәвештә алынган рифмачының да әсәрләрен, вөҗдан газабы кичермичә генә, бер үк күләм, бер үк тираж белән бастырып чыгаргалыйбыз.

Мәгълүм нәрсә, бериш талантлы кешеләрнең кайбер сәер һәм йомшак яклары да булгалый. Кайбер талантлы кешеләр, иҗатларында фидакарь хезмәт күрсәтсәләр дә, шәхси яшәешләрендә беркадәр инертрак, гел күзгә бәрелеп тормаучан булалар. Ә әдәби эшкуар үзенең актив «гражданлык» сыйфатлары белән һәр вакыт күзгә ташлана. Аның һәр эше алдан уйланган булыр, исәбендә ялгышмас, нәшер итү эшләрендә членлык хокукларыннан максималь файдаланыр. Ә күп санда китаплар чыгаргач, ул әдәби тәнкыйтькә гаеп ташларга тотыначак. Әлбәттә, аны вакытында язудан туктатмаган өчен түгел, ә иҗатын тиешле югарылыкта бәяләмәгән өчен гаепләячәк ул тәнкыйтьчеләрне. Күрәсең, кайчак без бик гади бер хакыйкатьне онытып җибәрәбез: хөрмәткә лаек биографиясе, җәмәгать эшләре һәм беркадәр әдәби грамотасы булган һәр яхшы кеше шагыйрь яки язучы булып китә алмый бит!.. Шулай итеп, укучыларыбызны примитивлыкта, шигъриятне аңламауда гаепләүдән элек, безгә үз иҗат «цехыбызда» байтак нәрсәләрне үзара ачыклыйсы бар әле. Нәрсәнең яхшы һәм нәрсәнең начар икәнлеген һәр даим ачыклап тору — бик мөһим эш. Әгәр чын поэзияне халтура әсәрләреннән һаман тиешенчә аралап бетерә алмыйбыз икән, аны коммунистик җәмгыять төзелешендә бөтен җегәрендә файдаланып бетермибез икән, бу — шигырьдә тигезләүчелекнең, «бер чыбыктан сөрү»нең ачы җимешләре булып саналырга тиеш. Бездә әдәби китаплар шактый күп чыгып килә. Тормыш катлаулырак һәм күпкырлырак була барган саен, әдәби китапларыбызның тематик диапазоны да киңәя тора. Әгәр шигырьләрне нәшер итүдә катнашучы иптәшләр, тема ягы белән нык кызыксынып та, әсәрнең әдәби сыйфатына игътибар биреп җиткермәсәләр? Кәсепче мондый хәлдән оста файдалана. Актуаль темага ул бик теләп тотына, аны рифма кысасына куып кертә һәм теманы әрәм итә. Бу бик начар нәтиҗәгә — гражданлык темасын ваклауга, кадерсезләтүгә китерә. Эстетика законнарын нык саклап, талантлы итеп язылган әсәрләр аша гына күңелдәге мөкатдәс идеяләрне күп санлы укучыларыбызга илтеп җиткереп, максатка ирешә алачагыбызны беребезгә дә онытмаска иде. «Талант — сирәк күренеш. Аның кадерен белергә кирәк»,— дигән Ленин. Ә моның өчен иң әүвәл талантны аера һәм билгели белергә, һәр даим яклый белергә кирәк. Бу урында партиянең XXIV съезды резолюциясендә әйтелгән сүзләрне тагын бер кат хәтеребезгә төшерү урынсыз булмас: «Безнең әдәбиятсәнгать тәнкыйте партия линиясен актив үткәрергә, таләпчәнлекне тактылык, художество кыйммәтләрен тудыручыларга сак мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән эш итәргә тиеш».

Шигърият һәм шагыйрьләр турында сөйләгәндә, тагын берничә мәсьәләгә тукталып үтми булмый. Тәнкыйть мәкаләләрендә, чыгышларда яки докладларда, гадәттә, әсәрләрнең үзләрен түгел, ә шагыйрь исемнәрен саныйлар. Әгәр шагыйрь поэмалар язмыйча, шигырьләр генә язса, аның теге яки бу шигыре, әйтик, кыска гына әйбәт шигырьләре, телгә дә алынмый. Шул ук вакытта берәр прозаик нинди дә булса отышлы, көндәлек темага повесть язса, әсәре бик үк уңышлы булмаган хәлдә



*Шәйхи Маннур һәм Нури Арсланов.*

дә, телгә кереп әйләнештә йөри башлый. Ә бит һәр шигырь юлы шагыйрьдән күпме эмоциональ киеренкелек сорый, җан байлыгын, зур рухи көч салуны таләп итә! Шагыйрьләребез матбугатта, бигрәк тә «Казан утлары» журналында җитди шигырь цикллары белән еш кына чыгып торалар. Аларның кайберләре, чыннан да, әдәби вакыйга булырлык. Ләкин соңгы елларда теге яки бу яңа поэма яки шигырьләр цикллы уңае белән дискуссия һәм бәхәсләр кабынганын хәтерләмим. Ә кайбер очракта, югыйсә, аерым бер чын шигырь турында да җитди фикер алышу комачауламас иде. Ихтимал, бераз арттырып җибәрү диярләр, шулай да әйтергә базам: минемчә, әдәбиятның үсү дәрәҗәсен шагыйрьләр билгели. Чөнки чын шагыйрь, гадәттә, башка жанрлар өлкәсендә дә уңышлы эшләп, әдәбиятка зур игелек күрсәтүчән була. Моңа мисаллар күп. Шагыйрьдә зур потенциаль мөмкинлекләр яшеренгән. Шигърият — яшьлек һәм, димәк, кодрәт, көч символы да.

Ләкин, шуңа карамастан, безнең чорда, алда әйтелгән сәбәпләр аркасындамы, (ихтимал, бүтән сәбәпләр дә бардыр) шагыйрьнең абруе, гомумән алганда, беркадәр төште дип уйлыйм мин. «Шагыйрь» дигән сүзнең мәгънәсе элекке классик югарылыгында тормый шикелле. Монда гаепнең бер өлешен шагыйрьләр үзләренә алырга тиеш. Без хәзер халык белән бик еш очрашабыз һәм һәр очракта да иң яхшы тәэсир генә калдырабыз, дип әйтмәс идем. Шагыйрь исемен йөрткән индивидиум кайчак укучы яки тыңлаучы күз алдында кәтелгән яки хыялда йөртелгән шагыйрь образыннан калыша. Һәрхәлдә, безгә, кемнең кем булуына карамастан, укучының әдәбиятка һәм язучыга булган олы ихтирам хисен кадерләп сакларга кирәк. Һәм бу урында үзебезнең тагын бер йомшак ягыбызны икърар итеп китәргә тиешбез. Булырдай дигән талантлы шагыйрьләребез дә еш кына үз эшләрендә тиешенчә оперативлык күрсәтеп җиткермиләр, бүгенге тормыш симфониясен, пульс тибешен тоеп, әсәрләрендә чагылдыруда кирәк дәрәҗәдә өлгер түгелләр. Мисал өчен, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, шулай ук Казан шәһәре кебек индустрия үзәкләрендә хәзер яңа тип яшь эшче формалаша. Аларның хезмәтләре, хыял һәм омты-

лышлары бүгенге поэзиябездә лаеклы чагылышын табып җиткерми әле.

Бүгенге татар поэзиясен тулаем алып караганда, мин аны интенсив үсештә дип әйтер идем. Аның бүген зур таләпләрдән торып сөйләшерлек бай шигырь хәзинәсе бар. Шигъриятебез җәүһәрләрен тиешле биеклектә һәм актылыкта күрсәтә белгәндә, алар теләсә кайсы милләт укучылары алдында да йөз кызартырлык түгел. Бүгенге шигъриятебез төрле талантларга, төрле төсләргә, төрле авазларга бай. Менә бүгенге татар шигъриятендә актив һәм фидакарь эшләүче кайбер исемнәр: С. Хәким, Х. Туфан, Н. Арсланов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, М. Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, С. Сөләйманова, Р. Харисов, Р. Мингалимов, Зөлфәт, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, З. Насыйбуллин, К. Сибгатуллин һ. б. Эш — булган рухи поэтик байлыкны, күп милләтле социалистик культураның бер өлеше булырлык итеп, союз һәм дөнья күләменә чыгара белүдә, күрсәтә белүдә. Бу яктан безнең эшләр артык мактанырлык түгел. Рус һәм башка телләрдә хәзинәдә булганның иң яхшылары гына чыга дип булмый. Татарстан язучылар союзының яңа идарәсенә бу юнәлештә күп эшләр башкарырга кирәк булачак.

Сүземне шагыйрьләрнең тормышта тоткан урыны турындагы фикердән башлаган идем. Ялгышмас өчен, тарихка, халыкка, аның бәя бирү принцибына мөрәҗәгать итәсең. Ә халык ялгышмый, шәхесләргә һәм аларның кылган хезмәтләренә дөрес бәя бирә. Кирәген җыр итеп йөртә, һәйкәл сала, кирәкмәсен — оныта. Чит җирләрдә, чит шәһәрләрдә йөргәндә, урамнарын урап әйләнгәндә, көтмәгәндә бөек шагыйрьләрнең һәйкәлләре янына килеп чыгасың. Ирексездән алар язмышы турында уйланасың. Бездә дә бар андый һәйкәлләр, ул — Тукай, Җәлил һәйкәлләре. Ул һәйкәлләр янына килеп, әлеге шагыйрьләр һәм ил язмышы турында бераз гына булса да уйланып тору һәркем өчен дә файдалы һәм гыйбрәтле булыр.

## Фарваз Миңнуллин

# ТӘНКЫЙТЬНЕҢ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

Сүзне үзебездәге иҗат атмосферасы өчен сөенүдән башлыйсы килә. Бездә яшь талантларның ачылып-күтәрелеп китүе һәм төрле стильдәге язучыларның нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге өчен бик әйбәт атмосфера, ифрат уңай шартлар бар. Без үзебез моңа инде ияләнгәнбез, аны табигый һәм гадәти бер хәл дип саныйбыз. Башка республика һәм өлкәләрдән килгән кунаклар бездәге иҗат атмосферасына сокланып бетә алмыйлар.

Әйбәт әдәби атмосфера татар совет әдәбиятының дөрес юлдан, таза җирлектә үсүе өчен уңай шартлар тудырды. Нәтиҗәләре күз алдында. Бүген без, һич икеләнмичә, татар әдәбиятында халтурага җирлек, зәмин бетте дип әйтә алабыз. Ихтимал, әдәби эшләнеше ягыннан йомшак әсәрләр киләчәктә дә чыккалар. Әмма ачыктан-ачык халтурага урын булмас!

Күпмедер еллар элек безнең яшьләр тормышның күләгәле якларын сурәтләү, сугыш һәм сугыштан соңгы авыл тормышыннан кимчелекләр эзләү белән мавыгып алдылар. Әдәбиятыбыз бу «сырхаудан» да терелеп җитте. Бүгенге әсәрләребездә берьяклы мавыгулар, идея чатаклыклары очрамый диярлек. Бусы — аеруча куанычлы хәл.

Ике съезд арасындагы чор эчендә

татар әдәбияты бүгенге тормышка, заман темасына йөз белән борылды. Бүгенге тормышның бик мөһим һәм актуаль мәсьәләләренә багышланган әсәрләр саны нык артты. Заман темасын сәнгатьчә хәл итү җәһәтеннән дә әдәбиятыбыз шактый югары дәрәҗәгә ирешеп килә. Татарстан язучыларының заман темасына караган әсәрләре ил күләмендә матур яңгыраш тапты. Мин, беренче чиратта, Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасы, Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы, Диас Вәлиевнең «Дәвам» пьесасы кебек әсәрләрне күздә тотам.

Бүгенге совет әдәбияты барлык милләт язучыларының уртак тырышлыгы белән үстерелә. Һәр әдәбият уртак хәзинәгә үзеннән билгеле бер өлеш кертә. Берәүләрдә — бер як, икенчеләрдә икенче як көчле. Бездә эшче темасы көчәеп килә. Бик ихтимал, без совет әдәбияты тарихына шушы темага караган әсәрләр белән кереп калырбыз. Мин ышанам: әгәр киләчәктә дә еллар буе тудыра килгән иҗат атмосферасын саклый алсак, безне бу өлкәдә зур казанышлар көтә!

Билгеле, татар әдәбиятындагы әйбәт атмосфера үзеннән-үзе, җиңел генә тумады. Иң элек партия өлкә комитетының зур ролен билгеләп үтәсе килә. Партиянең Татарстан өлкә комитеты язучыларга идея-эстетик тәрбия бирү, аларның карашларын киңәйтү кебек мәсьәләләргә даими төстә җитди игътибар биреп килде, безнең алга баруыбызны, әдәбиятның үсешен тоткарлаган күренешләрне тәнкыйтьли барды. Шундый конкрет һәм эшлекле ярдәм, даими кайгыртучанлык республикада әйбәт әдәби атмосфера булдырырга ярдәм итте, язучыларны иҗат эшенә рухландырды.

Бездәге иҗат атмосферасын яхшыртуда өлкән буын әдипләребезнең хезмәте зур. Әдәбият язмышы өчен янып-көеп яшәгән, тынгысыз җанлы, мәңге яшь йөрәкле аксакалларыбызга рәхмәт моның өчен! Без әле бүген дә идарәнең элекке председательләре Мирсәй ага Әмирнең, мәрхүм Ибраһим ага Газиның бу өлкәдәге эшчәнлекләрен сагынып искә алабыз...

Әдәби атмосфераны яхшыртуда тәнкыйтьнең дә роле шактый зур булды. Үзәк Комитетның «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарыннан соң тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган уннарча мәкалә басылды. Ул мәкаләләрдә бүгенге татар тәнкыйтенә тәпле һәм тулы бәя бирелде. Ниһаять, кичә генә Рафаэль Мостафинның бездәге тәнкыйтьнең көчле һәм йомшак якларын тикшерүгә багышланган тәпле докладын тыңладык. Шуңа күрә тәнкыйтьнең уңышлары турында озаклап сөйләп торуның әллә ни кирәге булмас. Игътибарны тәнкыйть алдында торган бурычларга, аның йомшак якларына юнәлтәсе килә.

Сүз дә юк, безнең тәнкыйтьчеләр нигездә әйбәт сыйфатлы продукция бирәләр. Бездә әдәбиятны аңлый һәм ярата торган, сәнгать әсәрләрен нечкә сиземенли торган тәнкыйтьчеләр бар. Ләкин тәнкыйть цехыннан чыккан продукция искерәк кораллар, искерәк алымнар белән эшләнә, кыйммәткә төшереп эшләнә. Әдәби әсәрләр хакында фикер йөрткәндә, без тарих, философия, лингвистика, социология кебек фәннәр ирешкән казанышларга таяна, шулардан файдалана белмибез. Файдалана белсәк, бу — тәнкыйть сүзенең фәннилек дәрәҗәсен күтәрер, аның абруен һәм авторитетын тагын да арттыра төшәр иде.

Татар әдәбияты заман темасына, бүгенге тормышка йөз белән борылды, дибез. Йөз белән заман темасына борылган әдәбият хакында тәпле фикер йөртү өчен, бүгенге тормышка йөз белән борылган тәнкыйть кирәк. Без исә, бер мәртәбә дә КамАЗда булмаган килеш, әлеге зур төзелешкә багышланган әсәрләрне сүтәбез, буровой вышкасын барып күрмәгән килеш, нефтьчеләргә багышланган әсәрләр хакында фикер йөртәбез, бүгенге авылны белмәсәк тә, авыл турындагы әсәрләргә бәя бирәбез. Билгеле, якынча гына фикер йөртәбез, интуициягә таянып кына бәя бирәбез. Моның өчен тәнкыйтьчеләрнең үзләрен генә гаепләү дөрес булмас. Аларның барысы да диярлек кайда да булса эшли. Казна эшендә эшләгән кешенең йөрү өчен вакыты да, мөмкинлеге дә чикләнгән була. Димәк, бу хәлдән чыгу өчен ниндидер чаралар күрергә, оештыру эшләре алып барырга кирәк.

Илдар Юзеев та, Рафаэль Мостафин да дөрес әйттеләр, безнең чорда бер генә әдәбият та үз кысаларына гына бикләнеп үсми, үсә алмый. Шулай ук



*Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова.*

татар әдәбияты да. Тәнкыйть исә әле һаман да үз әдәбиятыбыз кысаларыннан читкә чыга алмый, татар язучыларының әсәрләрен башка милләт язучыларының әсәрләре белән чагыштырып өйрәнми. Башка республикаларда төрле әдәбиятларның үзара бәйләнешен һәм бер-берләренә йогынтысын өйрәнүгә багышланган калын-калын хезмәтләр чыкты. Без бик артка калдык, бу эшкә тотынырга ниятләп кенә торабыз. СССР төзелүнең 50 еллыгы уңае белән, «Казан утлары» журналында татар әдәбиятының кумык, чуваш, казакъ, үзбәк әдәбиятлары белән бәйләнеше хакында зур-зур мәкаләләр басылды. Ул мәкаләләрнең берсе генә дә безнең галимнәрнеке түгел.

Тәнкыйть матбугатка чыккан барлык китапларны рецензияләп барырга тиеш, диләр. Тәнкыйть аерым исемнәр белән генә чикләнеп калмаска, барлык язучылар иҗатын иңләргә тиеш, диләр. Мондый тенденция съездда ясалган аерым докладларда һәм чыгышларда да сизелде. Бу фикерләрдә дә күпмедер дөреслек бар. Чыннан да, җитди игътибарга лаек китапларның байтагы бөтенләй бәяләнми кала. Күренекле язучыларыбызның том-том «Сайланма әсәрләре» чыкты. Аларның берсе дә рәтле-башлы рецензия күрмәде. Әдәбият дәреслекләре, тәрҗемә әсәрләре тәнкыйть игътибарыннан читтә кала килә...

Сүз дә юк, дөньяга чыккан һәр яңа китап тегe яки бу формада искә алынырга һәм халыкка җиткерелергә тиеш. Әмма шулай да һәр китапка мәҗбүри тәстә рецензия язылырга тиеш, дигән фикер белән килешеп җитмәс идем. Бездә даими төстә әдәби ел йомгаклары уздырылып килә. Шул чагында барлык яңа әсәрләргә диярлек тулы һәм төпле бәя бирелә. Аерым китаплар өчен ел йомгакларында бирелгән бәя дә бик җиткән. Аннан соң, тегe яки бу язучының китабы нинди дә булса фикер уятырлык түгел икән, монда тәнкыйтьнең ни гаебе бар?! Тәнкыйтьче язучының хезмәтчесе дә, китап пропагандалаучы да түгел. Китап пропагандалау — библиография эше. Димәк, аларның эшен яхшырту турында күбрәк уйларга кирәк.

Безнең дистәләрчә китаплар чыгарып та, рәтле-башлы тәнкыйть фикере ишетмичә үлеп киткән язучыларыбыз бар. Бу — нормаль хәл түгел. Аннан соң безнең барлык язучыларыбыз да иҗат эшенә иң изге ниятләр белән тотыналар, халык өчен, партия өчен эшлиләр. Бу кадәресе дә — бәхәссез хакыйкать. Әмма ни генә булмасын, тәнкыйть барлык язучылар иҗатын иңләргә, барлык язучыларга бердәй игътибар бирергә тиеш, дигән таләп белән дә килешеп бетеп булмый. Бу таләп тәнкыйтьне урта кул әдәбиятка ориентация тотарга юнәлтә. Хәзер безнең өчен иң куркыныч нәрсә — урта кул әдәбият.

Язучыларыбызның саны арткан саен, урта кул әсәрләр күбәя бара. Нидән бу? Хикмәт нәрсәдә? Ашыгу бәласеме, әллә материалны белмәүдән киләме? Я булмаса, зур, яңа темаларны үзләштерергә тотынганда шунсыз мөмкин түгелме? Хәзергә без моның сәбәпләрен төгәл белмибез. Әмма зыянын беләбез. Урта кул әсәр актуаль теманың кадерен, ямен бетерә, дәрәҗәсен төшерә. Урта кул әсәр яхшы әсәргә бирелергә тиешле кәгазьне «ашый». Иң әшәкесе шул: урта кул әдәбият сиздерми генә укучының зәвыгын тупасландыра, укучының зәвыгын боза. Безнең тәнкыйтьнең киләчәктәге иң төп, иң зур эше — урта кул әдәбиятка каршы көрәш ачу.

Тәнкыйть алдында торган зур бурычларны уңышлы башкарып чыгу

өчен кадрлар кирәк. Ә алар җитми. Бердәнбер профессиональ тәнкыйтьчебез — Рафаэль Мостафин. Хәзергә тәнкыйтьчеләр өстенә төшкән йөкнең иң зур өлешен ул тартып бара. Яшьләр акрын үсә, аз килә. «Казан утлары» журналы каршында яшь рецензентлар түгәрәге оештырып карадык. Ике ел эчендә шул түгәрәккә йөрүчеләрнең күп кенә рецензияләре басылды. М. Вәлиев, Н. Гамбәров, Р. Абдуллина, М. Галиев кебек яшьләрнең рецензияләре җәмәгатьчелектә уңай тәэсир калдырды. Ләкин яшь рецензентлар түгәрәгенең эше без теләгәнчә җәелеп китә алмый тора. Димәк, нindидер чаралар күрергә кирәк.

Мәскәүдә махсус әдәбият институты бар, шул ук институт каршында ике еллык югары курслар эшли. Бәлки сәләтле яшьләрне табып, шунда җибәрергә кирәктер?.. Университетта һәм педагогия институтларында татар әдәбияты бүлекләре бар. Теләк булганда, яшь тәнкыйтьчеләр үстерү эшенә алар да күбрәк өлеш кертә алырлар иде...

Үзәк Комитетның «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарыннан соң, илебездәге күп кенә әдәби газеталар һәм журналлар каршында «литературный обозреватель» штаты булдырылды. Андый штат хәтта «Волга» журналы каршында да бар. Хәтта дим, чөнки РСФСР язучылар союзының «Волга» тибындагы журналлары дистәләрчә. Безнең съездда РСФСР язучылар союзы идарәсенең председателе һәм Үзәк Комитет вәкиле катнаша. Аларның монда булуыннан файдаланып, съезд исеменнән сорыйк әле: Татарстанда, һич югы, бер «литературный обозреватель» штаты булдырырга ярдәм итсеннәр иде.

*Съезд материалларында Э. ХӘКИМОВ һәм Н. СЕДОВ фотолары файдаланылды.*

# УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

**Хөрмәтле Габдрахман ага Әпсәләмов!**

**«Кояш тотылганда табылган хәзинә» исемле язмаларыгызны бик яратып укып чыктым.**

**Сез юкка гына: «Безнең татар укучылары мондый язуларны укырга бик үк күнекмәгән»,— дисез. Һич тә алай түгел. Татар укучылары да хәзер элекке укучылар түгел, аларның да уй-фикерләре елдан-ел байый, камилләшә бара. Бигрәк тә яшьләребезгә күпне белергә омтылу хас.**

**«Кояш тотылганда табылган хәзинә» сезнең тормышыгыз, иҗатыгыз турында укучылар өчен бер матур истәлек ул. Рәхмәт сезгә, Габдрахман ага. Сез безне, укучыларны, бер мизгелгә генә булса да, без яраткан Гөлсем Сөләйманова, Салих Сәйдәшев, Хөснул Вәлиуллин, Әхмәт Фәйзи кебек атаклы, Әбүзәр Терегулов шикелле яхшы кешеләр белән очраштырдыгыз. Бу кешеләр турында сезнең язмалардагы кыска гына җөмләләрне укуы да — үзе бер дөнья.**

**Шулар арасында Гөлдерн карт шикелле мәгънәсез, үз-үзен генә яратучы бәндәләр дә бар, билгеле. Нәкъ тормыштагыча!**

**Укучыларга фикерләү өчен дә урын калдырылган. Мәсәлән, сезнең җырчы Гөлсем Сөләйманова белән әңгәмәгезне яки шифаханәдә соңгы төндә күргән төшегезне тасвирлаган урыннарны укыганда, үзеңнән-үзең уйланырга мәҗбүр буласың. Күңел әллә кайларга алып китә, әллә кемнәргә барып тоташа.**

**Әсәрнең исеме дә җисеменә туры килә. Чыннан да, кояш та бит күңелләргә шом салып, сүнәм-сүнәм дип тора да, элеккедән дә яктырак булып, тагын балкып китә. Барлык укучыларның күңеленә хуш килгән «Ак чәчәкләр» романының дөньяга килү тарихы да шул күренешкә охшаш булган икән ләбаса. Без генә берни белмәгәнбез.**

**Мин үзем руслар арасында эшлим. Алар да сезнең әсәрләрне бик яратып укыйлар, сезне һәр вакыт зурлап, хөрмәт белән телгә алалар. Әле күптән түгел генә китапханәгә килгән ике рус иптәш арасында мондый сөйләшү булып алды:**

**— Нинди китап китердегез! Кызыклымы! — диде берсе.**

**— Бик матур әсәр. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы. Төн йокламый укып бетердем. Алыгыз, үкенмәссез,— диде икенчесе.**

**— Ә ниндирәк язучы соң ул!**

**— Ну, минә бездә, русларда, Лев Толстой, ә татарларда исә — Әпсәләмов. Ләкин аның әсәрләрен, иң беренчесеннән башлап, язылу тәртибендә укырга кирәк. Шулай иткәндә тагын да тирәнрәк аңлыйсың. Язучының иҗаты ничек үсә баруын хәтта үзең тоясың.**

**Сезнең бу язмалар без — китапханә хезмәткәрләре — өчен зур кулланма да. Сез дөрес әйтәсез, әйе, татар язучылары укучылар өчен үзләренең иҗат лабораторияләрен бик сирәк ачалар. Ә кирәк иде! Кайвакыт теге яки бу язучы иҗатына багышлап кичә үткәргәндә ул язучының тормышы турында эзләнеп аптырап бетәбез. Бит сөйләшү шуннан башлана — кем ул! Кайда! Ни эшли!**

**Күбрәк чыксын иде мондый истәлекләр.**

**Сүземне кыскарта төшеп тагын шуны әйтәм, Габдрахман ага: «Артист халкының тормышын каплап торган чаршауны бер күтәрсәң иде. Анда әлләниләр бардыр»,— дигән җөмләгез бик кызыктыргыч, күңелләрне кузгатып куйды. Бәлки ул чаршауны да ачып, безне тагын да куандырырсыз әле.**

**Сезгә йөзләгән укучылар исеменнән зур сәламәтлек һәм озын гомер теләп калам!**

Нәҗибә АРСЛАНОВА,
Актаныш районы, Дербышка
поселогы китапханәсе мөдире.

## КАЗАГЫСТАНДА СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Күп милләтле совет әдәбиятының гигант колачын һәм бердәмлек көчен, илебезнең иҗтимагый тормышында аның ролен берьюлы күз алдына бастырырлык вакыйгалар була. 20—27 июньдә Казагыстанда үткән «Совет әдәбияты көннәре» халыклар дуслыгы һәм әдәбиятлар туганлыгының әнә шундый олы бәйрәменә әверелде. Ул Совет Казагыстанының 50 еллыгына, чирәм җирләрне үзләштерүнең 20 еллыгына багышланган иде.

Казагыстан ССРның башкаласы Алма-Атага барлык союздаш республикалар әдипләренең делегацияләре килде. Язучылар бригадалары республиканың 12 өлкәсенә юнәлделәр. Алар завод-фабрика эшчеләре, игенчеләр, мамык, дөге үстерүчеләр, терлекчеләр белән очраштылар, совет әдәбиятының бүгенге казанышлары, үз иҗатлары турында сөйләделәр, әсәрләрен укыдылар. Хуҗалар исә кунакларны бишьеллыкның дүртенче елында ирешкән хезмәт уңышлары белән таныштырдылар. Культура сарайларында, клубларда, предприятиеләрдә, ачык мәйданнарда барысы 700 әнә шундый очрашу — әдәби кичәләр үтте. Әдәбият бәйрәме үзенең орбитасына бер миллион чамасы кешене алды.

Татарстан язучыларыннан әдәбият атналыгында СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури катнашты. Ул Кызыл Орда өлкәсендә дөге игүчеләр һәм терлекчеләр белән очрашулар үткәрүче язучылар бригадасын җитәкләде.

Бу олы бәйрәмне Алма-Атаның Ленин исемендәге Сараенда үткән зур әдәби кичә йомгаклады.

Язучылар шулай ук Җамбул Җабаевның авылына барып, атаклы акынның музей-йортын карадылар.

## КОМСОМОЛНЫҢ М. ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге республика премияләре комитеты карары буенча, әдәбият өлкәсендә 1972—74 еллар премиясе «Нигез ташлары» һәм «Үзебез сайлаган язмыш» дигән сәхнә әсәрләре өчен драматург *Туфан Миңнуллинга* бирелде.

Концерт-башкару өлкәсендәге осталыгы һәм уңышлы эшчәнлеге өчен М. Җәлил премиясе лауреаты дәрәҗәсенә шулай ук Татарстанның X еллыгы исемендәге культура сараеның *«Яшьлек» халык хореографик ансамбле* лаек булды. Комсомол премиясе лауреаты дипломнары һәм значоклары 12 июльдә М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында ВЛКСМның Татарстан өлкә һәм шәһәр комитетларының Бөтенсоюз Коммунистик Яшьләр Союзына Ленин исеме бирелүгә 50 ел тулуга багышланып уздырылган тантаналы пленумында ияләренә тапшырылды.

## КИТАП СӨЮЧЕЛӘРНЕҢ ИРЕКЛЕ ҖӘМГЫЯТЕ

Татарстанда дүрт китап магазины, унлап киоск, йөздән артык мәктәп кооперативы җәмәгать тәртибендә эшли. Ирекле китап таратучылар өч йөздән арта. Бу саннар китап пропагандасы эшендә җәмәгатьчелекнең роле һәм мөмкинлекләре никадәр зур булуын күрсәтә. Шуңа күрә республикабызда китап сөючеләрнең Ирекле җәмгыятен оештыру мәдәни тормышта күренекле вакыйга булып тора. Июнь аенда Казанда җәмгыятьнең оештыру конференциясе булып үтте. Конференция җәмгыятьнең идарәсен сайлады. Идарә председателе итеп Татарстан культура министры урынбасары М. Т. Низамиев сайланды.

## ДРАМАТУРГЛАР КИҢӘШӘ

Июнь аенда Уфада татар һәм башкорт драматургларының семинары булып үтте. Аның эшендә Татарстаннан драматурглар Риза Ишморат, Аяз Гыйләҗев, Хәй Вахит, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, театр белгече Азат Әхмәдуллин, республика дәүләт күчмә театры баш режиссеры Р. Тумашев, Минзәлә дәүләт драма театры баш режиссеры М. Мостафин катнашты. Татар драматургларының иҗаты хакында филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин, башкорт драматургиясенең бүгенге хәле турында филология фәннәре докторы Г. Рамазанов семинарда доклад белән чыктылар. Семинар барышында шагыйрь һәм драматург И. Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә» дигән яңа сәхнә әсәре, драматург Т. Миңнуллинның «Үзебез сай-

лаган язмыш» пьесасы, башкорт авторларыннан Р. Сафинның «Исәр», Н. Әсәнбаевның «Тормышның күзе», И. Абдуллинның «Айсылуның айлы төннәре», Ә. Атнабаевның «Ут» дигән пьесалары укып тикшерелде.

Семинар ике тугандаш халык әдипләренең иҗат эшендә ирешкән уңышлары белән ихлас күңелдән уртаклашу, әдәби осталыкны арттыру, чынбарлык материалын әдәби үзләштерү юнәлешендәге тәҗрибәне бергәләп өйрәнүнең, иҗади ярдәмләшүнең матур бер мисалы булды.

## МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАП

Әстерхан өлкәсендә март, апрель, май айларында «Шагыйрь, патриот-художник Муса Җәлил» дигән темага Әстерхан дәүләт филармониясе оештырган концерт-лекторийлар үтте. Ул герой шагыйребезнең үлеменә 30 ел тулуга багышланган иде. Концертларда катнашучылар шәһәр һәм район эшчеләре, балыкчылар, колхозчылар, студентлар һәм укучылар алдында йөздән артык чыгыш ясадылар.

Программада Җәлил сүзләренә язылган җырлар, аның ялкынлы шигырьләре, рус, татар, казакъ халык көйләре, патриотик җырлар, герой шагыйрьнең яраткан композиторларыннан Григ, Шопен, Чайковский әсәрләре яңгырады. Анда катнашу өчен шагыйрьнең Оренбургта яшәүче туганы Хәдичә Җәлилова килде. Муса Җәлил үзе дә 1932 елда Әстерханда булган һәм аның белән очрашкан, аны күргән кешеләр бу көннәрне әле дә хәтерләрендә саклыйлар.

Концерт-лекторийлар Әстерхан шәһәре һәм өлкәсендә яшәүче татарлар, казакълар һәм руслар арасында зур уңыш казанды.

## «МӘКТӘП ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНЕҢ ҖАНЛЫ СӘХИФӘЛӘРЕ»

Дистә еллар буе әсәрләре мәктәп дәреслекләрендә өйрәнелә торган күренекле өлкән буын шагыйрь һәм язучыларның Татарстан мәктәпләреннән, Идел буе автономияле республикаларыннан һәм күрше өлкәләрдән килгән укытучылар белән очрашу кичәләре хаклы рәвештә шундый исем алды. Ул очрашулар 17 июнь һәм 4 июль көннәрендә Казанның Г. Тукай исемендәге язучылар клубында узды. Кичәләрдә өлкән әдипләребездән Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Шәйхи Маннур, Гариф Гобәй, Мөхәммәт Садри, урта һәм яшь буын язучылары Х. Сарьян, Р. Мостафин, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, М. Хәбибуллин катнашты. Алар залдагыларга бүгенге әдәби хәрәкәт, иҗат мәсьәләләре хакында сөйләделәр, кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр. Очрашулар һәр ике як өчен дә кызыклы һәм файдалы булды.

## ӘДИПЛӘР УКУЧЫЛАР АЛДЫНДА

*
* *

Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең бер төркеме июльдә Зеленодольск районы авылларында булып кайтты. Драматург Риза Ишморат, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, прозаик Рәисә Ишморатова, үзешчән композитор Зиннур Гыйбадуллин, Татарстанның атказанган артисткасы Җәүәһирә Сәләхова, җырчы Генрих Шәймәрданов, Татарстан язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры Мөнип Шәймөхәммәтов колхоз һәм совхоз кырларында, болын, җәйләүләрдә игенчеләр, печәнчеләр, сыер савучылар белән очраштылар, аларга бүгенге әдәбиятыбыз, Татарстан язучыларының VIII съезды йомгаклары турында сөйләделәр, авыл эшчәннәренең хуҗалыкны үстерүдәге көндәлек хезмәтләрен күздән кичерделәр, яңа әсәрләрен укыдылар, җырлар башкардылар.

*
* *

Мари АССРның язучылар союзы чакыруы буенча, шагыйрь Гәрәй Рәхим июнь аенда Мари АССРның башкаласы Йошкар-Олага традицион чәчәк бәйрәменә барды. Яшел аланда һәм шәһәр паркында мари, чуваш һәм Мәскәүдән килгән рус шагыйрьләре белән бергә үзенең шигырьләрен укыды, әдәби иҗат мәсьәләләренә багышланган сөйләшүләрдә катнашты.

*
* *

Әдәби тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин 7 июльдә Казанның М. Горький исемендәге үзәк паркында Муса Җәлил турындагы «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» дигән китабы буенча уздырылган укучылар конференциясендә чыгыш ясады.

*
* *

Комсомолга Ленин исеме бирелүгә 50 ел тулу уңае белән Муса Җәлил исемендәге премия лауреатлары шагыйрь Илдар Юзеев һәм драматург Туфан Миңнуллин Казан шәһәренең укучы комсомоллары слетында катнаштылар. Яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов һәм яшь композитор Луиза Хәйретдинова Буа, Апас районнарында яшь игенчеләр, механизаторлар белән очраштылар, аларны үзләренең әсәрләре белән таныштырдылар.

*
* *

Өлкән язучыбыз Гомәр Бәширов 22 июньдә 15нче номерлы производство-техник училищесында «Намус» романы буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты.

## САБАН ТУЙЛАРЫНДА ЯЗУЧЫЛАР

Шагыйрьләрдән Гәрәй Рәхим, Мәхмүт Хөсәен, язучы Роберт Батуллин Мәскәүнең Измайловский паркында үткән сабан туенда катнашып, үз әсәрләре белән чыгыш ясадылар.

23 июнь көнне Әлмәт сабан туенда Гамил Афзал һәм Сажидә Сөләйманова үзләренең шигырьләрен укыдылар.

* * *

Июнь аенда язучыларыбыздан Гариф Ахунов һәм Геннадий Паушкин Васильево санаториесендә ял итүчеләр белән «Эшче — совет әдәбиятының төп герое» дигән темага кызыклы әңгәмәләр үткәрделәр.

## ҖӘЙГЕ ГАСТРОЛЬЛӘР

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры җәйге гастрольләрнең күпчелек өлешен Татарстан шәһәр һәм районнарында үткәрде. Бер бригада Фәнис Яруллинның «Әнә килә автомобиль» комедиясен (сәхнәгә куючы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Сәлимҗанов) Түбән Кама, Чаллы һәм нефть районнары тамашачыларына күрсәтте, икенче бригада «Галиябану» спектакле белән республикабызның көнбатыш районнарын әйләнде. Туфан Миннуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» комедиясен дә Татарстан һәм Башкортстанның күп район һәм авылларында карадылар.

Артистларның зур төркеме Башкортстанның Нефтекамск шәһәрендә кыска вакытлы гастрольдә булып кайтты. Гастроль репертуарында бүгенге чор татар драматургиясе әсәрләре — Шәриф Хөсәеновның «Әни килде», Роберт Батуллинның «Өчәү юлга чыктык», Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» һәм Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» повестьлары буенча сәхнәләштерелгән спектакльләр бар иде.

Гастрольләр барышында культура сарайларында һәм клубларда бер йөз кырыктан артык спектакль уйналды.

* * *

Татар дәүләт күчмә театрының ике бригадасы быел җәйге гастрольләргә яңа спектакльләр алып чыкты. Аларның берсен гарәп драматургы Сәхиб Җамалның «Хөрмәне бушлай бирмиләр» әсәре буенча сәхнәгә Г. Тукай премиясе лауреаты Рифкать Бикчәнтәев, икенчесен Аяз Гыйләҗевнең «Сары чәчәк ата көнбагыш» драмасы буенча Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Равил Тумашев куйган. Бригадалар бу яңа спектакльләр белән Арча, Саба, Кукмара, Балтач, Чистай, Алексеевск, Әлки районнарында булдылар.

## «ИДЕЛДӘ ОЧРАШУЛАР»

Июнь аенда Татар дәүләт филармониясе Мәскәү, Донецк шәһәрләренең кино һәм эстрада артистлары белән берлектә республикабыз шәһәр һәм районнары буйлап фестиваль концертлары үткәрде. «Иделдә очрашу» дигән бу фестивальдә РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Венера Шәрипова, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Авзалова, эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурсы дипломанты Зиннур Нурмөхәммәтов, җырчы Флера Сөләйманова, Татарстан җыр һәм бию ансамбленең биючеләр группасы, кино артистлары К. Столяров, Н. Максимова, А. Вертоградов, Н. Гаврилова, эстрада артистлары: УССРның атказанган артисткасы Т. Миансарова, МАССРның атказанган артисты Э. Радов һ. б. сәнгать осталары катнашты.

Бөгелмә һәм Әлмәттә, Алабуга һәм Мамадышта, Чистай һәм Буада, калган күп шәһәр һәм поселокларда бу концертларны 80 меңләп кеше карады.

## ТУЛАЛЫЛАР КАЗАНДА

Республикабыз башкаласы Казанның В. И. Качалов исемендәге зур театры бинасында август буена М. Горький исемендәге Тула дәүләт драма театрының җәйге гастроль спектакльләре барды. Туланың сәхнә осталары казанлыларга унлап әсәр, шул исәптән М. Горькийның «Варварлар» пьесасын, В. Константинов һәм Б. Рацерның «Тула сере» һәм «Үткәрүче балл» дигән икешәр пәрдәлек комедияләрен, Р. Ибраһимбековның «Арысланга охшап» дигән өч пәрдәлек мәхәббәт рапсодиясен, шулай ук инглиз драматургы Б. Шоуның «Цезарь һәм Клеопатра» пьесасын күрсәттеләр.

* * *

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле яңа концерт программасы белән июльдә Алабуга, Минзәлә, Актаныш районнарында чыгышлар ясады.

Татарстан дәүләт филармониясе артистлары республикада көнгә уртача 25 концерт бирделәр.

* * *

Татарстан Культура министрлыгы июнь аенда республикабызның яшь вокалистлары смотр-конкурсын оештырды. Жюри каршында (председателе Татарстан Культура министры урынбасары Ренат Харисов, членнары РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина, музыка училищесы директоры М. Б. Гумеров, җырчы Әлфия Заһидуллина) егермеләп районның үзешчән яшь җырчылары чыгыш ясады. Смотр нәтиҗә-

сендә иң сәләтле дип табылган жырчылар махсус музыка уку йортларына тәкъдим ителде.

## ТАТАР ЦИРКЫНА ДҮРТ ЕЛ

Автономияле республикалар арасында беренче булган татар циркы оештырылуга дүрт ел тулды. Бу вакыт эчендә ул үзенең маршрутларын Татарстаннан тыш Тула, Омск, Түбән Тагил, Кривой Рог, Курган, Ижевск кебек дистәләгән шәһәрләргә сузып өлгерде, профессиональ осталык һәм тәҗрибә туплады. Җәй айларында цирк коллективы Севастополь, Череповец, Мурманск шәһәрләрендә чыгышлар ясады.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Татарстан китап нәшриятында күренекле хәрби начальник, отставкадагы генерал-лейтенант Якуб Чанышевның «Үткән юллар хатирәсе» («Вспоминая былые походы») дигән китабы басылып чыкты. Автор анда илебез дошманнарына каршы көрәштә үтелгән гомер юлын хәтердән кичерә.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

КПССның Әлмәт шәһәр комитетында Әлмәт бүлеге язучылары Г. Афзал, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова, С. Кальметов, Ю. Әминов, Ш. Бикчурин, Э. Мөэминова шәһәрнең партия һәм совет органнары хезмәткәрләре белән очраштылар. Бүлекнең җаваплы секретаре Ә. Маликов язучыларның иҗат эшчәнлекләре хакында сөйләде. Партиянең Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Сания Хәкимова үзенең чыгышын КПССның XXIV съезды карарлары яктылыгында әдәбиятның бурычлары темасына багышлады. Хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты председателе Вәҗи Гыйрфанов язучыларны кызыксындырган күп төрле сорауларга җавап бирде.

Очрашуда партиянең Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Ринат Галиев, бүлек мөдирләре, партия комитеты инструкторлары катнашты. Бүлек җитәкчесе Әдип Маликов шәһәр комитеты китапханәсенә нефть ягында яшәүче язучы һәм шагыйрьләрнең соңгы елларда басылып чыккан китапларын бүләк итте.

*
* *

Июль аенда, мул иген уңышын җыю башланган көннәрдә, Әлмәт районы колхозларында һәм совхозларында татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Аны Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты һәм район культура бүлеге оештырды.

Очрашуларда шагыйрьләрдән Г. Афзал, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, К. Булатова һәм драматург С. Кальметов катнашты.

Язучылар колхоз-совхоз эшчәннәренең тормышлары, хуҗалыкта ирешкән уңышлары белән таныштылар, клубларда һәм культура сарайларында уздырылган әдәби кичәләрдә чыгыш ясадылар.

Алар хезмәт кешесенә, аның күркәм эшләренә багышланган шигырь-хикәяләрен, шулай ук юмор-сатира әсәрләрен укыдылар. Язучыларның чыгышлары һәркайда зур кызыксыну уятты. Урыннарда китап сәүдәсе оештырылды, автограф төшкән дүрт йөзләп китап — шигырь, хикәя җыентыклары әдәбият сөючеләр кулына күчте.



Съезд тәмам...

Н. СЕДОВ фотосы

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

«Казан утлары» журналы 1975 ел планы белән эшли башлады. Яңа елның беренче санында Мәхмүт Хәсәновның **«Ә җилләр исә дә исә»...** повесте, Нури Арсланов, Әхмәт Исхак һәм Сәҗидә Сөләйманова шигырьләре, совхоз тормышы, Казан эшчеләренә багышланган очерклар, бүгенге әдәбият турында тәнкыйть мәкаләләре һ. б. күп төрле материаллар урнаштырылачак.

«Казан утлары» журналына язылу әле дә дәвам итә. Әлегә кадәр язылырга өлгермәгән булсагыз, Сез журналга почта бүлекләренең теләсә кайсында языла аласыз.

Журналның индексы **73210.**

**Язылу бәясе бер елга 6 сум.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210